ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

2.2009





**Шәриф Камал**
**(1884—1942)**

**Казан утлары**

**Qazan utları**

2009

# 2

**(1036)**

*__ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:__*
***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***Редакциянең хезмәт коллективы***

*__НАШИРЕ:__*
***«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте***

татмедиа

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы**
**Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

*420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*Баш мөхәррир—292-38-60.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—541-38-77.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.*
*Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.*
*Исәп-хисап бүлеге—292-93-16. kazanutlari@yandex.ru*
**Факс**—*(843) 541-38-77.*
**E-mail:** *kazanutlari@telebit.ru.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Фәнис ЯРУЛЛИН. Кояш оясыннан нурлар җыям. *Шигырьләр.* ........ 5
Нур ӘХМӘДИЕВ. Мөнирстан. *Роман.* ........ 10
Рөстәм МИНГАЛИМ. Гөлләр анда гел чәчәктә... *Шигырьләр.* ........ 72
Лира ИБРАҺИМ-ВӘЛИДИ. Өстән карап. *Хикәя.* ........ 76
Госман САДӘ. Мин кабыздым гомер шәмнәрен... *Шигырьләр.* ........ 82
Фәнзаман БАТТАЛ. *Сатирик хикәяләр.* ........ 87
Эльвира ҺАДИЕВА. Тәрәзләрне ачтым. *Шигырьләр.* ........ 103

**ХӘТЕР**

Нурихан ФӘТТАХ. Беренче шигырь күк балачак... *Истәлекләр.* ........ 106
Әхмәт РӘШИТ. Һәркемнең... үз сукмагы. *Хатирәләр.* ........ 154

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Алла. *Фәлсәфи уйланулар.* ........ 122
Тәфкил ВАФИН. Мәкруһлар ........ 139
Фәнис ФӘТХИ. Без килмешәк түгел! *Р. Бигнов белән әңгәмә.* ........ 149

**Ә. ЕНИКИНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ ТУЛУНЫ КАРШЫЛАП**

Фактлар дәфтәреннән ........ 153

**ШӘРИФ КАМАЛНЫҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ**

Рифат СВЕРИГИН. Гүзәллеккә юл ярганда ........ 165

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ. “Күңелләрне уятыр” ........ 170

“Татар энциклопедиясе” битләреннән ........ 174

**ЮБИЛЕЙЛАР**

Флүн Мусинга 70 яшь ........ 176
Камил КӘРИМОВ. Татар эзләүче дустыбыз. *(Рәфыйк Шәрәфиевкә 70 яшь)*... 177

Безнең календарь ........ 179

**ЮМОР-САТИРА**

Госман ГОМӘР. Без нинди кавем? ........ 180

Берлекнең яңа әгъзалары ........ 182
“Казан утлары” архивыннан ........ 184
Укучы сүзе ........ 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 187

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": роман Н. АХМАДИЕВА "Мунирстан" (продолжение);
рассказы Л. ИБРАГИМА-ВАЛИДИ, Ф. БАТТАЛА; стихи Ф. ЯРУЛЛИНА,
Р. МИНГАЛИМА, Г. САДЭ, Э. ХАДИЕВОЙ.
"Память": Н. ФАТТАХ. "Детство—как первый стих" (продолжение);
А. РАШИТ. "У каждого своя судьба" (продолжение)—воспоминания.
"Публицистика": А. ТИМЕРГАЛИН. "Бог"; Т. ВАФИН. "Отпавшие" (продолжение);
Ф. ФАТХИ. "Мы не пришельцы!"
"К 100-летию А. Еники": "Из тетради фактов".
"К 125-летию Ш. Камала": статья Р. СВЕРИГИНА "Путь к Прекрасному..."
"Книжное обозрение": рецензия А. ЗАКИРЗЯНОВА на книгу А. АХМАДУЛЛИНА
"На перекрестке веков".
Страницы из "Татарской энциклопедии".
"Юмор и сатира".
Наши юбиляры.
Слово читателя.
Новые члены Союза писателей.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: "Лисичка"—картина Б. ГИЛЬВАНОВА;
поэт и художник Хамит ЛАТЫПОВ.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

"Prose and poetry": novel by N. AHMADIEV "Munirstan (continuation);
stories by L. IBRAHIM-VALIDI, F. BATTAL; poems by F. YARULLIN,
R. MINGALIM, G. SADE, E. HADIEVA.
"Memory": N. FATTAH. "Childhood as a first poem" (continuation);
A. RASHIT. "Everybody has his own destiny" (continuation) — memories.
"Publicism": A. TIMERGALIN. "God"; T. VAFIN. " Fallen down" (continuation);
F. FATHI. "We are not strangers!"
"For 100th anniversary of A. Eniki": "From notebook of facts."
"To 125th anniversary of Sh. Kamal": article by R. SVERIGIN "Path to beautiful..."
"Book review": review by A. ZAKIRZYANOV on book by A. AHMADULLIN "At
crossroads of centuries."
Pages from "Tatar Encyclopedia".
"Humor and satire."
Our jubilees.
Word of reader.
New members of Writers Union.
From photo archive of magazine.
Diary of the social-cultural life.
On our cover: "Fox", picture by B. Gilfanov;
poet and painter Hamit LATYPOV.

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 22.01.2009, график буенча 22.01.2009.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ В–70 Тираж 4788.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7. Индекс 73210. Бәясе ирекле.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2009 ел.



Фәнис
Яруллин

# КОЯШ ОЯСЫННАН НУРЛАР ҖЫЯМ

## Гомер китабымны укып ятам

Һәр яңа көн—гомер китабының
Укыларга тиеш бер бите.
Соңгы ноктасына кадәр укымыйча
Ябып куеп булмый ул битне.

Никадәрле генә тырышсаң да
Булмый аны ертып ташлап та.
Кай битләрен кисәк-кисәк итеп
Бик ертасы килә кайчакта.

Кайбер бите тамак төпләренә
Кайнар төер булып утыра.
Икенчесе каймак каптыра да
Кайнар төеренңне йоттыра.

Бу китапта берни кабатланмый,
Һәрбер бите тора ачыштан—
Нәрсә генә анда язылмасын,
Качып калып булмый язмыштан.

Гомер китабымны укып ятам,
Соңгы бите әле күренми.
Яңа битне ача башладыммы,
Куллар гына бераз дерелди.

## Өемташым

Өемташым, Өемташым,
Беренче менгән тавым.
Исемдә кыяга басып
Үземне сынаганым.

Исемдә иң каты ташка
Бер исем сырлаганым—
Ул исемне ташка язгач
Шатлыктан елаганым.

Фәнис ЯРУЛЛИН (1938)—*Татарстанның халык шагыйре, прозаик, драматург, публицист; күпсанлы китаплар (биш томлык "Сайланма әсәрләре" е дә дөнья күрде) авторы. Казанда яши.*

Мин офыклар буйлап киттем,
Ул исем калды тауда.
Гел җылылык биреп торды
Ул исем минем җанга.

Өемташым, Өемташым,
Кадерле һәрбер ташың.
Синнән өйрәндем һәрвакыт
Горур тотарга башым.

Туган якка кайткан саен
Карыймын Өемташка.
Ташлар кошка әверелеп
Очалар күк кояшка.

Өемташым, Өемташым,
Беренче менгән тавым.
Яралар телгән җаныма
Биеклек биргән тавым син,
Тереклек биргән тавым.

## Гүзәл Ыгым

Гүзәл Ыгым—горурлыгым,
Агасың да агасың.
Ишелә ярлар, өзелә юллар,
Син яңа юл ярасың.

Язын ярларга сыймыйча
Әйләнәсең диңгезгә.
Ярларның чик түгеллеген
Күрсәтәсең син безгә.

Гүзәл Ыгым—горурлыгым,
Борма-борма юлларың.
Үткәннәрдән киләчәккә
Ага синең суларың.

Гүзәл Ыгым, агасың син
Белмичә язны, көзне.
Кайсы диңгезләргә салдың
Безнең яшьлегебезне?

* * *

Тормышым көрәштән торды—
Яшим һаман көрәшеп.
Көрәшеп алган байлыкны
Кешеләргә өләшеп.

Артык булганлыктан түгел,
Байлык тормый котырып—
Бирәм кайбер нәрсәләрне
Йөрәгемнән умырып.

Йөрәгем канап калса да
Төзәлә яралары.

Күкрәгемә тула башлый
Көч, дәртнең яңалары.

Тагын дәртләнеп тотынам
Күңел тарткан эшемә.
Шатлык чаткылары чыга
Шул чагында төсемә.

Бәхет бит ул кешеләргә
Нәрсәдер эшли алу...
Шулай гына мөмкиндер ул
Мәңге биектә калу!

* * *

Ерактан бер тавыш килә
Күкләрне ярып-ярып;
Йә ул бик тә якыная,
Йә туктап кала, арып.

Бер карасаң ят кебек ул,
Бер карасаң—бик таныш.
Ниләр хәбәр итмәкче соң
Ерактан килгән тавыш?

Шатлык хәбәрчесеме ул,
Кайгы хәбәрчесеме?
Йә булмаса күкләрнең бер
Без белмәгән көчеме?

Бу тавышта сыкрап-сыкрап
Бала елавы да бар.
Ачлыктан үз тәпиен чәйнәп
Бүре улавы да бар.

Бәлки ул еракта калган
Балачак тавышыдыр.
Ә бәлки тол аналарның
Сыктавы, каргышыдыр?!

Ишетелә бу тавышта
Туплар шартлаганы да.
Сабыйларның ипи күргәч
Ничек шатланганы да.

Бу тавыш никтер куркыныч,
Бу тавыш никтер шомлы.
Кемдер кисәргә телиме
Җирне—күккә, күлне—җиргә
Тоташтыручы кылны?!

## Хәтерсезләр

Еллар яна. Барсы онытыла.
Кешеләрнең хәтере бик кыска.
Ярсып-ярсып аккан елгалар да
Туктап кала кайчак тормышта.

Урманнарны давыл егып ташлый,
Көтмәгәндә таулар ишелә.
Кеше әле каршы тора алмый
Табигатьнең бөек көченә.

Чөнки гамьсез. Уйлап карамыйбыз:
Бу афәтләр килә нилектән?
Уйлар идек, тәкәбберлек чире
Йөрәкләргә безнең береккән.

Башкалардан өстен булам диеп
Тәгәрибез һаман түбәнгә.
Халыкларның җилкәсенә басып
Үрмәлибез өскә—мөнбәргә.

Булмаса да сөйләр сүзләребез,
Тик тотмыйбыз телне бер минут:
Вәгъдә арты вәгъдә яудырабыз,
Күренер өчен бөек, зур булып.

Татлы сүзләр хакыйкатьне каплый,
Кемгә кирәк ачы дөреслек?!
Яшибез без газапланмый гына,
Татлы ялган белән килешеп.

Буталышып бетә чын һәм ялган,
Алхимиклар саны ишәя.
Ялган сүзләр тула аңыбызга,
Ялган алтын тула кесәгә.

Әкрен-әкрен хәтер төпләрендә
Барсы бергә бетә чорналып.
Әҗәл көтеп яткан карт шикелле
Хәлсезләнеп ята Чынбарлык...

Тын юлларын киңрәк итеп ачсаң,
Ул әлегә өскә чыгарлык!

* * *

Без үскәндә бар да матур иде,
Елгаларның суы саф иде.
Карыныбыз күпчак ач булса да
Күңелләрдә уйлар ак иде.

**Хыял белән дөнья гизеп йөрдек,**
**Кирәк түгел иде самолет.**
**Бар дөньяны урап чыга идек,**
**Хыялларга һич тә чикләр юк.**

**Кесәләрдә акча чылтырамады,**
**Ләкин барыбер ярлы булмадык.**
**Аякларны кар суында юып,**
**Айга менеп туплы уйнадык.**

**Күкләр зәңгәр, гүя юка ефәк,**
**Шул ефәкне менеп алдык без.**
**Һәм кичләрен сиздермичә генә**
**Кызлар иңнәренә салдык без.**

**Кызларны без фәрештәгә тиңләп**
**Акылыбызны җуеп яраттык.**
**Бөтен байлык—шашып сөю иде,**
**Шуның белән кызлар караттык.**

**Туган яклар хәзер бик үзгәргән,**
**Башка инде тау һәм елгабыз.**
**Без үскәндә бар да матур иде,**
**Чөнки үзебез матур булганбыз.**

* * *

**Студентлар каникулда,**
**Урамнар калган бушап.**
**Шәһәр тора моңсуланып**
**Картлар йортына охшап.**

**Кызларның чәченнән сыйпап,**
**Назлаучы җилләр тынган...**
**Мәхәббәт җырчысының да**
**Каләме... шартлап сынган!**

**Яшьләр алып киткән, ахры**
**Шәһәрнең бөтен ямен.**
**Тәрәзәләр, юлга карап,**
**Көтә кызлар килгәнен.**

* * *

**Сугышып үстек сөйгән ярлар өчен,**
**Бик еш кына тордык тукмалып.**
**Көчлерәкләр безне тукмаса да**
**Көчсезләргә үзебез сукмадык.**

**Сабантуйда бирәр бүләк ала**
**Хәтта арттан килгән чабышкы:**
**Безнең кызлар алай итмәделәр,**
**Җиңүчеләр ягына авышты,**
**Шуның белән күпләр ялгышты...**

Ә бит юкса йодрык сугышында
Җиңүчеләр тора алмашып.
Сөйгән кызлар, без яраткан кызлар
Калды еракларда адашып.

Йөрәгебез мәйданнарга чыкты
Туктап калган чакта йодырык:
Йөрәкне без утлы гөрзи итеп
Дошманыбыз башына тондырдык.

Сөйгән кызлар, без яраткан ярлар
Яра булып калды тәннәрдә:
Тәннәрдәге яра эзен сыйпыйм
Яшьлек искә төшкән мәлләрдә.

Һәм уйланам: безнең сугышулар
Кирәк булган икән, бик кирәк:
Сугышмасак, тормыш кыйнавына
Түзәр иде микән бу йөрәк?!

## Кирәк икән

Күк капкасын ачып кояш чыга,
Сибелә җиргә йомшак кызыллык.
Йөгерәмен кояш чыккан тауга
Шушы матурлыкка кызыгып.
Тирләп-пешеп менеп җитәм тауга
Һәм кояшка сузам кулларны.
Ләкин кояш мине көтеп тормый,
Менеп киткән була югары.
Тау артыннан, ташлар арасыннан
Эзли башлыйм кояш оясын.
Килә минем кояш оясыннан
Төсләргә бай нурлар җыясым.
Әллә нинди тиле бер хыял бу,
Арына алмыйм шушы хыялдан.
Тау өстендә йоклыйм, тик ул көнне
Кояш чыга башка оядан.
Беләм юкса: уйлар уйнавы бу,
Буй җитмәслек җиргә үреләм.
Шул яшәтә мине, шул яшәртә,
Авырып яткан чакта—тереләм.
Ләкин моны соңрак аңладым мин
(Пәйгамбәрлек килә бит кайчак!):
Үсүеннән туктап калмас өчен
Кирәк икән кешегә зур максат...

Нур
Әхмәдиев

# МӨНИРСТАН

РОМАН

***

Гайния белән идарәдә сөйләшү юаныч китермәсә дә, егет өметен өзмәде. Кызлар текә, тәкәббер халык, бигрәк тә чибәр булып күзгә бәрелеп торганнары. Ә Гайния шундый сирәкләрнең берсе. Мөнирҗанны күрү белән муенына сарылмавын да аңлап, аклап була. Ник дисәң, шәһәрнең азгын, җай чыгуга әрсезләнеп муенына асылынырга торган марҗасы түгел бит ул. Гайния—авыл кызы, авыл иркәсе.

Мөнирҗан әнә шулай уйланды. Кызның кыланмышларын күпмедер дәрәҗәдә akласа да, вакыйгаларны үзагымына куеп, кул кушырып утырырга җыенмады егет. Ярар, кыз горур да булсын ди, бераз гына иркәрәк тә булсын ди, ник шулкадәр кылана, Мөнирҗанның җанын ник шулкадәр телгәли соң ул?! Йөри торган бүтән егете булса, ишетелер иде, кем беләндер түшәк уены уйнап алган булса, сөйләрләр иде. Әнә ич Югары очтан Сәлимәне Хәсьяновның «үз итүе» хакындагы хәбәр белән сарафанлы радио авылны тутырды. Ә бит Габдерәхим абзыйның ул кызына уналты гына яшь. Авылның авызын томалый алмыйсың шул. Авыл авызы—мир авызы.

Буранлы төндә Гайния кочагына чумуын Мисбах томанлы гына хәтерли. Иртән уянып киткәч тә ул моны төш кенә булгандыр дип уйлады. Ничек инде уйламаган җирдән шундый чибәр, җитмәсә гыйффәтле кыз аны үз кочагына алсын! Бу бит сөлектәй егетләрнең дә төшенә кермәстәй хәл. Бик теләсә, үзе кебек бер аксак шайтан түгел, Хәсьянов кебек арурак ир-ат та бетмәс иде лә аңа. Мисбах Хәсьяновның Гайниягә йотардай итеп караганын сизми дисеңме? Үзенең бу эшен прсидәтел белсә ни эшләтер? Хәсьяновның талканы коры.

Мидхәт Хәсьянов комсомол активисты булып, сугыш алдындагы хәтәр елларда хезмәт баскычлары буйлап, яхшы чүпрә салынган камырдай, бик тиз күтәрелде. Фашистлар йөздән артык халыкның уртак ватаны саналган Советлар Союзына басып кергәндә, ул партиянең район комитетында пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире булып эшли иде. Башкаларны Ватанны сакларга җибәрү буенча көне-төне үгетләсә дә шәхси үрнәк күрсәтергә никтер ашыкмады Мидхәт.

Ләкин сугыш—сугыш инде ул. Сугыш үз законнары белән эш итә. Бармаска тырышып, бер ел чамасы бронь белән калып торса да, барыбер—ахыр чиктә Хәсьяновка солдат шинеле кияргә туры килде.

*Дәвамы. Башы 1нче санда.*

Өлкән политрук чинына кадәр күтәрелде, хәтәр бәрелешләрдә гаярь йөрәкле, үзен аямаучы Хәсьянов берничә тапкыр яраланды. Шулай да Ходай Тәгалә үзенең ата коммунистларының берсе саналган Мидхәтне миһербанлыгыннан ташламады: чираттагы ярасыннан тернәкләнгәч, комиссия аны фронт өчен яраксыз тапты.

Көн саен йөзләгән, меңләгән ир асыллары кырылып торганда, авыл-шәһәрләрдә ир заты күзгә кырып салырлык кына калган бер вакытта Хәсьянов кебек кешегә вакансия бетәме соң! Сугыш бит ул кадрлар үсүе өчен иң унайлы вакыт. Баштарак Мидхәт райкомда калырга теләгән иде. Ләкин ул сугышка киткән чагында инструктор гына булып эшләгән (бөркетләр югында чыпчык та әлләкем), ә хәзер ниндидер могҗиза белән беренче секретарьга кадәр күтәрелгән Һади Вәгыйзов икенче төрле уйлады: ана «Коммунизм өчен» колхозында рәис вазифасын тәкъдим итте. Райком тәкъдименең, гәрчә ул шәхсән беренче секретарь авызыннан гына чыкса да, хәрби приказдан ким түгеллеген белү өчен Хәсьянов кебек райком аппаратында эшләү мәҗбүри түгел. Аны чак-чак кына уйлый белгән һәркем аңлый. Шуңа күрә Мидхәт бу тәкъдимгә каршы төшеп, бүтән вариантлар эзләп тормады, беренченең кул астында башка вазифалар барлыгын белсә дә.

Һади Вәгыйзовның үзен читкәрәк тибәргә тырышуының сәбәбе кайчандыр аларның «сөт бажалары» булуында икәнен Мидхәт шунда ук төшенде. Вәгыйзовның кабул итү бүлмәсендә Люцияне күргәч, ул башта куанган иде, тик иртәрәк булган икән. Сугышка киткәнче, Хәсьянов иргә дә, миргә дә ярый белгән бу чибәр ханым белән татлы-ләззәтле минутларны аз татымады. Ул чакта Люция башлангыч классларда укыта һәм мәктәп комсомол оешмасын җитәкли иде. Аның ничек итеп үз кочагына шуып кергәнен, дөресен әйткәндә, Хәсьянов хәтерләми дә. Менә шул хәзер Беренченең кабул итү бүлмәсендә утыра. Беренче белән Люция арасында эшлекле мөнәсәбәтләр генә булмаганын аңлар өчен бу икәүне бөтенләй белмәскә яки ангыра булырга кирәк.

Ләкин Вәгыйзов та дурак түгел. Ул райкомда сирәк була, аның күп вакыты авылларда уза, Казанга да чакырып торалар. Ә азгын хатын-кызның акылы үзе белән: таза, яшь, чибәр Хәсьянов, райкомда калса, кабат Люциягә кармак салмас дип кем әйтә? Һадиның һич кенә дә Люцияне югалтасы килми. Ник дигәндә, Люция белән түшәктә булу ул бит бер тапкыр оҗмахка кереп чыгу дигән сүз. Нигә соң Һади үз хатыны белән андый ләззәтне татымый икән?

Колхозга җибәрелүенең төп сәбәбен аңлаган Хәсьянов: «Әй, эчене кадалсын сана Люциясе, баш исән булса аннан аруураклары да табылыр»,— дип юатты үзен. Һәм суга караган кебек булып чыкты. Авылда нәрсә-нәрсә, әмма күңелле мут ир-ат өчен хатын-кызга кытлык юк иде. Икенче бер авыр ягы бар: ничек итеп хатын-кыз урманында нәфсеңне тыеп калырга, чикчаманы белергә.

Хатын-кызны аңламассың. Берәүләре, фронтта тере ирләре була торып та типтереп калу ягын гына карый. Яшь-яшь кызлары артыннан йөри, форсат чыгуга, җәелеп ятарга гына торалар. Шул ук вакытта кайберләре, ирләренең һәлак булу хәбәрен әллә кайчан алып та, яки сугышка кадәр үк ирсез калып та, мәрхүмнәргә тугрылык саклап, ялгыз яши бирә. Мәрхүм ирләренә тугрылык саклаучыларны әле аңлап була, ә менә вәгъдәләшергә дә өлгермәгән егетләрен көтүче кызлар турында ни дияргә?

Колхоз рәисе вазифасының җаваплы, мәшәкатьле эш икәнен Хәсьяновка сөйләп аңлатасы юк. Авылда туды, авылда үсте, авылдан райком номенклатурасына күтәрелде. Колхоз партоешмаларын райком бюроларына хәзерләүгә дә аз җитәкчелек итмәде. Бу эштән аерылып торуына нибары ике ел чамасы гына. Ләкин рәис вазифасы гел-гел авырдан гына тормый,

утыз көн уразаның да бер көн гаете була. Кайсы колхозның председателе аерткан сөт эчеп утыра? Колхоз алдында бурыч бер генә—җинүне мөмкин кадәр якынайту өчен ит, сөт, икмәкне күбрәк житештерергә. Моның өчен колхозларда йөзләрчә һәм меңнәрчә кеше көнне төнгә ялгап эшли. Эшләсен! Даһи юлбашчыбыз Иосиф Виссарионович Сталин шулай куша, сугыш шуны таләп итә. Көне-төне эшләгән кешенең әллә нинди фәлсәфәләргә бирелергә вакыты да, хәле дә, теләге дә калмый. Ул кол хәленә төшә, әкәм-төкәмгә яисә бүтән бер бөҗәккә әверелә. Ә коллар белән идарә итү мең кат җиңелрәк.

Бу хакыйкатьне озак еллар активист булып йөргән һәм югары түрәләр белән дә аралашкан Мидхәт Хәсьянов комсомолда чакта ук тирән үзләштергән һәм сизенүенең моңа кадәр аны алдаганы юк иде әле.

Юк-юк, колхозга килеп ялгышмады ул. Авылның крепостнойлык чорында ук, ә бәлки тагын да элегрәк формалашкан коллык психологиясе чираттагы «прсидәтелне» нәкъ Хәсьянов уйлаганча һәм теләгәнчә кабул итте. Партиянең демократик централизм принцибына нигезләнгән «халыклар атасы»ның диктаторлыгы югары түрәләргә генә түгел, урта һәм кечерәкләргә дә үзләре эшләгән җирдә ике әйттертмәскә ирек бирде.

Ләкин, кулда власть бар дип Хәсьянов чик-чаманы онытмады, аратирә «ят ризык» авыз иткәләсә дә, моны үзмаксат итеп куеп, кайберәүләр шикелле «мир үгезе»нә дә әверелмәде, биш-алтыны алырга мөмкин булган чакта да өч-дүрт белән канәгатьләнә белгәнгә, комсыз диеп тә даны чыкмады. «Күп ашасаң, аз ашарсың, аз ашасаң, күп ашарсың»—бу аның күптәнге яшәү принцибы иде. Колхозга килгәннән бирле «нарком нормасын» капмаган көне калмады диярлек, ләкин ул беркайчан да халыкка исерек күренмәде.

Хәсьяновның даны бөтенләй көтмәгән яктан чыкты. Артык каты күңелле, кырыс, кансыз иде яңа рәис. Гаебе булганнарны әйтеп тә торасы юк, бер гаепсезләргә дә давыл, ураган булып ябырылды ул. Башак җыйган балаларны бастырып куып тоткач, кан сидерткәнче ярды. Ире сугышта үлгән Зәйтүнәнең малае шуннан тотлыга торган булып калды. Авыл хатыннарының төн йокысы исәбенә чокыр-чакырдан хәзерләгән печәннәрен колхоз ындырына кайтарып аударттырды. Килүенә ике ай узмады, яңа прсидәтелнең кемлеген аңларга да өлгермәгән халык Хәсьяновка «Дәҗҗал» дигән кушамат такты. Ләкин халык кемгә дә булса зарланырга, шикаять язарга уйламады да, чөнки замана—көчленеке, хакыйкать эзлим дип, Алла сакласын, тагын да зуррак бәлаләргә тарырсың. Моңа кадәр карга күзен карга чукыганы булмады. Ә сугыш елларында—бигрәк тә.

Бу кушамат көннәрдән беркөнне Мидхәтнең үзенә дә барып иреште. «Такмагайлары тагы,—дип уйлады ул, исе китмичә генә,—кара халык барыбер кара сарык булып калачак. Мин бит моны үзем өчен эшләмим, ил өчен, ватан өчен эшлим».

Баш хисапчы Мисбахны Хәсьянов электән үк белә иде. Райкомда эшләгән елларында «Коммунизм өчен» колхозына нинди генә эш, нинди генә йомыш белән килсә дә, баш хисапчыга «орынмый» үткәне сирәк булды. Колхоз хуҗасы әмереннән дә чыкмый, үзен дә онытмый торган бухгалтерның кайда да әшнәләре житәрлек. Айныр-айнымас йөрсә дә, Хәсьянов өчен Мисбах кебек кеше үтергән иде инде. Шуңа күрә ул башканы эзләп маташмады.

Яңа председательнең үзенә мөнәсәбәтен тиз ачыклаган Мисбах элек ничек яшәсә һәм эшләсә, нәкъ шулай дәвам итте.

Әйе, район үзәгендә Доха карчыкларда булган хәлгә кадәр ул Хәсьяновтан тамчы да шикләнмәде. Колхоз рәисенең кодрәте зуррак, анысы дөрес, тик алар икесе бер арбага җигелгән—Хәсьянов колхозның уң кулы булса, баш

хисапчы—сул кулы. Уртак эшне башкару өчен ике кулның бергә хәрәкәт итүе кирәк.

Каракның бүреге яна дигәндәй, бу хәл турында Гайния Хәсьяновка сөйләгәндер, тегесе хәзер матур кыз өчен үч алу җаен гына карап йөридер дигән шик кереп оялады аның башына.

Гәрчә Хәсьянов Гайниягә карата битараф булмаса да, вакыйганы ашыктырырга теләмәде. Әгәр ризык булырга язса, Гайния качмас, кирәсе ризык тешенне сындырып булса да керә ул. Әнә бит Сәлимә, янып торган уналты яшьлек кыз, фермада шаяртып кына кочаклаган иткән иде, сыгылды да төште. Җитмәсә:

—Мидхәт абый, син миңа беренче күрүемдә үк ошаган идең,—дигән була.

Мидхәт аны йөреп шомарган берәр нәрсәдер дип уйлаган иде, кыз икәнлегенә ышангач, исе китте. Алай да була икән дөньяда, югыйсә кырык мирдән калганнары да кайчакта шундый итеп кылана, шундый әртисләнә, шаклар катарсың.

Табигать шулай яраткандыр, күрәсең, яшь булса да дәртле, тәкатьсез иде Сәлимә. Нишләптер шушы чибәр кыздан тиз туйды Хәсьянов. Әллә оят дигән нәрсәне бик тиз онытуы, артык әрсезлеге, сабырсызлыгы, халык фикеренә исе китми төкереп каравы сәбәпче булды, әллә башка сәбәп... Хәзер ничек котылырга белми йөргән чагы. Җитмәсә, авылда даны да чыгып өлгерде. Ә нинди дер селәгәй кызлар белән телгә керү Мидхәтнең планында каралмаган иде.

Авылда эшсез күпме ятарга була. Йорт тирәсендә тегесен-бусын караштырып, октябрь узды, ноябрьнең җидесе алдыннан кар төште. Бөтен дөнья акка төренгән. Нәкъ теге вакытта Гайнияне беренче тапкыр озата кайткандагы кебек.

Кулы төзәлеп бетмәгән диптер инде, моңа кадәр Мөнирҗанны эшкә дәшүче булмады. Болай киләп сарып йөреп булмас, җитәр, кешедән оят дип уйлады Мөнирҗан һәм бригадир янына үзе китте. Өлкән яшьтә булуы аркасында гына фронтка алынмаган бригадир Харрасның аны күргәч шундук авызы ерылды:

—Әйдүк, әйдүк, Мөнирҗан энем. Килеп бик яхшы иткәнсең, безгә кешеләр, эшче көч бик кирәк.

—Килүен килдем дә бит, Харрас абзый, ни эшкә ярармын икән? Берәр кулай эш табылса дигән идем...

—Синең кебек егеткә эш тапмабызмы?! Әй, энем, энем, бик беләсең килсә, бер кешене биш итәр идем мин. Ат җигүне онытмагансыңдыр бит?

—Юк шикелле.

—Алайса җик Күк бияне, саламга барырсың. Арурак атлар барысы да урман кисүдә.

—Саламга барырга?—дип кайтарып сорады Мөнирҗан.—Шушы сыңар кул беләнме?

—Әйе, ник аптырыйсың аңа?

—Төяп булыр микән дим...

—Түбән оч Гыймади абзыйны хәтерлисеңме?

—Хәтерлим.

—Хәтерләсәң, шул: аның да бер кулы юк иде мәрхүмнең. Герман сугышында, теге ундүртенче елгысында, өздереп кайткан иде. Салам да ташыды, печәнен дә чапты, урман да кисте шул Гыймади абзый. Аллаһы боерса, син дә булдырырсың.

Мөнирҗан сәнәкне ничегрәк тотасын, саламны ничек төйисен күз

алдына китерде дә, йөгән эләктереп, ат тотарга кереп китте.

И Күк бия, танырсыңмы икән үзеңнең Мөниржаныңны? Мөниржан бит синең белән, тракторга утырганчы, күпме сабан сөрде, урманга йөрде, көлтә ташыды. Ул чакта Мөниржан, малай гына булса да, ике куллы иде. Ә син, Күк бия, якын, үз итмәгән малай-шалайга гына түгел, өлкәннәргә дә баш бирми идең.

Шундый уйлар белән Мөниржан сөякләре тырпаеп калган арык атлар арасыннан Күк бияне эзләде. Аранда тапмагач, нечкә бүрәнәләрдән колхозлашкач ашык-пошык әтмәлләгән абзарга керде. Баштарак аңа ярымкарангы абзарда барлык атлар да бертөсле булып күренде. Тора-бара күзләре ияләште, кайбер таныш атларны шәйли башлады: әнә сигез центнерны эһ тә итми тарта торган Төке. Әнә бер аягына аксаса да, бик җәһәт йөрүе белән аерылып тора торган Милиция; көч ягыннан Төкедән генә калыша торган Вафа, ботына кунган чебен-черкине дә куарга иренгән Кашка алаша. Ә Күк бия кайда соң?

Күзләре белән эзләп таба алмагач, Мөниржан элеккеге еллардагы кебек:

—Күк бия, бах, бах!—дип, әче иттереп сызгырып җибәрде. Менә Ходаның хикмәте—карангы почмактан бер ат хәлсез, ләкин назлы тавыш белән кешнәп җавап кайтарды һәм торып басты. Рәхмәт төшкере, онытмагансың икән бит. Күңеле нечкәргән Мөниржан Күк бия янына китте. Әйтерсең, ат шушы очрашуны гомере буена көткән, башын егетнең җилкәсенә салды. Гайнияне уздырдың әле син, Күк бия. Ул әнә ничек тиз онытты. Йөгән кидереп, Мөниржан атны яктыга алып чыкты.

Каһәр суккан сугыш! Әзмәвердәй ирләрне, сөлектәй зифа хатын-кызларны, гөнаһ кылу түгел, аның барлыгын да белмәгән сабыйларны үтереп кенә калмадың, атларны да карачкыга әверелдергәнсең бит син. Кара инде бу Күк биягә, Мөниржан җиккәндә баскан урынында да тик кенә басып тора алмаган ат бүген сөякләргә тарттырылган тиредән генә тора. Ә күзләрендәге сагыш! Елап җибәрүдән Мөниржан үзен чак тыеп калды. Мескен Күк бия! Әйтәм жирле бүген кешнәвең дә шактый хәлсез чыкты.

Ләкин бер Күк бия генә мондый арык булса, ярты гына бәла булыр иде. Фаҗиганең зурысы шунда ки—атларның барысы да, көчлерәк җил иссә, аварга тора. Сугыш аларны шундый талаган, талкыган ки, хәтта җәйнең авыз тутырып чәйнәр витаминлы үләне дә хәл кертеп өлгерә алмаган. Хәер, хәл керсен өчен атка ял, солы, он кирәк. Ә колхозда боларның берсе генә дә юк. Әле ничек бу атлар бөтенләй күтәрәмгә калмый, менә ул чагында ни эшләр идең?!

Күк бияне ничекләр генә кызганмасын, Мөниржан аны барыбер җигәргә һәм саламга барырга тиеш иде. Чөнки саламны фермада ач сыерлар, бозау, сарыклар көтә. Салам бу кышта малларның бердәнбер ризыгы, яшәү белән үлем арасындагы сират күпере.

Ул, атын җиккәндә, тешен кысып телен канатып бетерде. Нинди каты дуга эләкте, әллә соң сынамакка бригадир юри шунысын бирдеме—чөелдерекне кысып бәйләү мең газапка әверелде. Чулак кулын да бәреп авырттырды. Ләкин ничек итсә итте, ат җигелеп бетте. Маңгаена чыккан тирләрен Мөниржан, зур канәгатьләнү хисе кичереп, солдат бүреге белән сөртеп алды. Бу бит башкалар аңлый алмаслык, үзенә күрә зур бер җиңү иде.

Ул алып кайтасы солы саламы Торна тавында. Шушы яшенә житеп, Мөниржанның ул тауга торна төшкәнен күргәне булмады булуын.

Аның хәтеренә кайчандыр Фазлыйәхмәт мулланың бабасыннан ишеткәнне сөйләгәне килде. Имеш, элек бу тауга язын-көзен торналар ял итәргә төшкән. Бер язда сабан сөрүчеләр тауда ак торна күреп, авылга

кайтып әйтәләр. Бу могжизаны күрергә карты-яше шунда ашыга. Менә бит, Ходаның хикмәте, ак торна да була икән! Исләре-акыллары китә.

Ак торнаның бәхетсезлегенә каршы, бу хәбәр урыс алпавыты яшәгән имениегә дә барып ирешә. Шул төндә алпавытның балага уза алмый интеккән килене төш күрә. Гайсә пәйгамбәргә охшаган берәү ана, ак торна бавыры ашасаң, игез бала табарсың, ди. Хатын шунда ук ирен уята да ак торнаны атып алып кайтырга куша. Таң атуга, ире шулай эшли дә.

Ак торнаны атып үтергәч, торналар тау өстендә, кызганыч тавышлар белән коркылдап, бик озак очып йөриләр. Бу аларның корбан булган иптәшләрен юксынып елаулары мы, әллә шушы жирне, кешеләрне каргаулары мы булгандыр, шуннан соң алар дәррәү очып китәләр. Жирдә бер ялгыз торна гына әле тагын ике көн өзгәләнә. Анысы, мөгаен, ак торнаның яры булгандыр. Өченче көнне таң белән анысы да, соңгы тапкыр кычкырып, болытлар арасына кереп югала.

Бай килене балага узгандыр мы, юк мы, риваятьтә ул хакта берни дә сөйләнми. Әмма бу тауга торналар бүтән төшми. Шуннан аны башта Торна каргаган тау дип йөртәләр, тора-бара, ул Торна тавына гына кала.

Юл уңаенда Мөниржан өенә керде һәм кая барасын әйтеп чыкты. Аннан Торна тавына юл тотты.

Ноябрьдә көннәр шактый кыскарса да, әле вакыт бар, шуңа күрә Мөниржан атын ашыктырмый. Моңа рәхмәт йөзеннән Күк бия әкрен генә атлый. Аны юырттырырга теләсәң дә, ай-һай, түзәр микән...

Дөнья ап-актан киенгән һәм шундый саф, кайдадыр әшәкелек һәм әшәке күңелле кешеләр булуына да ышанасы килми.

Кар төнлә генә яуганлыктан, әле чана эзе төшеп өлгермәгән. Мөниржан тәүге юлаучы, дилбегәне сирәк-мирәк әле уңга, әле сулга тарткалап куя. Күк бия, ничек итсә итте, аны Торна тавына алып килде.

Атын туктатып, Мөниржан солы эскертләрен санады—егермеләп икән. Харрас абзасы, күңеленә ошаганыннан төярсең, дигән иде. Ул авылга якынрагыннан башларга ниятләде.

Чанасын эскерт янәшәсенә жайлап куеп, бастырыгын кырыйга ташлаган иде, сискәнеп китте: аягы астыннан гына диярлек әле тунын тулысынча алыштырып та өлгермәгән ярым соры, ярым ак куян чыгып ычкынды.

—Тьфү, шайтан, котны алдың бит!—дип куйды ул, күңеле булып.— Мылтык юк шул, ни эшләтергә икәнен белер идем, куян бәлеше эчне тишмәс иде.

Белә үзе, бер түгел, биш мылтыгы булса да, бу куянга атмаячак ул. Бәлеш дип шундый гүзәл жан иясен җәберләргә соң! Тагын бер тапкыр күреп калырга дип караса, куяннан жилләр искән иде.

Кар шундый йомшак, сәнәк белән эз генә кагыл, оча да китә. Әйе, хәзергә шулай. Менә бер-ике буран гына узсын, эскертенне көрт басып китә, карын көри-көри хәлдән таясың. Кар дигәнең дә бүгенге кебек таралып тормый, тыгызланып ката, бер-ике тапкыр жепшеккә эләксә, бозга әверелә. Ничек кирәк алай эскертне ачсаң, эшнең тагын да газаплырагы башлана: берәмтекләп диярлек салам йолкырга керешәсең. Көчәнүдән иреңең чәйнәлә, сыдырылып, беләкләрең каный, тырнакларың каерыла. Бәхетең елмайса, бераздан эскерт җаена төшәсең. Моңа ирешсәң, саламны сәнәк белән каерып ала башлыйсың. Ә бу инде кул белән берәмтекләп йолку түгел, күпкә үрчемлерәк.

Бүген Мөниржанга жиңелрәк булырга тиеш: кар юк, сентябрьда гына өелгән эскерт артык басылып та өлгермәгәндер...

Дилбегәсен чишеп алып, Мөниржан аның бер башын чана үрәчәсенә бәйләде, икенчесен исә эскерт аша ыргытты. Исәбе шуңа тотынып түбәгә менү һәм эскертне сәнәк белән иплән кенә сүтү иде. Дилбегәне ыргытуын

ыргытты, ләкин ул кыска булып чыкты. Очын эләктерим дип, Мөнирҗан сикереп-сикереп караса да буе җитмәде. Ә майлагандай шома солы саламыннан болай үрмәләп кенә менү сау-сәламәт кешенең дә кулыннан бик килми.

Беренче адымнан ук уңышсызлыкка очрагач, бәлки, башка берәүнең кәефе кырылыр иде. Мөнирҗан исә елмаеп кына куйды. Ничек инде аның шундый юк-барга да исе китсен. Ул бит бүген, бисмилла, эшкә чыкты. Елдан артык вакыт узганнан соң, дары иснәп, снаряд, бомбалар астында калганнан соң, салам ташу үзе бер бәхет, ләззәт ләбаса! Ул сынатмаска тиеш, бөтенләй төшеп калмаганлыгын үз-үзенә, Гайниягә, бригадир Харрас абзасына, бөтен авылга расларга тиеш.

Эскерт куюның үз осталары була. Алар һәр сәнәк саламны йозаклап салалар. Шуңа күрә саламга килүчеләр аны теләсә ничек сүтә алмый, моның өчен эскертнең җаена төшәргә кирәк.

Мөнирҗан бу хакыйкатьне онытып җибәргән иде. Менә ул сәнәгеен уң кулына кысып тотып, сабын чулак кулының җине астыннан җибәрде. Исенә төште: Гыймади абзый шулай итә торган иде.

—Бисмилла иррахман иррахим! Хәерле сәгатьтә!

Ул бар булган көченә сәнәгеен эскерткә батырды һәм тарта башлады. Эскерт селкенде, ләкин куелуына ике-өч ай гына узса да, саламы чыгам димәде. Мөнирҗан сәнәгеен бераз суыра төште, әмма моның да файдасы тимәде. Болай булгач бердәнбер юл кала: саламны кул белән йолкырга. Ул шул чагында очлы тимер ыргак алып килмәгәненә үкенде, ыргак белән йолкуы бөтенләй икенче шул.

Яраланып госпитальдә ятулар, өйгә кайткач та юньле-рәтле эш күрмәү сәбәпле хәлсезләнеп калган кулы, салам белән тарткалаша торгач, тиз арыды. Җитмәсә, ныграк көчәнсә, сул кулының өзелгән җире сулкылдый башлый.

Маңгаена күптән тир бәреп чыкса да, Мөнирҗанның аны сөртергә вакыт әрәм итәсе килмәде, ярсып-ярсып салам йолкыды. Күзенә кереп, тире әчеттерә башлагач кына сөртергә мәҗбүр булды. Ул шулкадәр бирелеп эшләде ки, саламнан күтәрелгән тузанның тамагын кытыклавын да, изүләренә солы, әпчүк кылчыгы тулганын да сизмәде.

Кышын саламга баруның беркайчан да җиңел булганы юк. Адәм-рәтле елларда колхозның унар-унбишәр аты бергә кузгала, бергә төяп кайталар иде. Күмәк эш һәрвакыт уен-көлке белән уза, арадагы җоррак кешеләр һәрвакыт көләр өчен сәбәп таба.

Авыл малайлары салам, печән ишене төяргә тугыз-ун яшьләрдән үк тартыла башлый. Иртәрәк булмаса әле. И ул төнне йокының тәмлелеге! Баш астына чынлап та баллы кашык салалар микән әллә? Ундүрт-унбиш яшьләргә җиткәндә, кавырсыннары катар-катмас малайларны «Нужа бабай» шундый итеп өйрәтә ки, алар бу эшнең «пырафисырларына» әвереләләр.

Күпмедер йолкыганнан соң, салам сәнәк белән тартканга да бирешер хәлгә килде. Мөнирҗан ашыкмыйча гына төяргә керешге. Бер кеше бер кеше шул, салган саламны таптап торырга берәр малай булгандыр югыйсә. Менә хәзер чилән инде ялгызың: төя дә, тапта да...

Баштарак әле ярый иде, йөге биегәйгән саен мену-төшүләре авырлаша барды. Җитмәсә тамагы кипте, авызына учлап-учлап кар тутырудан башка чара калмады.

Йөге кыек түгелме, туры төяләме? Мөнирҗан әледән-әле чананың алдына, артына чыгып, йөгенә күз салды.

Төяп бетерәм дигәндә генә, Ходай бүгенге тын һавасын күпсенде бугай— җил кузгалды. Саламны чанага салуың була, шуны гына көтеп торган җил аны тузгытырга тотына.

Ничек кирәк алай төяп бетерде. Инде хәзер, жил туздырып бетергәләгәнче, тизрәк бастырып бәйләргә кирәк.

Менә кайчан сиздерә икән ул дүрт санынның төгәл түгеллеге. Тикмәгә генә Ходай Тәгалә үзенең бәндәләрен ике куллы, ике аяклы итеп яратмаган. Шул бастырыкны бастырган чакта чулаклыгы белән чиләнеп бетте Мөнирҗан. Инде генә бастырып бәйлим ди, кысылган бастырык күтәрелеп китә дә борынын кабат һавага чөя.

Мең бәла белән бастырык та бәйләнде. Йөген як-яктан тараштырып, коелган саламын чана өстенә ыргытты. Утырып кайтырга йомшак булсын. Йөге артык зурдан түгел түгелен, әйдә, сынар куллы кешегә беренче тапкырына ярап торыр. Күнеле күтәрелеп, ул башта чана үрәчәсенә, аннан ат сыртына басты да йөк өстенә менеп утырды.

Килгәннән бирле җәйнен хуш исләре белән исерткүче солы саламы ашаган Күк бия бу мизгелне күптән көтә иде. Хуҗасының дилбегә кагуы булды, кузгалырга омтылды.

И Күк бия, Күк бия! Бетәшүен житкән икән, малкай. Шушы кечтеки йөкне дә кузгатып алып китә алмадың. Ике кулы да исән-сау булса, Мөнирҗан абзаң йөкне болай гына төяр идеме соң?!

Монын ише чакта ни эшләргә икәнен белә Мөнирҗан. Йөкне аны бер кузгатып алып китүе генә кыен. Кузгалса, бара ул. Ана йөк өстеннән төшүдән гайре чара калмады. Центнерга якын йөге кимегәч, өстәвенә Мөнирҗан чананы эткәч тә, йөк урыныннан кузгалды. Мөнирҗан башта бераз тәпиләде, үргә түбәнрәк жиргә житкәч, барган көйгә генә йөк өстенә менеп кунаклады.

Болытлар астында булса да кояшның төшкелектән авышуы сизелә. Торна тавыннан авылга дүрт-биш чакрым чамасы. Аллаһы боерса,тагын берәр сәгатьтән кайтып житәрләр, әйе бит, Күк бия! Мөнирҗанның кәефе кабат күтәрелеп китте, хәтта иртәдән бирле жәфалаган, кар ашап та басылмаган эчәсе килүе дә беткәндәй булды.

Син уйлыйсын алтыга, ә ул кала ярты, диләр. Иртәрәк сөенгән икән. Ярты юлдан артыгын узгач, авылга житәргә кул сузымы дип әйтерлек ара калгач, күпме тырышса да ныклап бәйләп бетерә алмаган йөкнең саламы, чанасы салулап китте дә, сул якка ишелеп төште. Солы саламы елгыр шул, елан кебек шуып чыгарга гына тора. Аны төяү аеруча осталык сорый. Һи-и, ике кулы да исән булсамы! Болай таралып, кеше көлдереп ятмас иде абзагыз! Әле уналты-унжиде яшьләрдә үк ул печән, салам ишене эскертләгәндә бер йөкне өч кенә тапкыр кадап ыргыта иде.

Ауган, ишелгән йөкне кабат төяүдән дә яманы юк. Аны сипләштереп кенә котыла алмыйсын. Мөнирҗанның да, чананы бөтенләй бушатып, өр-яңа баштан төями чарасы калмады. Ярый әле якын-тирәдә кеше юк, мондый хәлдә халык теленә бер эләксәнме!? Көлеп, эчләре авыртачак.

Фермага ул кичке эңгер-меңгер төшкәч кенә кайтып керде. Кайтып туктауга, аны мал караучылар сырып алды. Бер-бер артлы төртмә сүзләр яварга кереште:

—Шул гомер ни эшләп яткандыр анда...

—Әллә сон берәрсен иярттеп барган иденме?

—Шулайдыр, шулайдыр, Майжамал, бик рәтен бетереп кайтарганга охшый...

—Мондый мал кулга керсә, кадерен белер идек, әйеме, ахирәт!

Терлекче хатыннарның чырык-чырык көлә-көлә төртмәле сүзләр сөйләвенә Мөнирҗан ачуланмый, ни дисәң дә «ужым» тәмен белмәгән егет кеше буларак, ана бераз оят кына. Оят булса да рәхәт. Ул канәгать, язмыш аны бүген генә дә ничә тапкыр сынап карады, бирешмәде бит, барыбер саламны алып кайтты. Сөйләсеннәр әйдә, авыл халкы төртмә телле булса да,

киң күңелле ул. Усаллыктан сөйләми. Күп вакыт аның мантыйгы: сүз юктан сүз булсын, ата казыгыз кукәй саламы? Кызык, араларында Гайния булса, ул да сүзгә кушылыр идеме икән? Юк-юк, ул болар кебек чытлыкланмас.

Кат-кат салам төягәндә дә чыгымламаган йөрәге, Гайния исенә төшүгә, чәнчеп куйды. Онытылмый да, баш та бирми бу Хәниф кызы. Нәкъ табан астына чыккан сөял булды. Бүтән берәү белән йөргәне дә ишетелми юкса. Әллә соң патша малаен көтә микән? Кызларны бит аны башта патша малаена барам, ул булмаса санатка, санат та булмаса, солдатка чыгам дип әйтә, диләр. Ну, кызый, яндырасың йөрәгемне! Ичмасам, башкалар кебек клубта да күренмисең бит!..

Ул көнне Мөнирҗан кич чыгарга уйлап кайткан иде, әнисе бүлеп биргән умачтан соң, гипнозланган шикелле, ике күзен дә йокы басты, керфекләренә авыр гөрзиләр асылды да, ясаган чәен эчеп бетерер-бетермәс, мендәргә барып таянды. Исәбе әз генә ятып тору иде дә, әмма шул ятудан ул, уянмыйча, иртәнгә кадәр йоклады.

Әлеге көннән башлап декабрь урталарына кадәр салам ташуда булды ул. Тик икенче көнне үк бригадирдан кулдашка кеше сорап алды. Аның кебек чулакка башкача мөмкин түгел иде. Ярдәмгә, җиде ел укып, дүртенче класска этеп-төртеп көч-хәл белән китереп җиткергән, анда да әле һаман сүзләрне ижекләп кенә очын-очка ялгаган Мөҗәһит исемле малайны бирделәр. Укырга мие сыек булгандыр инде бахырның, ләкин эшкә тырыш булып чыкты үзе. Һәрхәлдә аның белән бер йөкне ике тапкыр төяргә туры килмәде.

Маллар суелды. Сугымлыгы булган бәхетле хуҗаларның казанында тансыкка итле шулпа кайнады, мичнең сыек төтененә кушылып, юклыкка һаман да күнегергә теләмәгән ашказанын үртәр өчен салкын һавага сирәк-мирәк бәлеш исе таралды. Көн саен корбаннар сорап торган ачкернә сугыш елларында ачлык- ялангачлыкны, мохтаҗлыкны бөтен гомерләренә җитәрлек итеп татыган кешеләр, тыныч көннәр килүгә, ут эченә тагын да якыннарын озатасы булмаганга куанып, кайтмый калганнарны юксынып, тормышның бер яхшырасына өметләнеп, гадәти тормыш белән яши башладылар. Алар инде салым түләргә күнеккән, соңгысын чыгарып салырга өйрәнгән (чөнки, үзең бирмәсәң, финагент барыбер талап алачак), авызын ачса үпкәсе күренүгә исе китми башлаган, кешедән бигрәк туплаудагы сарык көтүенә охшап калган иде.

Читтән караганда мохтаҗлыкка, рәнҗү-кимсетелүләргә корылган ул тормышта якты минутларга бер генә урын да калырга тиеш түгел иде сыман. Ләкин нинди генә авыр шартларда да кеше, башка чара калмаса, үз-үзеннән көлеп тә, шул караңгылыкка нур иңдерә, ямь таба. Авыл яңа хәбәрсез бер генә көн дә яши алмый. Хәер, сугыш беткән елда хәбәрләргә кайдан килеп кытлык булсын. Әле һаман да фронтовиклар кайткалап тора. Алар турындагы хәбәр сөенче алудан башланып, көне-сәгате белән авылга тарала.

Көннәрдән бер көнне Әсма карчыкның сугышка кадәр биш ел рәттән Әскәй сабан туенда, хәтта башкорт якларына чыгып та, көрәштә баш батыр калган улы Шәйхетдин кайтты. Аны электән белгән, белү генә түгел, андый батырның нәкъ менә алар авылыныкы булуы белән горурланып яшәгән халык аһ итте: әзмәвер кебек адәмнән сөяк белән тире генә калган, карачкыга әверелгән гәүдәсе атлаганда чайкала, җил иссә, аягында басып кала алуы да шикле иде. Җитмәсә бер күзе чыккан, колаклары саңгырау—юньләп берни ишетми. Сугышның башында ук алынган иде ул, бер генә хаты килеп калды мескенкәйнең—хәбәрсез югалганнар исемлегенә бу фәкыйрь дә кертелде. Аның хаты гадәти хат түгел иде, эчтәлеге көне-сәгате

белән авылга таралды, хәтта кайберәүләр озак вакытлар яттан да сөйләп йөрде әле үзен.

Шәйхетдин авылда бик күпләрдән көч-гайрәте белән генә түгел, шаянлыгы, уен-көлкене яратуы, ярдәмчеллеге һәм бераз кыланчыклыгы белән дә аерылып торды. Халык аны ярата, хөрмәт итә, бәлки шуна күрәдер дә кыланчыклыгын гаепләми. Гүя ул авылның Хуҗа Насретдине, Шәйхетдиннең сүзләре мәзәк урынына телдән телгә күчеп йөри. Дөресен әйткәндә, бүтән берәү Шәйхетдинчә сөйләшсә, анардан күптән йөз чөерерләр иде, Шәйхетдингә исә бу кыланчыклык хәтта килешеп тә тора.

Хатның эчтәлеге болай иде:

«Исәнмесез, хатыным Фирзания ( дөресе Фирдания), улым Фәнзәс (дөресе Фәндәс)!

Без Мәскәү янынза (янында) нимесләр белән әйбәт кенә, матур вә күнелле генә сугышып ятабыз: алар безгә пүләмүттән ата, снаряд, бомба яузыра (яудыра), без ана кесәдән йозрык (йодрык) күрсәтеп, балчык, таш ыргытабыз.

Бәгырь чабатамның кинзерәсе (киндерәсе) кебек күнелемә казерле (кадерле) Фирзаниям (Фирданиям), җибәр мина санзык (сандык) төбендәге унике япьле пәскене (пәкене), мин аның белән нимесләргә казармын (кадармын) вә тотып алып суярмын.

Кайнар сәлам белән атагыз вә ирегез Шәйхетзин (Шәйхетдин). Сез бәгырькәйләргә: абыйларга, күрше-күләнгә, авылзашларның һәрбарчасына күптин-күп сәлам».

Минзәлә сөйләшенең «без» алмашлыгын «бед», «кызыл бозау»ны, «кыдыл бодау» дип сөйләшүче Әскәй халкының исе-акылы китте: кара инде син бу Шәйхетдинне, киткәненә яна гына, шул арада культуралы сөйләшергә өйрәнеп өлгергән! Гомер бакый «Шәйхетдин», «Фирдания», «Фәндәс», «сандык» дип сөйләшкән җирдән «Шәйхетзин», Фирзания», «Фәнзәс», «санзык» дип хат язган. Ул «пәке» ничек итеп «пәске»гә әверелде икән?

Күпне белүче Мәрьямбикә карчык мона үзенчә нәтиҗә ясады:

—Бед дөрес сөйләшмибед, телне бодабыд икән. Әнә Шәйхетдин фрунтка баргач бик тид өйрәнгән. Сугышта камандирлар татарча дөрес сөйләшергә дә өйрәтәләр икән...

Бәлки чыннан да шулайдыр, мәктәптә җиде ел буена кермәгәнне тутыга башлаган шарикларга сугыш җиде көндә сендерә торгандыр. Сугыш бит ул...

Фазлый мулла рәхәтләнеп көлде бу хатның эчтәлеген ишеткәч. Фикерен белдереп тормады, указлы мулланың ут эчендә йөргән авылдашы исеменә тел-теш тидермәслек культурасы бар иде шул. Аның каравы абыйсы Гамир бер сүз белән күнелендәген ачып салды:

—Шалапут!—Кем кем, ә ул үзе белән әвәрә килеп үскән энесенең кем икәнен белә иде.

Хатыны Фирдания хатны укыгач, елмаеп кына куйды:

—Әй, кыланчык, сугышка баргач ташласа да була иде бит бу гадәтен!—Ләкин үзе мондый хат көн саен килеп торса, уч төбен генә үбәр иде. Әмма Ходай Тәгалә бәндәсеннән бәхетен күпсенде—Шәйхетдиннән бүтән хәбәр килмәде, яшь хатын өчен озакка сузылган газаплы билгесезлек көннәре башланды.

Хаты килүдән туктаса да, өйдә Шәйхетдинне көттеләр: ничек инде шундый асыл егет юкка чыксын ди! Кайтыр, кайтмый калмас, яки бер-бер хәбәре килер. Ана кешенең көтүе табигый, алар балаларын гомер буена көтәргә дә риза, хатыны Фирдания дә ике җәй, ике кыш Шәйхетдинне озаткан юлдан күзен алмады. Юк-юк, Фирдания намуслы исемен керләмәде, югыйсә яшь, чибәр хатынга нәфсе уйнатучылар юк түгел иде. Үзенең тәне

дә наз теләгәндер.

Фирдания күрше авыл кызы иде, Шәйхетдиннең хәбәрсез югалуына өченче ел киткәч, кайнанасын җирләгәннән соң, баласын алып, авылларына ата-анасы янына кайтып китте. Әскәйдә аны бәйләп тотар нәрсә калмаган иде. Күпмедер вакыттан соң үзеннән шактый өлкән, ярты еллар чамасы элек хатыны үлгән берәүгә кияүгә чыгуы турында Әскәйгә хәбәре килеп житте. Моның өчен аны берәү дә гаепләмәде.

Шәйхетдин ник кайтмаган, нинди язмышлар аны кайларда йөрткән?

Авыл өчен бу озак вакытка табышмак булып калды. Сугыш вакытында тегене-моны ачыклау мөмкинлеге нык чикләнгән иде. Төрле фаразларга да урын житәрлек. Бәлки ул «аеруча мөһим задание үтәп», дошман тылында йөргәндер. Шәйхетдин бит ул, Әскәй малае бит ул! Хәтта үзе кайткач та, озак вакытка сер булып калды. Элек юктан да кызык таба белгән, башына төшкән бәласен дә мәзәккә әверелдерә алган җор телле Шәйхетдин хәзер, әйтерсең лә, телен кискәннәр, гадәттән тыш аз сүзлегә әверелгән. Бу хакта сораучыларга җавабы:

—Булды инде, сугыш бит,—диюдән артмады. Абыйсы Гамиргә генә бераз серен чишкән.

Аларның разведка взводы дошман тылында засадага эләккән булган. Атыш вакытында дошман пулясы күзенә тигән. Взводтан исән калган өч яралыны, шул исәптән Шәйхетдинне дә әсир алганнар. Лагерьдан лагерьга күчереп йөртә торгач, сугыш та бетеп куйган. Ике тапкыр качып караган, тотып тетмәсен теткәннәр. Үзебезнекеләргә эләккәч, фильтрация уздырганнар. Анысы тәмугтан да болайрак, ди. Үзебезнекеләр, үз кешеләребез кыйнап саңгыраулатканнар, сул кулының ике бармагын сындырганнар. Болары тыштан күренгәннәре, ә эчке әгъзаларының ниләр эшләп бәткәнен Ходай үзе генә беләдер. «Фашистлардан да уздырдылар»,—дип әйткән ди Шәйхетдин.

Болар Мөниржанга да килеп иреште. Үзен әсир төшермәгәненә менә шул чакта ул язмышына кабат-кабат шөкрана укыды.

«Бездә әсирләр юк, сатлыклар гына бар»,—Сталинның бу сүзләре фронтта киң таралган иде. Шуна күрә әсирлектә түгел, хәтта чолганышта берничә көн генә булучыларга да «сатлык», «хыянәтче» дигән кара ярлык тагылды.

Шәйхетдингә туган авылына кайтып озак яшәргә язмаган икән, абыйсы өендә ике айдан артык кан төкереп яткан иде, көннәрдән беркөнне Гамирга:

—Абый, авыр булса да, Фирдания (Фирзания түгел)белән улымны алып кил, күреп калыйм,—дип соңгы гозерен белдерде.

Алдан ниятләгән бөтен эшен ташлап, икенче көнне иртән иртүк Гамир бригадир Мәхиянгә ат сорарга китте. Тик Мәхиян аңа:

—Кайдан алыйм, үзең беләсең, атлар Ширәмәттә, урман кисүдә. Синең враг народа сатлык эненә түгел, колхоз эшенә дә житкерә алмыйм,—дип канына тоз гына салды. Чыннан да аты юк идеме, әллә сугыш елларында бозылырга өлгергән бригадирга бирәр нәрсә кыстырып килү кирәк булгандырмы, Гамирның ачыклап торырлык вакыты калмаган иде. Ул аты-юлы белән бер сүгенде дә җәяүләп кенә юлга кузгалды. Энесенең күзләрендәге соңгы шәмнең сүнеп барганын күрде ул, ошбу дөнья белән бәйләгән соңгы җепселнең менә-менә өзелергә торганын аңлады. Шуны аңлау камчылаганнан да артык каулады, аңа ашыгырга кирәк иде. Шуна күрә иллегә якынаеп килүче, гәүдәгә сабан туе батыры булган энесеннән дә мәһабәтрәк, йөрәге начар булган өчен генә сугышка алынмыйча, хезмәт армиясендә җиңүгә өлешен керткән Гамир, ат юлы белән барсаң озын дип, күрше авылга турыдан—Әпкәли сазлыгы аша гына китте. Ул ашыкты,

кабаланды, мышный-мышный йөгереп тә алды. Сазлыктагы кәҗә сукмагы аша узганда , түмгәктән түмгәккә сикергәндә, таеп китеп, ни сәбәпледер кышын да тунмый торган сазга батты. Ләкин үзен турында уйлый торган чакмы соң, ана ашыгырга кирәк иде. Ул, аунап-тәгәрәп дигәндәй, саздан чыкты, ничек итсә итте, Фирданияләргә барып житте.

Әлбәттә, бу вакытта Фирдания өйдә түгел, ындыр табагында ашлык сугуда иде. Фирданиянең хәзерге иренә Гамир хәлне анлатты. Рәхмәт төшкере изге бәндә икән, әллә үзе дә лаеш шулпасын күп чүмергәнме, бәрәү булса көнләшер, киселгән икмәк кире ябышмый, дияр иде, бу алай итмәде, хатыны артыннан шунда ук беренче хатыныннан туган ун-унике яшьлек малаен йөгертте.

Бераздан тыны-көне беткән Фирдания кайтып та житте. Ул ни булганын, ни өчен чакыртканнарын, әлбәттә, белми иде.

—Килен,—диде Гамир элеккеге гадәт белән, гәрчә Фирдания бу нәсел белән алыш-бирешен өзсә дә,—Шәйхетдин бик хәл эчендә, менә-менә өзелергә тора. Сине улын белән бергә алып килергә кушты, бәхилләшәсе килә торгандыр, бик көтеп калды. Зинһар, тизрәк барыйк. Кызганыч, ат жигеп килә алмадым, бригадир ат юк диде...

Фирдания бит хәзер кеше кешесе, ни әйтер икән дип иренә карады.

—Бар, бар, монын эше чакта озак уйларга ярамый, Искәндәрне дә ал, әтисен күреп калсын.

—Әйдә, килен, утырып бер дога кылыйк та Аллага тапшырып кузгалыйк.

Зурлар сәке читенә утырып дога кылды. Инде кузгалабыз дигәндә, Гамир йөрәгенең каты чәнчүен, хәле китүен сизде һәм:

—Килен, сез атлый торыгыз, мин бераз хәл алганнан сон кузгалырмын,— дип тора башлаган урынына кабат чүгәргә мәжбүр булды.

Ни эшләргә белмәгән Фирдания кабат иренә карады.

—Барыгыз, бар, атлый торыгыз, ул әле сезне куып житәр,—диде тегесе.

Фирдания белән Искәндәр артыннан ишектән пар бөркелеп калды. Гамир торырга тагын талпынып карады, тик аны аяклары тынламады.

—Су, су,—дип пышылдады ул, янган ireннәрен ялап.

Анын ни әйткәнен ишетүдән бигрәк күз карашыннан анлаган йорт хужасы, йөгереп диярлек чүмеч белән су алып килде. Гамир көч-хәл белән чүмечне авызына китерде, ләкин эчә алмады—бер якка янтаеп китте, кулындагы кырыйлары ашалып беткән бакыр чүмечнең башта суы түгелде, аннан сон ул үзе дә зенгелдәп идәнгә төште һәм бер почмакта тын гына яткан сарык бәрәннәрен куркытып, сикереп торырга мәжбүр итте. Гамирнын ирен читендә ак күбек күренде, ана инде су кирәк түгел иде...

Ни ашыксалар да, Фирдания белән Искәндәр дә сонга калды.

—Юлга чыктылар, киләләр, киләләр,—дип ярым уяу, ярым саташулы яткан Шәйхетдин, хатыны белән улы капкадан кергән чакта тартышып куйды да жан бирде.

Төштән сон күрше авылдан Гамирнын жансыз гәүдәсен дә Фирданиянен ире ат белән Әскәйгә китереп житкерде.

Озын төн буена әскәйлеләр белән бергә алар да мәрхүмнәрнен жәсәден, керфек тә какмый, саклап чыктылар. Иртәгәсен зиратта Әсма карчыкнын кабере янәшәсенә ике улынын да мәетен ләхеткә индерделәр. Фирданияләр бары тик шуннан сон гына авылларына кайтып китте.

Тормыш һичкайчан да ин карангы төсләрдән генә тормый. Йөзләгән татар Шәйхетдиннәр, урыс Иваннар, яһүд Моисейлар, башка милләтләрнен мен төрле исемдәге газиз балалары фани дөньядан мәнгелек йортына кучә

торса да, тормыш дәвам итә. Яшь-җилкенчәктә гыйшык-гыйшрәт уты кабына, кемнәрдер өйләнешә, улы-кызы туа. Рус-төрек сугышы вакытында да, беренче бөтендөнья сугышы вакытында да шулай булган. Ә кем әйтә борынгы ыруг җәмгыятендә шулай булмагандыр дип? Мәхәббәт ул, туганкаем, мәхәббәт, инде аның белән шаярмыйлар. Тарихка Бөек Ватан сугышы дип кергән, әле хәзер дә ул китергән корбаннар санын төгәл генә берәү дә әйтәлмәгән сугышта да шулай булды. Бу—диалектика. Киләчәктә дә тормыш шулай дәвам итәчәк.

Беркөнне Мөнирҗаннар саламнан кайтуга, терлекчеләр авызыннан:

—Кайталар!—дигән шатлыклы хәбәр ишетелде. Кем кайта, ник кайта, кайчан кайта—ул хакта берәү дә сорамый, чөнки бу ике икең дүрт шикелле үк һәркемгә мәгълүм, сүзнең Ширәмәткә җибәрелгән урман кисүчеләр хакында икәнен барысы да белә. Ширәмәткә урман кисәргә баруның Мәскәү янына окоп-траншея казырга барудан ким түгел икәнен дә белә халык. Шуңа күрә анда атларның, чаналарның гына түгел, авылдагы адәми затларның да яшьрәген, тазарагын, хәллерәген җибәрергә тырышалар. Китүчеләргә якыннары хәзинәдә барын кызганмый. Колхоз да хәлдән килгән кадәр тырыша—онын, итен дигәндәй җибәрә.

Ике айлар чамасы элек үткен пычкылар, кайралган балталар белән Ширәмәткә китүчеләр кайта бүген. Якыннары аларны ничекләр сагынып көтте!

Авыл иртә тора. Бу иртәдә исә халыкның күпчелеге таң әтәчләре кычкырганны да көтмәде. Аналар, хатыннар кичтән изеп куйган камырларын янартты, симезрәк,тәмлерәк ит кисәгеннән аш салып җибәрде; хәллерәкләре бәлешкә элек туралган итләрен җылытырга өйгә кертеп куйды—их, булса булсын, сугыштан да, Ширәмәттән дә көн дә кайтып тормыйлар. Исән-сау гына кайта күрсеннәр дә, еллар тыныч булсын, Ходай Тәгалә ипи белән сөтле чәйдән аермасын. Даһи Сталин аларны онытмас, кайгыртыр, шулай булгач, тормышлары озакламый рәтләнер.

Өч-дүрт, кайдадыр биш-алты йортка берләшеп мунчалар ягылды. Мунча ягар өчен кичтән үк җәйдән хәстәрләнгән тирес кирпече дә, салам, чыбык-чабык та ташып куелды. Менә хәзер шул кара мунчаларның авыл урамына җәелгән үзенчәлекле төтен исе борынны кытыклый, әллә нинди ләззәтле минутлар вәгъдә итеп, татлы уйларга сала, ымсындыра.

Мунчага ни генә якма, ул җылыначак, ташыннан пары чыкмаса да, мунча кирәк. Читтә йөреп арыган, керләнгән тәннәрен юар өчен генә түгел, ата-анасы алдында, бала-чагалары әти-әни дип аякка уралып торганда, бер-берсенә булган хисләрен тыярга мәҗбүр ир белән хатынга тагын кайдан аулак урын табасың? Мунчада күкрәгең белән юри ышкыла-ышкыла айдан артык күрмәгән газиз иреннең аркасын, сирәк йон белән капланган күкрәген ышкудан да тәмле, ләззәтле тагын ни бар? Эссе парга уралган мәтрүшкәле, карлыган ботаклары кыстырып бәйләгән себерке белән селтәнгәндә, сулышларга ут кабу ул бит кайнар булганнан гына түгел. Йөрәк яна, йөрәк! Тир, сабын, себерке исенең сөю хисен ничек арттырганын ирләрен айлар буена күрми тилмергән яшь хатыннардан сора.Йа, раббым, рәхмәтеңнән ташлама, исән-сау гына кайта күрсеннәр дә тыныч кына яшәргә язсын.

Ә урман кисүчеләр сагынмаган дисеңме?! Ничек кенә әле! Аларның кайберләре каршы алырга чыккан хатынын, күз кысып, печәнлеккә чакыру ягын карый. Чөнки белә: өйгә керсә, анда ата-анасы, бала-чагалары, туган-тумачасы бар. Ә колач җитмәс агачларны аударган чакларда да нечкә билләре, биленә тоташкан сөзәк арт саннары, берсе-берсе сынар учка гына сыеп бетмәгән, һәрвакыт ымсындырып торган ләззәтле кайнар күкрәкләре күзалдыннан китмәгән, төшләренә кереп йөдәткән хатыны менә хәзер

монда, анын каршысында, кул сузымы җирдә генә—тагын күпме күтәргә мөмкин!? Мондый форсатны ычкындырсаң, гөнаһасын кая куярсын?

Урман кисүчеләр авылны, якыннарын гына түгел, анын гореф-гадәтләрен, җыр-моннарын, биюләрен дә сагына. Шуңа күрә ул көнне айлар буена ачылып карамаган, морҗа суыклыгыннан өшәнгән чәүкә һәм күгәрченнәр җирдә кунакларга мәҗбүр булган клубның да миче ягыла, күнелләрендә бәйрәм кояшы йөрткән авыл кешесе сукыр лампа яктысында чын-чынлап бәйрәм ясый. Кешеләр, юк, бәйрәмсез тора алмый. Бәйрәмнәр үзенне кеше итеп тою өчен, кара кайгылардан, әче хәсрәтләрдән арынып тору өчен дә кирәк.

Әйткәнебезчә, тормыш үзе дә, язмыш та тоташ кара, карангы төсләрдән генә тормый, анын, уйлап карасан, истә калырлык күнелле мизгелләре күбрәк. Кемнәрдер өйләнешә, кемнендер баласы туа, яшь-җилкенчәктә гыйшык уты кабына—болар сон шатлык түгелмени!?

Бу—диалектика. Элек тә шулай булган, киләчәктә дә шулай дәвам итәчәк.

И авылның ул җырлы-биюле уеннары!

Гармунчы уйнап җибәрүгә, түгәрәккә басканнар җыр башлый:

Аклы ситса күлмәгеннен
Якаларын кем уйган?
Исемен матур, кемнәр куйган,
Сине күреп кем туйган.

Түгәрәктә әйләнүчеләр һәр куплет саен туктый, биеп ала, уен дәвам итә. Кешесенә карап җыры табылып тора.

Биек таунын башларында
Германия капкасы.
Син дә әллә кем түгел лә,
Гыйбадулла маңкасы.

Менә шулай була ул борыныңны бик күтәрсәң! Авыл тәрбиясе, авыл педагогикасы—монда тәлинкә тотып тормыйлар.

Урман кисүчеләр кайткан көн авыл хәтерендә: «Исендәме, сугыш беткән елда Ширәмәттән урман кисүчеләр кайткан көнне клубта...»—дип сонынннан сөйләр көн. Сагыш һәм мәхәббәт, кавышу, ачыргалану көне. Юк, көне генә түгел, төне дә...

Салкын төн. Бәхетлегә дә, бәхетсезгә дә бердәй ай елмая. Урман кисүчеләр кайту хөрмәтенә шулай тулды микән ул?!

Кич чыгуларны Мөнирҗан инде онытып бетерә язган иде. Бүген аны да аяклары клубка тартты. Бәлки Гайния дә чыгар. Ул бит сазаган кыз түгел, җиләк кебек яшь гомерен өйдә генә уздырмас, йөрәге мүкләнмәсә.

Сугыштан кайткач, Мөнирҗанның гармунын үзе өчен генә тарткалаганы бар иде. Дәрт иткәндә чулак кулның терсәге белән бас ягына басып та була икән, ә уң кулының бармаклары, гармун теленә тиюгә, биергә генә торалар. Әллә бүген, бер дан булсын, гармун белән чыгаргамы сон? Ә нигә чыкмаска ди?!

Гайниябану, сылуым, иркәм...

Ашыкма, Мөнирҗан, җырларга ярамый сина. «Галиябану» көе аша гармун үзе генә дә йөрәгең янууларын бар дөньяга анлатыр. Гайния дә ишетер, әгәр чукрак булмаса. Ишетсә, анлар.

Өмете акланмады Мөниржанның. Гайния, әйтерсең, чукрак, саңгырау иде, клубка чыгасы итмәде, кешеләрдән яшерен күз яшьләренә буыла-буыла капка артыннан гына Мөниржанның гармун тавышын тыңлады. Аның бүген бик тә яшьләр арасында буласы, гармун уйнаган Мөниржанның иңнәренә сыенып, авыл буйлап узасы килгән иде. Ләкин аның хакы юк. Ул Мөниржанга, аның мәхәббәтенә лаек түгел. Хәтта күңелендәге серен, әрнү-януларын иң якын дус кызы белән дә бүлешә алмый. Тукта, гармун тавышы бөтенләй якынайды ич. Аңа ышансаң, йә килеп керер. Мөниржан башкисәр бит ул. Бу уйдан Гайния сискәнеп китте һәм, җанын урталайга бүлеп, абзар ышыгына ашыкты. Ә бәлки юкка качадыр? Кайтканына күпме вакыт узды, Мөниржанның кем белән дә булса йөргәне ишетелгәне юк. Чуар йөрәк булса, аты чыкмый калмас иде. Авыл хәтере нәкъ тишек иләк инде: бер-бер хәбәр эләктеме, дөньяга сибелә, җыеп ал аннары!

Әллә соң, тиз генә җыенып, чыгаргамы шул клубка? Гомер буе бер авылда яшәп, Мөниржаннан барыбер кача алмассың. Ул хәтта җыена да башлаган иде, ләкин тагын район үзәгендәге колхоз фатирында Мисбах белән булган вакыйга исенә төште дә (хәер, аның онытылганы да юк), җен ачулары кузгалды. Бигрәк җиңел акыллы булып чыктың шул син, кызый, гыйффәтеңне саклый алмадың. Югыйсә, авылда гына түгел, бөтен дөньясында Мөниржан белән Гайниядән дә бәхетле парны эзләп таба алмас иделәр.

Җырламаска үз-үзенә сүз биргән егет, капка төбенә җиткәч, яраткан көен ничек сузып җибәргәнен сизми дә калды:

Урам аша чыккан чакта,
Бүрәнәгә абындым.
Минуты ай, сәгате ел,
Гайниябану, сылуым-иркәм,
Шулкадәрле сагындым.

Җыр белән Мөниржанга җавап кайтармас өчен кызга никадәр ихтыяр көче кирәк булганын бер Ходай гына белә дә, Гайния генә белә. Бер ярты ел алдан кайтсаң да, Гайния бөтен көенә синеке иде бит, Мөнир!

Мөниржанның гармуны ыңгырашты, үксеп елады, иңрәве белән авылның тынычлыгын алды һәм, өметен бер өзеп, бер кабат кабызып, Гайнияләр өеннән ераклаша барды. Мөниржаннан абзар күләгәсенә качкан Гайниянең күз яшеннән аяк астында боз хасил булды. Клубка барырга ниятләп, ул кабат кузгалды, тагын капка төбеннән кире борылырлык көч тапты.

Мөниржан клубка килеп кергәндә, уенның нәкъ кызган чагы иде. Алар фронтка киткәч үсеп, егет булып җитлеккән бүлтерекләрнең берсе—Рәсим тирләп-пешеп тальян тарта, халык «Чупләмле» уйнау белән мәшгуль иде. Шыпырт кына кергән Мөниржан арттагы буш урыннарның берсенә утырды да күз йөртергә генә өлгереп калды—аны шунда ук күреп алдылар.

Кызларның:

—Ай, Мөниржан абый чыккан!—дип әйтүе булды, Рәсим шып туктады һәм:

—Булды, кызлар, үтерәсез, Мөниржан абыйны уйнатыгыз,—дип, тирләгән маңгаен уч төбе белән сөртеп алды.

Мөниржан аңына килгәнче берничә кыз аны култыклап түргә алып килеп утыртты. Җитмәсә, председатель Хәсьянов белән аты чыккан Сәлимә аның колагына:

—Мөниржан абый, бүген син минеке!—дип пышылдарга да өлгерде.

Кызлар шаяртып ни сөйләмәс, Мөниржан Сәлимәнең сүзләренә игътибар итмәде, шашып-шашып уйнавын белде. Йөрәгенең януы

басылсын ичмасам! Гармун телләрен бармаклары сагынса, күнеле белән ул үз авылларындагы менә шушы уенны, чабаталы кызларның тыпыр-тыпыр биюләрен сагынган.

Уйнап арыгач, гармунын калдырып, маңгай тирен исән кулының җиңе белән сөртә-сөртә, ул ишеккә юнәлде. Кечкенә уен кабат Рәсим кулына күчте.

Ишеккә җитәрәк берәү Мөнирҗанның җилкәсенә кулын салды:

—Замандаш, нихәл!

Тавышыннан таныган сыман булса да, шикләнеп, борылып карады Мөнирҗан һәм үз күзләренә үзе ышанмады: алдында анардан ике класс алдан укыган һәм ут эченә дә нәкъ ике ел алданрак ыргытылган Хаммат Сабирҗанов тора иде.

—Хаммат, син...

—Мин, Мөнирҗан, мин. Әллә ышанмыйсыңмы?

—Хәбәрең юк дигәннәр иде ич...

—Хәбәр биреп кем дә йөри. Мин болай гына кайттым.

—Кайтуың белән котлыйм. Кайчан кайттың?

—Бүген. Әле күптән түгел. Энгер-менгер төшәргә тора иде. Өйгә кагылдым, өй бикле. Әнкәйнең үлгәнен син ишеткәнсеңдер. Ә мин белмәдем. Сеңелне каядыр озатканнар. Үзең беләсең, авылда башка туган юк.—Хамматның тавышы калтырап куйды.—Их, сугышта үлеп калган булсамчы! Газраил белән очрашкалаган идек югыйсә...

Бу хис Мөнирҗанга таныш түгелме? Әллә ул әз өзгәләндеме?

—Ашыкма, Хаммат, барысы да җайланыр. Үзең беләсең, үлгән артыннан үлеп булмый.

—Анысын бик аңлыйм да бит. Тик йөрәк барыбер яна. Минем беркемем дә калмады хәзер авылда. Киткәнче кызлар белән дә йөрмәгән идем, ичмасам, бу кадәр үкенечле булмас иде!..

—Соң түгел әле.

—Үзең замандаш, үзең фронтовик, синнән яшермим: шушы көнгә кадәр кызларның бит очларын да үбеп караганым юк. Бер сүз белән әйткәндә, ул мәсьәләдә бозау мин!

—Мин дә!

—Мөнирҗан, дустым бул, авылга кайту хөрмәтенә дип Бөгелмәдә куенга кыстырган чәкүшкә бар. Кабыйк шуны урталай бүлеп.

—Ярар соң. Тик ничек? Кружка да юк.

Хаммат көлеп җибәрде:

—Их син, танкист! Бигрәк сабый бала икәнсең. Сугышта үтерергә генә өйрәттеләрмени соң сине?! Чәкүшкә генә бит ул: син бераз голт-голт, мин бераз голт-голт—бетте-китте.

Баскычка чыгып, алар ниятләрен тормышка ашырганда берәү дә комачаулык итмәде. Барысы да клубтагы уенны тансыклаган иде. Мөнирҗанның өенә кайтканнан бирле аракы эчкәне юк иде, башына чәкүшкәнең яртысы да китереп сукты.

Сугыш кешеләрнең психологиясенә шулкадәр нык кереп оялый, теләсәләр-теләмәсәләр дә анда катнашучыларда хатирәләр янара. Сөйләшә торгач беленде: Хаммат та кырык дүртенче ел азагында яраланып, Мәскәүдә бер ай чамасы госпитальдә ятып чыккан, ә сугышуын Мөнирҗаннарныкына күрше армия составында сугышкан икән.

Хатирәләр кызып җиткәндә генә, клубтан халык тарала башлады. Мөнирҗан:

—Син көтеп тор, мин хәзер,—дип клубка керде. Гармунын монда калдырырга һич ярамый, алып чыгарга кирәк иде.

Ләкин чыгып баручы халык төркемен һич кенә дә ерып үтәрлек түгел

иде, көтмичә чарасы калмады. Тик аңа эчкә үк узып торырга туры килмәде—гармунын әлеге дә баягы Сәлимә алып чыкты. Чая кыз, чытлыкланып:

—Мөниржан абый, менә гармунын, бер үпмәсәң бирмим!—диде.

Аракы пары, хатын-кыз тәненең исе Мөниржанның күңелен иләсмиләсли, житмәсә клубка да чыкмаган, анардан качып йөргән Гайниягә үпкә, үч тойгысы егет күңелен котырта иде.

—Синдәй сылуны үбү генә түгел, кулыма күтәреп, Жир шарын әйләнергә дә риза!

Азагының ни белән бетәсен уйламыйча, ул гармун тоткан кызны күтәреп алды да, күкрәгенә кысып ике-өч тапкыр әйләндерде. Уйнап кына кысты югыйсә, ләкин Сәлимә аның колагына пышылдап өлгерде:

—Бүген бездә аулак өй, кешеләр таралгач, Хаммат абый белән килеп житегез, яме, көтәбез!

Бу сүзләрнең мәгънәсен Мөниржан аңлады да, аңламады да. Шулай да Хамматка әйтми булдыра алмады. Әнисез калган йортка кайтканнан соң беренче төнне ничек уздырырга белми торган Хаммат өчен аулак өйдән дә зуррак бәхетне тагын кайдан табасың.

Алар егет булып житкәндә, Сәлимә әле бала гына иде, аның кайда яшәгәнен белер өчен ата-анасының кем икәнлеген искә төшерү кирәк булды. Уртак тырышлык белән анысы да тәгаенләнде. Сәлимәләргә үзе генә булса барыр иде микән Мөниржан? Хаммат белән булгач, икеләнеп тормады, бергәләп аулак өйгә юл тоттылар. Салган баштан Гайнияне сүкте:

—Чукынсын сана бу Хәниф кызы! Борынын алай бик күтәрә икән, үзенә үпкәләсен!

Әтәчләнеп сөйләнсә дә, моның бик үк килешеп бетмәгән гамәл икәнен аңлый иде ул, шуңа күрә үзен акларлык сәбәп эзләде: Сәлимә аның гармунын алып киткән икән ич!

Сәлимәләрнең капка төбенә килеп житкәч, моңа кадәр батыр кыланган егетләрнең күңеленә шик үрләде: бәлки кызлар шаярткан гынадыр? Бер катлы авыл мокытларыннан көләргә генә уйлагандыр?

Капканы этеп карадылар—ачык. Ә ишек ничек икән?

Ишеккә барганчы, башта тәрәзәдән күз салдылар. Ләкин пәрдә аша берни күренми. Мөниржанның күңеленә шик төште:

—Хаммат, әллә кереп тормыйбызмы?

—Юк инде, замандаш. Бу аулак өй миңа фәрештәләр бүләге. Сине белмим, әмма үземнең дүрт елга якын аулак өйдә булганым юк. Ничек сагынганымны сүз белән генә аңлатырлык түгел. Боргаланып маташма житлекмәгән кыз сыман!

Хаммат ишеккә китте:

—Тук, тук, тук!

Өй эчендәге ут кысыла төште. Өйалдына аяк тавышы якынайды. Сәлимәнең янгыравыклы тавышы ишетелде:

—Кем бар анда?

Хаммат Мөниржанның кабыргасына төртте: жавап бир.

—Без идек әле бу, Сәлимә.

Чая кыз чытлыкланып:

—Ә кем соң ул без?—дип сорады.

—Соң без инде. Кергәч күрерсең.

Өйгә кергәч, Сәлимә янәшәсендә Мөршидәне күреп, Мөниржанның йөрәге табан астына төшеп киткәндәй булды—Мөршидә бит ул Әскәйнең атаклы уйнашчысы.

—Сәлимә, минем гармун синдә бугай, шуны алырга кергән идем.

—Алырсың, алырсың, Мөниржан абый. Тик аштан олы түгелдерсез,

бәлеш ашатмыйча җибәрмим.—Сәлимәнең тавышы каршы килергә урын калдырмады.

Хамматның шатлыгы тышка бәреп чыкты:

—И кызлар,—диде ул чын күңелдән,—немецлар, японнар белән сугышып, ниләр генә ашарга туры килмәде. Дуңгызны әйткән дә юк, елан ите, эт ите дә ашалгандыр, анда бик сайланып тора алмыйсың, ә менә үзебезнең кабак бәлеше белән сыйлаучы табылмады. Мин кайтасын кайдан белеп пешергәнсездер, рәхмәт сезгә!—Хаммат шул минутта мәҗлесне үз кулына алды.—Кызлар, менә бусы безнең күчтәнәч. Кызганыч, сезнең кебек чибәркәйләр белән кич утырасын алдан белмәдек, зуррак күчтәнәч тә алып килгән булыр идек.

Мөниржанны шаккатырып, Хаммат куен кесәсеннән тагын бер чәкүшкә чыгарды һәм бәлеш янәшәсенә утыртты.

Хамматның исән-сау кайтуына бу шешәне дүрткә бүлеп эчтеләр. Кызлар эчмәс, кыстатырлар дип уйлаган Мөниржанның күзе дүрт булды. Ул ялгышты—Сәлимә дә, Мөршидә дә үз өлешләрен бер генә капладылар. Бәлешне бераз ашауга, Мөниржан күрми дә калды, чирекле шешә белән әче бал пәйда булды. Сәлимә кычкырып көлде. Ул исерә төшкән иде. Ихтимал, егетләр килгәнче алар Мөршидә белән әче балны тәмләп караган булганнардыр.

—Инде, егетләр, безнең эчемлекне авыз итегез!—Мөршидә балны стаканнарга тутырып салды. Бал әче, куәтле иде.

—Мөниржан абый, уйна әле, синең кебек уйнаучылар дөньяда бармак белән генә санарлык. Син уйнасаң, җырлыйсы гына килеп тора.—Сәлимәнең тавышы көтмәгәндә сагышланып калды һәм ул, уйный башлаганны да көтмичә, ярыйсы ук моңлы тавышы белән җырлап җибәрде.

Иртән торып тышка чыксам,
Өзелә бәгырьләрем.
Яшь гомерләр ике килми,
Белегез кадерләрен.

Уналтысын гына тутырган бу яшь, сылу кызда кайдан килеп шундый сагыш, шундый моң? Үзәкләргә үтә, бәгырьне эретә бит.

Мөниржан хәзер тулысы белән табын иркенә бирелде. Җанын бер үк вакытта көйдереп тә, җылытып та торган Гайния дә, аңа карата булган үпкә дә онытылды. Миллиардлаган кеше яшәгән Җир шарындагы караңгы бер татар авылының сукыр лампа янган кечкенә генә дүртпочмаклы өендә дүрт кешедән торган дәүләт, иртәгәге көн турында уйламыйча, хәзинәдә бары белән ашау-эчүне дәвам итте. Аларның һәрберсе үзенчә бәхетле иде. Хаммат, ниһаять, ут, мәхшәр эченнән исән-сау кайтуы, кайткан көнне үк аулак өйгә кызлар янына эләгүе белән бәхетле; Мөниржан исә бер генә көнгә, дөресрәге төнгә, Гайния турындагы борчулы уйлардан арынды. Ә Сәлимәнең яшәү кагыйдәләре бер көнлек, бер сәгатьлек кенә иде: җырда әйтелгәнчә, яшь гомерләрнең кадерен белергә кирәк, иртәгәсе өчен ишәк кайгырсын. Хатынлы ирләргә исәп тоту кыен, ә монда фронттан исән кайта алган сөлек кебек егетләр кочакка керәм дип тора. Сәлимә бигрәк тә куана бүген: теге, Хәсьянов, ишәк, сырлана башлады. Исе китте ди Сәлимәнең. Мөниржанның кайсы җире ким? Менә дигән егет, өстәвенә, гармунчы да әле. Бер кулы юк икән—баш бәласе түгел. Хәсьянов белән типтергәндә туплаган барлы-юклы тәҗрибәсе кызга шундый нәтиҗәгә килергә мөмкинлек бирде: хатын-кызга ир-атның кулы түгел, бүтән җире кирәгрәк икән. Хәсьяновның хатыны бар, ул барыбер Сәлимәгә өйләнмәячәк, ә Мөниржан егет кеше, Ходай кушып, чәчләре чәчкә бәйләнеп куймасмы...

Бик сайланыр, сырланыр чак түгел.

Җырлашып бераз утыргач, башта Мөршидә белән Хаммат әчке якка кереп китте, Сәлимә дә сукыр лампаны өреп сүндерде һәм Мөниржанның иреннәренә килеп сарылды. Мона кадәр Гайния өчен үзен саклаган егет Сәлимә кочагына ничек итеп инә барганын сизми дә калды.

Егетләр өйләренә яктыра башлагач кына кайтып киттеләр. Мөниржан сыер саварга чыгып баручы әнисе күзенә чалынмаска тырышып, ул лапаска кереп киткәч кенә өйгә чумды. Анын үтереп башы авырта, күнеле болгана. Ул инде ник баруына, куна калуына үкенә, аңа хәзер оят. Әтисеннән, әнисеннән, Гайниядән, тагын әллә кемнәрдән оят. Шул ук вакытта йөрәгенең кайсыдыр почмагында: «Булдырдың, сынатмадың»,—дигән бер хис тантана итә иде.

Урман кисүчеләр авылга кайтып, бәйрәм ясасалар да, Ширәмәттә әле эш бетмәгән иде. Көрешү шатлыгыннан кешеләр айнырга да өлгерә алмады, колхоз идарәсе тагын «удар бригада» җибәрү хәстәренә кереште.

Җәһәннәмгә тиң газапка китәргә берәү дә ашкынып-ясканып тормый иде шул. Элек барып, андагы шулпаны эчеп караганнар—бигрәк тә. Аларның күбесе, барын-югын сәбәп итеп, чәнечкесен сәнәк итеп, сыныкка сылтау булса да табарга тырышты. Ләкин житкерелгән планны читтән килеп кемдер үтәмәячәге дә көн кебек ачык. Шуңа күрә, хокуклары крепостной крестьяннарныкы дәрәҗәсенә төшерелгән Совет халкы белән сугыштан соңгы дәүләт күп сөйләшеп вакланмады, Хәсьянов кыздыра торды, бригадирлар исемлеккә “корбан тәкәләрен” яза торды. Ә инде исемлек идарә утырышында расланган икән, ике уйларга урын юк: бетте-китте, барасың и баста!

Ярар, дип ыңгыраашты халык, урман урман булыр әле, төрмәдә кандала туйдыру түгел. Алар мәҗбүри эштән качуның ничек тәмамланасын белмиләрме... Авылның авызы аз пешмәде гражданнар сугышыннан соң.

Исемлеккә үзенең дә кертелүен белгәч, Мөниржан башта унайсызланып калды: бер кулы белән эш майтара алырмы? Аннан чулак кулын, тикшереп карарга теләгәндәй, селкеп куйды: салам ташырга өйрәнде бит әле, урманда да сынатмас. Ул бит эштән, авырлыктан курыкмый, кеше алдында көлкегә калудан шүрли. Ә болай караганда ул япа-ялгызы—кайберәүләрнеке шикелле елап калыр хатыны, артыннан йөгерер баласы юк. Өйдәгеләр түзәр әле. Ичмаса, шул Хәниф кызы турындагы әрсез уйлардан котылып торыр.

Салам ташудан гарык булган кешегә, бер яктан караганда, бу тәкъдим хәтта кызыктыргыч та иде. Беренчедән, ул бу кышта кибәге күзгә кереп, трахомага житкерә торган салам ташудан котылып тора, икенчедән, хезмәт көне дә ат белән салам ташуга караганда арурак язылачак. Дөрес, ул хезмәт көненә кайчан нәрсә алачагыңны белгән юк, шулай да ала каргадан алачагың булуын белү рәхәтлек бирә. Өстәвенә, дөнья күреп кайтасың.

Иртәгә китәбез дигән көнне тагын мунчалар ягылды, тагын урамга таралган икмәк, ит, бәлеш исе борынны кытыклады. Дөрес, урман кисү сугыш түгел, анда бомба шартламый, снаряд төшеп ярылмый, әллә кайдагы снайперның үткен күзле пулясы сагалап тормый. Өстенә ажгырып дошман танклары килми. Ләкин кышын урман кисүне уенга да санап булмый. Анда бит бот төбеннән бата-чума, ауный-тәгәри дигәндәй, кисәсе агачың янына барып аударып кына калмыйсың. Ширәмәткә бару турында ишетүгә үк, башын икенче якка боручылар житәрлек Әскәй авылында. Хәер, Әскәйдә генә микән?

Мөниржан Хамматны да җибәрерләр, иптәш булыр дип уйлаган иде. Сәлимәләрдә кич утырганнан соң, аларның, тагын берничә тапкыр очрашып, ярты төнгә хәтле юкны-барны сөйләшеп вакыт уздырганы булды. Ләкин,

Мөниржаннан аермалы буларак, Хамматның колхозга койрыгы ябышып катарга өлгермәгән, аның ниятләре икенчерәк булып чыкты:

—Беләсенме, Мөнир дус,—диде ул бу хакта сүз чыккач,—минем бит солдаттан алып кайткан запас бетте. Әнкәй мәрхүмә дә, бердәнбер малаена чуртымны да калдырмыйча, ни сәбәпледер, оҗмахка керергә ашыккан.—Аның тавышында ачыктан-ачык мыскыллы көлү яңгырады.—Хәсьяновка аванс сорап барган идем, тыңлап та тормады, куып чыгарды. Үзең беләсең, әнкәй юк, туганнар юк, туып-үскән йорт төртсәң аварга тора. Шулай булгач, мин ни пычагыма дип авызын ачса үпкәсе күренеп торган, тире белән сөяккә калган, бетләп, корчангыланып беткән колхозны саклап ятарга, аны муеныма атландырырга тиеш әле?! Шуның өчен сугыштыкмыни?!—Хаммат бу сүзләрне шундый ачыргалану белән әйтте ки, Мөниржан дустының йөрәгендә янартаулар кайнавын аңлады. Ул инде бу хакта сүз башлаганына үкенә дә башлаган иде.—Аннан соң минем колхозда калуымнан гына чуртым да үзгәрмәячәк.

—Ә Мөршидә?—дип шаярткан булды киеренкелекне йомшартырга теләгән Мөниржан.—Ул Хамматның Мөршидә белән тагын да очрашкалавын белә иде.

—Мөршидән үзенә булсын!—Хаммат елмаеп җибәрде.—Ай, оста ул, малай, кочагына эләксәң, ереп агасың. Башың кайда да, аягың кайда—онытыла. Белмим, Сәлимә ничектер, ә Мөршидә—искиткеч! Төшләргә керәчәк әле ул минем.

—Алып кит алайса үзең белән!

—Кая? Юк инде, дус, өйләнсәм, унсигез-унтугыз яшьлек гыйффәтле кызга өйләнәм мин. Мөршидә ул авылда кирәк, аны читкә җибәрергә ярамый. Югыйсә синең белән минем ише уҗым бозауларын ир булырга кем өйрәтер!—Хаммат рәхәтләнеп көлеп җибәрде.—Ну, малай, сугышка кадәр Мөршидә ише берәрсенә эләккән булсаммы! Күпме немка, япун кызларын, полячкаларны бәхетле иткән булыр идем! Аяк астында гына күпме иде алар. Юк шул, башкалар гыйшык уйнаганда, без шырпы сызып тордык. Карале, Мөнир, син ничек уйлыйсың, берәрсендә озату кичәсе ясасаң, начар булмас иде, малай, ә? Сәлимә сагынып үлә язгандыр инде үзеңне...

Мөниржан колак яфракларының кызышуын, чәч төпләреннән тирләп чыгуын тойды. Бүреген салса, валлаһи, башыннан пар күтәрелер иде. Ник алай ояладыр, югыйсә бала-чага түгел, кайчан да булса ир-ат белән хатын-кыз арасында була торган якынлыкны ул бер кылырга тиеш иде ләбаса! Ләкин шәригать кануннары буенча ул кеше синең хәләлең, ягъни никахлы җәмәгатең булырга тиеш. Очраклы берәү белән мондый бәйләнешкә керү зина дип атала ул, туганкаем, зур гөнаһ санала. Кешегә ишетелсә, оятыңнан җир тишегенә керерсең...

Теге көннән соң Сәлимә аның саламнан кайтканын гел сагалап кына тора, төрле сәбәпләр тапкан булып, тирәсендә буталу җаен карый. Бер карасаң, сабый бала кебек, бер карасаң... Аңламассың тагын. Аның Хәсьянов белән чытлыклануын күрсә, Мөниржанның кытыгы килә, ни эшләргә белми, йөрәген берьюлы йөз мең корт кимерергә керешә. Көнләшү дигән нәрсә әллә соң шулмы икән?..

Кызык бу адәм баласы. Мөниржан Сәлимәне яратмаганын да белеп тора. Ә күңелендә көнчелек бар. Бер генә кич янында кунып чыгуына карамастан, анысы да алдан ниятләп түгел, очраклы рәвештә, көтмәгәндә генә. Җырда ничек әле: «Үзем сөймим, ятка бирмим»,—диләрме? Мөниржанның Сәлимәгә мөнәсәбәте дә шулмы? Шәхси милекчелек хисе синдә бигрәк көчле икән, иптәш! Харап икән, председательдән калган кыз белән бер кич кунган икән! Әйе шул, ул гап-гади Сәлимә түгел, председатель Хәсьянов сөяркәсе. Пәри, җен затыннандыр ул Сәлимә дигән мөртәт! Аның белән

йоклаганга үкенүләре, оялу-кызарулары барысы да ялган микәнни? Башкача булганда, көнләшер идеме? Кочагы кайнар, иреннәре татлы, «Мөниржан абыкаем!» дигән сүзләре сулышыңны өтәрлек иде шул, каһәрнен. Юк-юк, Хаммат ничекләр генә мактамасын, Мөршидә Сәлимәгә җитми торгандыр. Сугыштан исән-сау кайтып та, ләззәтнең мондые барлыгын башына да китереп карамаган мәми авыз Мөниржанга җитә калды. Аның кебек мокытны түгел, Хәсьянов кебек азау ярган мир үгезен дә үзенә каратырдай булгач, бер-бер тылсымы бардыр ул дәртлекәйнен! Хаммат әнә ничә ирдән кайткан Мөршидә турында сөйләгәндә дә селәгәен җыя алмый.

Шулай да Мөниржан үзен ни өчендер Сәлимә каршысында гаепле санады. Югыйсә көчләп буйсындырмады, әрсезләнмәде, киресенчә, дәртен тыялмаган кыз, рәхмәт төшкере, аның куенына кереп, Мөниржанны, Такташ әйтмешли, үзе «көчләде». Уналтысын тутырып күптән түгел унҗидегә чыккан яшь кенә кыз бит әле, ничек шулкадәр иртә оҗмах алмасын авыз итәргә өлгергән. Бу эштә әлифне таяк дип тә белмәгән егеткә бер дә аптырап, югалып калырга ирек бирмәде. Сәлимә яшьтәшләренең кайберсе әле ирләр астына керү түгел, клубка да чыкмый торганнардыр. Сәбәбе нидә? Сугышка кадәр авылда азгынрак ир-атлар «ужымга» баргалый торган бер-ике генә хатын була, ул хатыннар янына да кешегә сиздерми генә йөрергә тырышалар иде. Алары да ире үлгән яки аерылышкан хатыннар иде. Ә Сәлимә... Их син, сугыш, син кешеләрне орыш кырында гына үтереп калмадың, тылда да татарның әхлаклы тормышын пыран-заран китердең! Моның өчен кемне гаепләргә, кемне җәзага тартырга? Яшьлекләре сугыш чорына эләкмәсә, Сәлимә, Мөршидәнең тормышы бүтән юл белән китмәс идеме?

Уйларын Хаммат бүлдерде:

—Сәлимә исемен ишетүгә уйга калдың?

—Әй, башымны катырма әле шул кычыткан чыпчыгы белән! Бик кирәк икән, үзенә булсын!—Мөниржанның бу хакта сөйләшәсе килми иде, сүзне икенчегә борды.—Менә син колхоздан китәм дисең, кая бармакчы буласың? Агыйделнең аръягында бер энәгә бер сыер биргәннәре турында ишеткән бар. Сине кайда көтеп торалар? Кемгә кирәк син?

—Баулы тирәсенә китсәм дим...

—Үкенмәссеңме соң?

—Үкенер өчен үкенерлек гамәл кыларга кирәк бит әле башта. Баулыда нефть чыгаралар. Сугыш, беләсең, ирләр сафын нык иләде. Эшчеләр җитми ди. Бәлки син дә ниятләрсең? Бергә-бергә күңеллерәк булыр иде. Тора-бара фатир да бирәселәр икән.

Мөниржан өчен көтелмәгән тәкъдим иде бу, аптырап калды.

—Юк, Хаммат дус, минем кебек чулак белән нифтедә ни эшләсеннәр. Аннан соң әти-әни дә картайды, бар ышанычлары миндә.

Аны авылга бәйләп куйган төп сәбәпнең Гайния икәнен Хамматка әйтүне ул кирәк санамады. Бер бетмәгән баш авыртуы булды шул Хәниф кызы, миһербансыз!

Авыл сагындыра, әти-әнисе, туганнары, дуслары. Җаныңның җиденче тамырына кереп оялаган Гайния турында әйткән дә юк. «Сынар кул белән әллә авылга кайтып та тормаскамы?»—дигән уй ничә тапкыр килде башына һәм үзе үк бу уйны юкка чыгара торды. Ничек инде туып-үскән авылына кайтмый калырга мөмкин? Моның өчен таш бәгырьле булырга кирәк. Ул, әлбәттә, кайтачак. Әгәр Гайния читкә какса, ул чагында күз күрер.

Хаммат үпкәләсә үпкәләгәндер, икенче көнне ерак сәфәргә кузгаласын сылтау итеп, Мөниржан аның тәкъдимен кире какты. Өзәргә булгач өзәргә ул Сәлимә атлы кычыткан чыпчыгы белән араны!

Иртән урманчылар карангылы-яктылыда идарә янына җыйналды.

Китәсе кешеләрнең исемлеге белән кызыксынмаган иде, урманга баручылар арасында балачак дусты Фазыл һәм Гайния белән Сәлимәне дә күреп, аның күзе мангаена менде. Ярый, Гайния белән Сәлимәнең баруын әле аңларга була, ә менә Фазыл кайдан килеп чыккан? Ул бит төрмәдә иде, кайчан кайтты икән? Кайтканын ничек Мөниржан белми калган?

Китүчеләргә Хәсьянов хәер-фатихасын бирде:

—Кадерле иптәшләр,—дип башлады ул сүзен,—безнең каһарман урман кисүчеләребез—сезнең, ягъни безнең авылдашларыбыз, Ширәмәттә урман кисүдә зур уңышларга ирештеләр. Ләкин алар даһи Сталин куйган заданиенең яртысын гына үтәделәр. Арагызда сугышта булган кешеләр дә бар, куелган бурычны үтәмәүнең нәрсәгә китергәнен беләсез. Сезгә урман кисү һәм ташуны азагына кадәр җиткерү бурычы йөкләнә. Моны партия куйган зур бурыч дип кабул итегез.

Хәсьянов киткәч, Мөниржан ул киткән якка карап тел шартлатып куйды. Мондый шомалык белән бу кеше утта янмас, суда батмас. Әнә бит ничек: партия исеменнән генә сиптерә! Муеныннан тиклем батырсаң да, суда аягын чылатмас.

Фазылга сугышта озак булырга, Әскәйдә чакта үзе хыялланган каһарманлыклар күрсәтергә язмаган икән. Аның иң зур теләге кавалерист булу, сөлектәй акбүз атка атланып, дошман тылына бару, фашистларны кылыч белән унлы-суллы тураклау иде. И-и беркатлы авыл малае, мокыт! Гражданнар сугышы күптән узды, маршал Семен Буденный кавалериянең ролен никадәр генә купайтырга тырышмасын, җиңү язмышын ат һәм кылыч түгел, бәлки танклар, самолетлар, "катюшалар" хәл кыла иде. Моны аңлаган булса, Фазыл кавалериягә эләгү турындагы хыялларыннан шунда ук ваз кичәр иде.

Язмыштыр: алгы сызыкка барып җиткәнче үк, аларның эшелонын дошман самолетлары эзәрлекли башлады. Безнекеләр килеп, фашист козгыннарын куып җибәргәнче, бомбаларны житәрлек яудырырга өлгерделәр. Берсе Фазыллар утырган вагонның күршесенә генә төште. Ирен читләрендәге сөтләре дә кибеп өлгермәгән, сугышка барып кына житим, фашистларның арт сабагын укытам, дип хыялланган япь-яшь малайларның өч дистәдән артыгы, дошманга төбәп бер тапкыр атарга өлгермичә, фани дөньядан мәңгелеккә күчте. Ихтимал, аларның әти-әниләренә «сезнең улыгыз батырларча һәлак булды» дигән формаль хатлар киткәндер. Бәлки китеп тә өлгермәгәндер: әнә ич хәбәрсез югалганнар, шәһәрне инде әйткән дә юк, авыл саен никадәр.

Фазылның әҗәле житмәгән икән—исән калды. Моны, йә, могҗиза дими ни дисең. Тәкъдирендә шулай язылгандыр, күрәсең. Югыйсә ул бомба ун-унбиш метрлар гына алгарак төшсә, Фазыллар вагонының нәкъ уртасына туры килеп, көлен күккә очырасы иде.

Ирекле булып язылып, алгы сызыкка омтылган егетнең өмете авылга күкрәк тулы орден-медальләр белән кайту иде, айга якын гына сугышып калды. Хәтта дары исен дә туйганчы иснәргә өлгермәде. Хәер, дары хушбуй түгел, аны кемнең иснисе килсен, иснәп кем хозурлансын. Чираттагы һөҗүм вакытында яраланып, госпитальгә эләкте. Сул кулын мина ярчыклары теткәләп бетергән иде. Фәрештәләр аны бу юлы да саклады—кыр госпиталендә беренче ярдәмне күрсәтүгә, поездга утыртып, Фазылны тылга озаттылар. Утырып киткән чакта егет туган авылыннан нибарысы кырык биш-илле чакырымнар ераклыктагы Бөгелмә стансасы аша узасын да, Чиләбе шәһәрендәге госпитальнең йөзләгән ярлысы арасында бер тары бөртеге буласын да белми калды. Начальниклар, ни өчендер, яралылардан маршрутны яшерделәр. Югыйсә Фазыл авылны, туганнарын нык сагынган

һәм аларга хәбәр салмый калмас иде. Ә хәбәрне алганнан соң кем дә булса күрешергә барыбер килер иде.

Госпитальгә барып житкәч, шактый вакыт Фазылны операциягә әзерләделәр. Ниһаять, күп эшләүдән күзләре эчкә баткан яһүд табибы Семен Моисеевич Зильберман аны операция өстәленә яткырды. Фазыл табибның гаять кин уч төбенә һәм берсе-берсе шешә юанлыгы бармакларына игътибар итте. Башына, моңа врач булып түгел, урман кисүче булып эшләргә кирәк, дигән уй килде. Шулкадәр юан бармакларның скальпель тота алуы гаҗәп иде.

Ләкин Семен Моисеевич тылсымчы кебек эш итте: тимер ярчыкларны чүпләде, чәрдәкләнгән сөякләрне тәртипкә китереп җыйды. Кулы терсәктән өстә бераз кәкрәебрәк калса да һәм берничә ярчык алынып бетмәсә дә, иң мөһиме, аны кисеп ыргытмадылар. Менә хәзер, авыррак эш эшли башласа, йә һава үзгәрергә булса, иң әүвәл әнә шул тимер кисәкләре хәбәр бирергә тотына.

Госпитальдән ул, хәрби хезмәткә яраксызга чыгарылып, 1944 елның маенда өенә кайтты. Әскәйдә яшьтәш егетләреннән бары тик Мөнирҗан белән икесе, унсигез яшьләре тулганчы ук, фронтка җибәрүләрен сорап, хәрби комиссариат бусагасын житәрлек таптаганнар иде. Чөнки, тирән ышануларынча, алар фронтка элэгү белән, немецлар дер калтырап качарга тиеш иде. Ләкин хәрби комиссариатта шушы хакыйкатьне никтер аңларга теләмәделәр. Баштарак яшегез тулсын, диделәр, соңрак Фазылны алдылар, ә тракторчы Мөнирҗанны, син тылда кирәк дип, тагын калдырдылар.

Күрәсең, сугыш чорының кырыс законнары кешеләргә, аларның психологиясенә генә түгел, яра-җәрәхәтләренә дә бүтәнчә тәэсир итә торгандыр. Тыныч вакыт булса, Фазыл әнисенең яшь кычыткан салып пешергән умачлы ашын ашап, өендә әле шактый озак ятар иде. Ә аны, кайтып бер атна үтте микән, бригадир эшкә дә кодаларга керешТе.

Август аенда Фазылны ашлык сугучылар звеносына бригадир итеп билгеләделәр. Әскәйнең Уразай белән Карамалы басулары кисешкән жирендәге бодай басуы иде ул. Эш режимы болай куелган: иртә таннан төнге унга-унбергә кадәр алны-ялны белми эшлиләр дә, барысы бер арбага төялеп, кайтырга кузгалалар. Басу җәһәннәм аръягында, әле ун чакрымлап кайтасы бар. Аңа иң тиз дигәндә дә сәгатькә якын вакыт уза. Ә иртәнге дүрттә кире кузгалырга кирәк. Шул арада ашарга хәзерлә, юын, бала-чагаларыңны иркәләргә дә өлгер. Ләкин иң үзәккә үткәне—ачлык. Бар җыйган икмәк сугышка озатыла. Шуңа күрә ашлык сугучылар ничек тә булса үз җайларын үзләре карарга тырыша.

Бу юлы да арбага кечерәк ике капчык салганнар иде. Аларның кемнәрнеке икәнен Фазыл кызыксынып тормады. Ул көнне бәхетсез юлга кузгалганнар икән—кузгалуга, күгендә чекрәеп йолдызлар янган салкынча август тынлыгын челпәрәмә китереп, айгыр кешнәгәне ишетелде. Фазылның башыннан шунда ук «беттек» дигән уй сызылып үтте. Вәкил айгырының тавышын ул әллә кайдан таный. Вәкилдән биш кеше утырган, өстәвенә ике капчык бодай да салынган арбада аягында көчкә басып торган Бәбәй белән кача аласыңмы? Качарсың сиңа, тот капчыгыңны! Иң яхшысы, капчыклардан котылу! Ләкин соңга калдылар—алар төшеп өлгергәнче, Әфләтүнов арба янына килеп баскан иде инде. Ул, кесә фонаре белән яктыртып, бер генә карады да сорауны кабыргасы белән куйды:

—Капчыклар кемнеке?

Мирсәет абзый бер капчыкның үзенеке икәнен шунда ук таныды.

—Ә бусы?

Әфләтүнов авыл хужалыгында әлифне таяктан әлләни аермаса да, тегенди-мондый гына кеше түгел—ул Казанның үзеннән үк районга,

районнан Әскәй авылына җибәрелгән кеше. Аны барысы да таный, барысы да курка. Хәтта колхоз председателе дә. Һәм, әлбәттә, берәү дә яратмый. Фазылның сакау Әсгать белән булган хәлне һич онытасы юк. Бабеч-Карам буенда сабан сөреп йөриләр иде, берзаманны басу башында Әфләтүнов күренде. Моңа кадәр тыныч кына эшләгән Әсгать кинәт күкерт булып кабынды:

—Фадыл, вәтил тилә, тител тәләтәне, бәлеп үтеләм мин аны!—дип, Фазылны дә булса әйтергә өлгергәнче, тәләкәне эләктерде һәм вәкилнең өстенә ташланды. Әфләтүнов ничек кирәк алай качып өлгерде. Сабанчылар аның кыланышыннан туйганчы көләргә дә өлгерә алмый калды, кичкә табан ике милиционер килеп, Әсгатьне районга алып китте. Шул китүдән бары бер тапкыр гына, Минзәлә төрмәсендә икән, дигән хәбәре ишетелгән иде, бүтән кайда икәнлеген белүче булмады ул бичараның.

Шәһәр кешесе шәһәр кешесе шул. Әскәйгә беренче килүендә атна буена колынлы бия җигеп йөргән иде, аннан соң Соры алашаны биргәч:

—Моның колыны кайда?—дип сорап, көлкегә калды.

Атлар караучы Сәлах карт аңа:

—Иптәш Әфләтүнов, ул алаша бит,—дип әйтеп караган иде, ләкин вәкил үз кырыгын кырык итте:

—Алаша икәнен беләм, колыны кайда дип сорыйм мин синнән!—дип колын таптыруын белде. Шул көннән авыл халкы җае чыккан саен Әфләтүновның бу канатлы сүзен куллана торган булып китте.

Икенче тапкырында Әфләтүнов ашлык сугучылар янына килгәч, молотилкага карап:

—Моның ишеге кайда?—дип мәсхәрә булды.

Менә шул вәкил хәзер, Газраил булып, аларның барысын да бер җепкә тезде. Әфләтүнов Фазылның бригадир икәнен белә иде, сорау алуны аңардан башлады:

—Кемнеке дип сорыйм мин синнән! Ишетмисенме әллә, ник җавап бирмисең? Син бит бригадир, син белергә тиеш!

Кемнеке икәнен әйтергә Фазылның ничек теле әйләнсен. Ул дәшмәгәч, Әфләтүнов хатын-кызлардан алда машинист Сафа абзыйга ябырылды:

—Әйт, контра, барыбер төрмәдә черетәм мин сине!

Сафа абзыйны әллә төрмә сүзе куркытты, әллә яшь балалы булгач, тимәсләр, кызганырлар дип уйладымы икән, алты айлык баласын күтәреп басып торган хатынына күрсәтте. Ник шулай итте—Фазылның шушы көнгә кадәр аңлый алганы юк. Үз хатынынны күрәләтә чокырга төртеп төшер инде.

Сугыш чоры бит, хөкем озакка сузылмады—капчык хуҗаларын һәм Фазылны ябылуга хөкем иттеләр. Урлаганнарны ни өчен икәне аңлашыла инде, ә менә Фазылга үз вазифасына салкын караганы, урлашуга юл куйганы өчен бирделәр статьяны.

Ул Казан шәһәренең бишенче колониясенә эләкте.

Сугышның кара канаты берәүне дә читләп узмый, һәркемгә кагыла, барысы да фронт өчен, җиңү өчен эшли. Кем оек бәйли, кем бияләй, кем кием тегә. Фазыл исә төрмәдә кәрҗин үрүчеләргә тал чыбыгы ташыды.

Колония башлыгын ат белән Харис исемле татар егете йөртә иде. Эш белән аларга еш кына Казанга да чыгарга туры килде. Егет, ышанычка тәмам кереп беткәч, чанасында төргәге белән сукно да алып чыккалый башлаган. Төрмә башлыгы утырган чананы яки тарантасны кем тикшерсен. Ничә тапкыр алып чыккандыр, анысын төгәл әйтүче булмады, әмма бер тапкырында сакчылар егетне шул сукно белән эләктерәләр. Кабат суд була һәм Харисны бу төрмәдә срогын тутырганчы утырталар. Йөзләгән тоткын арасында Харисның тавышы моңлы булуы белән аеруча хәтердә калган.

Күп җырлары арасында «Мәдинә» исемлесен аның ишеткәне дә юк иде.

> Мин утырып хатлар язам,
> Синең исеңдә дә юк.
> Мәдинә, гөлкәем,
> Синең исеңдә дә юк, бәгырькәем.

Җыр болай да сагынудан телгәләнгән йөрәкләрне парә-парә китерде.

Үзенең хөкем ителүе хакында Фазыл төрмәдә чакта да, соңыннан да кабат-кабат уйланды. Дөрес эшләдеме соң ул арбадагы капчыкларны күргәч тә кире ташлаттырмыйча? Әгәр дә ташлаткан булса, бераүне дә хөкемгә тартмаслар иде. Урлашуның зур гөнаһ икәнен әллә ул белмәдеме? Белмәс сиңа! Ул бит мулла баласы. Өйләрендәге ач балаларын кызганды, менә шул. Ә бу миһербанлылык аларны гына түгел, үзен дә харап итте. Менә хәзер кая гына барса да,ниләр генә эшләсә дә, төрмәдә утырган дигән хәбәре кара сакал урынына үзенә тагылып йөриячәк.

Төрмәдән чыгуы гына түгел, мең бәла белән акчасыз-нисез авылга кайтуы турында язсаң, үзе бер китап булыр иде. Кайтып аңына килергә дә өлгермәде, урман кисәргә чыгып китте. Өйдәгеләр белән хәтта туйганчы сөйләшә дә алмый калды. Бар курыкканы өйдәгеләргә төрмә бетен йоктыру иде. Шуңа күрә кайтканның икенче көнендә мунча яктырып, киемнәрен ныклап кыздырды, озын-озаклап юынды һәм әнисенең сагындырган сөтле умачын ашап, мәтрүшкәле чәен эчеп яткан иде, тоташтан унике сәгать йоклады. Юлда ул бик нык туңган һәм эт кебек арыган иде. Ул йоклаган арада, кайтканын кайдан белгәндер, бригадир аның урман кисәргә барырга тиешлеген кереп әйткән. Юлга җыйналырга да вакыты чамалы гына калды. Мөниржан белән күрешмәвенең сәбәбе менә шул иде.

Урман кисүчеләр Ширәмәткә берничә тәүлек барды. Иң алда бригадир итеп билгеләнгән Гыйният абзый, аннан соң Гайния утырган ат, алар артыннан тагын берничә хатын-кыз. Мөниржан белән Фазыл бер-бер артлы уртагарак туры килде. Ничек кузгалсалар, юлны шул тәртиптә дәвам иттеләр. Чөнки карлы юлда бик теләсәң дә узышып булмый, әле каршыдан килүчеләрне үткәреп җибәрү дә мең бәла. Гыйнвар бит, кар тирән, буран әледән әле юлны күмеп тора.

Бер карасаң изелгән, еш кына туйганчы ашый да алмаган, каторга хезмәтенә баручы шушы «лашманчы»ларның уен-көлкегә теләкләре дә, хәлләре дә булмаска тиеш иде. Ләкин яшьлек уен-көлкесез яши алмый, аңа хәрәкәт, кызык кирәк, аралашу кирәк. Әскәй урманчылары да юк җирдән тәм тапты: әле берничә чанага төялеп мәзәк сөйләштеләр, әле туңа башлаганнары төшеп, әүмәкләшеп алды. Яшь егетләрнең аяклары, үзләре дә сизмәстән, Гайнияләр, Сәлимәләр тирәсенә тартылды. Мөниржан белән Фазыл да Гайния янына барып килделәр. Аякларын саламга төреп утырган Гайния карангы чырай да күрсәтмәде, бик ачылып та китмәде. Фазылны кайтуы белән тәбрик итте, хәл-әхвәлен сорашты. Аннан тынып калды.

—Ни булган бу Гайниягә?

Кыз янынннан үз чаналарына кайткач, Фазылның Мөниржанга биргән беренче соравы шул булды.

—Кияүгә чыкмагандыр бит?

—Юк.

—Сылу үзе, каһәрен. Бер кашык су белән йотарлык.

Дустының соклануын яшерми әйткән сүзләре Мөниржанның йөрәген чәнчеп алды. Юк, бик газиз ана бу тәкәббер кыз.

Өченче көн генә кайтып төшкән, авыл яңалыкларыннан бихәбәр булган Фазылның сорашуы табигый иде. Дөнья бит, тормыш дәвам

итә, төн чыкканчы да, йон чыга—әллә никадәр яңалык өстәлә. Әскәйдә булмаганына биш былтыр бит. Кайчан чыгып киткәнен бер Ходай һәм әнисе Хөршит абыстай гына беләдер. Төрмәгә хәбәрләр озак йөри. Анда закондагы карак-угрылар хакындагысы гына тиз тарала. Аның да белергә ярый торганнары гына.

Мөниржан дәшмәгәч, тагын сорау бирде:

—Араларыгыз ничек? Әллә ташлаштыгызмы?

Фазыл Мөниржан белән Гайния арасындагы серле мөнәсәбәтне сизенә иде инде.

—Аптыраган ла!—Бу сүзләрне Мөниржан ачынып әйтте.—Йөргән кешесе барлыгы да сизелми, мине дә якын китерми. Югыйсә вәгъдә биреп сугышка озатып калган иде.

—Кит аннан! Имәндә икән чикләвек...—Фазылның гайре гаҗәпләнүе чыраена чыкты.—Вәт, ышан син кызларга!

—Әллә чулак кайтуым өркетте. Сөйләшми. Хәтта кичләрен дә чыкмый. Миннән качу җаен гына карый.

Фазыл, юатып, дустының җилкәсеннән кагып куйды:

—Кайгырма, Ширәмәт барысын да ачыклар.

Фазылның күрәзәсе рас килде.

Күпләрнең Ширәмәткә беренче баруы иде.

Саклау урманнарында кәкре-бөкре каен, усак, әле юанаерга өлгермәгән имәннәр генә күреп өйрәнгән Әскәй кешеләре Ширәмәтнең очлары белән соргылт күкнең үзен терәткән колач җитмәстәй мәһабәт нарагларын күреп, телсез калды. Йа, Хода, урманның мондые да була микәнни?! Элек барганнар кайтып сөйләгәч, шыттыралар дип, ышанасы итмәгәннәр иде. Их, шушы наратлардан йорт салып керсәң иде дә тыныч кына яшәсәң иде! «Гайния белән, бала-чагалар белән... Мондый бүрәнәләрдән салган йорт кимендә йөз ел торырга тиеш». Мөниржанның күнеленә ихтыярсыздан әнә шундый уй килде. Ул, уен Фазыл сизмәдеме икән дип, дустына карап алды.

Халык телендә Ширәмәт дип сөйләсәләр дә, Әскәй урман кисүчеләре Кама Аланы авылына урнаштылар. Ширәмәтнең үзе кебек, Кама Аланы да урыс авылы икән.

Мөниржан белән Фазыл икесе бер фатирга керде. Фатир хуҗасы Пелагея Трофимовна шыңгырдап торган нарат бүрәнәләрдән салынган йортта ялгызы гына яшәп ята иде. Әскәйдә мондый йортның гомер-гомергә, һәрхәлдә Мөниржан белән Фазыл белгән дәвердә булганы юк иде.

Язмышның үз сценарие бар. Югыйсә фатирның бер ягына Гайнияне, икенче ягына Сәлимәне урнаштырырлар идеме?! Үтенеп сорасаң да алай булмас иде. Ә монда яшь йөрәкләрне юри үртәгәндәй килеп чыкты.

Яңа елга кадәр урман кисү, аны чыгару, бәлки, җинелрәк булгандыр. Ник дисәң, күптән түгел генә көзге күлмәкләрен салып, шәрәлегеннән оялып калган урманга әле кар юньләп төшәргә өлгерми. Ә хәзер, әнә кара, атлар, әйтерсең сөт күбегендә йөзә. Кар шундый тирән, кая гына басма, кимендә билеңнән чумасың. Атлар әле буш көенә дә корсакларына хәтле тирәлгән кардан көч-хәл белән генә йөри. Аларның, мескенкәйләрнең, такы-токы тукланып, болай да чыкмаган җаннары гына калган. Шулар әле йөк төягән чананы өстерәргә, план үтәргә тиеш.

Урманчылар иртә тора. Тормыйча соң, әле бит үзеңне тәртипкә китерү генә түгел, атларны да карарга кирәк. Чит-ят җирләрнең салкын абзарында ачлы-туклы төн уздырырга мәҗбүр булган атлар синең үз яннарына чыкканыңны дүрт күз белән көтеп тора. Күзләре белән күрәме, әллә адымыңнан танымы—син якынаюга, назланып кешнәп җибәрә:

—Иho-ho-ho!

Бу аларның үз телләрендә: «Саумы, хуҗам! Исән-сау йокладыңмы?—дип хәл белешүләредер, мөгаен. Әнә ич, яннарына килсән, җилкәнә башларын салу җаен гына карыйлар.

Урманчылар иртә тора. Тормаслар, әле тагын әз генә, печтик кенә булса да иркәләнеп ятарлар, сыңар күзләрен генә йомып, черем итәрләр иде, ярамый.

Кышкы көн бит ул яшьлек кебек: борылып карарга өлгермисең, ник кырык эшең кырылып ятмый, узып киткән була. Караңгы шулкадәр тиз төшә. Ә югарыдагы агайлар көн кыска дип норманы киметмиләр. Таш яуса да, кан коссаң да, син аны үтәргә тиеш. Бу дәүләт заданисе, эленкесалынкы йөрсәң, җавапка тарттырып, таш капчыкка тыгарга да күп сорамаслар. Сталин заманасы бу, корыч замана. Шуңа күрә, аз гына яктыра башлауга, төнге йокыдан уянып җитмәгән урманның тынычлыгы кача: чаналар шыгырдавы, атлар пошкыруы кеше тавышы, аларның кычкырып сөйләшүе, көлүе, сүгенүе бергә кушылып китә. Беренче тапкыр балта белән тун агачка суккан тавыш болай да туңган, күшеккән җәнлекләрнең котын ала. Агачка чапкан саен коелган кар, сынган ботак тавышы бу куркуны тагын да көчәйтә.

Берзаманны аркылы пычкылар ансамбле хәрәкәткә килә: бзин-бзин, тиң-туң... Менә берсенең агачы гөрселдәп җиргә ава. Аннан икенчесе... өченчесе... Һәр ауган агач үзе белән бик күп кар, башка агачларның ботакларын ияртеп төшә. Монда һәрдаим сак булырга кирәк—югыйсә башыңа зур ботак төшкәнен, гәүдәңне агачның бет урынына сытканын сизми дә калырсың.

Ауган агачның ботакларын чапканнан соң, кәүсәсен билгеле бер озынлыкта кисеп, атларга төяп тиешле урынга чыгарырга кирәк. Мөниржан белән Фазыл һәм тагын дистәдән артык кеше әнә шул эш белән мәшгуль.

Чанага төяп агач ташуның, читтән караганда, авырлыгы артык юк сыман. Төйисең дә алып китәсең, илтәсең дә бушатасың. Таза ир-атка нәрсәсе бар. Ләкин монда берничә ләкин бар. Иң әүвәле, юлсызлык—калын кардан атлар буш көе дә чак атлый. Икенчедән, колач җитмәс агачларны төяү җиңел эш түгел—җайлы-җайсыз эш итсәң, чана үрәчәң шартлый да сына. Ә ул сынса, эшләр ханә: яңасын ясап куйганчы, кәҗә маең сыгылыр, үзең хәлдән таярсың, нормаң үтәлмәс.

Юлсызлык һәм йөк төяү эшләре һәркемгә тигез эләгә. Әле бит төялгән йөгеңне тиешле җиргә илтеп җиткерәсе дә бар. Атларның исә тазалыгы, көче, холык-фигыле төрлесенең төрлечә. Мөниржанга рәхәтрәк—ул үзенең Күк биясе белән килде. Күк бия хәзер, саламга барган беренче көндәге төсле, төртсәң аварга торган өрәк түгел. Бер генә кулда булу, Мөниржанның, авызыннан өзеп, икмәк каптырулары, какмавы-сукмавы, бик тәҗел чакларда чыбыркысын офыкта нәҗагай урынына ялтыратып кына алулары Күк биянең хәлен күпкә яхшырткан иде. Дөрес, Күк бияга сугышка кадәрге хәленә җитәргә ерак, бик ерак әле. Ләкин аның башы хәзер салынкы түгел, сырты да, атланган унайга, күтеңне пычактай суймый.

Төрмәдән берничә көнгә алданрак кайткан булса, бәлки Фазылга да арурак ат эләгер иде. Урман кисәргә барачагы аның бит төшенә дә кермәде. Кайдан килеп ат сайлап тора алсын инде ул. Бәхетеннән, дөресрәге, бәхетсезлегеннәндер, аңа җигәргә Үгез кушаматлы карт алаша гына калган иде.

Их, Үгез, Үгез! Никләр генә дөньяга тудың икән син? Кемнәрне генә кан-яшь елатмадың, хәзер менә Фазылны интектерәсең... Адәм мәсхәрәсенә калдырасың...

Үгезнең кемлеген, ниндилеген сугышка кадәр үк яхшы белгән Фазыл ана якын бармас өчен, әлләниләр бирер иде дә бит... Юк шул. Бригадада ике уйламаслык итеп әйттеләр:

—Сайлана, сырлана торган вакыт түгел, алсаң да—Үгез, калсаң да—Үгез!..

Анасын сатасынмыни! Аз гына каршы төшсә дә яңа гына төрмәдән кайткан кешегә «халык дошманы» ярлыгын тагарга әзер торуларын белмимени ул. Әле тагып кына калсалар бер хәл, каһәр суккан органнарның «Макар бозаулар көткән жиргә» озатулары да бар. Ә Фазылның анда һич кенә барасы килми. Житәр, булды, шулпасын эчте.

Үгезгә жан индергәндә, Аллаһы Тәгалә аның белән эшлисе бәндәләре турында ник уйламагандыр. Карап торуга башкалардан әлләни аерылып тормаган Үгезнең бик сәер гадәте бар: ул бара-бара да шып туктап кала. Менә шул чакта аны житәкләп тә, юмалап та, хәтта чыбыркы белән кан чыгарганчы ярып та кузгатам димә. Таш та таш, Үгез дә таш. Иң хәлиткеч мизгелдә сине төп башына утырта да куя.

Йөккә төялгән агачларны бер авыл аша узып илтергә кирәк иде. Авыл аша инеш ага, аның олау узарлык күпере бар. Менә шул күперне чыгуга, үр менәргә кирәк. Үгез үзенең холкын беренче көнне үк күрсәтте: бер тын белән менеп житәргә теләп, Фазыл атын мөмкин кадәр кызурак алып килергә тырышты. Күперне чыктылар, үрнең дә күп өлешен менделәр, кул сузымы жир калды һәм Үгез, ни уйлагандыр, ару гына барган жирдән шып туктады. Алга бармагач, бер генә юл кала—кире төшәргә. Төшеп, кабат менәргә өч тапкыр талпынып карады Фазлыйәхмәт мулланың төпчеге. Юк та юк. Башта бу кызыкны карарга бала-чага гына жыйналган иде, тора-бара узып баручы өлкәнрәкләр дә, тукталып, тамаша кылырга тотынды. Аю биетәләр диярсең. Һәрберсе үзенчә акыл өйрәтә, кинәш бирә. Хәтта жыйнаулашып чананы этеп тә карадылар. Чана урынынан купты, әмма Үгез, аякларын терәп, карышуында булды. Мөнирҗанның Күк биясе күптән үр башында, Үгез мәхлукның менгәнен сабыр гына көтеп тора. Мөнирҗан үзе Фазылга булыша.

Болай булмый, ниндидер чарасын табарга кирәк. Ә нинди?

Ахырда, Үгезне тугарып, чанага Күк бияне жиктеләр. Үрне менгәч, тәртә арасына кабат Үгез керде.

Үгезнең тискәрелеге шул ук үрдә икенче көнне дә кабатланды.

Мөнирҗан бу юлы:

—Фазыл, әйдә юкка вакыт уздырып жәфаланмыйк, Күк бия генә алып менсен,—дип әйтеп караган иде дә, Фазыл риза булмады:

—Юк инде, ничек итсәм итәм, бу йөкне үзеннән менгерттерәм!—дип, катгый карарын белдерде.

Ни эшләргә жыенадыр—уйлаганын Фазыл берәүгә дә әйтмәде.

Үрне гадәттәгечә юыртып төштеләр. Күтәрелә башлауга, Үгезнең адымнары акрынайганнан акрыная барды һәм ул нәкъ элекке урында туктап калды. Артык та түгел, ким дә түгел. Ары куалауның файдасыз икәнен белгәнгә, Фазыл бүген нервысын бозып тормады. Ул чанасына салган нарат ботагын сындырып алды да бернинди этлек сизмәгән Үгезнең койрык төбенә шул ылысны кыстырды. Әле генә тискәреләнгән Үгезнең өермәдәй ничек кузгалганын Фазыл сизми дә калды. Ул чана үрәчәсенең тезенә бәрелүеннән юл читенә очып барып төште. Фазыл торып басканда, Үгез үрне менү генә түгел, куш аяклап чабып, урам борылмасында күздән югалып бара иде. Менә сиңа ялкау Үгез! Менә сиңа хәлсез, беткән алаша!

—Карт тәре!—дип канәгать елмайды Фазыл.—Хәзер инде даруынны беләбез.

Атын куып тотканчы ана шактый йөгерергә, тирләргә туры килде.

Башка көннәрдә исә ул акыллырак булды, Үгезнең койрык астына ылыс кыстырганда, дилбегәне кулыннан ычкындырмады.

Гайния апалы-сенелле маржаларда өченче кеше булып урнашты. Авылыннан чыгып карамаган татар кызы өчен урысча сөйләшү үлемгә тиң. Шулай булмыйча соң, аның бит Әскәй мәктәбендәге укытучысы да «моя хлеб», «мой жена» дип сөйләшүдән ары китәлмәгән дүрт класс белемле Мәгъфия апа иде. Ярый әле Гайния үзе зиһенле, ушлы кыз, сүзләрнең тәгәл мәгънәсен белеп бетермәсә дә, аңлый. Тик, кайтарып җавап бирәм дигәндә, ни өчендер, теленә тегермән ташы асыла.

Гайниянең вазифасына башкалар белән рәттән ботак чабу өстенә Әскәйдән алып килгән азык-төлекне, атлар фуражын бүлеп бирү һәм чыгарылган агачның төгәл исәп-хисабын алып бару да йөкләтелгән. Урман кисүчеләр арасында дәрәҗәсе буенча Гыйният абзыйдан кала икенче кеше.

Мөниржанның госпитальдән өенә кайтуына дүрт ай тулып килә. Гайния белән аралары кая ул якынаю—көннән-көн ерагая гына бара сыман. Кызның үзенә карата битарафлыгы (Гайния йөрәгендә янартаулар көрәше барганын кайдан белсен) үзәген өзсә дә, ул—чарасыз. Кызның кеме дә булса барлыгын белсә, алай ук сызланмас, бәлки, тәкъдир дип килешер дә язмышына күнәр иде. Юк бит, юк! Кеме дә булса, авылда моны яшерү мөмкинме: авылның колагы сак, күзе—үткен. Авылда бит барысы да үтәли күренә: кич белән берәрсен озатасы булсаң, аны иртән үк белеп торалар. Ә инде озатсаң яки куна калсаң—әйтеп тә торасы юк. Әнә ич, Мөниржаннар Сәлиməләрдә бер генә кич утырдылар, икенче көнне үк чыш-пыш китте. Кем белә, бәлки шул чыш-пыш Гайниягә дә барып ирешкәндер.

Бу Сәлимә Сәлимә генә түгел, бер кычыткан чыпчыгы булды, валлаһи! Күршедә генә яшәгәч, юк йомышны бар итеп, кичләрен гел Мөниржаннардан чыкмый. Урманда очрашкан чакларда да күзе белән ашардай итеп елмая.

Килгәннәренә ике атналап вакыт узды. Урманчылар мондагы шартларга ияләшеп беттеләр. Хәзер инде наратлары да артык юан, кары да чамадан тыш тирән, көне дә зәмһәрир суык тоелмый. Аударганнар аудара, ботаучылар балта белән ботак чаба, ташучылар—ташый. Ару-талу кайбер көннәрне шул дәрәҗәгә җитә ки, өстәвенә суык та үзенең мәкерле эшен эшли—кайтып ашауга, күз кабакларына таш тагалар. Сызлаганнарын бетеп, арыганнарын язылып өлгерми, тагын торырга туры килә. Югыйсә төне дә озын. Ярар, дип юаталар урманчылар үз-үзләрен, баш исән булсын, михнәткә түзә ул адәм баласы. Аллаһы Тәгалә аны шуның өчен яралткан.

Килгәннәренә ике атналап вакыт узгач, урманчы хатын-кызлар эш башлар алдыннан Гыйниятне утлы табада биетергә кереште:

—Нәкәнис, ял бирәсенме безгә, юкмы?!

—Калхузчы дигәч тә!

—Эшләп үләбез бит инде!

Төртмә телле, сугышның беренче елында ук тол калган Катифә мәсьәләне бөтенләй кабыргасы белән куйды:

—Син, карт алаша, беләсеңме озак юынмаган хатын-кыздан нинди ис килгәнен? Бригадир хатыннары урман кисү кебек кәтергәгә йөрми шул, белмисеңдер. Озакламый безнең истән өйләнмәгән егетләр коса, урман җәнлекләре тончыгып үлә башлаячак бит, черек бүрәнә!—Сүзен ут булып башлаган Катифә кинәт сүрелеп, иңәлүгә күчте.—Ял бир син безгә, Гыйният абзыкаем, ял бир. Кер юыйк, мунчалар ягыйк. Югыйсә, ташка үлчим, маржалар да җирәнерлек бит.

Бу сүзләрдән ирләр шаркылдап көлде, кияүгә чыгарга өлгермәгән кызлар, яшь киленнәр, оялып, кайсы башын иде, кайсы читкә үк китеп басты.

Гыйният—карт төлке—ситуацияне дөрес чамалап уйга калды: бераз

ял бирмәсән, дилбегә анын кулыннан ычкынып, ата улны, ана кызны белми башлаячак. Сыер думаса, аттан яман була диләр. Аннан сон ул үзе дә йомшак күнелле кеше, хатын-кызларны гына түгел, ир-атларны да кызгана иде. Ә мескен бахбайлар?.. Алар да бит җан иясе, аларга да ял кирәк. Ләкин бу урдага йомшаклыгынны сиздерергә ярамый, юкса башына менеп атланырлар.

—Ыслушай, сез нәрсә умарта күче кебек шаулашасыз? Падумаешь, дөньяда сез генә икән алланын кашка тәкәләре! Уйлашырбыз. Ә хәзер барыгыз, бар, эшегездә булыгыз! Сезнен өчен планны алабай килеп эшләмәс...

—Кара аны, Гыйният абзый, артык озак уйлама. Югыйсә, бригадир дип тормам, хатынына кирәкле җиренне үз кулларым белән тартып өзәрмен!

Бу сүздән Гыйният абзый елмайды гына:

—И-и, Катифә, синдәй яшь хатын кулы кагылса, үлсәм дә үкенмәс идем! Бәлки әле, бер тарта башлагач, өзеп үк чыгарасын да килмәс. Әйе бит, кызлар!

Анын бу сүзе киеренкелекнен эзен дә калдырмады. Урманчыларнын шаркылдап көлүеннән агач ботакларындагы кар коелды. Болай ук булыр дип уйламаган иде бугай, Катифә төкереп куйды:

—Тфү! Син карт дурак белән сөйләшкән мин юләр!

—Ярар, уен бетте, балакайлар, барыгыз, эшкә башлагыз. Бераздан хәбәр итәрбез. Ә син, Гайния, калып тор.

Гыйният Гайниядән азык-төлек һәм фуражнын калган запасы турында белеште. Саран булмаса да сак тота иде хисапчы кыз. Әйтерсен, гомере буена келәтче булып эшләгән.

—Йә, ничек уйлыйсын?—Гыйният соравын сорады да, җавап биргәнне көтмичә, фикерен дә житкерде.—Сәгать өчләр тирәсендә туктатсак, иртә булмасмы?

—Син нәрсә, Гыйният абзый?—Гадәттә сабыр Гайния чак кабынып китмәде.—Мыскыл итәсенме әллә? Сәгать өчтә эштән туктап, ни генә кыра алырлар икән алар? Мунча яксыннармы, кер юсыннармы? Минемчә, әбиткә кадәр эшләтергә дә ял бирергә кирәк.

—Ярар, кызым, кызма әле син дә. Рәзе мин каршы! Булгач-булгач, әллә сон, мәйтәм, ризыкны да ике порция бирәбезме бүген? Эшлиләр бит. Аннан сон бүген җомга көн дә. Мөселманнарнын бәйрәм көне.

Бу тәкъдим Гайниянен күнеленә сары май булып ятты. Ник бирмәскә! Тик, бар чагында бүредәй, юк чагында шүредәй генә булмаска кирәк.

Бераздан кабул ителгән карар чыбыксыз телефон аша һәр урманчыга барып иреште.

—Ура, әбиткә кадәр генә эшләргә!

—Бүген урман ташучыларга да бер генә йөк илтергә!

—Маладис икәнсен, Гыйният абзый!

—Карале, Гайниянен дә юмарт чаклары булыр икән...

—Яшибез, егетләр, болай булгач!

Төштән сон мона кадәр йокымсыравын дәвам иткән урыс авылы гүя уянды. Фатирга урнашучылар белән хуҗалар арасында ипле сөйләшүләр башланды. Мөниржан белән Фазылнын иртәрәк кайту сәбәбен белгәч, Пелагея Трофимовна егетләргә гозерен белдерде:

—Балакайларым, күреп торасыз, ягарга утыным бетеп бара. Берәр нәрсә юнәтә алмассызмы үзегез кискән җирдән?

Фазыл белән Мөниржан бер-берсенә карашып алдылар: ә ник ярдәм итмәскә ди бу әйбәт карчыкка? Балалары кебек күрә, аларга бирелгән барлы-юклы продукциягә үзенекен дә кушып, кайтуларына ашын пешереп, чәен кайнатып тора. Өстәлгә тозлаган гөмбә, кыяр кебек ят ризыклар да

менгәли. Яхшылыкка яхшылык белән җавап биреп өйрәнгән егетләр шунда ук ризалашырга ашыкты:

—Борчылма, анакай, хәзер алып кайтырбыз. Тик...

—Что, сынки? Авырыксынсагыз, кирәкми, бармагыз,—аларның «тик» диюләрен хуҗа карчык авырыксыну дип уйлаган икән.

—Юк, анакай, авырыксынмыйбыз,—диде төрмәдә дә урыслар белән аралашкан Фазыл. Аның урысчасы Мөнирҗанныкына караганда арурак иде.—Берәрсендә мунча ягып булмас идеме икән? Күптән мунча кергән юк. Суын да ташыр идек...

—Татар мунчасыз тора алмас инде...—диде Пелагея Трофимовна үзалдына. Бу аның хуплавы идеме, әллә өнәмәвеме—егетләр аңламады.

Пелагея карчыкның йорты зур, каралтысы төзек булса да, ни сәбәптәндер, мунчасы юк иде. Кирәк санамаганнармы, әллә вакытлары, хәлләре җитмәгәнме—анысын бер Ходай гына белә.

—Ярар, Тимофеевна белән сөйләшеп карармын!

Тимофеевна дигәне Сәлимә торган йорт хуҗабикәсе Ксения иде. Аның урыныннан тора алмый ятучы хаста ире дә бар диләр. Ләкин аны ни Мөнирҗанның, ни Фазылның бер тапкыр да күргәне юк. Әллә бөтенләй һавага чыкмый инде...

Егетләр утын кайтарырга ризалыгын бирде бирүен. Урманда утынга ярарлык агач ботаклары, оч буйлары дөнья кадәр. Ләкин рөхсәтсез алырга ярамас. Әскәйдә әнә корыган агач, черек төп алып кайтсаң да, тотыла калсаң, авыл советына чакыртып акт төзиләр, штрафы белән янә бер кат ыштаныңны салдыралар.

Бу яклар Әскәй белән чагыштырганда, кайсы яктан гына карасаң да, иркенрәк яшиләр сыман. Урманы кул сузымы җирдә, аннан бер йөк утын алып кайту күп дигәндә сәгать ярым ике сәгатькә сузылыр. Кузгалырга кирәк. Гыйният абзыйдан сорарга да ...

Кайсы атны җигү турында бәхәс булырга мөмкин түгел иде. Бәйрәмгә тиң шушы көндә, үзеңне мыскыл итеп, Үгезне җикмәссең бит инде.

Атны җигеп кенә бетергәннәр иде, күлмәк өстеннән җилкәсенә фуфайка гына салган яланбаш Сәлимә кереп житте:

—Егетләр, сез кая барырга җыендыгыз?—Ул әле Мөнирҗанга, әле Фазылга карады.

Шаяртып, җавапны Фазыл бирде:

—Күпне белсәң, тиз картаерсың!

Фазылга аңа Сәлимә белән ничек сөйләшсә дә ярый, Мөнирҗан кыз каршында теге көннән соң үзен гел гаепле саный—дәшмәде.

—Шаяртмагыз инде, мин чынлап сорыйм бит!

—Фатир хуҗасы утын алып кайтып бирә алмассызмы, дигән иде. Ә нәрсә?

Сәлимә:

—Ярый инде алайса,—дип кулын селтәп китә башлаган иде дә, Мөнирҗан юлына аркылы төште:

—Берәр йомышың бар идеме әллә? Әйт!

—Әй, минекеләр дә болыннан берәр чүмәлә печән менгереп бирә алмаслармы, белеш әле, дигәннәр иде. Ат җиккәнегезне күргәч, киенеп тә тормыйча, шуңа йөгереп чыккан идем. Ярар инде, башка берәрсенә әйтеп карармын. Югыйсә ире дә бар, тик ул сүгенүдән бүтән бер эшкә дә ярамый.

Мөнирҗанга бу минутта кыз ни өчендер бик кызганыч күренде. Ул:

—Сәлимә, туктап тор!—дигәнен сизми дә калды.—Менә Фазыл абзыең каршы килмәсә, без тиз генә вәгъдә иткән утынны кайтарабыз да аннан печәнгә юлларбыз. Син ничек уйлыйсың?

Фазыл һаман шаяртуын белде:

—Сон инде үзебезнең авыл чибәренең сүзен дә тыңламасаң, валлаһи, дим, жир йотар. Үзең дә барасыңмы соң ярдәмгә?

—Кирәк дисәгез, барам, әлбәттә...

—Юк инде, юк,—дияргә ашыкты Мөнирҗан. Бу юләр кызга ышансаң, тәки чанаңа чат ябышыр.

—Рәхмәт сезгә, егетләр!—Аннан Мөнирҗанга мут елмаеп күзен кысты да,—кирәк булсам, әйтерсез,—дип өстәде.

Бригадир Гыйният, егетләр кергәндә, урта яшьләрдәге хуҗа хатын белән табын артында утыра иде. Өстәлдә шешә белән көмешкә күргәч, башлыкларының күзләре ник елтыраганы сорамыйча да аңлашылды. Хуҗа хатынның да төнлә туганны шактый гына авыз иткәнлеге күренә. Бераз салмыш хатын-кызның шунда ук битенә кызыллык чыга, елмаюы да икенчеләнә.

—Әйдәгез, әйдәгез, мактап йөрисез икән!—Гыйният егетләрне ачык чырай белән каршы алды һәм, урыныннан торып, аларның ай-вайларына карамыйча, түргә чакырды.—Таныш бул, Марфа,—диде ул урысчаны ватып-җимереп,—безнең авылның асыл егетләре Мөнирҗан белән Фазыл. Ял көне хөрмәтенә берне тотып җибәрик!

Өч кенә секундка дип кергән егетләр уңайсызланып калды. Ләкин Марфа:

—Садитесь, ребята, угощайтесь,—дип, аларның каршы килерлеген калдырмады.—Нет, нет, Гена, я им сама наполню!—Ул килешле хәрәкәтләр белән Гыйниятнең кулыннан көмешкә шешәсен алып, ике стаканга да тутыра язды.—Ваш Гена без ума от моего первача. А вы как оцените?

—За ваше здоровье.—Чәкешеп, Мөнирҗан ялт кына стаканын каплап куйды һәм тизрәк кыяр кабу ягына карады.

Фазылның сынап караганы бар, ләкин ул Мөнирҗан шикелле алай уптым илаһи эчә алмый. Яңа туган бозау сыман—сөзеп-сөзеп эчә. Анда да авырлык белән.

Көмешкә бик куәтле иде. Фазыл аның яртысыннан артыгын эчә алмады, тамагына, эченә ут капты һәм стаканын кире куярга мәжбүр булды.

—Хорош самогон!—Чыраен сыткан Фазыл елмаерга тырышты. Марфа аңа дуңгыз салосы сузды.

—Закусывай и допей. У нас так не принято. Да ведь, Гена!—Фазыл авызына капканын чәйнәп йотуга, хуҗа хатын аның кулына эчелеп бетмәгән стаканын янә тоттырды.

Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырларсың, ди халык мәкале. Егетләргә бу арбадан тизрәк төшәргә, йомышларын әйтергә дә, чаналарына утырып, моннан таярга кирәк. Тагын берәр шундый доза җибәрсәң, утын, печән алып кайту турындагы хыялларың буш сүз генә булып калачак. Фатир хуҗасы алдында сынатырга ярамый, Сәлимәне уңайсыз хәлгә кую да егетлек түгел.

Гыйният, әлбәттә, каршы килмәде. Егетләр, хуҗаларга рәхмәт әйтеп, китәргә кузгалды. Бригадир аларны озата чыкты.

—Ярар, егетләр, сез берни дә күрмәдегез, килештекме? Югыйсә Мәүлидә апагызның әлләни уйлавы бар.

—Шту син, шту син, Гыйният абзый, без синең янга кермәдек, кермәгәчтен күрмәдек!

Егетләр шаяртып җавап бирде дә аларны сабырсызланып көткән Күк бия янына юнәлделәр. Аларны озатып өйгә кергән Гыйниятнең ишек келәсен төшергәне ишетелде.

—Аһ, карт төлке, Мәүлидә апагыз әлләни уйлавы бар, диме! Үзе Гыйният икәнен онытып, Генага әверелгән.—Мөнирҗан шаркылдап көлде.

—Әйтәм аны хуҗабикәсе белән кети-мети уйный дип ишеттергәннәр иде,—диде Фазыл, исенә төшереп.

—Кем?

—Әллә тагын. Кайсысыдыр әйтте инде, хәтерләмим. Син ишетмәгән идеңме?

—Юк.

Авыл өстенә авып диярлек торган урманнан киселгән ботак-санак төяп алып кайтуның урман кисеп каешланып беткән егетләргә, әлбәттә, әлләни авырлыгы булмады. Җитмәсә, такыр юлдан. Алар капкадан керүгә, Пелагея Трофимовна каршыларына йөгереп чыкты:

—Спасибо, сынки мои! Если бы моего Николая проклятый Гитлер не убил, разве вас просила бы... Вы уж извиняйте меня, старушку...

—Полно, полно, мать. Успокойся. Люди должны помочь друг другу.—Фазыл күңеле тулган фатир хуҗасын тынычландырырга теләп, аркасыннан сөйде.

—Кая бушатабыз? Куда разгружаем, дим.—Мөнирҗан утынны бәйләгән бауны чишә башлаган иде.

Аларның утынны бушатканын көтеп торып, хуҗа хатын чукына-чукына рәхмәт укыды. Соныннан:

—Мунчаны яктым. Тагын бер-ике сәгатьтән әзер булыр,—диде.—Аныңчы, әйдәгез, ашап алыгыз.

Егетләрнең әле ашыйсы килми. Ләкин катылыгы спирттан ким булмаган көмешкә тамакларын киптергән иде. Берәр стакан чәй, чәй булмаса су эчмичә түзәр тәкатьләре калмады.

Керсәләр, күзләре маңгайларына менде: өстәлдә самавыр җырлап утыра, аның каршысына әбиебез бер шешә дә куйган. И-и, бу адәм баласының юктан да күңеле булыр икән...

Пелагея Трофимовна бик кыстаса да, алар:

—Әле эш бар,—дип, шешәгә кагылмады.

Чәй эчтеләр. Инде Сәлимәнең йомышын гына үтисе калды. Үзләре генә китеп барырлар иде, болында кибәннәр, чүмәләләр күп. Белмичә йә кешенекен төярләр. Иренең барырлыгы булмагач, чанага хуҗа хатын үзе менеп кунаклады. Су буендагы кибәнен күрсәтүгә, җәяүләп кайтып та китте.

Кибәнне кар баскан. Шулай буласын чамалап, көрәк алганнар иде, тансыкка тары ярмасы дигәндәй, мондый эшләрне төрмәдән тансыклап кайткан һәм әле сусыны басылып өлгермәгән Фазыл, ун-унбиш минут дигәндә, карны көрәп тә ыргытты. Ул шулкадәр кызды ки, бүреген салгач, тирләгән башыннан бөркеп пар күтәрелде.

Бер чүмәлә печәнне чана өстенә ыргыту яшьтәшләр өчен уен гына иде. Сәгать тә үтмәде, йөк төялеп бетте.

Алар Сәлимәләр ихатасына кергәндә, эңгер-меңгер төшеп килә иде. Хуҗа хатын бушатасы урынны күрсәткәндә, Фазыл сүз юктан сүз булсын дигәндәй, Сәлимәне сорады.

—Ул мунчада. Күптән киткән иде инде,—диде Ксения.—Кереп аркасын юмыйсыңмы соң, тизрәк чыгар иде,—дип шаяртты да соклануын белдереп әйтте.—Больно уж девка хороша!

Ул китә башлаган иде, исенә төшеп, кире борылды:

—Онытып торам икән, Бушатып бетергәч, атыгызны тугарыгыз да безгә керегез. Щи пешердем.

—Юк инде, күрше, юкка мәшәкатьләнмәгез. Безнең Пелагея Трофимовна да көтә-көтә көтек булгандыр. Рәхмәт чакыруыгызга,—диде егетләр.

—Керәсез!—дип кистереп әйтте ике сөйләшергә өйрәнмәгән маржа.—Югыйсә, обижусь.

Егетләрнең ризалык бирүдән бүтән чарасы калмады.

Йөкне бушатып бетереп килələр иде, шыгырдап мунча ишеге ачылган тавышны ишетеп, Мөнирҗан белән Фазыл шул якка карады. Һәм шаккатты: мунчадан албасты кадәр пар чыкты да ап-ак кар өстенә ауды һәм, ләззәтле ыңгырашып, әйтерсең, карда түгел, аккош мамыгы өстендә ауный, тәгәри башлады. Егетләр аның бернинди дә албасты түгел, Сәлимә икәнен бераздан гына аңлап алдылар. Хәзер инде алар, печән бушатуларын онытып, карда аунаучыга карап тора башлады.

Менә Сәлимә торып басты да өстеннән куллары белән карны сыпырып төшерергә тотынды. Ул ашарга житеп үзенә текәлгән ике егетне күрми иде. Аның күкрәкләре, ташып торган тал чыбыгыдай зифа гәүдәсе кышкы кичнең саран яктылыгында да шулкадәр ымсындыргыч күренә иде ки, егетләр телдән калды. Шунда каушавыннан Фазылның сәнәге кулыннан төшеп китте һәм баганага бәрелде. Шык иткән саңгырау тавыш Сәлимәне сискәндереп җибәрде. Ул «ой!» дип кычкырып, бер кулы белән оят җирен, икенчесе белән күкрәкләрен каплады, аннан ишеген ябарга да онытып, мунчага кереп шылды.

—Гомеремдә беренче тапкыр шәрә кыз күрдем,—диде әсәрләнеп калган Фазыл, күзләрен уа-уа.—Кара әле, Мөнир, чыннан да Сәлимә идеме ул, әллә берәр җен кызымы?

—Әле соң түгел, мунчага кер: җенме, Сәлимәме икәнен күрерсең!

Әле генә төрмәдән кайту сәбәпле, Сәлимәнең Хәсьянов белән гыйшык-мыйшык уйнавы хакындагы бөтен авыл күптән чәйнәп төкергән хәбәр дә ана барып ирешмәгән иде.

—Син нәрсә! Мине юләргә санныйсыңмы әллә?—диде ул үпкәли төшеп.

—Түгел инде, түгел. Шаяртканны аңламыйсыңмыни?

Чакырган җиргә бар, куган җирдән кач, ди халык мәкале. Атларын тугарып, алар Ксенияләргә керде. Ризыктан берәү дә олы түгел.

Егетләр кергәндә, Сәлимә мунчадан кайткан, таратып салган чәчләрен сөлге белән корытып утыра иде. Аларны күргәч, кызарып һәм тагын да чибәрләнеп китте.

—Җиңел пар белән!

—Рәхмәт.

Кәбестә шулпасы искиткеч тәмле булып чыкты. Аны болай итеп мичтә чуен белән бары тик марҗа хатыннары гына пешерә белә торгандыр. Югыйсә щи дип биргән кәбестә шулпасын сугышта да, төрмәдә дә авыз итәргә туры килде егетләргә, әмма моның белән янәшә куярлыклары очрамады. Хуҗа хатын ихластан кыстап, егетләргә көмешкә салды. Печән алып кайткан өчен ул тагын рәхмәт әйтә башлаган иде, мич башыннан карлыккан ир тавышы ишетелде:

—Ксюша, а ты меня не забыла?

Ксения тагын бер стаканга көмешкә койды:

—Как же я тебя забуду!? Какой ты нетерпеливый. На, милый, на, пей на здоровье!—дип, дуңгыз салосы белән стаканны иренә илтте.

Ашагач, рәхмәт әйтеп, егетләр кузгала башлады. Ксениянең аларны тиз генә җибәрәсе килмичә, тагын көмешкә алырга керешкән иде, егетләр бирешмәде.

—Алайса мунчадан соң чәй эчәргә керегез!

Хуҗа хатын ихластан чакыра иде, әмма кеше булган адәм баласы чикчама дигәнне үзе белергә тиеш. Өч тиенлек эш эшләп, биш сәгать кунак булып яту килешмәс, оят кирәк.

Сәлимә авылдаш егетләрен озата чыкты һәм, җаен туры китереп, Мөнирҗанның үзенә генә:

—Мөниржан абый, сагындым, барысы да юынып бетергәч, мунчага кил, күтәрмен. Синең үзеңә генә әйтер сүзләрем бар,—дип пышылдарга һәм кулын мәгънәле итеп кысарга өлгерде.

Тыныч тормышта күтелмәгән мәшәкатьләрсез генә яшәгәндә, татар атна саен мунчасын керми калмый. Ә бу юлы урманчыларның ике атнага китте. Алар мунчаны, хуш исле каен себеркесен сагынуның аръягына чыкканнар иде, шуңа күрә ашыкмыйча юындылар. Мөнирҗанның сыңар кулы белән чабынуына җаны түзмичә, Фазыл аны ләүкәгә яткырып, үзе чабарга кереште. Селтәнә-селтәнә дә, себеркесен суга манчый һәм, аны таш өстенә куеп, парландырып ала. Күзләрне әчеттереп, колак яфракларын көйдереп, мунча эченә пар тарала. Фазыл ничек түзә торгандыр, Мөнирҗанның тәне ут булып кызды инде, менә-менә кабынып сыман. Ул әллә эсседән, әллә тәненә тарала барган рәхәттән әледән-әле ыңгырашып ала. Дусты ыңгырашкан саен, Фазыл аны себеркесе белән ышкый.

Бу рәхәт күпмегә сузылгандыр, ниһаять, Фазыл себеркесен идәнгә ыргытты һәм тышка атылды. Мөнирҗан—аның артыннан.

—Әйдә, без дә карда аунайбыз! Сәлимәгә яраганны, безгә ник ярамасын!

Кар тәнне өтеп ала да кызыштыра. Егетләр ике-өч тапкыр аунап кергәч кенә, канәгатьләнделәр.

—Мөнир, хәтерлисеңме, гармун яндырып көлен ашаган идек?

—Хәтерләми соң!.. Ике юләр.

—Юләр димә әле син. Менә син, ашагач, тәки гармунчы булып киттең бит. Чын гармунчы булдың. Ә мин «эт сөяккә бара»дан ары китә алмадым.

Кәефләр әйбәт. Мунчаның пары шәп, эчтән көмешкә кыздыра. Бала чакларын искә төшереп, күпме хатирәләр яңарды бу мунчада. Соңыннан, күп еллар узгач, сагынып искә алгаладылар әле алар урыс авылының карлы кышында кергән шушы кара мунчаны.

Аларның мунчадан кайтуын Пелагея Трофимовна табын көйләп көтә иде. Тик егетләрнең ашар урыны кайдан калсын. Бүген болай да гел кунак сыенда йөрделәр. Аның каравы «нарком нормасы» җибәреп, карлыган яфраклары салып пешергән такта чәйне тирләрен сөртә-сөртә озаклап эчтеләр. Утыны кайтканга бик күңеле булган Пелагея түти аларга карап-карап торды да:

—Бу татарларның карчыклары гына чәй ярата мы дисәм, ир-атлары да кимен куймый икән,—диде.—Әллә соң самавырны тагын яңартыйммы?

Егетләр бертавыштан:

—Юк, кирәкми, кирәкми!—диештеләр.

Аларның урыны кайтуларына ук җәеп куелган иде. Фазылның вакыт әрәм итәсе килмәде, урынына барып ятты. Күп тә үтмәде, мыш-мыш килеп йоклап та китте.

Бүген көмешкәне югыйсә шактый эчәргә туры килде. Әмма Мөнирҗанның башына әллә китте, әллә юк. Киресенчә, аның баш миен бөтенләй башка нәрсә бораулый: ник чакырды икән Сәлимә мунчага? Барыргамы, юкмы? Бәлки ул шаярткан гынадыр... Әллә шаяртмадымы икән? Нидер әйтәсем бар, диде түгелме соң. И, ул кычыткан чыпчыгының юньле сүзе булыр дисеңме! Ә шулай да теге кичне бик тәмле иде ул шайтан кыз. Кыз битараф түгел. Моны күрмәү өчен сукыр булырга кирәк. Хәтта сукырлар да тән күзәнәкләре белән сизәр иде Сәлимәнең ялкын бәреп торган сулышын.

Ни эшләргә белмичә, ул ишек алдына чыкты. Ихтыярсыздан, күзе күршеләренең мунча тәрәзәсенә төште: анда тонык кына ут яна иде. Икеләнү-шөбһәләнүләрен кызыксыну җиңде: чыннан да Сәлимә микән мунчада? Әллә Марфалар барганмы?

Шыгырдавык кар өстеннән аяк тавышларын үзе дә ишетмәстәй атлап, Мөниржан мунчага юнәлде. Мунча эчендә кем барын күрү өчен ана тәрәзәдән карау кирәк түгел—көндез дә йолдыз күрергә сәләтле күзләр «мунча иясенен» Сәлимә икәнен шунда ук абайлап алды. Жинаять өстендә тотыласы да килми, кызыксынуын да җинә алмыйча, ул песи адымнары белән сукыр лампа яктысы төшеп торган кечкенә тәрәзәгә якынайды. Йа Хода, нинди гүзәллек! Чыгып карга аунаганда, бу гүзәллекнен йөздән бере дә күренмәде. Алай да Фазыл телдән калды, хәзер күрсә, бөтенләй акылыннан язар иде. Их, исерекбаш, аулак өйдә теге чакта нинди гүзәл тәннен ләззәтен эчкәненне анлмагансын бит син! Бәлки төкерергәдер Хәнифнең тәкәббер кызына һәм өйләнергәдер шушы чибәркәйгә?! Подумаешь, Хәсьянов белән чуалган. Фронтта күрде инде кемнең ничек гүләйт иткәнен. Офицер хатыннарының да, тере ирләре була торып, кайберләре гел «уҗымга» каеру ягын гына карый. Алар өчен сугыш та, мәхәббәт, тугрылык дигән изге хис тә юк. Сугышка алынгач өйрәнүләр вакытында бер капитанның хатыны Мөниржанга бәйләнеп йөдәтте. Ят ризык ымсындырса да, шәригать кануннары нигезендә тәрбияләнгән һәм хәрби хезмәткә алынганчы Бөгелмә стансасын да күреп карамаган Әскәй малае командирына хыянәт итү турында уйлап та карамады. Анын фикеренчә, командирга хыянәт—ул илгә, Ватанга хыянәт белән бертигез. Гомумән, мондый якынлык бары тик ир белән хатын арасында гына булырга тиеш дип исәпли иде. Шуңа күрә сугыш елларында ирекле яки мәҗбүри рәвештә фронтка эләккән кызларның, бигрәк тә чибәррәкләренең, еш кына өлкән офицерлар сөяркәсенә әверелүләрен ул берничек тә анлый һәм күнеле белән кабул итә алмый иде.

Бер уйласан, ул кызларны да анлап була: сугыш бит сабан туе түгел, анда син шушы минутта бар, борылырга өлгермисен—инде син юк. Дөньяга яратылган адәм баласының акылы гына түгел, табигый инстинктлары да хакимлек итә сугыш вакытында. Ходай Тәгаләнең бар биргән гыйшык-гыйшрәт хисләрен ник тыеп торырга? Ник ул байлыкны үзең белән кабергә алып китәргә? Сугыш ул кылган гына түгел, кылынасы гөнаһларны да ярлыкарга тиеш. Кемнәрдер шулай фикер йөртә. Ләкин үз сүзләренә, сөйгән ярларына соң сулышына кадәр тугры калган кыз-хатыннарны да, ир-атларны да күрергә туры килде Мөниржанга. Димәк, дөнья бер генә калыптан яратылмаган, димәк, күпме кеше яши—шунын кадәр холык-фигыль.

Ә капитан хатынының мәхәббәтен, анын кайнар кочагын кире кагуы Мөниржанга шактый кыйммәткә төште. Ул бит әле хатын-кыз мәхәббәтеннән мәкергә бер генә адым икәнен белмәгән сары томшык кына иде ул вакытта. Теләгенә ирешмәгән, дәртенә чыдый алмаган хатын ире аша Мөниржанга шактый әшәкелек эшләргә өлгерде. Ләкин алар Мөниржанның чираттан тыш нәрәт алуыннан артмады. Канлы, дәһшәтле сугыш барганда, көн саен танышларын, сугышчан дусларын һәлак булып торганда, ашханәдә чираттан тыш кизү тору яки бәдрәф юу, кем әйткәндәй, бәйрәм генә ул.

Мөниржан күз алдына тагын Сәлимә белән Гайнияне янәшә куеп карады һәм чагыштырырга тотынды. Сәлимә яшь, чибәр, энергиясе ташып тора. Анын кайнар кочагында егет түгел, таш булып таш та эрер иде. Ул кочак әле һаман сагындыра, төшләренә кереп йөдәтә. Кыз Мөниржанга үзе омтыла, сөйләшергә, аралашырга җай чыкканда, форсатны ычкындырмый. Менә бит әле бүген дә мунчага дәште. Ләкин...

Гайния исә, киресенчә, һаман анардан кача. Гәрчә сугышка озатканда вәгъдә биреп калган булса да. Мөниржан кызга хисләренен элеккечә калганын (бәлки көчлерәктер дә әле) анлатырга тырышып карамады түгел, карады. Юк, Хәниф кызы селкенмәде дә. Әллә соң анарда йөрәк дигән нәрсә

бөтенләй юк микән? Алай дисәң, Гайниянең күз карашлары ник шулкадәр сагышлы? Сирәк-мирәк икәүдән-икәү генә калырга туры килгәндә, күз карашлары очрашса, йөрәгенә утлы күмер коела Мөниржаннын.

Шушы сагышлы күз карашы Сәлимәнең мунчадагы ымсындыргыч шәрә тәнен дә, кайчандыр үзенә суырып алган кайнар кочагын да җиңде. Мунча тәрәзәсе аша күренгән сылу гәүдәгә тагын бер тапкыр күз ташлады да егет, кереп, Фазыл янәшәсендәге урынына ятты. Ятуын ятты, ләкин таң әтәчләре кычкырыр алдыннан гына йокыга китте.

Көтте Сәлимә, көтте Мөниржанны. Аны көтә-көтә, киемнәрен кат-кат юып элде. Өметләре акланмаудан үзәкләре өзелде, эче янды. Шул минутта карга чыгып аунаса да, бу януы басылмаячак иде—анысын да белде.

Ул бүген Мөниржанга бары тик аны гына яратуын, карынында бәби тибүен, ул бәбинең әтисе Мөниржан булуын әйтергә теләгән иде. Кызның тозлы күз яшьләре кара мунчаның себерке яфрагы белән чуарланган һәм сабын суы сеңгән җир идәненә тамды. Көтеп-көтеп тә көтеп ала алмагач, Сәлимә елаудан кинәт туктады һәм таш өстенә бер-бер артлы өч чүмеч су салып, атылып чыккан парда себеркесен кыздыра-кыздыра, тырпаешкан күкрәкләрен һәм бил тирәсен ярсып-ярсып чабарга кереште.

Ул мунчадан кайтканда, хуҗалар изрәп йоклый иде. Сәлимә, ут кабызмаса да өстәл өстендә торган шешәне күрде. Януына чыдый алмыйча, шул шешә авызыннан голт-голт итеп көмешкә йотты һәм көн дә йоклый торган түшәгенә ауды.

Кичтән ял иткән урманчыларның бүген тавышлары көр чыга, балта, пычкы тавышлары да икенчерәк яңгырый сыман. Кемдер хәтта, әллә айнып бетмәгән инде, «Алмагачлары» көен интектерә башлады.

Электән әзерләп калдырган бүрәнәләрне төяп, урман чыгаручылар икешәрләп-өчәрләп кабул итү пунктына кузгалды. Бер җаен белгәч, Үгез хәзер теге үрдә туктамый. Төш вакыты җиткәнче, Мөниржан белән Фазыл әйләнеп кайтырга өлгергәннәр иде. Кайттылар да коточкыч хәбәрдән өнсез калдылар: Сәлимә башына агач төшеп үлгән. Бу хәбәр егетләрнең җаннарын өшетеп җибәрде. Аларның әле кичә генә мунчадан карга чыгып аунаган, тәненнән сәламәтлек, ныклык аңкып торган Сәлимәнең үлеменә һич кенә дә ышанасылары килми иде.

Бәхетсезлек болай була. Бер агачны аударганда, тегесе корыган наратка барып сөяләә һәм аны да аудара. Коры нарат җиргә килеп төшүгә, ботагында әйләнә дә Сәлимә кисә торган агачка китереп бәрә. Ул агачның зур гына ботагы сынып, кызның туп-туры башына төшә. Кыз бер тапкыр кычкырырга гына өлгерә. Янына кешеләр килеп җиткәндә, ул инде җан биргән була.

Саксызлыкмы, бу язмышмы? Ни генә булса да, әле унҗиденче яше белән генә баручы, сөяргә-сөелергә, җиргә ана булыр өчен туган кыз фани дөнья белән хушлашты. Аның үзе генә белгән көмәне дә мәңгелек сер булып теге дөньяга күчте. Мәрхүмәнең җәсәден ат чанасына салып, Катифә белән Әскәйгә озаттылар.

Сәлимәнең үлемен урманчылар, бигрәк тә Мөниржан авыр кичерде. Чакыргач, мунчага бармый калганы, башка көннәрдә дә кызга ачык чырай бирмәгәне өчен үзен битәрләде. Дустының кинәт кенә йомылып калуы Фазылны гаҗәпләндерсә дә, юк-бар сорау биреп Мөниржанны бимазаламады. Кайгыны да, шатлыкны да һәркем үзенчә кабул итә һәм кичерә. Сәлимәнең үлеме тетрәндермәслек түгел иде шул. Нишлисең, язмышның хөкеме шулдыр. Бәлки уйнаш кылганы өчен күкләрнең җәзасы булгандыр.

Көн артыннан көн уза торды. Әскәйлеләр озакламый үзләренә тигән заданиене үтәячәкләрен, тиздән авылга, якыннары янына кайтасын уйлап,

дәртләнеп, куана-куана эшлиләр. Алардагы дәрт атларга да күчте, ахры, ашарларына такы-токы гына булса да, ике әйттертмиләр.

Февраль урталары якынлашты. Әле чын-чынлап яз килергә иртәсен иртә, әмма кояшнын каравы бөтенләй икенче. Көннәр дә сизелерлек озынайды. Озынаймыйча сон, хәзер гыйнвар башы гына түгел бит!

Шушы көннәрдә кечкенә авыл тормышында сизелерлек бер вакыйга булып алды. Көтмәгәндә-уйламаганда күкрәге орден-медальләр белән тулы егерме биш яшьләрдәге бер егет кайтып төште. Язган хаты буенча ул сонрак кайтырга тиеш булган икән. Авылныкылар: «Настянын Степаны кайткан. Ул орденнары, ул киемнәре, әллә генерал , әллә полковникмы шунда!»—дип гөж килде. Алар Настя өчен бер куансалар, кечкенә генә авылдан шундый «зур» кеше чыгуы белән авыл кешеләренә хас самими горурлану белән горурлана да иделәр. Авыл гадәте шулай бит: кайтуынын беренче көннәрендә Степан кызмача хәлендә өй борынча хәл белешеп йөрде. Беркөнне Пелагея түти янына да керде. Егетләр эштән кайткannan сон юынып, табын янына утырганнар гына иде.

Степаннан Ходай Тәгалә чибәрлекне кызганмаган. Өстәвенә күкрәгенә ике Кызыл Йолдыз ордены, «Батырлык өчен» һәм бүтән медальләр таккан. Сугышнын башыннан азагына кадәр булып, рота командирына кадәр күтәрелгән икән егет. Хәрби дәрәҗәсе «старлей», ягъни өлкән лейтенант икән. Кем инде жиде класс белем белән шуннан ары күтәрсен.

Үзләре дә дары исен иснәгән кеше буларак, егетләр Степан күкрәген бизәгән орден-медальләрнен чын бәясен беләләр. Степаннын пехотада хезмәт иткәнен дә ишеткәч, ана карата булган хөрмәтләре бермә-бер артты. Ник дисән, кайда-кайда, әмма пехотада хезмәт иткәннәрнен дүрт ел буена исән калулары сирәк була торган хәл. Сугышчылар арасында ин күп үлүчеләр—пехотада. Димәк, Степан чыннан да күлмәк белән туган. Ир-атлары сугышка кадәр дә бармак белән генә санарлык авылга Степан кебек егет асылы кайту, әлбәттә, зур вакыйга. Сугыш кайчысы кемнәрне генә кыркымады. Кайткан көненнән алып Степан күз өстендә кара кашка, авыл кызларынын, яшь тол хатыннарнын татлы сагышына әверелде.

Иртәгәсен бригадир Гена-Гыйният беренче рейстан кайтуына, Мөнирҗанга көтелмәгән эш кушты:

—Энем, бар, Ширәмәткә минем фатир хуҗасын илтеп кайт әле. Авырыксынсан, кирәкми, бүтән берәрсенә кушармын...

Мөнирҗан ник авырыксынсын, Ширәмәткә кеше илтеп кайту бүрәнә төяп ташу булмас әле. Шуна күрә:

—Кайчан китәргә?—дип сорады.

—Хәзер. Ул көтеп тора.

Чыннан да, капка төбенә ат килеп туктауга, кулына кечкенә төенчеген тоткан Марфа килеп тә чыкты. Анардан бераз көмешкә исе анкый иде.

—Киттекме?

—Киттек.

—На, малкай! Әйдә, Күк бия!

Хуҗасынын тавышыннан ук ни теләгәнен анлаган бахбай Ширәмәт юлыннан жай гына юырта башлады.

Көн кояшлы. Җинелчә генә җәяүле буран себерә. Толып эченә кереп чумган Марфа башта тегесен-бусын такылдап барды-барды да тынып калды. Күрәсен, йоклап киткәндер.

Кола яландагы бу ялгызлыктан Мөнирҗан күнелен сагыш корты кимерә башлады. Ул жырлап җибәргәнен сизми калды.

Жыр юлны кыскарта диләр. Ширәмәткә кадәр калган ара сизелмәде. Шунда, көтмәгәндә, Марфа телгә килде:

—Матур жырлыйсын, Мунирка. Татар жырларын яратам мин. Татар

ирләрен дә!—Тапкыр сүзеннән үзе үк көлеп тә җибәрде.—Әллә үземдә дә татар каны бар инде бераз...

—Все может быть,—диде Мөнирҗан сүзсез калуны килештермичә, гәрчә Марфа үзалдына гына сөйләнсә дә.

Ширәмәткә керделәр. «Унга», «сулга», «турыга» дип бара торгач, Марфа бер йортның капка төбендә төшеп калды.

Кесәсендә җилләр уйнаган Мөнирҗан кая да булса кагылып тормады, кайтыр юлга чыкты. Алла боерса, озакламас, кайтып та житәр.

Тик ул иртәрәк юанган икән. Ширәмәтне чыгуга, юлда тоташтан кара киенгән бер хатын басып тора иде. Кулын болгап, туктавын үтенде.

—Сез бит Кама Аланына кайтасыз. Зинһар, Ширәмәткә кереп, бер капчык кына салып чыгыйк әле,—дип гозерләнергә кереште.—Мин сезне буш итмәм.

Хатынның тавышына караганда, ул чарасызлыктан гаҗиз иде. Чыннан да бу хатынны авылда күргәне бар бугай аның. Ярар, капчык икән капчык. Тикмәгә генә кеше бу суыкта кырга чыгып басмас. Әле вакыт бар, ярдәм итәргә кирәк.

Мөнирҗан кая барасын сорап тормады, теге хатын әмеренә буйсынып, атын куалавын белде. Ниһаять, хатын туктарга кушты. Күзе белән күрүдән элек госпиталь-лазаретларда житәрлек аунап, дару исен калган гомеренә житәрлек итеп сеңдергән Мөнирҗан моның хастаханә икәнен аңлап алды.

Чанадан төшкән чагында, хатын Мөнирҗанның исемен сорады. Үзенең исеме Евдокия икән.

Көтеп торырга кушып, Евдокия кереп китте дә гаип булды. Кайда йөри, ни эшли—берни билгеле түгел. Мөнирҗан толыпка төренеп черем итеп тә алды, аягына суык үтә башлагач, йөреп тә килде. Күк бия дә алдына салган саламны сайлый-сайлый ашап бетерде. Ул әледән-әле хуҗасына акыллы кара-зәңгәр (бәлки коңгырт-карадыр?) күзләрен теки һәм:

—Ни эшләп торабыз, хуҗам? Ник китмибез?—дип дәшәргә итә. Ходай Тәгалә атларга акылны мул бирсә дә, сөйләшергә телне кызганган.

Ике сәгать чамасы вакыт узды. Инде күз бәйләнеп килә. Җил дә зәһәррәк исә башлады. Мөнирҗан күнеленә ирексездән кереп оялаган хәвеф канатын һаман саен ныграк җәя бара. Ник чыкмый бу хатын? Бәлки кереп эзләргәдер? Ә кайдан, кем дип сорарга? Беләләрдер монда синең бер кечкенә авылдан килгән Евдокияңне! Әллә ташлап кайтып китәргәме? Юк, ярамас. Кеше бит тикмәгә гозерләнми. Никләр генә ризалашты. Ул инде хәзер чын-чынлап үкенә башлады. Мөнирҗан, инде күптән тагын бер йөк агач илтеп, Пелагея Трофимовнаның җылы өенә кайтып житкән булыр иде. Аннан сузылып ят та ял ит.

Больница янында торган атлар берәм-берәм кими торгач, берзаманны алар үзләре генә торып калды. Тәмам күз бәйләнде. Ниһаять, чанага таба өч шәүлә якынаюы күренде. Икесе кулларына бер капчык тоткан. Күтәрүләренә караганда, ул капчык бик үк җинел түгелдер. Артларыннан канатларын салындырган кош төсле, Евдокия атлый.

Капчык тотканнары ак халатлы ирләр булып чыкты. Йөкне чанага урнаштыруга, Евдокия:

—Көттергән өчен гафу итегез, зинһар! Поехали!—дип чанага менеп утырды. Татар авылында туып үссә дә, бу сүзнең мәгънәсен Күк биягә тәрҗемә итеп торуның кирәге калмады, килгән юлыннан Кама Аланына табан теркелди кереште.

Төнгә каршы һава суыта төште. Ләкин юлаучыларның куркасы юк, тун белән толып ул арада гына суык уздырмаячак. Тик буран чыкмасын да, бүреләр генә очрамасын. Бүреләрне быел күп диләр. Ач бүренең ничек тә корбанын бугазларга тырышасы билгеле. Бу явызлар исенә төшүгә, ул аяк

астындагы балтасын капшап тапты. Балта мылтык түгел түгелен, шулай да буш кулга караганда бераз ышанычны арттыра төшә.

Жай гына кайталар иде, кинәт чана салулап китте. Мондый гына салулаулар юлда булып тора, шуна күрә Мөниржан ана артык игътибар итмәде. Ләкин Евдокиянен:

—Останови!—дигән әмерен ишетеп, Күк бияне туктатырга мәжбүр булды. Баксан, чанадагы теге капчык төшеп калган икән. Юл читеннән өч-дүрт метрлар читтә ята. Мөниржан үзе генә күтәреп алып килеп салырга теләгән иде, кая ул, капчык шактый авыр булып чыкты. Әле Евдокия белән икесенә дә таманга туры килде.

Мөниржан түзмәде:

—Таш тутырганнармы әллә анын эченә?—дип сорады. Евдокия, әйтерсен, бу сорауны ишетмәде, жавап бирүдән тайчанды.

«Әйтмисен икән, үзенә үпкәлә». Мөниржан күнеленнән рәнжүле уй узды, ләкин бу хакта сүз куертып тормады.

Еракта Кама Аланынын сирәк утлары күренде. Сәгать ничә икән сон? Сигезләр генә бардыр. Капчыкны Евдокиянен чоланына кертеп куйгач, хужа хатын ихлас күнеленнән рәхмәтен укыды. Өстәл янына утыртты. Өйләрендә әнисе дә бар икән, үзара чыш-пыш килеп, тиз генә табын хәстәрләделәр. Мичтән бәрәнге тулы чуен чыкты, чирекле шешә белән өстәлдә көмешкә пәйда булды.

Тунмаган дисән дә, салкында озак булу үзенекен иткән иде, корсагы да ярсып-ярсып ашарга сорый. Арыганлыгы да бар, Мөниржан аштан да, көмешкәдән дә баш тартмады. Киткән чакта хужалар кәгазьгә төреп бер шешә көмешкә һәм киндер капчыкка салынган ике ипи бирде.

Кайтып, атын ишек алдына кертеп тугарганчы, капканы ябарга барган иде, кемнәрнендер сөйләшкән тавышын ишетеп, колак салды. Гайнияләр ягында икән.

—Кит, жибәр! Югыйсә каравыл кычкырып кеше чакырам!

Тукта, бу бит таныш тавыш. Гайния тавышы. Кем белән сөйләшә ул? Мөниржан колакларынын бар сизгерлеген эшкә жикте.

—Кычкырма, дура! Үз кадеренне анламыйсын. Бу чибәрлеген белән татарга әрәм син, понимаешь?!

—Анысы синен эш түгел. Жибәр, мин керәм!

—Ахмак, хәзер жиде-сигез хатын-кызга бер генә ир-ат туры килә. Минем сина күзем төшкәнгә куан гына.

—Бүтәннәр куансын. Минем сөйгән егетем бар.

—Төкерәм мин синен егетенә!

Кем булыр бу? Бу сөйләшүне ничек тыныч тынлап тормак кирәк?!

—Ярдәм итегез!—Гайния сүзен әйтеп бетерә алмады, авызын томаладылар ахры.

—Ах, син, сука, әле тешләшәсенме? Мә, ал кирәгенне! Синен кебекләрне мин сугышта видал-перевидал!

Күрше ихатага кадәрге араны Мөниржан ике атлап бер генә сикерде. Хәрби киемдәге берәү Гайнияне сарайга сөйрәп маташа иде. Мөниржан мәче житезлеге белән бу кабәхәтне якасыннан эләктереп алды һәм өзелгән кулы белән Степаннын—ул аны шунда ук таныды—касыгына төртте. Шактый салмыш Степан сыгылып төште. Ул арада ачудан үзен тыя алмас хәлгә килгән Мөниржан исән кулы белән анын чыраена тондырды. Степан каршылык күрсәтергә тырышып караган иде дә, Мөниржан «герой»ны сугып аударды һәм типкәли башлады. Әле генә ирексезләп мәхәббәтен тәкъдим иткән кавалер, беренче форсат булу белән, чыгып йөгерде. Капканын теге ягында, үзенә бүтән куркыныч янамавын күреп, әтәчләнеп кычкырды:

—Сука, әле минем аска үзең шуып керерсең! Мин әле сезгә күрсәтермен!

Коты очып бер читтә басып торган Гайния Мөнирҗанның күкрәгенә килеп капланды һәм сулкылдап елап җибәрде:

—Рәхмәт!—Ул бары шушы сүзне генә әйтә алды.

Мөнирҗан бу мизгелне күпме көткән, Гайниянең үз янәшәсендә торуы хакында күпме хыялланган иде. Ләкин бу хәлнең нәкъ менә биредә—Әскәйдән ерак бер кечкенә урыс авылында—Ханифнең сер бирмәс кызы күкрәгенә башын салыр дип күз алдына ялгыш та китереп карамаган иде. Кызның ни халәттә икәнен күреп, ул сораулар биреп йөдәтмәде, чәченнән, яшькә чыланган битеннән исән кулының бармаклары белән сыйпады һәм үзе дә сизмәстән, иреннәренә үрелде.

Аның иреннәре кагылуга, Гайния дерт итеп китте. Күрәсең, эш моңа кадәр барып җитәр дип уйламаган булгандыр. Ләкин бу халәт бик тиз узды һәм ул да, күңелендә кайнаган янартаулар ихтыярына буйсынып, шашып үбешергә тотынды. Егет аяклары сыгыла барган кызны күтәреп, үзләренә алып кереп китте.

—Нишлисең?

—Мин сине берәүгә дә бирмим. Матурым син, кадерлем син!..

Юк, кызны ул өйгә алып кереп тормады, чанасына утыртты. Баядан бирле үзен тугарганны көтеп арыган Күк бия, аптырап, хуҗасына карады. Мөнирҗан исә атын борды да юыртып чыгып китте. Чана үрәчәсе хәтта капка баганасына орынды.

Гайния бераз ушына килә башлаган иде инде:

—Нишлисең, кая алып барасың мине?—дип куркынып сорады. Ул үзенең нинди зур хәвефтән котылып калганын аңлап бетерә алды микән?

—Борчылма, Гайниябану, барысы да әйбәт булыр,—дип, күтәренке күңел белән җавап кайтарды Мөнирҗан.—Күрше авылга барып, мулладан никах укытып кайтабыз. Мин сине беркемгә дә бирмим. Бирмим, бирмим!—дип кабатлады ул.

—Мөнир, бәгърем, тукта, син бит берни дә белмисең.

—Белмим дә, беләсем дә килми!

—Тынла инде...

—Юк, тыңламыйм!

Минуты ай, сәгате ел,
Гайниябану, сылуым, иркәм,
Шулкадәрле сагындым.

Бүген үк, Гайния, сиңа өйләнмәсәм, йөрәгем ярылып үләчәкмен!

Мөнирҗанның күңеле тантана итә. Ул Гайниягә сүз әйтергә дә ирек бирми: йә туктаусыз сөйләнә, йә кочагына кысып, иреннәреннән, салкын яңакларыннан үбә.

Татар авылында инде күбесе йоклаган, сирәк йортларда гына ут күренә. Керосинына да кытлык бит аның, шуңа күрә авыл халкы иртә ята йокларга.

Мөнирҗан уты янган беренче йортка керде. Өйдә башына түбәтәй кигән карт белән ак яулыклы карчыктан башка кем дә юк иде. Сәлам биргәннән соң, мулланың кайда торганын сорады.

—Безнең мулланы сөрделәр шул,—дип җавап бирде йорт хуҗасы, төн уртасында кергән бу сәер кунакка гаҗәпсенеп карап.

—Соң татар авылында җеназа укучы, исем кушучы булмый калмас бит инде. Әллә соң ясин чыкмыйча гына күмәсезме?

—Син, энем, көфер сүзләр сөйләмә,—диде карт ачулана төшеп.—

Йомышын нидә, әйт. Үзең кем буласың? Бер дә күргән-ниткән кешегә охшамагансың. Берәр мосафирмы әллә?

Әйтергәме, әйтмәскәме? Әй, Мөниржан нәрсә югалта соң! Гайния, чанада утырып, көтә-көтә көтек булып беткәндер инде.

—Син, бабай, безне белмисең. Без сезнең күрше урыс авылында урман кисәбез.

—Алай икән. Ишеткән идем шул. Ә мулла ник кирәк булды?

Мөниржан уратып тормады, тәвәккәлләп, йомышын әйтеп салды:

—Безгә, бабай, хәзер үк никах укытырга кирәк иде!

—Әстәгъфирулла тәүбә! Шушы төн уртасындамы?—Бабайның карчыгы гаҗәпләнүдән кулларын шап итеп аякларына сугып алды.—Бер дә көтәрлегегез калмадымыни? Әллә, Ходаем, бәбәй алып кайтырга җыенасызмы?

Карчыкның бу соравыннан оялып, Мөниржан кая карарга белмәде. Нинди бәбәй ди ул! Моны күреп, бабай карчыгына:

—Сиңа әйтәм!—дип бер генә карады, әби шым булды.

Шулай да Мөниржан әбигә җавап бирде:

—Юк, әбкәй, барысы да тәртиптә. Минем авылдаш кызым ул. Сугышка озатып калган иде. Кама Аланында урыс егетләре бәйләнеп җанына тия. Әле яңа аралап алдым бер кабәхәтеннән. Никахсыз гына бергә яши башласак, зур гөнаһ булыр дибез. Ярдәм сорап килдек.

Картның йөзе яктырып китте.

—Бәрәкалла!—диде ул сөенеп,—Әле инсафлы яшьләр дә бетмәгән икән.—Аннан сынаулы караш белән,—кыз ризамы соң? Үзе кайда?—дип сорады.

—Монда гына. Чанада утырып тора.

—Алып кер алайса, Ходага тапшырыйк.

Мөниржанның күзләре маңгаена сикерде:

—Ничек? Ә кем укый ул никахны? Безгә бит чын мулла, чын никах кирәк!

—Бәхетле бала икәнсең, улым. Хәзрәтне сөргәннән соң, авылда йоланы башкару миңа калган иде.

Бабай сүзен әйтеп бетерүгә, шатлыгын тыялмаган Мөниржан Гайниясе янына чыгып йөгерде һәм, атын бәйләп, инде туңа башлаган Гайнияне җилтерәтеп өйгә алып керде.

—Бабай, без әзер!

Теле бик кычытса да, баягы кисәтүне онытмаган карчык бүтән сорау бирмәде, бары тик күзләре белән Гайниянең корсак тирәсен капшады.

—Йә, балалар, түргә узыгыз. Кызым, исемең кем инде синең? Гайнияме? Бик күркәм, бик мәслихәт. Инде әйт, бу егет чын сүз сөйлиме, әллә иләсләнеп кенә йөриме?

—Нинди иләсләнү ди ул, бабай! Йә, әйт инде, Гайния, сүзеңне!

—Чын сөйли,—диде Гайния кыяр-кыймас.

—Алайса тәһарәтемне генә янартыйм да Ходайның ризалыгы белән үзегезне шәригать хөкеменә тапшырыйм. Никах уку бик саваплы гамәлләрдән санала.

Шартын туры китереп, бабай ашыкмыйча гына Мөниржан белән Гайниягә никах укыды. Ул арада хуҗа карчык самавыр да кайнатып өлгерткән икән.

—Балалар, чәй эчеп алыгыз да бездә генә йоклап китәрсез,—диде ул ягымлы тавыш белән. Карчыгының бу гамәлен карты да хуплады:

—Маладис якларың бар да инде, карчык,—дип мактап алды.

Көтелмәгән тәкъдимнән яшьләр бер-берсенә караштылар.

—Кыенсынмагыз, без түрдә йоклярбыз. Әбиегез сезгә алгы якка җәяр.

Гайния хәзер чарасыз, Мөниржан ничек теләсә, Мөниржан исә хәзер аның никахлы ире, шулай булсын. Ул хәл итсен. Аның исә үз кайгысы кайгы.

Ә Мөниржан чынлап торып уйга калды. Ул бизмәнгә тегеләй дә, болай да салып карады. Никахлашкан төнне аерым йокламаслар бит инде алар. Үз фатирларына бергә кайтырлар иде, Пелагея түти белән аның сеңлесе ни әйтәсен белми. Аннан соң алар кайтып җиткәнче, төн уртасы да җитәр, ятып торасы да калмас. Фазыл да бар бит әле. Гайния яшәгән апалы-сеңелле ике марҗа янына кайтуны уйлыйсы да юк. Шулай булгач, куана-куана бу тәкъдимгә ризалашырга кирәк.

—Сезгә мәшәкать тудырабыз бит. Болай да изгелегегезне ничек бәяләп, бәхилләп бетерербез. Исемегезне дә сорамадык.

—Син, улым, юкка борчылма,—диде карт.—Исемгә килгәндә, мин Габдулла бабагыз, ә карчык Гашүрә әбиегез булыр. Әйдәгез, чәй эчеп алыйк. Бәхетле тормыш сезгә, балакайлар! Улларыбыз исән-сау кайта алган булсалар, без дә аларны башлы-күзле итеп, оныклар сөяр идек тә бит, булмады. Олысы Мәскәү янында, кечесе Курск дугасында ятып калды. Уртанчысы хәбәрсез югалды. Менә син, улым, сугышта булган кешегә охшагансың, Ризатдинов фамилияле кешеләр белән очрашырга туры килмәдеме?

—Юк шул, юк. Кемнәр белән генә бергә сугышмадык, Ризатдинов фамилияле кешеләр белән очрашырга туры килмәде. Хәбәрсез югалганы бәлки табылыр. Әле һаман кайткалап торалар бит.

—Алла кулында инде, улым, Алла кулында. Йә, ярар, балалар, хәзинәдә барыннан җитешегез, сыебыз сыек дип гаепләмәгез.

Шул чакта Евдокия биргән икмәк Мөниржанның исенә төште һәм:

—Минем атым да урамда калды, чыгып кына керим әле,—дип урыныннан кузгалды.

Ул дулкынлана иде. Хәтта гомер булмаганны чөелдерекне чишә алмый интекте. Атын тугарып бетергәч, өстенә Марфадан онытылып калган толыпны ябып, Күк бияне Чулман болынының хуш исле печәненә кушты. Печәннән Евдокия бераз өлеш чыгарган иде.

Кызык бу тормыш. Уйласаң, чәчләрең үрә торырлык. Бер-берсеннән бик ерак тоелган нәрсәләр дә кайвакыт күзгә күренмәс җепселләр белән үзара шулкадәр тыгыз бәйләнгән—гаҗәп! Менә кара инде: әгәр Гыйният абзасы аңа Марфаны Ширәмәткә илтергә кушмаса, ул фатирына иртәрәк кайтыр иде. Иртә кайтса, Степанның Гайниягә бәйләнүен, ихтимал, белми дә калыр иде. Белмәгәч, Гайнияне күрше авылга алып барып, никах укыту форсаты чыкмас иде. Шул ук Евдокиянең йомышын йомышламаса, бу ике түгәрәк ипи аның кулына кермәс иде. Ә ипиләр булмаса, никах укыган өчен ничек бәхилләр иде. Кесәсендә шымытыр бит. Ә бәхилләргә тиешлеген, хәтта никах укучы моны өмет итмәсә дә, белә ул. Икмәк исә бу елларда алтыныннан да, акчаңнан да кыйммәтрәк бүләк.

Мөниржан алып кергән тегермән ташы кадәр ике икмәкне күргәч, Гашүрә карчыкның күзеннән яшь чыкты.

—Чын ипекәйләрне дә күрер көн бар икән!—Аның икмәкне күкрәгенә терәп кисүдән искитмәле ләззәт алганы күренә иде. Болай иттереп гомере буе икмәк үстереп тә бик күптән туйганчы чын икмәк ашамаган кеше генә кисә ала.

Менә бит ул язмыш дигәнең: сөйгәнең белән кавышып, зөфаф киченне туган авылыңнан еракта, беренче тапкыр бусагаларын атлап кергән кешеләр өендә уздыр инде. Чәй эчкәндә Мөниржан күңеленнән шундый уйлар узса, Гайния үзе өчен хәлиткеч минутлар якынлашуын тоеп тетрәнә иде. Аның курку хисе көчәйгәннән көчәя бара. Яткач, иң кадерле җимешенә корт

төшүе беленәчәк бит. Мөниржан ни дияр, анларга тырышырмы? Юлда чакта үзенең гыйффәтле кыз түгеллеген ни әйтергә теләде, әйттертмәде. Әллә хәзер берәр сәбәп табып чыгып качарга һәм Мөниржан белән бүтән бер дә очрашмаскамы? СССР зур бит. Әнә төрле төзелешләргә, Урта Азия якларына күпме кеше китте. Бер Гайниягә генә урын табылыр әле. Ул китәр дә котылыр, ә Мөниржан ни эшләр? Ярата бит ул аны, ярата!

Чәй тәмамланды, ут сүнде. Бәлки менә хәзер әйтергәдер. Әмма яту белән Гайнияне Мөниржан шунда ук кочагына алды, икесенең дә сулышлары кысылыр хәлгә җиткәнче, шашып-шашып үбәргә һәм кыз өчен тансык, күнелен иркәли торган берсеннән-берсе матур татлы сүзләр пышылдарга тотынды. Әче хакыйкатьне әйтергә Гайния тагын омтылды, ләкин Мөниржанны инде тотып тыярлык түгел иде...

Хатын-кызлар дөньясы Мөниржан өчен галәмдәге ерак караңгылык кебек үк билгесез иде. Ул белгән беренче хатын-кыз Сәлимә булды ( авыр туфрагы җинел булсын ). Дөрес, фронтта да, авылда да адәмнәрнең бу темага шапырынганнарын тыңларга туры килгәләде. Ләкин ишетү бер нәрсә, ә менә үз башыңа төшкәч исә...

Әйе, ул тәҗрибәсезен тәҗрибәсез, ләкин Гайниянең кызмы, түгелме икәнен аңламаслык ахмак түгел. Әйтерсең, аның башына күсәк белән китереп ордылар. Бәлки ул ялгышадыр, бәлки аның шик-шөбһәсе урынсыздыр...

Хәлиткеч мизгелне тойган Гайния үксеп еларга кереште. Мөниржанның да дәрте кинәт сүрелде. Ул вазифасын да төгәлли алмыйча кырыйга ятты һәм:

—Кем?—дип кенә сорады. Кайда, кайчан дигән сораулар киләчәккә калды.

—Мөниржан бәгърем, гафу ит. Минем бит синнән качып йөрүем дә сөймәгәннән түгел, үземне саклый алмаган ояттан иде. Хәтта Сәлимә белән кунганыңны ишеткәч тә рәнҗемәдем.

—Син аны белдеңме? Каян ишеттең?—Мөниржанның гаҗәпләнүенең чик-чамасы булмады.

—Һи, авылда һәр капка баганасы күз, коймалары колак бит, Мөниржан. Икенче көнне үк бөтен авыл сөйләде.

—Алай икән...

—Ләкин, әйтәм ич, мин сиңа үпкәләмәдем. Чөнки үземне сиңа лаек санамадым. Монда килгән чакта никах укыганчыга кадәр ничә тапкырлар әйтергә омтылып карадым, ирек бирмәдең. Кичерә алсаң, кичер, гомерем буена турылыклы хатының, йомшак түшәгең булырмын, чәчем белән җир себерермен. Кичермисең икән, синең эш, хәзер үк талак ит. Син яшь, саф, гыйффәтле кызга өйләнерсең. Әле соң түгел. Монда булган монда калыр.

Гайниянең яшьләре Мөниржанның шәрә күкрәгенә тамды. Хәзер егетнең күңелен бер генә сорау талкый:

—Кем?

Бу сорауга җавап бирүгә караганда, җан бирүе, ихтимал, җиңелрәктер. Ләкин моңа җавап бирми торып, тормыш алга таба дәвам итмәячәк, вакыт шул ноктада туктап, әлеге сорауга эленеп калачак иде.

Мөниржан хәлиткеч соравын өченче тапкыр кабатлады. Кыз үзен бу хәлгә төшерүченең исемен телгә алырга ничекләр генә теләмәсен, барыбер әйтергә мәҗбүр булды:

—Мисбах...

—Кайсы Мисбах?

—Хисапчы...

—Теге аксак шайтанмы?

—Шул инде.

Менә сиңа мә! Гайниянең кыз буларак асылы ачылгач, Мөнирҗан, гөнаһлы баштан, Хәсьяновтыр дип уйлап куйган иде. Үзе таза, үзе чибәр, иң мөһиме, колхозның чыбыркысы аның кулында. Аның кулында власть, ул колхозда үзе закон. Теләсә кемеңне сузылып ятарга мәҗбүр итәр. Кайтканнан соң, Гайнияне эзләп, кәнсәләргә баргач та бик төксе күренгән иде.

Гарьлегеннән Мөнирҗанның тыны кысылды. Бәлки ул бу минутта бик-бик нык кычкырыр да иде, дивар аша үзләренә якты чырай күрсәткән, аларны кавыштырган мөхтәрәм карт белән карчык ята. Ярамый. Яр-раммый! Ул йөрәген яндырган, иренен көйдергән сүзләрне тешен кысып кына чыгарырга мәҗбүр булды:

—Алай бик дәртеңә чыдый алмагач, юньлерәк адәм беткән идемени, шул чатан тәрегә бирмәсәң?! Икенче аягын да сугып сындырам мин ул өч тәпинең!

Гайниянең елавы көчәя барды һәм, күз яшьләренә буыла-буыла, каһәрле буранлы төндә колхозның Доха карчыклардагы фатирында булган хәлләрне Мөнирҗанга бәян итте.

—Әкият!—Үзен хөрмәт иткән һәм чак-чак кына булса да акылга зәгыйфь булмаган кайсы егет моңа ышансын. Акланыр өчен Гайния ниләр уйлап чыгармас.

—Ышансаң ышанасың, ышанмыйсың икән—анысы синең эш.—Ачы хакыйкатьне сөйләп биргәч, Гайниянең өстеннән гүя авыр йөк төште. Күпме сакларга була шундый күңелең теләмәгән нәрсәне!—Икмәк белән ант итәм, мин бары тик дөресен генә сөйләдем. Ходай шаһит.

—Ходай шаһит, Ходай шаһит!—дип үртәлде Мөнирҗан.—Аннан миңа ни файда?!—Аның тагын кычкырасы килде.

—Минем тәкъдим үз кулыңда кала.—Бу юлы ул елаудан туктаган, Гайниянең тавышы тыныч иде.—Әйтәм ич, теләмәсәң талак ит, әле соң түгел.—Ул торып киенә башлады.

Ни эшләргә? Егет ике ут арасында калды. Бу шундый да четерекле хәл ки, башка берәү белән киңәш-табыш итеп тә булмый. Моның белән чагыштырганда фронтта өстеңә пуля явуы да чүп кенә сыман. Анда синең өчен күбрәк командирың уйлый, командирың хәл кыла. Ул командир өстеннән дә командир, юлбашчыбыз Сталин бар. Башкалар ялгышканда да иптәш Сталин ялгышуны белми. Аның акылы һәм кулы җитмәгән җир юк. Кодрәте чиксез. Әгәр дә даһи Сталин монда булса, нинди киңәш бирер иде икән?

Алар сүзсез озак яттылар—бер-берсенә чит тә, газиз дә булган ике җан. Ниһаять, Мөнирҗан бер карарга килеп, торып утырды һәм күлмәген кияргә өлгергән Гайнияне кабат кочагына алды.

—Мин синсез яши алмыйм,—дип пышылдады ул.

Кыз ни әйтсен?

—Мин дә,—дип күңелендәгене ачып салды.

—Мисбах турында оныт, яме!

—Мин онытырга тырышырмын, ә син үзең оныта алырсыңмы?

Җавап урынына егет кызның иреннәренә капланды.

Алар бик озак яратышты. Гайния сөйгәне кочагында үзен искиткеч бәхетле сизде. Хәтта ул, ни гаҗәп, оялуын да онытып торды. Йа раббым, ләззәтнең мондые да була икән! Берүк бездән бәхетне кызганма!

Хуҗаларга рәхмәт әйтеп, яна өйләнешкән ир белән хатын караңгылыяктылыда Кама Аланына кайтып китте.

Фазыл инде күптән аякта иде. Мөнирҗанны күрүгә, дустын битәрли келеште:

—Кайда йөрисең син? Киттең дә югалдың. Берәр нәрсә булдымы әллә?

Куанычын тыя алмаган Мөниржан Фазылның кайнана кебек сорау алуына елмаеп, серле генә җавап бирде:

—Бик мөһим эш белән йөрелде.

—Соң аны әйтеп китәргә ярамый идемени?

—Вакыт булмады, дустым, вакыт булмады, гафу ит.

—Нигәдер авызыңны җыя алмыйсың әле син! Гел инде кыз куеныннан чыккан кияү егете төсле.

Мөниржан шаркылдап көлеп җибәрде:

—Нәкъ өстенә бастың, сыер икәнсең!

Фазылның хәтере калды:

—Мин синнән чынлап сорыйм, ә син ихахайлап җавап бирәсең. Кайда булдың, дим мин сина!

—Нәкъ син әйткән җирдә.

—Ягъни мәсәлән, кайда инде ул?

—Бигрәк хәтерең начар икән! Әле генә әйттең ич, кыз куеныннан чыккан кияү төсле дип. Белмәсәң бел, үскәнем: абзаң өйләнде.

Фазылның күзләре маңгаена менде: чынлап сөйлиме бу, әллә шыттырамы?

—Шаяртма инде.

—Кем шаярта? Һич кенә дә шаяртмыйм, дөресен сөйлим.

—Кемгә? Неужели берәр марҗага? Алдан ук әйтеп куям, марҗага өйләнсәң, туеңа да бармыйм, дус та санамыйм!

—Бигрәк хәтәр кеше икәнсең. Тынычлан, марҗаң үзенә булсын. Тынычлан, йә йоклый алмассың, әйтәм: Гайниягә!

Фазыл өнсез калды.

—Яки мин аңгыра, яки син дурак,—дип нәтиҗә чыгарды ул ахырдан, ни әйтергә белмәгәч.

Мөниржанга хәлнең ничек булганын сөйләп бирүдән башка чара калмады. Әлбәттә, Гайниянең кызлык намусына, Мисбахка кагылышлысын әйтмәде.

—Үзең дә бер мыштым икәнсең,—диде Фазыл, тыңлап бетергәч.—Менә дус дип йөр инде сине. Гайния исемен теленә дә алмадың бит.

—Карале, теге Степанны әйтәм, нинди кабәхәт кеше булып чыкты. Әллә үзең тотып ярыйммы?

—Кирәкми, сасысы чыгар. Мин ярганы да җиткән.

Урманчылар арасында яңа хәбәр күз ачып йомганчы таралып өлгерде. Очраган берсе яшьләрне котларга ашыкты. Хәтта бригадир Гыйният абзасы да:

—Әйбәт кызны эләктергәнсең, бәхетле яшәгез,—дип кулын кысты.—Әллә бүгенгә ял биримме?

—Кирәкмәс.

—Тешәү елны хәл бик булмый дип кенә әйтүем!—карт төлке белә шул ничек төрттерергә.

Мөниржан белән Фазыл бер рейс ясап, төшкелеккә кайтканнар иде, урамнан табут күтәргән халык узып китте. Алда баручыларның берсен таныды Мөниржан—ул кичә үзе утыртып алып кайткан Евдокия иде. Күңеле сизенеп, хуҗа хатын Пелагеядан сорады:

—Кемне күмәләр? Нәрсә булган?

—Евдокиянең ирен,—дип җавап бирде Пелагея түти.

—Нишләп үлгән?

—Сугыштан яраланып кайткан иде, мантымады. Аякларында гангрена башлангач, икесен дә бот төбеннән кискәннәр. Барыбер үлгән, мескен.

Әҗәлең житсә, кем дә коткара алмый шул.—Пелагея Трофимовна почмакка карап чукынып алды.—Кичә алып кайткан. Саклап больницада ята иде.

Шунда Мөнирҗанның башына кичә нинди капчык алып кайтканлыгы барып житте. Әйтмичә, бәлки, Евдокия дөрес эшләгәндер. Белсә, мондый йөкне чанасына салдыртыр иде микән?

Тиздән кайтасы булганга, Гайния белән Мөнирҗан, һәркем үз фатирында яшәп торыр дип килешкәннәр иде. Чыннан да ике-өч көн өчен кайда яңа оя корасын.

Сәлимә мәрхүмә фатирда торган Ксения кайдан ишеткән дә ничек башы житкән диген, эштән кайтуларына:

—Мунирка, бар кәләшең белән кияү мунчасына,—дип шаккаттырды. Ярамаган эш өстендә тотылгандай, Мөнирҗан кызарып чыкты. Ләкин ул күп сөйләшергә ярата торган күрше марҗасына бу минутта бик рәхмәтле иде. Чынлап әйтәсеңме дигәндәй, әле Ксениягә, әле Пелагея Трофимовнага карады. Аннан, дулкынлануын яшерә алмыйча:

—Кайдан белдегез?—дип сорады.

—Саесканнар хәбәр итте,—дип шаяртты Ксения.—Ярар, бар-бар, кәләшеңне ал да сыпырт мунчага. Беренче мунча тәмле була ул. Әйе бит, Трофимовна!—Ксения шактый кабарынкы түшләрен селкетеп, куллары белән ботларын чәбәкләп куйды.—Ух!

—Фу, тебя, бестыдница!—Йорт хуҗасы Ксениядән читкә борылды.

—Что естественно, то не безобразно! Шуны онытма,Пелагея Трофимовна!

—Син аңа карама, Мунирка.—Пелагея Трофимовна күршесе өчен чын-чынлап уңайсызлану хисе кичерде.—Ә мунчага чынлап та барырга кирәк.

Гайнияне мунчага барырга озак үгетләргә туры килде. Үткән төннең мажараларыннан ул көне буена бәхетле, шул ук вакытта җанына тынычлык тапмый йөрде. Дөрес эшләдеме ул язмышын Мөнирҗан белән бәйләп? Мисбах белән булган хәлне исенә төшереп, җанын талкымасмы? Онытыйк дип әйтүен әйтте дә бит. Андый нәрсә алай җиңел генә онытылыр микән? Кайчан булган хәл, Гайниянең күңеле һаман урынына утырганы юк.

Аннан соң ничек инде мунчага бергә барасың? Баргач чишенергә туры киләчәк бит. Оялмыйча! Шул минутта Гайниянең никахтан соң үзләре генә калгач, яратышулары исенә төште һәм тәненә рәхәт дулкын таралды. Акыл белән уйлаганда, ник оялып торырга? Алар бит хәзер ир белән хатын. Берберсенә таяныч, тормышның авырын-җиңелен дә, шатлыгын-кайгысын да бергә бүлешергә, бергә-бергә тупырдап торган уллар, кызлар үстерергә тиешле кешеләр. Аларның ничә баласы булыр икән? Гайния беренче баласын имезер өчен күкрәгенә алган мизгелне күз алдына китерде. Шушы уйдан тәне рәхәтләнеп чемердәп киткәнен тойды.

—Әйдә, Гайния.—Мөнирҗан Әскәй гадәте буенча «карчык» дип дәшәргә уйлаган иде дә, кыюлыгы житмәде.—Әйдә барыйк, мунчаны үпкәләтергә ярамый.

—Оялам,—диде кыз ихластан.

—Соң безгә барыбер бер-беребезгә күнегергә туры киләчәк бит.

—Шулаен шулай да...

—Күтәреп кенә алып барыйммы?

—Көчең житмәс. Авыр бит мин.

—Һи, Гайния, әйт кенә, син әйтсәң, үзеңне күтәреп, артыма чана тагып, Әскәйгә кадәр алып кайтам!

—Юләр!—Гайния көлде дә Мөнирҗанның яңагыннан үбеп алды.

—Киттек.

Мунчага житәрәк туктап, Гайния:

—Син бераз көтеп тор. Башта мин кереп чишеним,—диде.

Гайния алдында батыр күренергә тырышса да, Мөниржан үзе дә кыенсына иде. Ләкин ул шушы чибәркәйнен ире. Ире икән, ир булырга кирәк!

Ул кергәндә, Гайния ләүкәгә менеп, аның иң ерак почмагына поскан иде. Чишенүгә, Мөниржан ташка бер чүмеч су салды. Кечкенә мунчаның һәр тарафына өтәли-өтәли кытыклаучы хуш исле пар таралды. Ул себерке алды да, Гайнияне яткырып, аркасын чәбәкләргә кереште. Яшь хатынның оялуы сәбәпле туган киеренкелеге торган саен кимеде. Ул инде исе җәйге урманны хәтерләткән себеркенең тәненә тию мизгелен көтеп ала. Аның тәне генә рәхәтләнеп калмый, гүя ул шул рәвешле табигать белән, гүзәллек белән очраша.

Аркасын туйганчы чапкач, Мөниржан:

—Борыл!—дип әмер бирде.

Бу әмергә ничек буйсынганын Гайния башта сизми калды. Сизгәч, шунда ук куллары белән кендектән түбән җирләрен каплады. Мөниржан мона игътибар итмәде—себерке белән хатынын чабуын белде.

Гайния соңыннан гына бер нәрсәгә игътибар итте: тәнен әнисе дә, дус кызлары да, үзен инде әйткән дә юк, чабып караганнары бар. Ләкин берсе дә бүгенге кадәр үк рәхәт булмаган икән. Аның тәне изрәп, җыеп ала алмас хәлгә килде. Шунда Мөниржан, туктап, башта Гайниянең өстенә, соңыннан үзенә салкын су койды. Көтелмәгән салкын Гайниянең мондыйга өйрәнмәгән һәм моны көтмәгән тәнен өтеп алды. Ул, сулышы кысылып, әле генә оятын каплап торган кулларын җәеп җибәрүен сизми дә калды.

—Ай, әнекәем!

Хатынының бу хәрәкәтеннән Мөниржан рәхәтләнеп көлде дә аны янә чабарга кереште. Берзаман Гайния аңына килде:

—Җитәр, Мөниржан, арыгансыңдыр. Китер себеркенне, үзенне чабыйм!

—Икенче мунчада, яме. Җитәр дисән, кил, төшерәм.—Ул Гайния «әйе», «юк» дияргә өлгергәнче, аны күтәреп алды һәм себерке белән чабудан куе-кызыл чия төсенә кергән ими башларына иреннәрен тигезде. Мөниржанны кочаклап алганын Гайния сизми дә калды.

Кама Аланының җир иданле шушы кара мунчасы аларның гомерләре буена хатирә булып, күңелләрен җылытачак әле.

Гайния акча алып килгән булган икән, татар йоласын истә тотып, мунчадан үзләре кайтып киткән чакта, утызлыкны күренә торган җиргә куеп калдырды.

Ура! Әскәйләр өчен 1946 елның урман каторгасы бетте. Соңыннан монда килүчеләр аны «Сәлимә үлгән ел», «Мөниржан белән Гайния өйләнешкән ел» дип искә төшереп сөйләячәк. Рәсми тарих моны ничек теркәр, әмма Әскәй авылы халкы хәтерендә шулай калачак. Халык исәбенең үз тәртибе бар.

Хәниф картлар, кызларын күзләрен күгәртеп көтсәләр дә, яшь гаилә туп-туры Мөниржаннарга кайтып төште. Урманнан чак кына алданрак кайтучылар Габделихсан абзый белән Минсафа карчыктан сөенче алырга өлгергән иде инде. Бу хәбәрдән аңнарына килеп бетмәсәләр дә, Минсафа үзенең киленен ишек төбенә бала каз мамыгыннан эшләнгән яңа мендәр салып каршы алды. Йола буенча Гайниягә бал да каптырган булыр иде дә бит, анысының тәме онытылган, сугыш башланганнан бирле өйләренә кергәне булмады. Алдан белсә, ничек тә бераз юнәтми калмас иде үзе. Бигрәкләр дә көтмәгәндә булды шул. Кышкы күк күкрәү шикелле. Ышанасылары да килми...

Урманчыларның кайтыр көне билгеле булганга, Исламовлар улларын хәзинәдә барын хәзерләп көтә иде. Ашап-эчкәч, алдан сөйләшкән буенча, яшь пар Гайнияләргә китте. Алар белән дә күрешергә, фатихаларын алырга кирәк ич.

Авылда хәбәрнең ничек тиз таралуына исең-акылың китәр. Гайниянең урманнан башта туп-туры Габделихсаннарга кайтуын ишеткәч, Хәниф картның башта бераз хәтере калган сыман иде. Тора-бара килеште: анда кайттылар ни дә, монда кайттылар ни. Кыз бала туган йортында бары кунак кына—вакыты җитте исә, канатын җилпи дә, оясыннан очып китә. Үзенә дә бит Тәзкирәсе ябышып чыкты. Сугыш елларында, аннан соң да хатын-кыз азды, ирләр кытлыгы үзен нык сиздерә. Уйнашчы дип телгә керүчеләре дә, уйнаштан бала табучылары да бар. Алар авылында гына шулай булса бер хәл, иле белән шулай диләр бит. Аллага шөкер, Гайнияләре яман ягы белән мир теленә эләкмәде. Үзен, никахлар укытып, кияве куенына тапшырган икән, бәрәкалла дими ни диярсең. Халык алдында карчыгы белән аның, нәселләренең йөзе ак, күңелләре тыныч. Тик шуны аңлый алмый Хәниф абзый: кавышуны аны кешечә, Әскәй йолаларына, татар, мөселман гадәтенә туры китереп тә эшләргә була иде бит. Ник ашыкканнар? Яшьләр шул, аларның законнары үзләре белән.

Уйларыннан аны капка шыгырдавы бүлде. Дегеткә кытлык булгач, майлаганы да юк. Ачкан-япкан саен шыгырдап тенкәләренә тия.

Хәниф карт буш вакыты чыгудан файдаланып, чабата үрә иде. Өйрәнелгән гадәт буенча, ул тәрәзәгә күз салды һәм кереп килүче Мөнирҗан белән Гайнияне күреп, мич тирәсендә мәш килүче карчыгына дәште:

—Сина әйтәм, Гайния кайтты!

Карчыгы Тәзкирә каушаудан корымлы кулларын чиста алъяпкычына сөртте.

—Үзе генәме, әллә к-к-кияү б-б-беләнме?

Гомер булмаганны, Тәзкирә кинәт тотлыкты.

—Күрмисенмени? Әнә ич кияү белән! Әйдә, тиз бул, аңгыраеп торма, каршы чыгып алыйк!

Алар нәкъ вакытында чыгып өлгерде. Яшьләр, ишек төбенә килеп җитеп, итекләренә иярган карны каз канаты белән себереп тора иде.

—Кайттыгызмы, балалар?—Кайтканнарын күрә торып кайттыгызмы дип сорау бәлки мәгънәсезлектер дә. Ләкин ни эшләсеннәр, телләренә килгән беренче сораулары шул булгач.

—Исәнме, әтәй!—Гайния башта атасына кул бирде, соңыннан әнисен барып кочаклады.

—Нихәл, бабай!

Мөнирҗан Хәниф картка күрешергә кул сузды.

—Аллага шөкер, кем...Мөнирҗан...—Ахыр чиктә ул «кияү» дип тә өстәде. Әллә кем малаена кияү диюләре бер дә җинел түгел икән.—Исән-сау кайтып җиттегезме? Бик авыр булмадымы?

—Ничава, бабай, без бит төрлесен күргән!—Мөнирҗанның һич кенә дә бабасы алдында сер бирәсе килмәде.—Менә, кызыгызны да алып кайттым әле, урманда адашып йөри иде. Ә ул урманнарда аюлар, бүреләр һәм... урыслар йөри...

—Мөнирҗан!

Кирәк чакта бу Хәниф кызы назлы гына кылана да белә икән. Һәм килештерә дә бит чукынчык!

—Балалар, әйдәгез, өйгә керик. Йә самавырым ташып түгелер.

Өйгә уздылар. Табын янында ата-ана сагындырган кызларын һәм беренче тапкыр бусагаларын атлап кергән кияүләрен хәзинәдә бары белән кунак иткәч, үзеннән-үзе туйлап озату хакында сүз кузгалды. Никах

укылган, тукыласы тукылган, алар инде хәзер ничә көн ир белән хатын булып яши.

Инде авыл советына барып рәсмиләштерәсе, туган-тумача, күрше-күлән, дус-ишне җыеп, кызны кыңгыраулап озатасы иде. Кызлары мона лаек, ул азып-тузып, исеме белән ата-анасын рисвай итеп йөргән бала түгел, хакы бар. Ахыр чиктә бергәләшеп уртак фикергә килделәр: бүген яшьләр Мөнирҗаннарда куна, иртәгә исә кызыл туйга тартым мәҗлес ясап алырлар да, берсекөнгә, Аллаһы боерса, шартын туры китереп, Гайния килен булып төшәр.

Йоласына һәм шәригатькә ни дәрәҗәдә туры киләдер, бу сөйләшүгә Хәниф абзыйдан бигрәк Тәзкирә түти куанды:

—Үстереп-үстереп тә, кызыңны кияүгә адәм-рәтле итеп бирмәгәч! Болай, ичмасам, кешедән оят түгел,—дип сөенечен яшермичә сөйләнде ул.

Туйлагач, кияү егете дә кирәк булачак. Монысы өчен баш ватып торасы юк. Фазыл булмый тагын кем булсын инде Мөнирҗаннын кияү егете. Хамматны да туйга чакырасы килгән иде, авылдан киткән, диделәр. Баулыгамы, Шөгер якларынамы—төгәл генә әйтүче табылмады.

Барысы да алдан уйлаганча булды. Мөнирҗан өчен Хәсьянов бәлки селкенмәс тә иде, Гайнияне килен итеп төшерү өчен ул үзенең Бурлы айгырын да кызганмады. Дилбегә Фазыл кулында, чанада Мөнирҗанның тальяны, туктаган араларда аны Фазыл бака ягын аеруча кычкыртып тартып җибәрә. Бертөрлелектән туйган авылга туй, бәйрәм рухы инде. Авыл советында язылышып, сәвит рәисе Садрый Минһаҗев аларны котлагач, авылны бер кат әйләнделәр дә, йомшак мендәргә кабат басып, Гайния Гаптелихсан белән Минсафа нигезенә закон тарафыннан рәсмиләштерелгән килен сыйфатында килеп керде.

Синнән-миннән сорап тормыйча, тормыш дәвам итә. Таң ата да, кич була. Гайния белән Мөнирҗан иртән торалар да һәркайсы үз эшенә китә. Дөрес, Мөнирҗан атлар карарга иртәрәк кузгала, аны озатып күп тә үтми, хисапчы да колхоз идарәсенә тырт-тырт атлап китеп бара. Ул инде үзенең килен булуына күнегеп килә. Минсафа карчыкның куануының иге-чиге юк, чөнки, килен кергәч, өйгә кот кунды, каралып беткән диварлар да яктырып киткәндәй тоелды. «И раббым, безне бәхетебездән аерма»,—дип, Минсафа карчык, көн туса, теләк теләде.

Ә Хәнифләр өендә исә элеккеге тынычлык югалды. Сәбәбе—Тәзкирә һаман, көн саен, ирен талкый: Гайния белән кияүне чакырып кунак итәргә кирәк, кешедән оят, имеш. Өйләнешкәннәренә айдан артык, әле һаман Мөнирҗанга кияү коймагын ашатканнары юк. Белә Тәзкирә, кияү коймагын пешерә—беләләр ул, майларда гына кыздырып, киявен чәй белән кыстый-кыстый сыйлар иде. Чәй арасында тел куәсенә генә ярарлык балы да әнә мич башында чемер-чемер итеп утыра. Сыйлар иде дә бит...ак оннары беткән. Яңа уңышка әле ерак, аңынчы кем бар да кем юк. Димәк, кичекмәстән каян да булса яхшырак он табарга кирәк. Кирәк икәнен Хәниф абзый да белә. Тик кайдан? Кулга керер акча юк, түлисе салымнар гына исәптә. Бар карап торганнары абзардагы буаз сыер да өч баш сарык. Икесе бәрәнләде, өченчесе, рәхмәт төшкере мал, кысыр бугай, бер дә җилем башлаганы сизелми. әллә шуны суеп сатаргамы? Өч-дүрт кило он алса, калганын салымга түләр иделәр...

Суеп сату дип әйтүләре генә ансат. Авылның үзендә генә аны алам диючене табам димә, базарга алып барырга кирәк. Ә базарның иң якыны Әскәйдән утыз биш чакрым ераклыктагы Ютазы стансасында. Соңрак чакырсалар да ярамас идеме икән? Берәр җае чыкмый калмас иде әле. Кияү үзебезнеке бит, авылдаш Гаптелихсан малае, ханзадә түгел.

Ләкин ир-ат мантыйгы белән хатын-кыз мантыйгы еш кына капма-каршы килә һәм жину кем ягында дисез? Күп очракта әнә шул чәче озыннар жинә. Дөнья белән без идарә итәбез дип ирләр күкрәк суга, мактана гына. Ә хатын-кыз дәшсә дәшә, дәшмәсә—юк, үзенекен итми туктамый.

Кысыр сарык суелды. Колхозлашкан елларда ук ясаган бака чанасына ат урынына жигелеп, апрельнең әрсез кояшы һәм юха жиле ашаган, адашмас өчен атлар калдырган тамгалар белән чуарланган һәм төн эчендә шыкраеп катарга өлгергән туң юлдан Хәниф абзый Ютазы базарына дип чыгып китте. Иренә хәерле юл теләп, ул күздән югалганчы, Тәзкирә аның артыннан карап калды.

Юл догасын укып, югыйсә бик изге ниятләр белән кузгалган иде дә бит, ләкин Хәниф абзыйның базарда юлы уңмады. Көч-хәл белән сәгать унберләргә генә килеп житә алды. Әскәй белән Ютазы арасындагы утыз биш чакрым аңа йөз чакрым булып тоелды—ул эт булып арыган иде.

Аруы ару, анысына гына ничек тә түзәрсең, аның бәхетсезлегеннән, базарда ит өелеп тора, алучылар исә берән-сәрән генә иде. Алары да бик сайлана торган булып чыкты: килеп карыйлар да, итең артык симез дип, Хәниф яныннан китеп баралар. Кызык инде, симез булса да, арык булса ярамый икән бу ит акчалы кешегә!

Хәниф картның базарга үз гомерендә беренче тапкыр ит сатарга чыгуы иде. Башкалар төсле ул үз товарын кычкырып мактарга өйрәнмәгән. Башкалар мактаганны тыңлый-тыңлый да гаҗәпләнеп куя: кешеләрнең бит маңгаенда ике күзе бар, алтынны көмештән, көмешне бакырдан, бакырны тутыккан тимердән аера белә торганнардыр...

Базар таралганчы торды Хәниф абзый, эчендәге ачу, үпкә-рәнҗүләре, бер йодрык булып тупланып, гарьләндерде, жанын талкыды. Өмете бөтенләй сүрелде, бер генә граммы да сатылмаган итен капчыгына салды да иң соңгыларның берсе булып, базардан чыкты.

Инде кая барырга? Юлда килеп, ул бик арыган-алҗыган иде. Аннан соң да базарда аяк өсте күпме торды. Үтереп ашыйсы, эчәсе килә. Кая барырга, ни эшләргә? Артык катлаулы бу сорауга Хәниф картның талчыккан мие, ни киерелеп уйласа да, жавап табар хәлдә түгел иде. Ул жеп өзәрлек хәле дә калмаганын сизде һәм, чанадагы ит капчыгы өстенә таянып, янә уйга калды.

Ни эшләргә?

Дөнья яратылганнан бирле адәм баласы четерекле хәлдә калган саен үз-үзенә менә шул сорауны бирә. Бирүен бирә, ләкин һәрвакытта да жавап таба алмый. Чөнки жавап табуга караганда, сорау бирүе күп тапкырлар жиңелрәк.

Хәниф абзый, башына кигән малахаеның колакчынын күтәреп, башын кашып торды-торды да, ашказанының боруына чыдый алмыйча, куенына төреп тыккан икмәк телемен тешсез авызы белән умырып алды һәм ашыкмыйча гына чәйни-әвәли башлады. Шунда гына үзенең өеннән чыгып киткәннән бирле берни капмаганы исенә төште. Ипи гаҗәп тәмле иде, ләкин күпме генә чәйнәмәсен, йота алмады—төкерек бизләре эшләүдән туктаган, ә коры икмәкнең йотыласы килми, тамак төбенә утыра иде.

Чәйнәгән икмәген яртылаш йоткан көе карт йокымсырап китте. Игътибар белән караган кеше аның чарасызлыктан яңагына тәгәрәгән күз яшьләрен күргән булыр иде.

Кыска гына черем итеп алганда, бик тәмле төш күрде Хәниф абзый. Имеш, базарда ит сатучылар күп булса да, халык аның янына жыела икән. Алар башкаларныкына борылып та карамый, берсеннән-берсе югарырак хак биреп, Хәнифнең итен алырга тырыша. Чиратсыз керергә теләүчеләр дә күп, аларны куып жибәрәләр. Хәнифнең кесәләре инде акча белән тулды,

кая куярга белми баш вата. Ни сәбәпледер, сата торган ите бетми генә түгел, кимеп тә карамый. Бу акчага әллә ничә капчык он сатып алып, Мөниржан кияве белән кызына көн дә коймак пешерергә була... Шунда ул:

—Әллә Хәниф абзый инде?—дигән тавышка уянып, күзен ачты һәм төшенең дәвамы түгелме дип, як-ягына каранды. Каранырсын да, каршысында авылдашы Мирхәбибжан басып тора иде.

—Хәниф абзый, исәнме дим, әллә танымыйсынмы?!

—Таныйм, таныйм, ничек танымаска ди! Мирхәбибжан, син бит бу!—Үзе дә сизмәстән, анын күнеле күтәрелеп китте. Күтәрелер дә, чит-ят җирләрдә япа-ялгызын калгач, авылдашын килеп чыксын әле!

—Мин шул, мин. Нинди җилләр ташлады Ютазыга? Ни эшләп утырасын?

Башыннан үткәннәрне сөйләгәндә, карт чак кына елап җибәрмәде. Бу минутта хәленә керүче, үзен кызганучы кеше барлыгын тою күнелен нечкәртте.

Ул сөйләп туктагач, Мирхәбибжан сорады:

—Инде ни эшләргә уйлыйсын?

Их, әгәр белсә икән! Ул әле һаман ни эшлисе хакында бер карарга килеп өлгермәгән иде. Дөресен әйтте:

—Белгән юк. Ичмасам, өч-дүрт кило он алырлык кына булса да саталмадым,—диде ул ачынып.—Мөгаен кайтырга кузгаласы булыр...

—Син нәрсә, Хәниф абзый, акылындамы? Төнгә каршы шундый ерак арага юлга кузгалаларммы!? Итен дә барын сизсәләр, үзенне бүреләр ботарлап бетерер. Хәзер алар ач, бик аздылар. Әле беркөн Бөгелмәдән төнгә калып кайткан идем, урап алдылар. Хәлләреннән килсә, машина өстенә сикерерләр иде, һич курыкмыйлар. Юк-юк, уйлама да, әйдә, безгә киттек! Итенне сата алмаганга да бик бетеренмә, ул турыда да уйлашырбыз. Иртә кичтән хәерлерәк, диләр. Әйдә! Аннан сон, итенне сатмый кайтсан, Тәзкирәттәй сине өенә дә кертми бит.

Мирхәбибжан көлеп җибәрде һәм, каршы килергә урын калдырмыйча, чана бавына үрелде. Хәнифнен буйсынмыйча чарасы калмады.

Авылдашы базардан ерак тормый икән.

—Менә шушы инде безнен куышыбыз,—диде ул, борынгылыгы әллә кайдан күзгә бәрелеп торган кечкенә генә йорт янында туктагач.—Искесен иске инде, ләкин үзебезнеке!

Мирхәбибжан «үзебезнеке» сүзен ниндидер, эчке горурлык белән басым ясап әйтте.

—Фатирларда торып карамадык түгел, карадык, иске булса да үз өенә җитми икән. Әйдә, Хәниф абзый, уз, гаепләмә генә. Икенче килүенә яхшырак йорт салып куярбыз, Алла боерса.

Мирхәбибжанның хатыны да ачык йөзле, сөйкемле генә икән.

—Менә минем йөземем—Гөлйөземем шушы була инде. Таныш бул, карчык, безнен авылдаш Хәниф абзый.

—Исән-сау гына торасызмы? Нихәл, килен!

Карт кыенсынып кына хуҗабикәнен ап-ак кулын кысты.

Гөлйөзем унган хатын икән. Ирләр чишенеп, кулларын юган арада табын хәстәрләп өлгертте. Өстәл артына утырам дигәндә, Хәниф карт авылдашы өенә бөтенләй буш кул белән кергәнен исенә төшерде һәм, чыгып, сатасы сарыгынын әйбәтрәк җиреннән бер кисәк ит алып керде.

—Кызым, ал әле, миннән кечкенә генә күчтәнәч булыр.

Гөлйөзем иренә карады. Мирхәбибжан исә:

—Юкны сөйләмә, Хәниф абзый, без алай сүз кушмадык,—дип, күчтәнәч хакында авыз да ачтыртмады.

—Юк-юк, Мирхәбибжан энем, килешмәгәнне!—Карт та шактый үзсүзле.

Аның бик четерекле хәлдә үзенә ярдәмгә килгән авылдашы белән бу ачык йөзле хатынга ниндидер яхшылык эшлисе килде.—Шикләнмәгез, бисмилла әйтеп, үзем суйган сарык ите. Барыбер сатып булмады. Ходай Тәгалә кушмагандыр инде.

—Юкка көяләнмә әле, Хәниф абзый. Әйттем бит инде, берәр нәрсә уйлашырбыз дип. Җан биргәнгә җүнен бирми калмас. Һич кенә дә кыенсынма, син безнең кадерле кунагыбыз, үзен күчтәнәч.

—Әйе-әйе,—дип иренә ярдәмгә килде Гөлйөзем.—Бу йортка күчкәнгә ярты ел, Әскәй кешеләренең аяк басканы юк. Сез беренче. Аягыгыз җиңел булсын. Тартынып утырмагыз, үз өегездәге кебек хис итегез.

Юк, хуҗалар кабул итмәде картның нужа мәҗбүр иткәнгә генә суеп, базарга алып килгән итен.

1944 елда авыр яраланып кайткач, Мирхәбибҗан авылда озак тормады, терелүгә, Ютазыдагы автоколоннага шофер булып эшкә урнашты һәм заманына күрә ару гына акча ала башлады. Туган авылына күптән кайтканы булмаса да колхозчыларның кесәсендә җилнең ничек уйнаганын аны белми дисеңме.

Хуҗаларның ихлас кыставына каршы тора алмады Хәниф карт, ярты стакан аракы да эчте. Әнә шул аракы, итле токмач ашы, кайнар чәй һәм чиктән тыш арыганлык үзенекен итте—амин тотуга, Гөлйөзем җәеп биргән урынга башы тиюе булды, шунда ук изрәп йоклап та китте.

Иртән Мирхәбибҗан аңа:

—Хәниф абзый, син мин кайтканны көтеп тор, беркая да китмә,—дип, эшенә кузгалды.

Гөлйөзем мәктәптә укыта икән. Ул да эшенә җыена башлады. Картның борчылуы йөзенә чыкты: «Ә Мирхәбибҗан кайтмаса? Ашыгыч рәвештә берәр кая җибәрсәләр...»

Гөлйөзем аның хәлен аңлады:

—Борчылма, абый. Мирхәбибҗан әйткән икән, эшләр. Ул сүзендә тора торган кеше.

Ул сүзләрен әйтеп бетерергә дә өлгермәде, капка төбенә йөк машинасы килеп туктады.

—Әйттем ич, әнә кайтты да!

Шау-гөр килеп, Мирхәбибҗан өйгә керде. Аның шатлыгы йөзенә чыккан.

—Булды бу, Хәниф абзый! Гараждагы малайлар белән сөйләштем. Хәзер итеңне алып бетерәчәкләр. Әйдә, киттек. Аннан соң мин эш белән Азнакайга барам. Юри шунда сорадым. Сине утыртып кайту өчен. Азнакайдан Әскәйгә уникe чакрым тәпиләү әлләни булмас әле. Дөрес, турыдан машина юлы юк, Бөгелмә аша барырга туры киләчәк. Туйганчы бер машинага утырып йөр әле! Киттекме, карчык!—Ул шаяртып, хатынының биленә төртеп алды.

—Кит, юньсез!

—Менә кара инде бу хатынга, юньсез дип әбиҗәйт итә.!

—Әләкләшмә!

Гадилек, киң күңеллелек хөкем сөргән бу йортта Хәниф абзыйның янә күңеле йомшарды.

Машинаның кысан кабинасына өчесе кереп утырды. Мәктәп шактый еракта икән, башта шунда Гөлйөземне калдырдылар. Аннан соң гына выжылдатып, автоколонна гаражына барып керделәр. Шушы яшенә житеп, Хәниф картның машинага беренче тапкыр утыруы иде, куркуыннан тирләп чыкканын тоткага чытырдатып ябышкан кулларын алган чакта гына сизде.

Менә бит Ходаның хикмәте: кичә базарда берәү дә алырга теләмәгән итне шул ук бәядән шофер халкы кулына да тигезмәде. Тагын ике

сәгать ярымнардан Мирхәбибҗан машинасы Азнакайда иде инде. Алар кочаклашып аерылыштылар.

—Сорашкан идем, кызганыч, Әскәйгә машина юлы юк икән, югыйсә авылга кадәр илтеп килгән булыр идем,—дип уфтанды Мирхәбибҗан.—Ходай биреп, нефть чыкса, сезне дә юлсыз тотмаслар әле, иншалла.

—И энем, булган кадәресенә дә нинди генә рәхмәтләр укырга да белмим. Олыгайгач, утыз-кырык чакрым ара ерак икән ул. Яшь чакта алай ук сизелми иде. Син очрамасаң, ни эшләр идем. Фәрештәләр җибәргәндер сине кичә минем янга. Бөтенләй хәлем бетеп, мием ангыраланган иде бит. Исән-сау йөр, авылга кайтсаң, безгә керми китмә, яме! Туп-туры үзебезгә кайтсаң, тагын да яхшырак.

—Авылда безнең нәсел-нәсәп калмады шул инде...- Мирхәбибҗанның һәрвакыт көләч йөзенә моңсулык, сагыш иңде.—Сагындыра авыл... Ачлангач булса да...

—Әйтәм ич, туп-туры үзебезгә кайт дип. Гөлйөзем киленне дә алып кайт. Матур бит ул безнең Әскәй!

—Матур...

Хәниф карт, сәфәренең көткәннән дә уңышлырак булуына куанып, сарык ите саткан акчасына кибеттән биш кило ак он, ярты кило зур шакмаклы шикәр һәм бер такта кытай чәе алды. Озак уйлагач, капчыгының төбенә бер шешә аракы да салды. Киявен беренче тапкыр кунакка чакырганда, оятыңнан битең ертылырлык түгел инде болай булгач. И-и, кайлардан очрады бу рәхмәт төшкән Мирхәбибҗан!

Ул Әскәйгә кайтып кергәндә, көндезге икеләр иде. Карт куанычыннан Ютазы хәлләрен карчыгына кат-кат сөйләде. Боларны сөйләгән чакта ул үзен гаять булдыклы кеше итеп санады һәм Тәзкирә карчык каршында бер башка үсеп киткәндәй тоелды. Әйтерсең, берүзе Берлинны алып кайткан.

Икенче көнне үк алар кичке якка Мөнирҗан белән Гайнияне кунакка чакырдылар. Әүвәл яшьләрне мунчага җибәрделәр, аннан кайтуларына өстәлдә кунакларны майда гына йөздереп пешергән «кияү коймагы» көтеп тора иде. Аны мактый-мактый ашап, кытай чәен эчкәндә, Хәниф карт белән Тәзкирә карчыктан да бәхетлерәк җан ияләре Әскәй авылында бүтән булмагандыр. Бәхет өчен адәм баласына күп кирәкмени!

Бу сыйның өстәлгә нинди авырлык белән килгәнен Мөнирҗан белми дә калды.

Җир шары кояш тирәсендә туктаусыз әйләнгән кебек, тормыш та өзлексез дәвам итә. Ачмы син, тукмы, кәефең яхшымы, начармы, бәхетлеме, бәхетсезме, илең котлымы, котсызмы—берсенә дә карамый. Кешеләрнең бәхете, бәлки, шушы һәр секунд, һәр минутны сизмәвендәдер. Әнә шулай берни сизмичә яшисең-яшисең дә берзаманны аһ итәсең: карале, гомер узып бара түгелме соң! Бигрәк тә яшьлекнең гомере кыска.

Агымсулар ничек ага,
Яшь гомерләр дә шулай, -

дип җырлый халык.

Ширәмәттә урман кисқәндәге авырлыклар онытыла төште. Анда барган кешеләр, бер-берсе белән очрашкан чакларда, бары тик истә калган кызыклы мизгелләрне генә хәтергә төшерәләр иде.

Язгы кыр эшләре беткәч, татар авылларында борын-борыннан сабан туйлары уздырыла. Сугыш елларында исә бу йола онытылып торды. Илдә вәйран барганда, бәйрәмгә урын каламы соң! Сугыш тәмамланып, бер ел

узганнан соң, ягъни 1946 елның июнь башында, сабан туе уздырылачагы турындагы хәбәр киләчәккә өметен югалтмаган халыкның күнелен күтәреп җибәрде. Уен эшмени: 1941 елда авылның күпме ир-егетләре мәйданнан туп-туры фронтка озатылды. Дүрт ел буе тарткан, бер генә минутка да туктап тормаган үлем тегерменнәннән аларның ничәсе генә исән-сау кайта алды икән?

Кешеләр яу кырында кан койган чакта, тылдагылар фронт өчен дип соңгы тирен сыкканда, бөтен эшне ташлап сабан туйлы уйнау кемнең башына килсен. Һәм моңа кем рөхсәт бирсен. Башбаштакланып, кемдер уздырырга уйласа, системаның үткен күзләре тиешле урынга җиткереп, гаярь башлар үзләренең ничек урыннарыннан очып барып төшүләрен сизми дә калыр иде.

Шуңа күрә 1946 елдагы сабан туе турындагы хәбәрне халык яхшыга, бары тик яхшыга—фашистларны җиңүнең чынлыгын раслау дип, тормышларның рәтләнүгә таба баруы дип юрады. Югыйсә әле халыкның иң зур күпчелеге һаман да ак күмәч турында түгел, бәлки туйганчы бер ашау хакында хыялланып яши иде.

Сөрән җыюны Фазыл һәм тагын сугыш гарасатыннан исән калган берничә егет яңа үсеп килүче һәм үзләрен зурга санаучы берничә бүлтерек белән бергә башкардылар. Өйләнгәннәр инде зурга сан була, шуңа күрә Мөниржан читтә калырга теләгән иде, ләкин яшьләр аның ай-ваена карамады: чыгасың һәм и бетте вәссәлам! Гайния дә каршы килмәде.

Йоланың язылмаган законнары нигезендә яңа йортка күчүчеләр, өйләнешүчеләр, баласы туганнар сабан туена махсус бүләк әзерли. Сөрән җыючыларның хәтере яхшы: кемнең нинди бүләк бирергә тиешлеген онытмый, әгәр дә кем дә булса «оныта» калса, аларның исләренә төшерә, хәйләләп калырга теләүчеләрне җыр белән фаш итәргә дә күп сорамый.

Үзен бүгенге көннең иң бәхетле хатыннарының берсе санаган Гайния, Ширәмәттән кайтуга, алдына шундый максат куйды: быелгы сабан туенда иң затлы сөлге аныкы булырга, баш батырга яки алдан килгән менге атка бирелергә тиеш! Шуңа күрә ул ашыкмады, кабаланмады: буш вакыты булган саен, бирнәгә әнисе сугып биргән җитен сөлгене чигүен белде.

Мөниржан хатынының сөлге чигүен карап торырга ярата. Гайния җепле әниләрнең әле берсен ала, аннан икенчесен, өченчесен... Мондый чакларда ул онытыла, хәтта үзенә карап торган ирен дә күрми.

Соңгы вакытларда яшь хатын үзендә моңа кадәр булып карамаган сәер үзгәрешләр сизә. Йа Раббым, йа Ходам, шикләнүләрен дөрескә чыгар да аны бәхетле ит. Бәлки Мөниржанга да әйтергәдер? Юк, кирәкми. Ашыккан ашка пешкән ди. Беләсе иде, аларның беренче мәхәббәт җимеше кем булыр икән: малаймы, кызмы?

Ә үзе аның малай булуын тели. Малай булса, Мөниренең түбәсе күккә тиясен белә. Дөрес, бу хакта аларның сөйләшкәне юк-югын. Ләкин кайсы ата әүвәлге баласының үзенә ярдәмче, нәсел агачын дәвам итүче тыпырдап торган малай булуын теләмәс.

Хатынының күз нурлары сеңдерелгән, аның кул һәм күңел җылысын саклаган сөлгене Мөниржан сөрән колгасының иң башына бәйләп куйды. Ә сабан туенда ул сөлге баш батырның киң җилкәсен бизәде.

Күпме көтеп алган сабан туе үтте дә китте. Бәйрәмдә җыр-моң эчендә йөзгән авыл икенче көнне тынып, ямансулап калды. Авыл тынды, тик кешеләрнең күңелләрендәге рух күтәренкелеге әле озак сакланды.

Авылда кеше, бик теләсә дә, эшсез яши алмый. Тормыш мәшәкатьләре берсе артыннан берсе туып, үзара ялганып тора.

Әскәйдә дә башта печәнгә төштеләр. Колхоз дәүләт урманыннан һәм урман алдындагы болыннардан, өмә ясап, берничә көн печән чаптырды.

Карты-яше, кыскасы, чалгы, тырма, сәнәк ишене тотарга яраган берәү дә өмәдән читтә калмады. Беренче герман сугышында сынар аягын калдырып кайткан Фәхразый карт кына чалгы чүкеп өлгертә алмагач, ана ярдәмгә ике коданы—Гаптелихсан белән Хәнифне дә куштылар.

Башта көннәр бик әйбәт торган иде. Кояш иртән чыга да, печән хәзерләүчеләрнен хәленә керергә теләгәндәй, кыздыра да кыздыра. Бүген чапкан печәнне икенче көнне төштән сон һич икеләнмичә жыярга да була. Кызар дип куркасы юк—шулкадәр тиз кибә.

Дүртенче көнгә киткәч, Саклау урманы артындагы Үчәлле авылы ягыннан башта ак болытлар күренде, озакламый күзгә күренмәс көчләр аларны куып жибәрде дә күк йөзен берсеннән-берсе карарак болытлар белән тутырды. Күнелләргә шом салып, күк күкрәде. Бу күкрәү әле еракта иде, ләкин янгыр явасына инде берәүнен дә күнелендә шик калмады. Күкләр ихтыяры каршында көчсезлекләрен, каршы торырга яки ни дә булса үзгәртергә кодрәтсез икәнлекләрен анлаган кешеләр язмышларына буйсынырга мәжбүр иде.

—Их, тагын өч-дүрт көнгә түзмәде,—дип аһ итте халык.

—Боз гына ява күрмәсен иде...

—И раббым, хәерле янгырлар гына булса иде!

Алар кайту хәстәренә дә керешмәкче иде, ләкин Хәсьянов бу хакта ишетергә дә теләмәде, чак кына каршы әйткәннәрне аты-юлы белән сүгеп ташлады; сукмаса да, чыбыркысы белән кизәнде. Ул әле һаман янгырнын яумасына, яуган очракта да печәнчеләрне читләтеп узасына өметләнде.

Чикерткәләргә кадәр тынып калган, сайрар кошлар аваз чыгарырга курыккан бу мизгелдә печән төягән арбаларнын атларын ай-һайлап куалаган, чалгы янаган һәм чалгыларнын бер-берсе белән ярышып үлән кискән тавышлары аеруча көчле ишетелә. Әле бая гына еракта ишетелгән күк күкрәү авазлары якынайганнан-якыная барып, кинәт гадәттән тыш көчле шартлау янгырады. Бу юлы ул баш өстендә генә иде, ахры. Күк йөзен карангылык басты, анда бияләйгә салырга ямаулык кадәр генә дә яктылык калмады. Ни әйтер микән дип кешеләр Мидхәткә карады. Бу карашларда курку һәм өмет бергә тупланган иде. Ләкин «Дәжжал» кайтырга әмер бирүне һаман кичектерде.

—Ләхәүлә вә лә куәтә...

Әле генә күкрәгән тавыштан куркудан котлары ботларына житкән кешеләрнен берничәсе авызыннан берьюлы шушы сүз ычкынды. Чөнки бу күкрәүнен көчен сөйләп кенә анлатырлык булмады. Ул печәнчеләрнен колакларындагы тавыш ярыларын томалады, урман буенда бу күкрәүнен кайтавазы адашып, каеннардан имәнгә, имәннән яшел кәүсәле усакларга бәрелеп-сугылып йөрде, күнелләргә тычкан кебек кереп оялаган шомны тагын да көчәйтә төште. Атларнын колаклары шомрайды, Хәсьянов жигеп йөри торган Бурлы айгыр, тезгенен өзеп, жан-фәрманга авылга табан элдерде. Печәнчеләр арасында чын-чынлап анархия башланды: мона кадәр арба үрәчәсенә бәйләп куелган атлар ашык-пошык жигелде. Курку һәм ашыгу аркасында каушап, кемнәрдер камытларын ат муенына тискәре ягы белән кидерде, чөелдереген кыса алмый интекте. Жигелгән атларга кем өлгерә, шул утырып китә торды. Мөниржаннар кузгалганны гына көткән диярсен, мона кадәр берән-сәрән генә төшкәләгән янгыр тамчылары кинәт болыты белән ишелде. Монысына артык хафаланмадылар: янгыр күрмәгән, чыланып карамаган бәндәләр түгел лә... Берәү дә тоз түгел, эремәс. Игеннәрне генә екмасын иде... Йа раббым, рәхмәтеннән ташлама. Кешеләр, Аллага шөкер, янгыр гына ява дип куанырга да өлгермәде, өсләренә чыпчык башы кадәрле боз төшәргә тотынды. Гарасатка эләккән халык өстенә таш булып ишелгән боздан ничек сакланырга белмәде. Баш өстендә учмасы

белән печән тотып караганнар иде, файдасыз гамәл икәненә төшенгәч, кул селтәделәр. Пешекчеләрнең генә хәле арурак иде: алар башларына чиләк киеп куйды. Чиләк төбенә эләккән боз чәчрәп читкә оча, тавышы калай мичкәгә таш белән орган авазны хәтерләтә.

Күз ачып йомган арада тирә-юнь яп-якты боз белән капланды, күңелләргә ышаныч, аерым бер ләззәт биреп утырган басу санаулы минутлар эчендә кызганыч бер хәлгә килде: өсләренә төшкән боз авырлыгына түзә алмыйча, әскәйлеләрнең кул белән чәчеп үстергән, яхшы уңышка өметләндергән бодае ауды, боз белән тапалып изелде, ә дигәнче юкка чыкты.

Атлар томырылып чаба, аларны куалап торасы да юк. Тәгәрмәчләрдән, ат тоягыннан чәчрәгән пычрак арбада утыручыларның киеменә, битенә, чәчләренә сылана. Кемнең кем икәнен чыраена карап кына танырлык та түгел—барысы бер кыяфәткә кергән. Манма су булган кешеләрнең хәзер чыланудан, пычранудан, яуган боздан куркасы юк. Барысының да башында бары тик бер уй: тизрәк, тизрәк кайтып җитәргә кирәк! Күптән, бик күптән мондый көчле, афәтле яңгыр яуганы юк иде.

Кайтканда ике тау төшәсе: Кызыл тауны һәм Гатият тавын. Кызып ярсыган атларны тыеп кына төшмәсәң, әллә нинди бәлаләр китереп чыгарулары бар. Мөнирҗан Күк бияне туктатып, түшлеген тарттырып бәйләде, камыт бауларына күз төшерде. Сакланганны саклармын дигән бит Ходай да.

Печәнчеләр, Аллага шөкер, ике тауны да исән-сау төштеләр. Әмма иң зур сынау су буенда көтеп торган икән. Гадәттә күп җиреннән атлы арба белән чыгып йөри торган Эстәрлене хәзер танырлык түгел. Аркылы салынган күпер су астында калган, култыксалары гына тырпаеп тора. Эстәрле кыргый көчкә ия, котырыпмы-котырып ага, әйтерсең, тау елгасы. Көчле ташкын инеш буенда җыелып яткан чүп-чарны гына түгел, төрле күл-чокырларны да чистартып алып төшкән. Печән күбәләре, киртә агачлары, бүрәнәләр, хәтта буралар да актарылып-актарылып аккан ташкын кочагында калган. Алар Җиһанша картлар турындагы борылмадан килеп чыгалар да, күпер өстеннән агып үтеп, күздән югалалар.

Хәлнең никадәр хәвефле икәнен анлап алган Хәсьянов күпергә шунда ук кереп китәргә теләгән дуамалларның юлына аркылы төшмичә булдыра алмады. Бу минутларда ул үзен кабат фронттагы кебек хис итте.

Бу күпер—авылда бердәнбер күпер. Язгы ташуда ул ел саен сүтелә. Сүтеп өлгермәсәләр, гаять зур көчкә ия ташкын, Уразайдан ук агып килгән калын-калын буа бозлары аны барыбер алып китә. Күпер булмагач, Аръяк белән Бирьяк арасында бәйләнеш өзелә. Күперсез яшәгән көннәр Әскәй мәктәбе укучылары өчен сабан туе кебек үк бәйрәм көннәре. Чөнки аръякныкылар мәктәпкә укырга чыга алмый. Ә анда җидееллык мәктәптә укучылар саны йөздән артык. Шуңа күрә мәктәп дирекциясе язгы каникулга да, шәһәр мәктәпләрендәге сыман, мартның егерме өченнән түгел, күперсез калган көннән туктата. Һәм, күпер төзелеп бетми торып, укучылар үзләренең тузанлы мәктәпләренә аяк басмый. Алар өчен укымаудан да зуррак тагын нинди бәйрәм булырга мөмкин.

Аръяк белән Бирьяк арасында бәйләнеш өзелә дип әйтү ул шартлы рәвештә генә. Күперсез калган көнне үк гаярьрәк йөрәклеләр субайларга буалып калган бозлар аша юл сала. Ул юл салучылар арасында, әлбәттә, бераз кызмача Әмирша Мәгъсүме дә була. Мәгъсүмнең бозлы суда коенып чыкмый калган елы булдымы икән?

Мәктәп дирекциясе боз аша балаларга йөрергә рөхсәт итми, ләкин вакытлы «күпердән» укучылардан да күбрәк йөрүче юк.

Һы, йөрмәссең сиңа! Таулар бит Аръякта. Аларның көньякка карап торган битләре авыл урамнары кардан арынырга өлгергәнче үк, кипшенеп,

яшелләнеп чыга. Көзен кышны сагынып көтеп алсалар да, аның кырык корама йөз ялгаулы кием эченнән кереп чеметүче зәһәр, миһербансыз җиленнән, зәмһәриреннән туеп өлгергән нарасыйларның тизрәк яланаяк чабып йөрисе, ямьле язны якынайтасылары килмиме!

Мөниржан күнелендә бер яз аеруча нык саклана. Бишенче класста укый иде. Күпер китте. Боз өстенә боз өелде. Укымаган малай-шалайның (хәер, кызларның да) әлләни эше юк. Эшләре юк, ә вакытлары исә тагын да азрак: чөнки су буена төшәсе, бозлар акканны карыйсы, яр буендагы чирәмдә уйныйсы бар. Су буе, бигрәк тә кичкә таба, ташу көчәйгәч, нык җанлана.

Фазылларның Магниткада чагы. Төшкә кадәр Мөниржан малайлар белән ат абзарындагы саламлыкта кәрт сукты. Аны зурларга күрсәтеп уйнарга ярамый, югыйсә колагыңны боруларын көт тә тор. Ашарга таралышканда, әбиттән соң тауга менәргә сүз куештылар.

Кызлар ничектер, ә малайлар киләчәктә егет буласы кеше, сүзләрендә тора торган халык, бигрәк тә уен дигәндә,—сөйләшкән вакытка күпер буендагы ярга җыйналдылар.

Мәктәптә чакта Аръяк малайлары белән еш кына үзара чәкәләшсәләр дә, күрешми торган ике-өч көн эчендә алар бер-берсен сагынып өлгерә. Аннан соң, аннан соң... Аръякның кызлары да чибәррәк бугай. Һәрхәлдә, Бирьяк кызлары кебек чебен тисә чер итәргә генә тормыйлар.

Яз кешеләргә иркенлек һәм өстәмә борчу-мәшәкатьләр тудыра. Кышны кем чабата-тула оек, хәллерәкләр исә калын итеп олтан салынган киез итекләр белән уздыра. Ә язгы пычракта кияргә һәркемнең дә аяк кияме юк. Димәк... Димәк, галошы, күн итеге булмаганнарга яланаяк йөрергә кала.

Яланаяк дигәннән, анысы ул кадәр куркыныч түгел. Язын яланаяк йөреп, аягын чебиләтмәгән малай авылда кала микән? Һи, аягын чебиләтмәгән малай малай түгел инде ул. Чебиләгән аяклар уйнаганда сизелми, ә менә кайткач... Җылы суда юып ак май, солидол сөртүләр, сытып, чәүкә күкәенең сарысы белән сылаулар дисеңме, берсе дә калмый. Чып-чын җәйгә чыккач та бик озак төзәлә әле ул чебиле аяклар. Тик карлы-бозлы җирдә яланаяк йөрсәләр йөрделәр, суык тидереп чирләүнең ни икәнен белмәде Әскәй малайлары һәм, күпер салганчыга кадәр, Аръякка чыгып, тау битендә уйнаудан туктамадылар.

Эстәрленең язгыдан да хәтәррәк ташуын күреп, Мөниржан менә шуларны исенә төшерде.

Уйларын Гайния бүлдерде:

—Мөниржан, кара әле, кара, сарыклар ага! Әнә тегесе безнең Чуар борын түгелме соң? Валлаһи, шул!

Сарык әллә хуҗасын таныды, су тавышын җиңеп, кызганыч тавыш белән аның мәэлдәве ишетелде.

Хәзер Мөниржан да таныды: Чуар борын иде агып баручы сарыкларның берсе.

Гайния түзмәде:

—Тәч-тәч-тәч!—дип сарыгын чакырырга керешге.

Сарыкны ангыра хайван дип әйтәләр. Булыр сина! Әнә ич, Чуар борын борылды да, агым белән көрәшә-көрәшә, ярга табан йөзә башлады. Аңа тагын берничә сарык иярде.

Күз карасыдай саклап үстергән малларны күрәләтә харап итмәсләр бит инде. Ирләр, актарыла-актарыла аккан су ташкынына бу мәхлукларны коткарырга ташланды. Барыбер чыланган булгач, кием салып торасы да юк иде.

Чуар борын бәхетле сарык, өстәвенә үзсүзле дә. Әнә ич, кайсысыдыр эләктереп алырга теләгән иде, читкә тартылып, Мөниржан янына юнәлде.

Мәхлук дисәң дә мәхлук шул, югыйсә кем коткарса да барыбер түгелме?!

Печәнчеләр ничекләр генә тырышса да, күзгә чалынган сарыкларның барысын да коткара алмады. Гаять ярсыган, бөтерелә-бөтерелә аккан инеш аларның кайберләрен күз алдында чоңгылына йотты, кайберләре су өстеннән анда-санда калкып күренгән күпер араталарына бәрелә-сугыла ары таба йөзеп китте.

Кызганыч кыяфәт белән аргы яр буйлап агучы ике бозау да күренде.

Янгыр барлыгы сәгатьтән артык кына яуды. Аннан соң ялтырап кояш чыкты. Ләкин су кимергә һич уиламый, киресенчә, артканнан-арта гына бара иде. Печәнчеләрнең көтә-көтә көтеге бетте. Шаулаша башладылар:

—Җәмәгать, кайтырга кирәк бит!

—Күпме көтеп торырга була инде!

Кешеләр өйләренә ашыга иде. Ләкин Хәсьянов аларны күпергә кертмәде. Дуамал Шәһит:

—Фәлән итәм мин синең рөхсәтеңне, мин үзем генерал!—дип башбаштакланырга уйлаган иде, артыннан куып житеп, Хәсьянов изүеннән күтәргәч, тынды, «генерал» икәнен дә онытты. «Дәжжал»ның бала башы зурлыгындагы йодрыгы ипи шүрлегеңне җимермәсен дисәң, «ефрейтор» дәрәҗәсенә дә канәгать калырсың.

Ләкин халыкны болай тотуның да гамәлгә сыймаганын белә Хәсьянов. Авыл адәмнәренең берсен ияртеп, ул сәнәк сабы белән капшый-капшый, күпердән аргы якка юнәлде. Аның ни өчен бу кадәр кыланганын аңларга була иде. Күпер бит ул гадәти шартларда йөрү өчен салынган. Субай өстендәге өрлекләрне ташу агызып алып китмәгән яки күпергә керә торган жир катламын юмаган дип кем ышандыра ала? Бәладән башаяк. Берәрсе батып үлсә, кем җавап бирә? Әлбәттә, ул—Мидхәт Хәсьянов. Дөрес, авыл советы рәисе, үзе әйткәндәй, «местный блач» Садрый Минһажев та бар барлыгын. Ләкин Хәсьянов бу кешегә ышанырга ярамаганын танышкан мәлләрдә үк аңлаган иде. «Ярый әле күпергә култыксалар куйдыртырга баш житкән»,—дип уйлап куйды Мидхәт. Шулардан кырыйны чамалап барырга була.

Печәнчеләр бәхетенә, күпергә зыян килмәгән иде. Атларын йөгән тезгененнән житәкләп, печәнчеләрнең бер-бер артлы күпер аша чыгуы сәгатьтән артыкка сузылды.

Көндезге икеләрдә башланган ташкын суы кичкә таба гына кимеде. Эстәрле үз эзенә үк кайтып житмәсә дә, кояш баер алдыннан күпер аша курыкмыйча йөрерлек иде инде. Бирьякның янгырга манма чыланган, ләкин кибәргә өлгергән көтүчеләренә, көтүне тау башына туплап, бу мизгелне әллә ничә сәгать көтәргә туры килде. Авылга керер-кермәс мал көтүен тыеп торып кара әле! Арада, сарыклары бер хәл, Вәгыйзьләрнекеке кебек башкисәр сыерлар, мең төрле хәйләгә ия кәҗә-мәкерҗәләр дә бар. Сарыгын да әйтмә, ул мие сыеклар да, бер кузгалса, саранча кебек, бара да бара, егылып үлгәнен дә белми. Көтүчеләргә әгәр дә ул көнне этләр ярдәм итмәгән булса, бигрәк авырга туры килер иде. Әле шулкадәр чабып-йөгереп тә, Югары оч белән Түбән оч көтүләре барыбер кушылган, буталып беткән. Шуна күрә, көтү кайтып, малларның төп өлеше үз ихаталарына кергәннән соң да, урамда адашып калган бәрәннәр, балаларын жуйган сарыклар кычкырып йөрде. Аларның тавышы шулкадәр кызганыч иде ки, сугышта якыннарын югалткан кешеләрнең йөрәкләрен телде.

Мөниржаннарның Югары оч көтүе янгыр гарасатына Шомыртлык туплавыннан кузгалгач эләкте. Ярдәмгә ике малаен ияртеп Чатан Шәрәфи малларын калку жиргә чак менгереп өлгертте. Ары китәрләр иде, Әйшә кулыннан төшкән көчле ташкын суы юлларын бүлә. Ләкин хайван аңгыра тек аңгыра, бердәнбер котылу юлы шушында тыныч кына тупланып тору

икәнен анларга теләми, күк күкрәгән саен, куркышып, койрык чәнчеп авыл ягына чабу ягын каера. Бигрәк тә сарыкларны тыеп тоту кыенга туры килә. Акыллы, хәйләкәр, кирәк чакта урлашуны да гөнаһка санамаган Чуар борын тота да ташкынга ташлана. Әниләре артыннан ике бәрәне дә иярә. Шуннан соң ни булганын белмәдем, дип соныннан сөйләде Шәрәфи.

Чуар борын карт сарык. Анын ничә яшьтә икәнен, белсә дә, бары тик Минсафаттәй генә беләдер. Гаптелихсан абзый аны өченче ел ук суярга ниятләгән иде. Акыллы хужа бер сәбәпсез җәй уртасында сарык бугазламый, көзне, кышны көтә. Ә анын корсагы көзен як-якка бүлтәеп чыкты. Карасалар, җилене тулып килә икән. Гомерен Ходай саклаган шул мәхлук яңа ел алдыннан менә дигән ике бәрән китерде. Буазлыгы аркасында ул алдагы көздә дә, пионер булып, кызыл галстук киюдән котылып калды. Инде менә бу ташкыннан да исән-имин чыгуы—үзе бер могҗиза. Әйтерсен, Чуар борынның гомерен Аллаһы Тәгаләнең фәрештәләре махсус күзәтеп, саклап тора.

Бозлы янгыр, сил дип әйтерлек көчле ташкынның китергән зыянын ул көнне генә бәрәү дә әйтә алмады. Чуар борынның ике бәрәне табылмады. Тора-бара авылда шактый гына сарыкның, берничә бозауның житмәгәнлеге ачыкланды. Ике кешенең бурасын агызып, унлап бакчаның читәнен жимергән. Черек салам түбә аша су үтмәгән йорт калмагандыр да.

Колхозга килгән зыян житәрлек иде. Имеш-мимешләргә караганда, кырыктан артык сарык юкка чыккан. Көтүче Ибрай сарыкларны көндез Бабеч-карам буендагы утарга япкач, галәттәгечә, әче бал чүмергән дә ятып йоклаган. Аруы да житкәндер, кара таннан торган кеше бит, бал да тәэсир итми калмагандыр, һау-һаулап өргән этләр тавышына уянса, астына ташкын суы кергән. Анына килеп, малларны коткару хәстәренә тотынганда, әллә никадәр сарыкны ташкын үз кочагына алып өлгергән була. Ибрайның сөйләвенә караганда, үзе дә батып үлмичә чак исән калган.

Бусы әле баласы гына булган. Анасын икенче көнне күрделәр. Ташкын көченә түзә алмыйча, тегермән буасы ерылган. Аны язгы ташудан соң озак кына буагач, сабан туе алдыннан гына өмә ясап, арыгын басканнар иде. Хәзер Эстәрлене кабат бумый торып, тегермән тартмаячак, ә тегермәнсез авыл—авыл түгел инде ул. Бозлы янгырдан соң, әйтерсен, күкнең төбе тишелде. Нәкъ жырдагыча: «килә ява, килә ява, иyләшкән бер болыт». Озакка сузылмаган, ләкин бик көчле янгыр икенче көнне, өченче көнне дә яуды. Иртән ялтырап кояш чыга, кешеләрдә якты өмет кабына. Төштән соң, бар халыкны туплап, печәнгә китәргә ниятлиләр, хәстәрен күрәләр. Әллә Алла боерса диярга оныталар, әллә башка сәбәп—төш житте исә, теге көндәге кебек, башта кечкенә генә ак болыт чыга да, бераздан каралары белән алышына. Ул кара болытлар зурайганнан зурая бара. Инде кояш та күренми башлый, һәм ишеп янгыр яварга тотына. Июнь беткәнче шулай булды. Хәсьяновтан печән әзерләү турында көн саен белешмә сорыйлар, бер тапкыр хәтта бюро утырышына да куеп пешерделәр.

Бюрога барыр алдыннан кемнәндер ишеткән мәзәк хәтеренә төште. Имеш, бер колхозның рәисен алыштыралар икән. Китүче рәис янасының кулына өч конверт тоттыра һәм дә әйтә:

—Менә сиңа өч конверт. Син аларга хәзергә тими тор. Бик кыен булганда башта беренчесен, аннан икенчесен, коймаң бөтенләй комга терәлгәч, өченчесен ачарсың,—ди.

Яшь председатель бер ай, ике ай эшли. Берзаманны монын көймәсе комга терәлә: терлекчелектә план үтәлми: ит юк, сөт юк. Бюрога чакырталар. Шунда барыр алдыннан монын исенә келт итеп теге өч конверт төшә. Беренче конвертны ачса, анда: «Барысын да миңа сылта»,—дип язылган була. Шул киңәшкә таянып, ул бюродан исән-имин чыга.

Күпмедер вакыттан соң хуҗалыкта хәл тагын кискенләшә. Тагын бюрога чакырталар. Барыр алдыннан егетебез икенче конвертны ачып укый. «Алдаш, вәгъдә бир!»—Конверттагы киңәш бу юлы да аның башын саклап кала.

Бераздан чират өченче конвертка җитә. Колхоз рәисе, котылуны өмет итеп, өченче конвертны ача. Анысында: «Туган, өч конверт әзерлә»,—дип язылган була.

Хәсьяновның өч конверты юк иде, бюрода, аның учет кенәгәсенә язып, шелтә бирделәр.

Шелтәсен шелтә, эшкә файдасы тиярдәй булса, Мидхәт берне түгел, биш шелтә алырга да риза булыр иде. Ләкин шелтәсе дә, райком, обком бюросы да, кирәк чакта яңгыр яудыра алмаган кебек, вакытында аны туктата да алмый иде. Соң ул райком бюросында тавык мие ашаган нәрсәләр утырмый лабаса, берсе дә күктән төшмәгән, печән хәзерләү өчен кояш, коры көн кирәк икәнен барысы да белә.

Колхоз рәисе камытын киеп җигелеп тартучы Мидхәт Хәсьянов хәзер шулай уйлый. Кеше үзгәрсә дә үзгәрер икән. Райкомда бүлек мөдире булып эшли башлагач кына түгел, гап-гади инструктор чагында да печән хәзерләүдә артта калган колхоз җитәкчеләрен яңгырны сылтау иткәннәре өчен утлы табага бастыручыларның берсе, әйтерсең, ул булмаган. Беренче секретарь Һади Вәгыйзов аны бюро әгъзалары алдында бастырып, ялкаулыкта, эшне оештыра белмәүдә, булдыксызлыкта гаепләп аты-юлы белән сүккәндә, ул шул турыда уйланды. Ахмак! Бохар диванасы! Әгәр дә мөмкин булса, хәзер ул кайчандыр үзе рәнҗеткән кешеләрдән гафу үтенер иде.

Аеруча аңа бервакыт «Коммунизм» колхозы рәисе Кашапов рәнҗегән иде. Урыны оҗмахта булсын, Сталинградны саклап, башын салган, мескен. Хәсьяновны кичердеме икән ул, әллә шул рәнҗегән көе китеп бардымы икән бу якты дөньядан?

Шул ук вакытта тәҗрибәле, партия аппараты казанында кайнаган хезмәткәр буларак, ул Һади Вәгыйзовның да гади генә бер сырлы тәгәрмәч икәнен аңламый түгел, аңлый. Әгәр дә шестерня үзенең кайда, кем икәнен онытып, партия тәгәрмәчләренә каршы әйләнергә яки туктап калырга теләсә, шунда ук сафтан чыгарылачагын Мидхәт кебек райком мәктәбен узган тәҗрибәле кеше ничек аңламасын.

Тарихта барысы да кабатлана диюләре хак икән. Бүген менә ул Вәгыйзовка рәнҗи. Ә иртәгә үзен беренче секретарь итсәләр, һәр көн саен район өчен җавап сорасалар, Мидхәт үзе ничегрәк сайрар иде икән...

Мидхәтнең башы катты инде. Катарлыгы да бар шул. Күкләр Әскәйне нинди гөнаһлары өчен шулкадәр җәзалый торгандыр. Сабан туеннан соң булган гарасатны гына ал: күпме бәла-каза китерде. Маллар акканга, буа киткәнгә кәефләре бозылса да, моны баш бәласе итеп санамадылар. Икенче көнне, атка атланып, берничә кеше белән кырда йөрде Хәсьянов. Басулардагы икмәкнең ким дигәндә өчтән икесен боз сукканын, көчле яңгыр аударганын, чокыр һәм уйсу җирләрдән агып, ундырышлы катламның әрлән туфрагына кадәр юылганын күрде ул, һәм Мидхәтне чак кына йөрәк өянәге тотмады. Ләкин фаҗига болар белән генә дә бетмәгән икән: өмә белән куелган эскертләр янына баргач, алар үз күзләренә үзләре ышанмады—җәйнең җиләкле аланнарын хәтерләтеп, хуш исләр тараткан, кышын маллар авызына кереп ит, сөткә әвереләсе печән—олы-олы кибәннең икесе дә янып көл булган иде. Кем ут төрткән, кем яндырган? Якында яшен сугып яндырган имәнне күргәч, табигатьнең илаһи кодрәте печәнне дә корбан иткәне әйтмичә дә аңлашылды.

Өмә белән чабылып, җыелырга өлгермәгән печән теземнәре көн дә яуган яңгыр аркасында кибә алмыйча яткан-яткан да тирескә әверелгән. Күкләр

кодрәте каршында Хәсьянов чарасыз иде. Ул хәтта, кешеләрдән кача-поса күрше авылга барып, йөзьяшәр карчыкка сәдака да биреп карады. Файдасы тимәде, яңгыр явуын дәвам итте.

Ин гажәбе, ул елны, ни сәбәпледер, янгыр башка хуҗалыкларга алай ук каныкмады. Урманайлар, эстәрлеләр әллә ничәшәр печән эскерте куя алды. Хәтта орынып ук торган митрәйләр дә. Ә әскәйләр курпы җитешкәч көч-хәл белән куйган бер эскерт печән белән кышка килеп керде. Хәсьянов аны да сарык бәрәннәренә генә ашатырга боерык бирде.

Печәне печән инде, саламы күбрәк булса, озын кышны ничек тә ерып чыгарлар иде. Яртысыннан артык басуынны боз суккач, җитәрлек саламны кайдан аласың? Күзгә күренеп, ачлык якынайды. Моны Хәсьянов кына түгел, олыга сан булган һәркем аңлый иде. Тик бу ачлыктан ничек котылып калырга, кышны ничек чыгарга—шуны әйтүче генә юк.

Хәсьянов ары сугылды, бире сугылды, ялынды, ялварды, кемгәдер алтын таулары вәгъдә итте. Бәхетенә бөтенләй үк тай тибеп бетермәгән икән: хәллерәк хуҗалыклардагы элеккеге әшнәләре кайсы арыш, кайсы бодай, солы саламы бирергә вәгъдә итте. Райкомда эшләгән чагында урман хуҗалыгы директоры Назаровны шактый гына зур күңелсезлектән коткарып калган иде, рәхмәт төшкере, онытмаган. Яшәсен әшнәләр, яшәсен дуслар! Алдагы елда түләү шарты белән Назаров бераз печән бирергә ризалашты.

Мидхәт—карт төлке, авызы бер генә пешмәгән, хәлләрнең кырыкка төрләнү мөмкинлеген белә. Бүген сиңа вәгъдә иткән колхоз председателе әле ул иртәгә дә председатель дигән сүз түгел. Алып атулары да, күтәрүләре дә бар. Шуңа күрә ул вәгъдә ителгән печән белән саламны тизрәк кайтару өчен колхозның бар булган көчен җикте. Унбиш-егерме көн эчендә ындыр табагында өч салам, бер печән эскерте үсеп чыкты. Ындыр табагы колхозның иң ышанычлы урыны. Анда сакчы булганы өчен түгел, сакчысы Нури карт булган өчен. Хәсьянов белә: әгәр дә тиешле документлары булмаса, Нури карт саламны башкаларга түгел, Мидхәтнең үзенә дә бирмәячәк.

Авылның бик кискен хәлдә—искиткеч авыр кышлау алдында торганын аңладымы, ул елны Хәсьянов, нишләптер, вакытлы-вакытсыз үзенә терлек азыгы хәзерләгән хуҗалыкларның печәнен тартып алмады. Алай гына да түгел, мең авырлык белән кайтарылган саламнан да өлеш чыгарды. «Дәҗҗал»ның миһербанлы бу адымы берәүләрне сагайтты, күпчелегендә рәхмәт хисе уятты. Ә райкомда моны башбаштаклык санап, Хәсьяновка тагын күсәк белән тондырдылар—янә бер каты шелтә чәпәделәр.

*Дәвамы киләсе саннарда.*



Рөстәм
Мингалим

# ГӨЛЛӘР АНДА ГЕЛ ЧӘЧӘКТӘ...

## Нигез ташлары

**Тау менеп тау төшәсе дә ...—
Минем авыл башланыр.
...Мин туган йорт күчеп киткән,
Калган нигез ташлары.**

**Ташлар елый җиргә ятып,
Мин йөримен юатып:
—Еламагыз, ташкайларым,
Файдасыз ул яшь түгү,
Шуңа әле мин еламыйм...
Тик йөрәгем таш түгел.**

## Җәннәт почмагыдай авыл

**Хуҗалары ташлап китkәч,
Кимсенеп яши бу як...
Чәчелмәгән кырларында
Каргалар йөри елап.
Горур тавы шактый чүккән,
Елгасы нык чигенгән...
Ташландык абзар башында
Соры чыпчык сүгенә.
Сүгенмидер:
—"Монда тудым, монда үстем,
Моннан китмим!—дидер ул.
Оямдагы өч баламны
Ятим итмим!"—дидер ул.
Җәннәт почмагыдай авылым
Югалган бит, таралган.
Кыяфәтен тасвирларга**

Рөстәм МИНГАЛИМ (1937) — *шагыйрь, драматург; күпсанлы китаплар ("Эзләр", "Шигырьләр һәм поэмалар", "Дәрт чулмәге" h.б.) авторы. Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Әйләнми тел, әрни җан.
Җанга дәва булыр иде
Хәзер яныма килсә—
Бала чакта сугышып үскән
Дусларымның хет берсе!

## Охшашлык һәм кыргыйлашу

*Юкка чыккан авылымнан узганда*

Монда капкалар җырламый,
Чиләкләр чылтырамый,
Хуҗабикәдән су сорап,
Бер сыер да мөгрәми.
Вакыт җиңгән шул—
Авылның
Туктап калган йөрәге.

Бар тарафын басып алган
Алабута, кычыткан:
Урамнар кыргыйлашкан.

...Мин шәһәрдә
Кыргыйлаштым:
Чүп-чар уем—
Чиктән ашты.

## Таралып та югалмаслар

Мин дә мәшәкатьле кеше:
Җирдә шактый уралдым,
Байтак ахмаклык та җыйдым.
Аз-маз акыл да алдым.
Инде, алганымнан сайлап,
Шуны да әйтми булмас:
Югалу юллары бик күп,
Табылу юллары аз...
Авылларда туганнарның
Сәер көче бар сыман:
Таралып та югалмаслар,
Гел табылырлар сыман...

## Туган як елгасын хәтерләү

Касады-су, әй кадерлем, туган су,
Әнкәм йөзен, әткәм йөзен юган су.
Юлың җиргә түгел.
Миңа уелган.
Төнбоеклы култыкларың
Куенымда.
Ашыгып яшел ярга ташлап
Кайчак кармагым,
Балыкларың тырпылдавын
Карадым.
Яр буйларың төркем-төркем
Тал гына,

Малай чакта
Ялап бeләм—
Яфраклары бал гына...
Исә дә җил,
Камышларың сөрлегә,
Туган якта
Җем-җем аккан
Бер генәм!
Тамчы күрсәм дә
Төшәсең исемә,
Диңгез күрсәм дә
Киләсең уема.
Дөньяда иң йомшак та
Иң яшел яр—
Синең яр,
Җирнең иң ак кызы
Синдә коена.

## Алып килдем сезгә җыр

Алып килдем сезгә гөл:
Күңелемдә гөл йөртәм,
Касады-су буеннан
Алып килдем яшьлектән.
Гөлләр анда гел чәчәктә,
Чәчәк тулы бал икән лә,
Анда гына кал икән.
Алып килдем сезгә уй—
Күңелемдә уй йөртәм:
Касады-су буеннан
Алып килдем—яшьлектән.
Анда көнең чәчәк ата,
Төнлә күгең чәчәк ата.
Чәчәк тулы бал икән лә,
Анда гына кал икән.
Алып килдем сезгә җыр—
Күңелемдә җыр йөртәм:
Касады-су буеннан
Алып килдем—яшьлектән
Анда бар да чәчәк икән,
Сөйгән яр да чәчәк икән.
Чәчәк тулы бал икән лә
Анда гына кал икән.
Анда гына, анда гына
Гомерлеккә кал икән дә...—
Калып булмау бар икән!

## Авылым урманында

Туган якны озак күрмәгәндә
Күңелемдә хис дәрьям саега.
Шигырь кояшым да—
Гомер кояшым да—
Сизелеп, бара сыман баюга...
Шөкер әле менә тагын юлым—
Авылым урманында,
Балачак юлларында.
Күрим әле, йөрим әле тагын
Баллы юкәләрем һавасын сулап.
Күптән киселгән,
Караеп калган төпләрдән
Үрентеләр чыга дулап.
Йөрим әле
Әткәмнең чалгы янавын
Хәтерләткән җирдә.
Чабып куйсаң, җыеп куйсаң,
Өеп куйсаң—
Эскерт-эскерт
Чәчәк булыр бирелә!

Урманында йөрим,
Урманында,
Кайчак, авыраеп уйларымнан,
Карт имәннәр күләгәсенә утырам.
Имәннәр,
Үрентеләр,
Үләннәр
Уйларымны
Киң һәм чиксез
Биеклеккә таба
Озатып тора!

## Казаннан бик еракларда тусак та

Казаннан бик еракларда тусак та
Бөек Ислам дине
Булды динебез.
Татарлыгыбыздан качмадык.
Чөнки данлы татар телендә
Ачылды телебез.
Кайдадыр кемдер безгә:
—"Казан татарымы?"—дисә,
—"Юк!"—диярга ашыкмадык.
Чөнки Казаннан
Бик еракларда тусак та без,
Бөек Ислам дине
Булды динебез.
Данлы Казан телендә
Ачылды телебез.
Әйтерсең Казан белән бергә
Инде мең ел яшәлгән!
...Өмет бар тагын бергә-бергә
Мең ел яшәргә.

## Өмет гөлем

Ал гөлем ак кар астында
Калды шул инде көлеп...
Юк, сулмас ул, югалмас ул,
Ул—минем өмет гөлем.
Йөрәгемнән ал гөлемә
Карлар аша көч бирәм.
Бик сизәм лә: кыш озын ла,
Кыш салкын ла, кар тирән...
Язлар килеп, карлар бетте,
Ал гөлем чыкты көлеп.
Юк, сулмый ул, югалмый ул—
Кешенең өмет гөле,
Һәр кешене каршысында
Җиңү шатлыгы котә:
Исән булса күңелендә,
Максатында—өмете!



Лира
Ибраһим-Вәлиди

## ӨСТӘН КАРАП

ХИКӘЯ

*«Үзгәреп торучан булганга күңел "калеб" дип аталган. Күңел сахрадагы бер агачка асылынып һәм җил искән саен әле артка, әле алга әйләнгәләп торган ялгыз каурыйга охшаган."*
*(1001 Хәдис).*

Күңелендә һәрчак биеклектән курку яшәде. Үз-үзен ничек кенә көйләп караса да котыла алмады ул аннан. Менә хәзер дә, самолет көчәнеп югарыга менә башлауга тагын шул курку тозагы эчендә калды. Ышанычлы Җирдән аерыласы килми, ул соңгедәй карашларын иллюминатор аша җиргә кадады.

«Алып кал мине Җир үзең белән! Ник ычкындырдың? Синдә каласым килә!»

"Күңелдәгене санламаган акыл сатлык бит ул!"

Ә анда аста, кайнар парларын бөркеп торган зур мегаполис, берсеннән-берсе биек йортлары, эреле-ваклы супер-гипер маркетлары, зур-зур завод-фабикалары, төрле мөһим һәм мөһим булмаган кысыр хәсрәтләре, мәшәкатьләре, чүп-чарлары белән—вулкан лавасы кебек тулышып килгән дә кинәт кенә кечкенә бер инеш буенда ухылдап туктап калган. Әйтерсең, гигант зурлыктагы бер ерткыч җанвар чүл буйлап су эзләп ыжгырып чабып йөреп ялгыш кына шушы кечкенә инешкә юлыгып беразга сусавын басып тынып калган.

Ә инешнең икенче ягы, янында ухылдаган бу ерткычның тавышын ишетмәгән, сулышын тоймаган да кебек, үтә гади, ябай үз тормышы белән тик яшәп ята сымак...

Әнә, кардан арчылып шәрәеп калган тар-тар бәрәңге бакчалары, бакча башларында шундый ук кечкенә, төссез генә моңсу йөзле агач өйләр. Шул бакчалар, өйләр арасыннан сузылган, төрле якка бөкрәеп теткәләнеп беткән юллар-сукмаклар, һәм тагын әллә күпме шушы үксез күренешне тулыландыручы кирәк-яраклар...

Күккә менеп җитми сагынып та өлгердеме, белмим, тик шушы күренеш аның да сусавын кузгаткан кебек булды. Әйтерсең, менә хәзер генә ул шул

Лира ИБРАҺИМ-ВӘЛИДИ—*яшь язучы; "Мирас итеп йолдыз калдырам" исемле китап авторы. Алабугада яши.*

язгы сусыл жирнең әчкелтем исен тойды. Үлеп ярата икән бит ул бакча чүбе янган исне дә. Кәкре-бөкре юллардан чабып йөрүче әнә теге балаларга, кулларына чыбык тотып каз-үрдәк куалап йөрүче әнә теге хатын-кызга, бакча уртасында бәрәнге чүбе янган учак буен уратып тәмәке көйрәтеп торучы ир-атларга чын күнеленнән кызыгып куйды. Аларның тыныч, матур йөзләрендә учак ялкынының шәүләсе сикерешәдер.

Яннарында гына үрсәләнеп-үкереп зур шәһәр кайнап торса да, нишләп алар һаман монда, шушы рәвештә? Нәрсә тота аларны шушы төссез жирдә?

Кешелек берсеннән-берсе камил компьютерлар төзи, галәмдә яна цивилизацияләр ача, нефть, газ сата, керемнәр ала, кайчак югалта, биржалар гөрли, ЦРУлар, ФБРлар шикле авантюраларны ачып ата, хатын-кызлар пробиркада ясалган тап-таза балалар табып ята да, ә болар, бәрәнге чүбе төтененә тончыгып тәмәке тарта!?

Кинәт кенә тагын, килгән саен, зинһар үзегез генә яшәп ятыгыз шәһәрегездә дип, ике кибетнең берсенә дә аяк атлап чыгасы килмәгән сенлесе исенә төшеп китте. Ул да нәкъ шулар кебек бит.

Замана агымы аларга кагылмыймы әллә?

Менә ул, яшәешне үзгәртер, алга жибәрер өчен зур идеяләр белән йөргән кешедәй, ашыга-кабалана, кырыгын кырыкмаса-кырык якка алып атып кайдадыр очып бара. Бүген дә, иртәгә дә, тагын әле бик күп көннәр очачак. Беркем дә аны ирексезләми, үзенә кирәк.

Үзенә чамасыз күп кирәк. Үз кочагына ярты дөньяны сыйдыру нияте белән планетаның бер башыннан икенче башына тизрәк очып житәр өчен самолеттан самолетка сикерә.

Тик үзе шул бәрәнге бакчасында тәмәке көйрәтүчеләрдән бер генә тамчыга да бәхетлерәк түгел сыман.

Ни өчен?

Аның кинәт тәннәре чымырдап китте. Шушы тормыш үлчәвенә ул бар гомерен, гаиләсен, жан тынычлыгын, тазалыгын салды.

Тик барыбер канәгать түгел.

Әнә шул ирләр, арзан тәмәке көйрәтеп бичара кыяфәтендә торсалар да, аннан мең артык бәхетлерәк, әйтерсең күзәтүчеләрне үртәп, үзләренең никадәр бәхетле икәнлекләрен башкаларга сиздермәс өчен генә шул сәләмә киемнәргә төренеп бөкрәеп торганнар сыман тоелды ана.

Йорт салу әллә аның кулыннан килмиме? Нишләп әле ул шушы күңелсез жирләргә карап моңаеп утыра? Менә әйләнеп кенә кайтсын, Казан янындагы иң матур урыннан жир алып төзеп куяр купшы гына бер йорт!

Аның тагын тәннәре чымырдап китте.

Андый йорты бар иде бит инде аның. Кара ничек сәер бу дөнья! Аның бит шушы әле күргән йортлардан мең кат гүзәлрәк үз йорты бар иде бит! Бар иде!

Инде тормышы жайланып, гөрләп яшәп ятканда гына тагын үкенечләрен әйләндереп кайтарып, тәүбәсен әйттерер өчен күккә күтәреп шушы жирне күрсәтteләрме соң ана?

Кичерелмәгән, димәк.

Бар да үзгәрде дип ялгышкан гына, берни үзгәрмәгән ләбаса. Дөнья һаман шул килеш, кайда тукталган булса шул урынында тора икән бит. Ничек үзгәрсен ди ул? Үзе бит үзгәрә алмаган. Тормышын үзгәртәм дип яшь хатынга өйләнде. Ун ел яшәгәч гажәпкә калып, алыштырмаган да кебек, вакыт узу белән гел бер төрлегә әйләнә икән хатын-кыз дип уйлады. Икесенең берсе дә ана кирәкле нәрсәнедер бирмәделәр. Ә ул үзе бирдеме? Эти итми дип гомере буе улына үпкәләп, рәнжеп йөрде. Минем рәнжеш

башына төшсә белер әле дип каргады. Ә үзе? Әти булдымы соң улына? Нишләп, саран гына төрткәләгән акчаларыннан гайре башка берни бирми, башкалардан күпне таләп иткән?

Ә улы? Ул үзе рәнҗеп яшәгәндер. Юк, үзләрен калдырып башка хатын-кыз янына киткән өчен генә түгел. Башка, тагын да мөһимрәк нәрсәләр өчен. Ничә тапкыр улын эзләп табып гафу үтенәсе килде. Батырчылыгы җитмәде. Баштарак эчендә җаны булса үзе килеп күрсен бер карт әтисен дип һаман гаепне аның бакчасына этәрде.

Аннары.

Табалмады ул аны. Беренче хатынының үлгәнен белде. Ә улын таба алмады. Белгәндер улы үзен эзләгәнен, тик юлына чыгарга яисә тавыш бирергә теләмәде.

Кичермәгән, димәк. Яисә, бөтенләй кисеп ташлаган.

Алар инде онытканнар, хәтерләреннән сызып атканнар да бар үкенечне ана мирас иткәннәр.

Баштарак гаиләсен җимергәнгә бер дә үкенмәде. Икесенә җитәрлек дәүләт калдырдым, калганын үзләре карарлар дип, юмартлыгыннан канәгать тә булып яшәде. Улын җае туры килгәндә күрде. Күрмәсә дә бик исе китмәде. Ул вакытта тормышы түгәрәк иде.

Кичерелмәгән.

Ул озак вакытлар улына дөресен әйтә алмый йөрде. Ни дип әйтсә дә аңламас сыман иде. Үскәч, ир булып чын яратуның ни икәнен тәмләп карагач анлар һәм берсүзсез кичерер дип уйлады. Ә кечкенә улы һаман тынгы бирми аяк арасында буталанды. Йомшак куллары белән муеннарына сарылды. Кызларныкыдай кечкенә генә бөрмә сусыл иреннәре белән чәп-чеп битләреннән үпте. "Мин сине яратам, әти", дип бертуктаусыз кабатлады да кабатлады.

—Син миңа кайчан тетрис аласың?

—Туган көненә улым.

—Юк, син миңа аны болай ал. Туган көнгә миңа зурларныкы кебек роликлы коньки кирәк.

—Әниең алыр, аңа акча бирдем бит мин.

—Юк, син ал миңа. Әни миңа башка әйберләр алыр.

Ул кәнәфидә тыныч кына телевизор карап утырган хатынын сискәндереп:

—Нәрсә баланы миңа каршы котыртасың? Сиңа бит ул акча балага әйбер алырга дип бирелгән, һаман котыртып миннән акча соратасың,—дип җикеренде.

Улы берни аңламаган карашларын әтисенең ярсулы йөзенә төбәп торды да, барып әнисенең итәгенә менеп утырып кечкенә учлары белән ябык җилкәләрен кысып тотып, яңагын күкрәгенә салып тынып калды. Әйтерсең, җимерү уты чәчкән амбразураны кечкенә күкрәкләре белән каплап әнисен кимсетүдән саклап калды.

Хәтерендә, һәр көн иртән эшенә китәргә чыгуга машинасы янында аны улы белән Казбек дигән этләре икәүләшеп көтеп торалар иде. Алар инде бар дөньяны айкап чабып килгәннәр. Ул чүгәләп бер кулы белән улының тирләп беткән маңгаеннан сыйпый, бармаклары белән юеш чәчләрен аралый. Икенчесе белән алдында уйнаклаган Казбекның колак артларын кашый. Аннары машинасына утырып улының яшел, куаныч белән балкып торган күзләреннән алган нурга коенып, кузгалып эшенә китеп бара.

Һәр көн булды микән ул шулай? Ничектер һәркөн булган кебек гел күз алдында тора.

Аерылышасы билгеле булган көннән соң улы аның күзенә күренмәде диярлек. Бәлки күренгәндер дә ул, үзе күрмәгәндер.

Ә бер кичне, машинасын кабыза алмый интеккән чакта янына килде улы. Яңа гына яшенләп, көчле яңгыр бәреп явып киткән иде. Баешка төшкән кояшның матурлыгын шул көнне генә күреп калды бугай ул. Башкача аның кояш баешына сокланганы булмады кебек.

Хатыны белән яңа гына кычкырышып чыккан бик ачулы чагы иде. Әнә шул ачулы чаклар үкенечле дә инде. Әйтәсе килмәгән нәрсәләр әйтелә дә, рәнҗетәсе килмәгәннәр рәнҗетелә.

—Әти, әйдә сатма өйне, ә әти.

Ул ачу тулы күзләрен улына күтәрде.

—Нәрсә, тагын анаң котыртып чыгардымы?

—Юк. Мин калам ич монда. Мин, әти. Син кунакка килерсең.

—Ике бүлмәле фатирыгызга кунакка килермен мин улым, яме, бик киләсем килсә.

—Ә Казбек?

—Казбек монда, яңа хуҗаларга калыр. Калмаса, әнә эт җыючылар. Йоклатырга алып китәрләр.

—Ә мин?

—Нәрсә син?..

Бик ачулы иде шул. Улы, аның ачулы карашларыннан яшеренергә теләгәндәй, яшел күзләрен сизелер-сизелмәс торган сары кашлары астына көчләп тыгарга тырышты. Тик күзләре артык зур иде. Малай тавыш-тынсыз артка чигенде дә, бакчаның ачык капкасыннан эчкә кереп югалды. Казбегы да, оясы янында койрыкларын салындырып, ата белән улның бу сәер әңгәмәсен күтәрелеп карамый тын гына басып тыңлап торды да, малай кереп киткән якка борылып тирән итеп бер генә тапкыр үксеп куйды. Аннары иелеп, әле генә эндәшмичә яныннан узып киткән малайның ялан аягы калдырган эзенә җыелган яңгыр суын йотлыгып яларга керешә.

Кузгалып киткәч тә эте һәрвакыттагыча, койрыкларын болгап һау-һаулап озатып калмады. Суын эчеп бетергән эз чокырына аякларен салып бакчаның ачык капкасына төбәлгән килеш тын гына ятып калды.

Эт тә кичермәде.

Тормышының күп вакытын эшенә багышлаган, монда тик ашарга һәм йокларга гына сугылгалаган ата, асылда исә бу йортның шушы сары башлы малае белән этнеке булып беткәнен аңламаган. Хакыйкатьтә үз хакларын гына хак итәргә хаклы санап өйрәнгән ата, аны шушында тирән бәхетле иткән, шушы нигезнең чын хуҗасы, саклаучысы итеп тойган үз улын бабасының нигезеннән куып чыгарып, мәхрүмлеккә, билгесезлеккә, ятимлеккә, нәселсезлеккә дучар иткән булып чыга икән бит.

Аннары... Аннары тагын да тирәнрәк яралар...

Бердәнбер сатып алучылар өйнең беренче катындагы залы караңгырак булганга алудан баш тартырлар дип уйлап тәрәз каршындагы җәйрәп үсеп утырган миләш агачын балта белән чапкалап атарга уйлады. Башкача беркемнең башына кереп тә карамаган кысыр көенеч аның акылын томалады.

Гадәти булмаган ниндидер давыллы көн иде ул. Әллә аның балта күтәреп явызлык кылырга йөргәнен тойганга, каршы күтәрелде ул давыл.

Ул миләш... Ул миләш... Ул миләш...

Улы үзен яраткан кебек ул да ярата иде бит әтисен. Артыннан калдырмый гел ияртеп йөртә иде. Җәен, кичкырын эшләрен тәмамлагач капка төбендәге чирәмдә сөйләшеп утырырга яраталар иде. Юк, әтисе күбрәк аны, аның

бераз иркәләнүдән ирсеп бертуктаусыз лепелдәүен сабыр гына тыңлый иде. Ашыга-ашыга сөйләп бетергәнен көтә дә, аның башын күкрәгенә кысып рәхәтләнеп көлә.

Ниләр турында сөйләштеләр соң әле алар? Хәзер инде бик нык тырышса да хәтерли алмастыр. Ул авырту тойган сыман йөзләрен чытты. Юк, юк, менә берсен хәтерли икән бит.

...Чирәм өстенә икесе сузылып ятканнар—әтисе кулларын баш астына, ә ул аркылыга ятып башын аның күкрәгенә салган. Ниндидер гадәти нәрсәләр турында сөйләшкәннәрдер, ул барсын да хәтерләп бетерми, тик...

—Әти, күрәсеңме, әнә тегендә минем бәхет йолдызым,—диде ул, күкнең бер почмагына нәни бармакларын төбәп.

—Ыйы,—диде атасы, башта аның сөйләменә әһәмият бирми.

Малай бераз тын гына ятып карашлары белән йолдызлы күкне айкады.

—Әй, юк икән әтием, юк. Анысы түгел, әнә тегесе,—дип малай нәни бармакларын инде икенче якка төбәде.

—Ыйы,—диде атасы, инде бу юлы көлемсәр карашларын улының йөзенә күчереп.

Тагын бераз гына тын яттылар.

—Әй, төгәл генә белмим инде кайсысы икәнен. Ә, тукта!

Малай яткан җиреннән торып утырып бармагын күк йөзенең бер ягыннан икенче ягына күчереп төртеп күрсәтә-күрсәтә санарга кереште:

Әке-бәке,
Кыек сәке
Карга, чыпчык,
Син кал, бу чык.

—Әһә, менә монысы. Менә монысы әти, минем бәхет йолдызым. Хәтереңдә калдыр яме. Иртәгә табалмасам мин синнән сорармын.

И, көлде дә соң әтисе. Тончыга-йөткерә рәхәтләнеп, нидән көлгәнлеген аңлатмый гына кычкырып көлде дә көлде...

Менә шулар...

Башкача исенә төшерерлек әһәмиятле нәрсәләр дә булмаган сыман.

Әтисен... Әнисен...

Нигә кешечә түгел соң барсы да?

Нигә шул тиклем комсызланып, барысыннан йөз чөереп тормышның бугазына ябышкан соң ул? Берсе икенчесенә комачаулады микәнни соң?

Ул миләш... Ул миләш... Ул миләш...

Аның аягындагы җөе әрнеп сызлап куйган кебек булды. Ул тагын үрелеп аска карады.

Миләш чәчәк ата торган вакыт.

Ул миләш...

Ул миләшне әтисе белән икесе бергә утырткан иделәр. Өй алдындагы баланнарны да, миләшне дә. Ул үзе бит әле көн аралаш зур чиләкләр белән аңа су ташыды. Миләш нишләптер ул елны корыды. Урынын яратмагандыр. Ә икенче елга тагын төбеннән яңарып чыкты.

Миләшнең барлыгын оныткан кебек әтисен дә инде күптән оныткан икән бит. Аның кайчандыр булганлыгын, аны—улын, чын күңеленнән сөюе төсе итеп миләш утыртып калдырганлыгын һәм ниһаять үлгәнлеген оныткан да бит инде. Ул миләшне үз куллары белән чапкалап аткан да борчусыз-нисез генә тарих төпкеленә озаткан.

Менә бит, килеп чыкты әле. Тик әллә ничек ямьсез, куркыныч булып, барысы бергә төйнәлеп зур булып күкрәк читләрен авырттырып ертып килеп чыкты. Шул вакытта аягының йөзен ярып төшергән балта ярасы кебек...

Тегендә аста, бәрәңге сабагы төтенендә тончыгып тәмәке тартучыларның нәрсә өчен үзеннән өстенрәк тоелганын анлады ул хәзер. Аларның намусында нигез рәнжеше, туган җир рәнжеше, ата рәнжеше һәм миләш рәнжеше юктыр.

Ул кешеләрне үзе белмәсә дә, алар аны белеп, үкенечләрен үзләрендә тойганга, аның хәсрәтле карашларын күрергә теләми артлары белән торган сыман тоелды.

Әллә акылдан язамы соң?

Туктатыгыз, зинһар, самолетны! Туктатыгыз, мин төшәм!!!

Төшәр дә, каршыларына басып йөзләрен туры тотып барсын да анлатып бирер. Тынларга теләмәсәләр язып бирер, һич югы радиодан сөйләр! Аңларга тиешләр алар. Аңларлар! Аны кызганып әрнеп еларлар да әле. Еларлар! Ник еламаска? Кызганыч бит ул! Кызганыч!

Калын портфель кыстырып мөһим сәфәргә чыккан, бәрәңге сабагы яндыручы ирләрне күреп самолетның иллюминаторына сарылып үксеп елап баручы, шушы мәгъруур илнең бер эшлеклесе, ... ... ...бичарасы ул!

Шушы җир өчен яшим, хезмәт итәм дип уйлап ялгышкан ул. Җирдә түгел, гомере буе җирдән югары, һаман самолетта икән бит.

Ә җирдә әнә алар, бәхетлеләр, намуслылар, вөҗданлылар, тугрылар, аталылар, уллылар!

Бакчаларында миләшләре, баланнары! Этләрен ияртеп бакча буйлап чабучы яланаяклы малайлары...

Алар икенчеләр.

Ул алар кебек түгел!

"Үз егет" түгел ул.

Менә нигә курка икән ул биеклектән. Йә, Хода, ниһаять, вак һәм тун күңеленә курку салырга сәләтле бердәнбер чара икән бит бу! Җирен, аяк астындагы газиз җирен югалтудан, җир кешесе булуыннан туктаудан курка түгелме соң ул?

Чөнки, самолет та ничек кенә озак очуына карамастан, барыбер бер җиргә төшәчәк!

Бер төшәчәк!

Ул да җирдән атлап китәчәк...

Җир! Минем синдә каласым килә!



Госман
Садә

# МИН КАБЫЗДЫМ ГОМЕР ШӘМНӘРЕН...

## Яшәү белән үлем арасында

Яшәү белән үлем арасында—
Гомерләрнең якты һәр язы.
Гел иркәләп безне уятачак
Бишектәге сабый авазы.

Яшәү белән үлем арасында—
Сөюләрнең сагыш-газабы.
Шундый матур яшәү моңы булып
Җырланачак әле азагы.

Яшәү белән үлем арасында
Ачылмаган күпме сер ята.
Гомеркәйләр кылын чиртә-чиртә,
Язмышларны меңгә болгата.

Яшәү белән үлем арасында
Мин кабыздым гомер шәмнәрен.
Шул шәмнәрем бер көн сүнгәчтен дә
Җыр яктысы булып яшәрмен.

Яшәү белән үлем арасында
Гомеркәйләр безнең түгәрәк.
Сөюемне, берүк, онытма дип,
Очып йөри нәни күбәләк.

## Күрәзә

Иртән кояш чыгасын
Туганнан бирле беләм.
Алдашмам карурманда—
Янымда Хак Тәгаләм...

Иман тулы күңелем—
Хикмәти бер тәрәзә.
Догаларда язылган
Безгә дигән күрәзә.

Юк, иманга өндәми
Мәҗүси имче сүзе.
Күрәзәсе һәр өйнең—
«Аятел Көрси» үзе.

Госман САДӘ (1949)—*шагыйрь, публицист; "Мәхәббәт елы", "Җиләкле тәрәзәләр", "Тайфун күзе" һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

***

Бу гөнаһсыз кыз баланы
Күргүгә, йом күзеңне:
Күз тидерә күрмә, берүк,
Үтенәм, бул түземле.

Сорама син исемен дә—
Иртәгә үзе әйтер,
Әгәр үзе әйтми икән—
Керфеге, күзе әйтер.

Күзне язлар алыштырыр,
Төнен дә кояш балкыр.
Танышуны ашыктырма,
Ашыкма син, бул сабыр.

Ул каршыңда басып тора—
Сиздермә, эчтән куан:
Сизәсеңме, арагызда
Мәхәббәт күптән туган.

## Июнь урманы

Урманнарга кергәч, исем китте—
Шәм нурыдай якты елтырау.
Ландышларның бүген чәчәк туе,
Һәрбер чәчәк—нәни кыңгырау...

Урман чыңлый, урман җырлый бүген
Яратканга Ландыш сеңлесен...
Безнең телдә ландыш—энҗе чәчәк,
Энҗе булып сүзем тезелсен.

Урманнарга кергәч, бер туй күрдем,
Чәчәк туе июнь башында...
Ә Ландышым—мәңге сулмас чәчәк,
Ул утыра минем каршымда...

## Әссәламегаләйкем![1]

Таң ата да кояш чыга,
Кояшны сәламли көн.
Саумы, кояш, сүнмәс учак!
Әссәламегаләйкем!

Тел ачкычы, иман биргән
Сөекле туган телем!
Үз телемдә сиңа сәлам,
Әссәламегаләйкем!

Әй игенче, күкрәп үссен
Кырларда синең иген.
Икмәк тотып сәлам юллыйм,
Әссәламегаләйкем!

Ачыйк бәхет ишекләрен,
Бәхетле булсын һәркем.
Әй кардәшләр, милләттәшләр,
Әссәламегаләйкем!

Таң ата да кояш чыга,
Кояшлы бездә һәр көн.
Кояш белән сәлам юллыйм,
Әссәламегаләйкем!

## Хаин Һарун алтыны

(риваять)

Бер хикәят сөйлим, и оланнар,
Онытылып җанда калмасын.
...Һарун сатты бөек мәмләкәтен,
Ачты төнлә шәһәр капкасын.

[1] Резеда Ахиярова көе.

Өч көн, өч төн кала дөрләп янды,
Мәчет аен йотты көл-күмер.
Каһкаһәләп, шашып көлде кяфер
Өзелгәндә сыкрап кыл-гомер.

Дүртенче көн патша мәҗлес корды,
Җыйнап йөз ун меңле гаскәрен.
Канга бутап хәмер чөмерде ул,
Куккә чөеп тәре сәфәрен.

Ышкый-ышкый сөртте ул маңгаен,
Йөзендәге кара корымны.
Яранына аннан ул боерды:
—Китерегез бөкре Һарунны.

Карт мәчедәй ялт-йолт карангалап,
Узды Һарун ефәк чатырга.
Патша әйтте:
—Әгәр тәре үпсәң,
Рөхсәт бирәм бездә калырга.

—Ү-бәм! Ү-бәм!—диде Һарун шашып.—
Тик бирегез алтын—бер чүмеч...
Падишаһка аның бу гозере
Китермәде һич тә сөенеч.

— Сиңа алтын кирәкмени, мәхлук,
Саткан өчен илең-халкыңны?
Яңартмакчы әллә буласыңмы,
Тәре үбеп, иман шартыңны?

Юхарак син буар еланнан да,
Балаңа да тәре тагарсың.
Син хаингә ничек таяныйм мин?—
Иртәгә үк мине чагарсың.

Аяк тибеп патша бер җикерде:
—Яла башта минем корымны.
Чүмеч тулы алтын кайнатыгыз
Һәм сыйлагыз Херон-Һарунны.

...И оланнар! Гомердән дә кыйммәт
Ил иманы, милли тойгылар.
...Чүмеч белән—Һарун авызына
Кайнап торган алтын койдылар...

## Кремльдә—тарих дәресе

*—Әйтче, әни, безнең Казан*
*Кремлен кемнәр төзегән?*
*—Аны, балам явыз Иван*
*Салдырган татар сөягеннән.*
(Ана белән бала сөйләшүеннән)

Ни өйрәндек, нәрсә белдек
Без тарих дәресеннән?
Бер җиңелгән гел җиңелә—
Куркаклык канга сеңгән.

Җиңелгәнне хурлау җиңел,
Безне дә хурладылар.
Күзне куркып ачалмагач,
Тарихны урладылар.

Үзләренә ничек кулай,
Язылды тарих шулай.
Урладылар хәтерне дә—
Уңайга килгәч уңай.

Һаман урлый. Һаман туймый.
Һаман да әзсенгәне.
Урладылар, ахыр, телне—
Иң соңгы хәзинәне.

Бер җиңелгән гел җиңелә—
Бу инде канга сеңгән...
Тарихымны эзләп йөрим
Урланган дәресемнән.

Кем тергезер тарих утын?—
Урланган хәрефләре.
... Казанның нәкъ йөрәгендә
Хәнҗәри алтын тәре.

***

Төркиләр—күк уллары.
Күктән килә юллары...

Күлмәкләре—ак канат.
Канат саен каһанат...

Челләдә, бик эсседә
Анасу—Енисейдә

Юам канат-күлмәгем.
... Искә төшә Күлтәгин.

## Артыклык

(Төрекчәдән)

Кайгы-хәсрәт белән тулды янә кичләр...
Бүлмәм салкын—син керәсең төшләремә.
Бикләделәр тыштан тимер зур ишекне,
Зынҗыр-богау кигезделәр йөрәгемә.

Төннәр буе ыңгырашып, саташам мин...
Исемеңне уеп яздым һәр кирпечкә...
Балдан татлы иренеңне үпсәм иде,
Ай-йөзеңне күрсәм иде шушы кичтә.

Әй, сабыр бул, сынма, күңел, газапланма,
Килер бер мәл: чыгарырлар якты көнгә.
Дүрт тарафта, бер китапта бер исем бар,
Исемеңне саклый фәкать Коръән генә.

Тоткыннардан артык тоткын (белә кем дә).
Мин үзем дә шундый хәлдә—артык мин дә.
Баш очыңа Коръән куеп йокла төнен—
Сына белмәс кодрәт туар йөрәгеңдә.

Беләм: кабат кояш кунар тәрәзәмә,
Йөрәгем дә ялкынланып һаман янар.
Балдан татлы җаным минем уяныр да,
Тау елгасы сыман күздән яшем агар...

Мин үзем бар—миннән башка миннән артык,
Син үзең бар—синнән башка синнән артык.
Мин үзем бар—миннән башка миннән артык...
Мин бар, син бар—бездән башка бездән артык.

## Лачыннар юллыйм

Бер сүз мине һаман тетрәндерә...
Коръән аша иңгән Илаһтан:
«Үз Лачынын сөйгән хатын-кызны
Мин саклармын барча гөнаһтан.»

Күк катында гөнаһ туа алмый—
Галәм иңләп йолдыз сибелгән.
И хатын-кыз, йолдыз кочагында
Янып сөйгән, янып сөелгән...

Биеклеккә, һаман югарыга,
Күккә әйди йолдыз ялкыны.
Хатын-кызны саклап гөнаһлардан,
Канат кагып очар Лачыны.

Мәрхәмәтле, изге мәхәббәтнең
Мәңгелеген күреп сөенер.
Бездән соң да... нәфис сеңелкәйләр
Янып сөяр, янып сөелер.

Хатын-кызлар белән аңлашуның
Беләм кебек якын бер юлын:
Илаһыдан килгән әмер белән
Лачыннарны Сезгә юллыймын!

**Редакциядән:**

***Бу айда шагыйрь, публицист, журналыбызның даими авторы Госман Садәгә 60 яшь тула. Аңа яңа иҗат уңышлары, исәнлек-саулык телибез!***



Фәнзаман
Баттал

# САТИРИК ХИКӘЯЛӘР

### Чегән сугышы

Гөжләп торган базар мәйданының кыл уртасында колак пәрдәсен ярырдай тупас сүгенү яңгырады. Шул ук мизгелдә, бүредән өреккән сарык көтүедәй халык, төрле якка тартылып, тораташтай катып калды. Әле генә сату-алу белән кайнаган базар, күз ачып йомганчы, сабантуй мәйданына әверелде. Урталыкта бары тик ике кеше калды: берсе кырык яшьләрдәге чем-кара сакал мыеклы, күнитекле ир, икенчесе—кызыл бизәкләр белән чуарланган кара яулыклы хатын. Хәер, боларның икесе дә әнә шул ике төстән генә тора кебек. Ирнең җиң очлары сүсәрә башлаган иске телогрейкасы белән чалбары кара булган кебек үк, хатынның да курткасы, итәге кара. Нәфрәттән янып торган күзләре дә тере шомырттай бу икәүнең. Тегесенең—күлмәге, монысының кофтасы кызыл. Икесе дә чибәрләр әле, житмәсә!.. Кочаклашып, назлашып кына йөрергә тиешләр сыман... Ә болар, бер-берсен өзгәләп ташларга әзерләнгән ата ерткыч белән ана җанвар кебек кара-каршы басканнар. Кинәт кенә алга ыргылган Хатын, баш-башлары тимер белән түгәрәкләнгән калын гына метрын кылычтай селтәп, Ирнең инбашына сукты. Шундук кычкырып та җибәрде:

—Барыбер түләттерәм бурычыңны, сволочь! Инде елдан артык качып йөрисең бит, кабахәт!

Ир, әлеге метрлы линейканы эләктерергә омтылды сыман—алга тартылды. Әмма ярсыганлыгы йөзенә генә түгел, бөтен гәүдәсенә чыккан хатын, чәчрәгән очкындай сикерде дә, бу юлы ирнең муенына тондырды.

—Бир бурычыңны!..

Кызарып чыккан муенена кулын куйган Ир, икенче кулын йодрыклап, Хатынның борын астында уйната башлады:

—Ничә тапкыр кабатларга була сиңа бер үк сүзне?! Йөз сумыңны шул ук көнне кайтардым бит, ана эт! Башыңдагы яулыгыңны кем алып бирде?! Мин!

—Бүләк итеп бирәм диден син аны!..

—Какой хрен бүләк сиңа?! Син кара еланга нинди бүләк бирим мин?!

—Елмая-елмая... Тфү! Ыржая-ыржая, жилкәне сыйпый-сыйпый, бүләк иттең бит, зараза! Сигезенче март иде бит ул көнне!

—Сиңа мин тотылган туалет кәгаземне дә бүләк итәсем юк! Чөнки шакшы кулыңда ул да пычраначак!

Әлбәттә инде, боларның «әңгәмәсе» урыс телендә бара. Урысның сүгенү культурасында нинди сүз бар—болар барысын да бик оста куллана! Ләкин шул сүзләр арасына урыс та, татар да аңламый торган сүзләрнең килеп кысылганлыгы сизелеп куя. Шушы манзарага текәлеп тонган һәм тынган халык телгә килә башлады:

—Бәй, бу хатын тәрәзә тюле сатып тора иде теге башта. Шул бит бу! Чегән хатыны ул!

—Сон... Хәзер генә белденмени әле анын чегән икәнен?—дип, әкрен генә һиһелдәде икенчесе.—Теге сакалбае да чегән инде анын! Кемнәр икәне күренеп тора бит.

Ул арада, мәйдан уртасындагы хатынның Ир йөзенә төкерүен күреп, халык дертләп куйды:

—Хәзер үзенә тондырачак тегесе...

—Ир кешегә төкергән икән, авызын сугып ярса да таманга туры килер!

Чынлап та Ир хатынга ыргылды. Ләкин сукмады да, җилпенмәде дә. Хатынның яулыгын урап тотты да, йөзен, сакал-мыегын шунын белән уарга кереште:

—Мә, үз пычрагын үзенә булсын! Мин дә төкерер идем дә... төкермим! Төкерегем пычраныр дип куркам.

Ярсыган хатын, башындагы яулыгын сыерып кына алды да, аңа кат-кат төкереп, борынын да сеңгереп, Ирнең йөзенә каплады:

—Ал үз чүпрәгенне, бетле сакал! Ә минем йөз сумымны кайтар! Шушы телогрейканы алырга да акчаң җитмәде бит синең, хәерче хәчтрүш, теге вакытта. Шул чакта бурычка сорадың бит син теге йөз сумны! Бирмисең икән, телогрейканы салдырып алам өстеннән! Ярты бәясе минеке анын!

Шушы сүзләрне ишетүгә, моңа кадәр тын да чыгармаска тырышкан халык шаркылдап көлә башлады. Әмма шунда ук меңгә якын авыз тыгылып та калды. Чөнки мыскылланган Ир, кайсы төшеннәндер елтыр да, озын да пычак тартып чыгаргач һәм аны чекрәеп торган кояш яктысында уйнатып алгач, китү юлына борылган Хатынга таба сикерде:

—Ах ты, сука!..

Хатынның сыртына керәчәк пычакның озынлыгын, базар уртасына кан җәеләчәген абайлаган халыкның бер өлеше, коты алынып:

—Милиция! Милиция!—дип илерергә кереште. Ә инде шул ук халыкның акыллырак өлеше, күк күкрәтеп дигәндәй, көлә торды. Чөнки болары белә: Казан дигән калада, бигрәк тә гадәттән тыш хәлләр булганда, милиция дигән кавемне көндез чыра яндырып эзләсәң дә таба алмыйсың. Аларның исендә дә юк хәзер халык дигән чиру. Ник анда тәмам кырылып беткәнче суешмыйлар! Алар түрәләрне, замана байларын, авторитетлы бандитларны саклап көн күрә бу заманда!

Юк, Ир дигәнебез, ничек кенә үрсәләнсә дә, пычагын тыкмады Хатынга. Тегесенең, борылып карап һәм халыкның котын алып, җан әчесе белән чәрелдәве булды, Ир җәһәт кенә артка тартылды һәм телогрейкасын салып, күз ачып йомган арада аны судай үткен пычак белән урталайга ярып, бер яртысын Хатынга ыргытты:

—Мә, ал үз өлешенне, тыгыл, каберенә капларсың, йә корчаңгы иренә кидерерсең!

Хатын исә, һушына килеп, мамыклары бүселеп чыккан телогрейка «сынарын» читтәрәк җыелып торган пычрак күлдәвеккә ташлады һәм аны таптый-таптый аякларын сөрткәч, лычма ләпек бу нәрсәне Ир өстенә ыргытты. Ир аны, футбол типкәндәй тибеп, хатын чыраена таба олактырды. Аннары, телогрейканың җилкәсендә эленеп калган яртысын алып, аны берничә кисәккә туракларга кереште.

—Мә, ал, дуңгыз күте кебек пычрак чыраеңны сөртү өчен сөлге итеп файдаланырсың!—диде ул, телогрейканың җиңен ыргытканда. Якасын томырганда исә болай дип өстәде:—Монысы кульяулык булыр, минем төс итеп иснәп яшәрсең. Ха-ха-ха!..

Ир тынычланды. Телогрейканың калган яртысы белән ышкый-ышкый итеген ялтыратты, аннары, Хатын кебек үк, аны аяк астына салып, ашыкмый гына табаннарын сөртте. Хатынга мыскыл белән карап, авызын чалшайтты, шуннан соң, җинүенең тантанасын тойдырырга теләпме, биегәндәй сикергәләп куйды да, аяк астындагы телогрейка кисәкләрен җыеп алып,

якындагы чүп савытына илтеп тыкты. Көтелмәгән нәзәкатьлелеккә исе киткән халык тагын бер мәртәбә көлүдән шартлады. Хатынның үз тирәсендәге аламаларны җыюы тагын да кызыграк тоелды: ул башта телогрейканың ләпектә аунаган кисәгенә өзелгән яканы, аннары үз «каберенә» бөркәнергә тиешле чистарак өлешен каплады, шуннан соң, кулына бер пычрак та тидермичә, барысын да төреп, инде чүмәкәй тулган шул ук урнага салды. Аның төргәге, ике сәдәп тышка чыгып калганлыктанмы, адәм башына охшап калды. Чегән хатынының шул «баш» өстенә шакшы яулыгын илтеп каплавы булды, болай да көлүдән тартышучы халык, кем әйтмешли, аятан егылды. Бу мизгелдә Ир, үзенә текәлгән хатынга кәҗә тоягы күрсәтеп һәм аның тарафына җирәнүле кул селтәп, җил-җил атлап китеп барды. Хатын исә, теге борылып караган мизгелдә, дугадай бөгелде дә, ана төбәлгән арт санын әле бер кулы белән, әле икенче кулы белән чәбәкләп калды. Мондый әкәмәт тамашага юлыккан бәхетле халык, инде ничәнче мәртәбәдер, тагын эче катканчы шыркылдады. Тегеләр күздән югалгач та:

—Вот дура и дурак!..

—Ахмаклар да инде бу чегәннәр! Алама телогрейка өчен дә сугышып, адәм мәсхәрәсе булып йөрмәсәләр соң!

—Пулнай кәмит булды бу!—диештеләр.

Ләкин шундук икенче кәмит башланды базарда: халыкның бер өлеше—чинарга, икенче төркеме уларга йә еларга, кайсыларыдыр—аһылдарга, уһылдарга кереште. Илереп-илереп кычкыруларыннан, утка баскандай үрсәләнүләреннән шул аңлашылды: без авыз ачып каткан өч-дүрт минутта күпләрнең кесәләрен, пакетларын, капчыкларын, сумкаларын ярганнар, берәүләрнең сатып алган тауарларын арбалары-ниләре белән бергә «шудырганнар», бик күп кесә телефоннары юкка чыккан, дистә-дистә мең акчалар җилгә очкан, әрҗә-әрҗә аракылар, колбасалар аякланган...

Ике ыспай ир аеруча өтәләнде. Баксаң, бәйләме белән ачкычлары югалган! Шул ачкычлар белән паспортлары һәм правалары да юкка чыккан. Базар читенә чыксалар, берсе «джип»сыз, икенчесе «ниссан»сыз калган...

—Аһ! Ачкычларыбыз да, адресларыбыз да бар бит хәзер аларда!

—Өйгә дә хуҗа булмадылар микән?!—диешә-диешә, юл читендә кул күтәрделәр һәм беренче булып туктаган «Ока»га утырып, күздән юк булдылар.

...Мин ул көнне бер журналдан саллы гына гонорар алган идем. Язучыларча әйтсәм, бер кесә акча инде ул... Шуңа күрә, кассирша акча санаганда ук, үз-үземә: «Болай булгач, елга бер мәртәбә булса да ресторанга алып барам үзеңне, байларча сыйлыйм!» дип вәгъдә биргән идем, эчемнән генә. Сүземдә торып, кичкә таба затлы рестораннарның берсенә кереп утырдым. Башымны күтәреп, як-ягыма карасам, ни күрим, якын гына өстәл тирәсендә... базар уртасында сугышкан, төкеренә-төкеренә талашкан ир белән хатын һәм икесенә дә бик охшаган кара бөдрә чәчле бер малай сыйланып утыра. Алларында—шампан, затлы шәраб, төрле-төрле шоколадлар, туңдырмалар, тәлинкә-тәлинкә ит ашлары, кызган балыклар, кызыл, кара уылдыклар, тагын әллә нәрсәләр!.. Киемнәре дә замана байларыныкыннан калышырлык түгел. Хәтта кара малайның кардай ак күлмәгенә күбәләк-бабочка тагып куйганнар. Күкрәген киереп, креслога ята төшеп утыручы ир хатынга карап серле елмая, йодрыгын төйнәп, баш бармагын алга чыгарып, әледән-әле: «Во! Во! Талант!», дип куя. Икесенең дә бәхетле карашлары малайга юнәлә. Башыннан да, җилкәсеннән дә сыйпап кына торалар, кыстый-кыстый ашаталар...

"Ә үзең бернәрсә дә югалтмадыңмы базарда?"—дип соравыгыз мөмкин бит әле! Яшермим, дөп-дөресен әйтәм: әйе, минем дә кесәгә кергәннәр. Бер кап сигаретымны шудырганнар. Югалтуыма караганда табышым зуррак булды базарда. Нәрсә ул, дисезме? Кулыгыздагы шушы хикәямне яздым ул кичтә...

*30 август, 2006 ел.*

## Лаборатория

(ФӘННИ АНАЛИЗЛЫ МОНОЛОГ)

Нәрсә дисен?! Хатынымны аерам, дисенме? Чамалабрак сөйләш әле син, энекәш. Уйлап, башыңа килгән һәрбер фикерне фәнни яктан анализлап хәл итәргә өйрән! Әнә, башларында бик күп булса бер тамчы ми бардыр—чыпчыклар да гомерләре буе бер генә хатын белән тора...

Әйттем мин сиңа җиде ел элек: энем, дидем, югары уку йортына кер, дидем, һич югы аспирантура тәмамла, фәннәр кандидаты бул, фәнни анализ белән яшәргә өйрәнерсен, дидем... Колагыңа да элмәдең, гыпытуга барып кердең. Көн туса, пычкы тартасың, балта чабасың, такта ышкыйсың...

Менә без—гыйльми-фәнни хезмәт кешеләре, энем, нинди дә булса нәтиҗәгә килү өчен, лабораторияләрдә меңнәрчә реактивлар белән йөзләрчә анализлар, төрле экспериментлар үткәрәбез. Шуннан соң гына ныклы нәтиҗә ясыйбыз. Әйтик, дары ни өчен шартлый? Артык кызганнан шартлый. Без ешрак салып һәм каядыр кунып кайтсак, хатыннар да шартлый. Алар шартласа, уклаулар, тәлинкәләр, үтүкләр оча. Хатын кыз ул, энекәем, үзе бер уникаль лаборатория! Менделеев таблицасында нинди матдәләр булса, хатын-кыз эчендә шуларның барысы да бар! Биологик, психологик якларын да истә тотсак, синең хатының да гомер буе экспериментлар үткәрерлек фәнни академияга тиң, энекәем.

Менә, мәсәлән, мин озак вакытлар бакалар белән тәҗрибәләр үткәрдем һәм зур ачыш ясадым: баксаң, алар да салкынга караганда җылыны, алай гына да түгел, иркәләүне ныграк яраталар икән! Күз алдыңа китер: салкын сулы аквариумдагы баканы алып, сыкылы пыяла өстенә салып, аркасына яткырам. Аякларын, ботларын җәеп ята бахыркаем, нәрсә эшләр микән бу дип. Миһербанлы мөнәсәбәт көтә инде... Бездә дә бар бит ул бүлнисләрдә була торган җылыткычлар. Ие, грелка дип әйтәбез инде... Кайберләре түшәк хәтле, кайсылары уч төбе кебек кенә. Бакакаемның корсагына шуны салуым була, күз читләрендәге сөрмәләре балкып китә прәме! Әле шуннан соң кендегенә җылы май да тамызсаң, рәхәттән, ләззәтләнүдән дерт-мерт килә, телен чыгарып, күзләрен йома. Хәзерге яшьләрчә әйтсәк, полный кайф!

Ә бит, энекәем, хатыннар да нәкъ шул җан иясе кебек. Алар да якты караш, җылы мөнәсәбәт өмет итеп яши. Үзең дә беләсең: кайдадыр кәеф бозылып, йә булмаса, эштән талчыгып-таушалып кайтсак, хатыннарыбызга игътибарыбыз җитми. Урынга яткач та салкынлык бәреп торадыр инде бездән андый чакларда. Хатын, мескен, елыша, кайнарланып куенга сеңәргә ниятли, җылы өмет итә. Ә мин ятам, күзле сал бүрәнәсе кебек түшәктән түшәмгә карап. Кәеф юк чөнки... Әгәр дә шул килеш йокыга китсәң, беләсеңме иртән хатынның караваттан ничек күтәрелеп кузгалачагын. Сикереп тора теге, карават "дырк!" итеп кала. Үзем дә түшәмгә таба күтәрелеп киткәндәй булам. Ашказаным да селкенә хәтта. Йокы бүлмәсеннән залга чыгып китүе була, ике бала берьюлы акырып җибәрә. Әллә күтләрен чеметә, әллә борыннарына чиртә—белмәссең аныкын... Балаларның тынын катырырлык итеп җикеренә:

—Бакырмагыз, атагыз сыңарлары, тамакларыгыз тыгылгыры!

Андый чакларда кичтән калган салкын йомырка да күренми өстәлдә, чәй дә куелмый... Китәсең эшкә, ач карынга тәмәке суырып... Әйе, бакалар да яратмый салкын мөнәсәбәтне, энем. Берсенең корсагына, җылы өмет итеп ятканда, суыткычтан алып боз терәгән идем, беләсеңме нишләде? Чикый-чикый килеп, каядыр сикерде. Сикергәндә чәлт итеп йөземә чәпәлде хәтта!

Ә, әйе, хатын турында сөйли идем бит әле... Ә менә төнлә кочагыма

алсам, күнелен күреп, яхшылап жылытсам, хатыныным иртән мамыктай гына күтәрелеп китә дә, йошак кына атлап, әлеге дә баягы залга—балалар янына чыга. Әгәр дә кайсыдыр шыншып куйса, хатын имән бармагын иренөнә куеп, пышылдый тегеләргә:

—Чү! Атагыз йок-лый!! Шым булыгыз—тыныгыз чыкмасын!

Шуннан соң өйгә коймак исе тарала, чәйнүк сызгыра башлый... Килә дә, назлап кына уята:

—Тор, атасы... Эшкә барасың бар. Ашарга әзер...

Нинди генә тәм-томнар юк өстәлдә! Хатын үзе дә май кояшы кебек балкып тора, минсинайтим! Менә бу бит инде, энем, үзе бер эксперимент. Әгәр дә мин егет чакта синең кебек ялкау булсам, аспирантура бетереп, фәннәр кандидаты булмый калсам, анализлар, экспериментлар ясый белмәсәм, аңлый алыр идемме тереклекнең уртак сыйфатларын? Шундый зур ачышлар өчен сәләтем житәр идеме? Ту-ты!.. Яшәгән булыр идем синең кебек надан булып, хатыннан гаеп эзләп...

Әгәр мин хәзер шушындый ачышларымны Америкага сатсам, беләсеңме кем булам? Мил-ли-он-ер!.. Ә бу илдә безне милли пионер итеп тә танымаска тырышалар...

Әйтәм бит инде мин сиңа, хатын-кыз үзе бер лаборатория, дип. Шуңа күрә, тату яшәү өчен, аларны гомер буе фәнни яктан өйрәнергә, күп төрле тәҗрибәләр үткәрергә кирәк. Хәзер бигрәк тә. Чөнки фән заманы бу!

Әйтик, без нинди дә булса матдәне икенче матдә белән колбага салганда, реакциягә керткәндә һәрвакыт нәрсә килеп чыгар икән дип баш ватабыз, дулкынланабыз. Көтелмәгән нәтиҗәләр дә килеп чыгуы бар бит! Бигрәк тә атом бомбалары эченә тутыра торган реактивларны бер-берсенә кушканда... Лабораториябез шартласа, бөтендөнья сугышы башланмас дип иман китерә алабызмы без?! Хатын-кыз дигән лаборатория дә көтелмәгән нәрсәләр китереп чыгара. Исендәдер бит әле, мин өйләнгәч, аннары хатынны бала табу йортына илткәч, кем чыгар икән, малаймы икән, кыз микән дип йөрдем. Малай булсын иде дип теләдем. Ә нәрсә килеп чыкты? Кыз... Чөнки ул вакытта әле мин фән дөньясына тирән кереп житмәгән булганмын—хатыныма назым житеп бетмәгән. Уйлагандыр эченнән генә: синең кебек мүкләкләр үстергәнче үзем кебек затлар үрчетим әле, дип...

Мүкләк дигәннән, мүкләк кәҗә дә ярата иркәләүне, энем. Безнең фәнни академиядә бар андый кәҗә. Баш түбәсен ипләп кенә кашысаң шунын, рәхмәт әйтүе күзенә мөлдерәп чыга. Әгәр дә инде сыйпап-кашып утырган мәлдә кинәт кенә сакалын учлап, бөтен көченә тартсаң, юк мөгезләре белән сөзә башлый үзенне. Кабыргалар чатнагандай була! Тагын бер мисал сиңа: әгәр куян алдына кишер салсаң, сөенә-сөенә кимерә, инде дә мәгәр колбаса куйсаң, иснәве була—иманнан качкан иблис шикелле, лабораториянең икенче стенасына хәтле ыргыла. Әллә сыер исен, әллә эт исен яратмый—аңлавы кыен... Ә моны, тәҗрибәләр үткәреп, фәнни яктан өйрәнү кирәк. Безгә бит замана колбасаларының составын өйрәнү өчен дә приборлар кайтардылар күптән түгел.

Менә син үзең дә бер тәҗрибә үткәреп кара әле хатының белән, жае чыкса. Тәлинкәсенә печән сал да, өстәл янына чакыр... Нәрсә килеп чыгар икән? Үзе бер эсперимент булыр ул фән дөньясында.

Юк, юк, аерма, энем. Бигрәк юкка бозылышкансыз бит... Хуш, машина сатып алмакчы булгансыз жыйган акчагызга—автокибеткә баргансыз. Аңа аркалары төшә торган утыргычлы машина ошаган. Бик әйбәт бит инде! Андый утыргычлар "ә" дигәнче ятакка әйләнә дә куя. Бәлки, синең шау-шуыңнан котылып торасы, урман аланына барып, сузылып ятып ял итәсе киләдер. Машинаны шәп йортә бит ул! Бәлки әле үзенне дә өйрәтер, тора-бара... Татулашыгыз, ыштубы! Үзе йөрмәгәе, дип куркасыңмыни әле син?! Йөрсә дә исең китмәсен. Ул бит барыбер сине ташлап китмәячәк.

Хатын-кыз ул сине яратмаганнан йөрми башка ирләр белән. "Минем ирем башкалардан шәбрәк яки хөртиерәк түгел микән?" дигән сорауга җавап эзләүдән, чагыштырып карарга омтылудан гына йөри ул! Ягъни, һәр лаборатория кебек үк, фәнни анализ ясарга тырыша дигән сүз!

Менә син мине гаеп итеп утырасың. Хайваннар, ерткычлар белән чагыштырып, кешеләрне мыскыл итәсең дип дәгъва белдерәсең. Юк, энем, хайваннарны кешеләр белән чагыштырмыйм мин, кешеләрне хайваннар белән чагыштырам! Менә син үзең дә чагыштырып кара да җавап бирергә тырыш: кайсы ерткычның үз хатынын кыйнаганы яки үтергәне бар да, кайсы ана хайванның туарга тиешле баласын, карынынннан өзеп алып, чүплеккә ташлаганы бар?! Агач ышкып кына яшәп булмый, маңгаеңны да ышкыштыргала бераз...

Давай, тагын бер стакан сал да, китим әле мин... Ләх исереп кайтып, хатынның холкын экспериментлап карыйм әле. Нәрсә килеп чыгар икән?..

*9 сентябрь, 2007ел.*

## Путинның үги малае

Безнең авылда бер-берсен җандай якын күреп яшәгән ике хатын сугышты. Аннан соң, мартның соңгы көнендә, аларга безнең клубта күргәзмә суд булды...

Бер уйласаң, сугыш диярлек җире дә юк иде инде, кәнишне, бу чәкәләшнең. Әйтик, ирләр сугышкан булса, йодрыклар белән орышырлар иде, бөтен авыл гөпелдәп, шапылдап торыр иде шул йодрыклар биешкәндә. Берәрсенең борыны яки ияге дә җимерелсә тагын, театр да килми торган авылыбыз өчен ай буе көлә-көлә сөйләрлек, күңел ачарлык тамаша итеп кабул иткән булыр идек ул сугышны. Ә боларныкы, ягъни Пидура белән Сәндрә арасындагы сугыш пүчтәк ул. Пидура Сәндрәнең танавын тешләде, Сәндрә, кызып китеп, Пидураның итәк путасын чәйнәп өзде. Аннары чәч йолкыштылар, тырмаштылар һәм тәтелдәшә-тәтелдәшә яңакларын чәбәкләштеләр дә, шуның белән вәссәлам.

Хәер, әйткәләшеп тә алдылар:

—Әгәр дә синең малаең үсеп житсә һәм аны Путин чичиннәргә каршы сугышырга җибәрсә, белеп тор: мин үз малаемны чичиннәр әтрәтенә җибәрәчәкмен дә синең малаеңны теге яктан аттырып үтертәчәкмен,—диде Пидура китеп барышлый, бармак янап.

—Юләр тәре!—диде аның артыннан йодрык күрсәтеп калган Сәндрә,—үз малаеңның энесен үтертү була бит ул, әнәрә! Аталары бер бит аларның!

Чыннан да, дүрт ай элек кенә бер-бер артлы туган Айдар белән Хәйдәрнең аталары бер үк кеше иде. Ел чамасы элек колхозның электр челтәрендәге контактларны тикшерү өчен район үзәгеннән җибәрелгән электрик Габдрахман иде ул. Фермалардагы, клубтагы, мәктәптәге, кәнсәләрдәге һәм тагын әллә кайлардагы контактларны атна буе тикшереп йөргәндә, ул урам буйлап килүче Пидура белән Сәндрәне очраткан да, контактларыгыз рәтлеме, төзекме, ут кабарлык түгелме, чистартыр вакыт җитмәгәнме дип кызыксынган. Баксаң, ут кабызгач, Сәндрә өендә янган каеш исе килә икән, ә Пидураның чүтчиге өстендә очкын күренгәләгән. Кич житкәч, эш беткәч, иң әүвәл Сәндрәгә, аннары Пидурага кереп чыгарга вәгъдә биргән энже тешле, сызылып киткән кара мыеклы, майлы күзле шаян Габдрахман. Ләкин, ни сәбәптер, сүзендә торып ук бетмәгән—башта Пидураның контактын тикшергән, аннан соң гына—төн уртасы үткәч кенә Сәндрә өенә юнәлгән.

Бу ике ахирәт арасындагы сугыш та нәкъ менә Габдрахманның сүзендә торып бетмәве аркасында чыкты дип фараз кылды авыл халкы. Ни өчен

дисән, тугыз ай үткәч, Яна елны каршыларга ярты көн калгач, бу ике хатынны бер үк көндә бер үк машинага утыртып, бик ашыгыч төстә район үзәгендәге бала табу йортына илтергә мәҗбүр булдылар.

Шуны әйт әле син тагын, ике ел арасында бала тудыруларны японский видеокамера белән төшереп торганнар врачлар, адәм гыйбрәте! Бала туып житүгә үк шуның бер төймәсенә басып куялар икән дә, видеокамераның сәгатенә, минут һәм секундына кадәр теркәп баралар икән. Бер сүз белән әйткәндә, Пидура Айдарын—Яна елга өч минут кала, ә инде Сәндрә үз Хәйдәрен Яна ел башланып дүрт минут үткәч тапкан. Врачлар һушына да килеп бетмәгән Сәндрәне, кулын кыса-кыса, котлый башлаганнар:

—Маладис, син тауариш Путинның 250000 сумлык ана капиталына лаек булдың! Бәхетең бар икән, Александра Петровна!—диешеп.

Ә инде күрше караватта сабыен беренче мәртәбә кочкан килеш елап ятучы Пидура, врачлар чыккан арада, үкси-үкси әйтеп куйган Сәндрәгә теш арасыннан:

—Син, мөртәт, миңа соңрак килергә тиешле Гаптырахманны юри иртәрәк җибәргәнсең. Минеке соңрак туасы булган. Ул 250000 тәнкә дә миңа тиясе булган. Үчти, исеңдә тот!—дип янаган.

Үчти-үчти диешә торгач башланган сугыш иде теге чәкәләш. Инде менә клубта суд бара. Участковый Сөләйман төпченеп төзегән документлар судья өстәленә яткан, ул тапкан шаһитлар һәм дә гаепләләр залдагы урындыкларның иң алгы рәтенә утыртылган. Әйе, шаһитларның ул тапканнары гына... Чөнки безнең авыл кешеләре, бөтен хәлне белгән сурәттә дә, шаһит булырга ашкынып тормыйлар. "Судка кергәнче..." дип башланган әйтемне һәркайсы яхшы белә. Шуңа күрә алар монда да өчәү-дүртәү генә.

Беренче сүзне шул шаһитларның берсе булырга ризалашкан Ибуш дәдәйгә бирделәр...

—Иптәш судья дөрес әйтә, иптәшләр. Ырас инде чын дөресен генә сөйлим дип кул куйганбыз икән, ничек булган—шулай сөйләргә кирәк,—дип башлады ул сүзен.—Ничек булды дисәгез, Начты җингәгез белән мин күргән хәл болай булды: кояш баер-баемас чакта йокларга дип яткан идек, урамда чыр-чу янгырады. Мин башта Ягүрләр ихатасында чучка өтәләр дип торам. Ул әйткәние инде миңа, шушы көннәрдә бер чучканы чәнчим дип әйтеп... Әх, мин әйтәм, чәнчемәс борын утка салган ахрысы бу мәхлукны, исерек баштан!.. Чучка булса да җан бит ул, кызганыч... Көтмәгәндә бу чырылдау чәрелдәп талашуга әйләнеп китте. Бәй, диешәбез җингәгез белән, чәчбикәләр талаша түгелме соң?! Гелләрем безнең тәрәзә артында гына кебек бу җәнҗал. Сикереп торып, җингәгезнең күлмәк итәген күтәреп башымны тыгып карасам, андагы гарасаткa шаклар каттым. Чәчләр генә түгел, йоннар да пыр туза сыман. Үзе бер галәмәт!.. Текәлебрәк карасам, ни күрим, анда Пидура белән Сәндрә пәрмә-пәр сугыша. Туктале, мин әйтәм...

Болай да чырае чытыла башлаган судьяның шул ук чыраенда җирәнү галәмәте сизелә башлаган иде. Түземе бетте, ахрысы, ул суд үткәрү өчен Гөргөриләрнең песи ашата торган, ә инде суд уңае белән суд өстәленә каплап куелган әлүмин тәлинкәгә, нәкъ менә телевизордан көн саен күрсәтелеп торучы судтагыча рәвеш китереп, Чалыш Метрәйнең итек басканда файдалана торган агач чүкече белән сукты.

—Үзең туктале, яме! Әйт миңа, ни өчен син авылдашларыңның исемен дөрес әйтмисең, бозасың һәм... Менә бу документларда Федора дип, Александра дип язылган бит!

Халык дертләп куйды, Ибуш та тотлыгып калды. Ләкин Ибуш курыкса да өрекмәде:

—Анысын паспорт тотыручылардан сорагыз. Без үз исемнәребезне бик

дөрес әйтәбез... Урысчага тел әйләнми безнең...

Бөтен зал берьюлы "дөрес әйтә ул, бозмый" дип аваз салгач, аптырап калган судья, сүзен бирмәс өчен, кабат калкынып куйды:

—Ул хатыннар кайда сугыша иде соң?!

—Урамда дидем бит инде...

—Шулай булгач, причум монда хатынынның күлмәк итәге?

Моңа хәтле тавыш-тынсыз гына янәшәдә утырган карчыгы зәһәрләнеп Ибушның сырма чабуын тартты:

—Сөйләмә, атасы, тел әрәм итеп, мыскыл итәргә чакырганнар безне монда! Үзеңне төрмәгә тыгып куярлар, шул булыр!.. Тыңлап бетерергә дә теләмәделәр сүзеңне.

Шундук Ибуш, сәхнә тарафына кул селтәп, урынына түнде:

—Ярый, сүзем бетте! Башкалар сөйләсен, алайса...

Ул арада участковый сикереп торды:

—Сөйлә, Ибуш агай, сөйлә! Син бит бу хатыннарның чәкәләшүләрен башыннан ахырына кадәр күреп торган бердәнбер шаһит!—Аннары ул, судья ягына карап өстәде.—Ул да сөйләмәсә, судны туктатырга кала бит...

—Нигә туктатыйк соң әле без судны?!—дип, судья милиционерга усал караш ташлады. Аннары, өстәлдәге кәгазенә күз төшереп алгач, тавышын көчәйтте.—Монда бит әле син шаһитларның берсе итеп Михайлова Татьянаны теркәгәнсең. Ул сөйләсен!

Ул арада участковый беренче рәттә йоклап утыручы Татый әбине уята башлады.

—Уян әле, әби, сөйлә теге кичтә күргәннәреңне. Ничегрәк булды аларның сугышулары? Басып сөйлә.

Туксанына житеп барган, авызындагы соңгы тешеннән дә житмеш яшендә үк мәхрүм калган Татый әби урыныннан тору өчен кат-кат калкынып куйды:

—Башып шөйлә дишең дә шин, Шөләйман улым, рематиз бит минем. Билем дә үтерә. Ничегрәк шөйләргә икәнен дә белмим. Шудларда йөргәнем юк бит минем. Куркыта бит әле шуд каршына башу. Хөкем эше—күтем эше диләр бит. Бик катәр нәмәкәй диләр бит шудны...

—Ничек булган, шулай сөйлә, әби. Нишләгән чагында ишеттең аларның әрләшүен, нәрсәләр күрдең—барысын да бәйнә-бәйнә тезеп сал,—ди-ди күтәрә торгач, участковый әбекәйне аякка бастырды. Судья алдындагы бер кәгазьне китереп, ул кәгазьне кызыл папка өстенә салып, кул да куйдырды.

—Түлке барысын да дөп-дөрес сөйлә ыштубы! Ялган сүзең булса, үзеңне хөкем итәчәкләр. Статьясы шундый!

Сөләйманның авып китмәслек тотып торуын чамалагач, сөйли башлады карчык:

—Әй-йе...Э-э... Нишлидерием шоң әле мин ул чакта?... Ә, э-э, ие... караңгы төшкәнче, йокларга ятканчы тышка чыгып керием әле диеп, тышка чыккан идем, балакаем. Э-э, э-э... Чыктым. Тышка да чыгып килдем бугай әле... Әйе, чыгып килдем сыман... Туктале, ялган шөйләп, өтермәнгә китә күрмим тагын... Утыз жиденче елны атайны тыккан кебек егерме биш елга тыкшалар, мин кайтканчы авылда бер танышым да калмаш, Кодай шаклашын! Юк-юк, тышка чыгуын чыктым, иллә дә мәгәр тышка чыгып килергә житешмәгәнием бугай әле... Әллә килдем инде шунда, әллә барып та тормадым? Әй, бу хәтерне әйтерием. Иштә калмаган бит... Шул инде, шию... ә, юк... тышка чыгып керү өчен тышка чыккан вакытта булды ул әкәмәт...

Әбинең тышка чыгу өчен тышка чыкканын гел шулай кабатлап торачагын абайлаган судьяның чыдые бетте:

—Сугышканнарын күрдеңме соң, әби? Шуны әйт син!

—Күрмәшкә ни! Тешләрем калмаша да, күзләрем бар бит әле...
—Кемнен сукканын күрден?
—Пидура шукты...
—Тагын ниләр күрдең?
—Шәндрә шукты...
—Шуннан соң ниләр булды?
—Пидура шукты...
—Йә, шунна-ан?
—Шуннан дип шоң инде, шулай шугыштылар да шугыштылар инде... Ибуш чыгып аермаша, төне буе шугышырларые... Ярый Ибуш булды әле, үлгән булырларые... Ибуш миннән күбрәк белә ул...

Судья, суд каршына баскан хатыннарның кайсысы гаеплерәк икәнен ачыкларга теләптер, ахрысы, тагын берничә сорау бирергә ниятләде әбекәйгә:

—Синең әйтүенә караганда, беренче булып Федора суккан. Шулаймы?
—Шулайдыр инде. Нигә дишән, Пидураның борынынннан кан тама иде бит инде. Шуңа күрә беренче булып шуккандыр...
—Уйлап бетер әле, шаһит!.. Федораның борынынннан кан тамгач, беренче булып Александра суккан булып чыга түгелме соң?
—Шулайдыр инде, алайша... Патамышты анын да чырае тырмалган иде бит инде. Шуңа күрә, жене котыргандыр да, ул беренче булып шуккандыр.

Гаепләне ачыклау өчен тотынырлык жеп тә тапмаган судья, участковыйга карап алгач, бүтән шаһитлар юклыгын аңлады. Аптыраган участковый исә Ибуш хатынының каршына килеп басты:

—Син дә күрдем диден бит, Нәчтүк түтәй. Нәрсәләр булды ул көнне сезнең тәрәзә каршында?
—Күрүен күрдем,—дип киреләнде кайнар холыклы Нәчтүк түтәй.—Әмма дә ләкин сөйләсем жжук! Акыллы гына сөйләп торучы картымны да бүлдердегез. Хур буласым килми!

Ләкин Сөләйманның йомшак һәм ялварулы карашына игътибар иткәч, урындыгын да арты белән генә шудырып торып басты да, сүз ташкынын сиптерә башлады:

—Сөйләсәм дә синең хакка гына сөйлим, энем. Жунне кеше син. Түлке милиция булып харап булгансың... Ибушым торып, күлмәгемнен итәген күтәреп башын тыккач, тыштагы сугыш-талаш тагын да куәтләнгәч, мин дә тордым. Аннары, Ибушның чалбар балаклары арасына башымны тыгып, тегеләрнең тәпәләшүен күзәтә башладым. Ибушым әйткәнчә, учма-учма чәч йолкышалар, учларын ачуга, чәчләрен жил туздырып алып китә. Тырнашалар, яңакларына чабып-чабып жибәрәләр, бер-берсен этеп-төртеп егалар. Нишләсеннәр инде сугышмыйча! Мәскәү мыскыл иткән бит аларны. Анда бит юньле законны жаза да, чыгара да белмиләр. Ничек була соң инде ул: жиде минутка соң туган сабыйга ике йөз илле мең сум биргәннәр дә, адәм мәсхәрәләре, аннан алда туганының авызына күкиш терәгәннәр. Барыбер сабыйлар каргышы төшәчәк ул эттем-сүктем житәкчеләргә. Аналары да гаепле түгел. Алар кияүгә чыккан егетләрне Мәскәү жә Әпганга, жә Чичнәгә илтеп үтерткәч, алар нишләсен?!. Әллә судьялар гаепләмәкче буламы болай да бәхетләре таланган ул катыннарны? Болай да ятим көе берәр бала үстереп яталарые бит инде, бу сабыйлары туганчы дип әйтүем. Төрмәгә тыктырмыйбыз, Кодай кушса! Тәтеми торсын! Аларның тормышы калхузда да төрмәдән ким түгел. Контактлар ясап йөргән Гаптырахманга да рәхмәт кенә әйтәбез. Анын кебекләр дә килгәләп йөрмәгән, безнең кызларга күз төшермәгән булса, бу авыл урынында тигәнәк белән шайтан таягы гына үсеп утырыр иде хәзер! Безнең авылда бер кеше дә гаепле түгел мондый жәнжал чыккан өчен. Гаепле кешене хөкем итсеннәр әнә... Анын

кем икәнен безнең атвакатыбыз белә—ул әйтер!

Бу кадәр озын да, зәһәр дә телмәрне тыңлаганда каты бәгырьле судья да телсез калгандай булды. Елмайды, күзләре түгәрәкләнде, яшьләрен сөрткәләп алды, әледән-әле авызын ачып катты. Бары тик Нәчтүк түтәй шып туктагач кына һушына килде.

—Барысын да аңлаешлы итеп ачып салдың бит апа. Рәхмәт сиңа,—диде ул йомшак кына.—Шулай да, үпкәләмичә генә, бер сорауга җавап бир инде. Ирең дә, үзең дә күлмәк итәге, чалбар балаклары турында сөйләдегез. Шуның хикмәтен аңламый калдым...

Тагын чәчрәп торды да Нәчтүк түтәй, җавабын да чәчрәтеп бирде:

—Бәрәч, шуны да аңламагач инде, энем, акыллы башың белән... Тәрәзә пәрдәсе алырлык та акча юк бит хәзер. Пенсия бәләкәй, пүчтәк... Ибуш абзаң белән йокларга ятыр алдыннан чишенәбез дә, пәрдә эләсе бауларның берсенә—минем күлмәкне, икенчесенә Ибуш абзаңның чалбарын элеп куябыз. Шулар арасыннан, җә астыннан карап яшибез инде без дөньякайларга...

Адвокат дигәнебез үз авылыбызның Михәйләсе булды. Законнарны, суд хәйләләрен шәп өйрәнеп кайткан Михәйлә инде... Ул гыйлем алган җирдә—төрмәдә бергә утыручы бөтен зэклар еллар буе законнар турында гына сөйләшеп яталар икән дә, һәркайсы үз статьясы турында җентекләп сөйли торгач, Җинаятьләр Кодексын биш бармакларыдай белеп кайталар икән. Төрмә ул—юридик академия, дип тә сөйләнеп йөргән иде, кайткач...

Башта Пидура белән Сәндрә районнан тапмакчылар иде адвокатларны. Һәркайсы, шартына китереп, берәрне ялламакчы булган. Сәндрәне бик нык тәҗрибәле адвокат белән таныштырганнар. Ул биш мең сораган. Пидурага ун мең сорый торганын тәкъдим иткәннәр: "Ни өчен бик кыйммәт?" дигәч: "Эшен әйле-шәйле генә белсә дә, судьяның якын дусты ул", дигәннәр. Имеш, судта җиңеп чыгу өчен шуннан да шәбрәк хикмәт юк икән... Шунысын да аңлатканнар Пидурага: Россия законнары бары тик зуррак ришвәт бирсәң генә кешелекле һәм гадел законга әйләнә икән. Бер сүз белән әйткәндә, меңәр сум хезмәт хакына эшләүче хатыннар район үзәгеннән котлары очып кайтканнар. Бу хәлне ишеткәч, Михәйлә әйткән аларга:

—Бер дә кайгырмагыз. Бер "савыт" белән бер тавык куйсагыз, икегезне дә фәрештәдәй гөнаһсыз итеп чыгарам судтан,—дигән.

Менә адвокат торып басты ахырга таба. Шул хәтле әзерләнеп килгән Михәйлә судка, хәтта армиядән кайткан гимнастеркасын табып киеп, аңа ферма мөдире булып эшләгән мәрхүм атасыннан калган кызыл галстукны да тагып куйган. Шулай итеп, чын интеллигент булып килгән судка! Шуңадыр, тәкәбберлек белән башлаган беренче җөмләсе үк судьяны сагайтты.

—Нишлисең бит инде, законнар, указлар күбәйгән саен сугыш-талашлар, җинаятьләр арта инде ул... Логически уйлап карыйк әле: әгәр дә мәгәр ике сабыйның берсен үстерә торган, икенчесен үтерә торган указ чыкмаган булса, бу мескен хатыннар канга батып сугышкан булырлар идеме?

Мондый ук акыллы сүзне дәүләт башлыкларыннан да ишетмәгән һәм ошбу минутка кадәр шым гына утырган халык беравыздан кычкырып куйды:

—Ж-жук-к!

Судья Чалыш Метрәйнең сүсәргән чүкечен кулына алып, песи тәлинкәсенә кабат сукмакчы иде дә, ләкин Михәйләне тыңлап бетерергә мәҗбүр булды. Чөнки адвокатыбыз чираттагы соравын ярып салды:

—Җиде минутка иртә туган өчен баланы җинаятьче дип тану, аны Рәчәй алдында үгисетү өчен кайсы статьяны кулланырга була? Әгәр хөрмәтле судья шундый статьяны укып күрсәтә алмый икән, әлепбине белмәгән кеше дә пулнай алиби икәнлеккә шикләнмәс бу очракта.

—Сез кемне гаепләгәнегезне беләсезме, господин адвокат?! Указның кемнеке икәнен белеп сөйлисез булса кирәк!..

Судьяның агулы соравы бераз каушатты бугай, Михәйлә койрык болгарга мәҗбүр булды:

—Беләм шул! Мондый тузга язмаган указларны бары тик Ельцин чыгара белә иде... Бөтен указларны ул патписайт итеп калдыргандыр... Исерек көе язгандыр инде... Юк-юк, мин бер кемне дә гаепләмим. Указны гына гаеплим.

—Ә бит бу указ господин Путинныкы! Президентның намусын һәм авторитетын закон саклый бездә! Аны хурлаган өчен нәрсә буласын беләсезме?!

—Нык беләм!—диде Михәйлә.—Чөнки мин төрмәдә нәкъ менә элеккеге персидәтелебезнең намуссызлыгын, караклыгын тәнкыйтьләгән өчен утырып чыктым. Безнең илдә башлыкларны бары тик тәхетләреннән киткәч, йә үлгәч кенә хурларга ярый!

—Ту-ты!!!—дип куйды судья, сүзенең бер каршылыксыз җөпләнүенә рухланып. Аннары шул рухтан канатланган хәлдә әлеге тәлинкәгә сабы черек чүкеч белән соңгы тапкыр бөтен көченә тондырды. Тәлинкәне коймакка әверелдергән чүкечнен түбәләгече читкә очкан минутта ук судның карары игълан ителде. Карар болайрак булды: судның дәвамын егерме елга кичектереп торырга. Әгәр дә шул чор эчендә Рәсәй үгие Айдар Чечня җирендә үзеннән җиде минутка яшьрәк энесе Хәйдәрне атып үтермәсә, судны тәмамланган дип санарга.

... Ләкин авыл халкы икенче көнне үк тагын пошаманга төште. Ник дисәң, төрмәдә ике ел буе хатын-кыз күрмәгән буйдак Михәйлә кабат дуслашкан Пидура һәм Сәндрә белән. Төн уртасында күршеләрдән тагын ике шешә аракы сатып алган. Аларын да бергәләп эчкәннәр. Михәйлә шунда кунып калган. Ике ахирәт алдагы Яңа ел алдыннан тагын бала табу йортына эләгеп, кайсыдыр указ аркасында җәнҗал чыгармасалар ярар иде инде, Ходаем, дип бөтен авылыбыз белән кайгырышабыз...

*20-22 май, 2007 ел.*

*Автордан искәрмә: Беркем дә кунаксыз яшәмәгән кебек, миңа да кунаклар еш килә. Аларның кайберләре үз төбәкләрендәге булган кызыклы хәлләрне дә сөйләп китәләр. Мин ул кыйссаларның кайберләрен сиплән һәм әдәби җәһәттән баетып язып барам "Күңелле кунаклар" циклына туплап яшим. Бу хикәят тә шул циклдан.*

## Милиционерны чишендердем...

(БАШТАН ҮТКӘН ЧЫН ВАКЫЙГА)

Алдан ук әйтеп куям, бу язмамда, мөгаен, бер кызык та табылмастыр. Бу язганым бары тик үзем кылган мәгънәсез гамәлләремнен берсе турында гап-гади истәлек.

Әйе, чыннан да, миңа бер милиционерны чишендереп, анын киемнәрен киеп, ике-өч сәгать чамасы милиция лейтенанты булып йөрергә туры килгән иде...

...1972 елның җәй башында туган Минзәләмнән Түбән Камага кунакка барырга туры килде. Ни хикмәттер, 100 чакрымда гына төзелеп ятучы бу шәһәргә бару дигән уй башыма да килмәгән иде ана кадәр. Янәсе: минем саф һавалы, чиста сулы, күңелне иркәләүче тынлыкка чумган Минзәләмнән дә матуррак, рәхәтрәк җирнең булуы мөмкинме сон?! Ләкин, беренче күрүгә үк, яңа шәһәргә гашыйк булдым. Сөбханалла! Булса була икән дөньяда шулкадәр гүзәллек: ине-буе ике-өч чакрымнан да артмаган мәйданда бишәр, тугызар катлы ап-ак йортлар төзелеп тора, киң урамнарның як-ягыннан да,

уртасыннан да чәчәк газоннары, ак каеннар тезелеп киткән. Инде монда күчкән якташларның яшәү шартларын күр: фатирларына су килә, юынтыгы китеп тора, җылы кергән, газ тоташкан! Ә мин тегендә көн саен су ташыйм, пычранганын чыгарып түгәм, кыш буе туңып ятмау өчен машина-машина утын ташып, җәй буе диярлек кисәм, ярам... Шунда ук тәвәкәлләдем дә, шәһәр башлыгына киттем. Күчү ниятемне аңлагач, сорап куйды:

—Язучы, журналист, хәтта СССР Журналистлар союзы члены икәнсең. Берәр гәзиткә урнашырга телисеңдер инде?

—Юк!—дидем,—матбугат кешеләренең кадере юк аларның. Миңа мөмкин кадәр тизрәк фатир кирәк. Әле койрыгым да бар—ун яшьлек малаем тагылган миңа... Фатир мәсьәләсе җинел хәл ителә торган эш бирегез. Хәтта дворник булып эшләргә дә риза!

Ул минем алга ярты бит чамасы кәгазь салды.

—Укы.

Укыдым. ДОСААФның Татарстан өлкә комитеты рәисе—генерал чыгарган приказ икән бу. Анда нибары бер җөмлә: "Образовать в г. Нижнекамске городской комитет ДОСААФ" диелгән и вәссәләм.

—Шушы яна эшне җитәкләргә, менә монда—шәһәр Советында бүлек башлыгы булып эшләргә ризамы?

—Миңа ДОСААФ комитетларының гамәлләрен күп тикшерергә, алардан еш көләргә, андый оешмаларның эшлексезлеге турында шактый фельетоннар язып бастырырга туры килде. Шулай булгач, бу эш белән шактый таныш икәнемне аңлыйсыздыр инде.

—Үзеннән һәм бездән көлдермәслек итеп оештырасын икән, ике елдан фатирлы булырсың. Ә хәзергә малаең белән ике бүлмәле фатирның берсендә яши торырсыз.

Кем әйтмешли, китте эшләр хутка! Җитмәсә, "служебный" дигән мөһер сугып, өр-яңа, чем-кара мотоцикл да бирделәр, бер ай чамасы эшләгәч. Кирәк икән, Айга менәргә дә әзер мин, дигәндәй, пошкырып, ажгырып тора, гөнаһ шомлыгы! Дөресен әйтим, аның дүрт-биш атналык "службасы" кызлар утыртып йә Чулман комлыгына төшүдән, йә шул гүзәлләрне табигатьтә—урман аланнарында, матур болыннарда ял иттерүдән гыйбарәт булды. Аннары, төннәрен бүлмәм тәрәзәсе каршында торучы матур мотоциклым... юкка да чыкты. Бер иртәдә, йөземә янгыр тамчылары төшкәләүдән уянып китсәм (җәй көне ачык тәрәзә янында йокларга яратам), ай буена сузылган чиләдән соң ерганаклар агарлык итеп, янгыр явып үткән, мотциклымнан да җилләр искән. Билгеле инде, милициягә барырга булдым—табуларына өметләнеп, гариза яздым. Көннәр үтә—юньле хәбәр ишетелми. Үзенә күрә бер кайгы: беренчедән, ярты еллык хезмәт хакын түлисе була, икенчедән дигәне тагын да хәтәррәк—ишетә калса, шул ук шәһәр башлыгының: "Пешмәгән кеше, ахрысы, бу Минзәлә егете... Килмәс борын дәүләт малын югалта башлады, ачык авыз",—диюе ихтимал.

Шуна күрә үзем дә тәгәрмәчле шул бәланың "эзләрен иснәштереп" йөри башладым 60 мең генә халыклы шәһәр буйлап—ягъни, берәрсе күрмәгәнме, кемнәрнең урлавы, кая яшергән булулары ихтимал?.. Колакка мондыйрак хәбәр дә килде: имеш, һөнәр училищеларының берсендә укучы ике-өч малайга шундыйрак шик төшә икән. Алар атна саен шәһәрдән кырык чакрымдагы авылларына йә мопедка, йә мотоциклга утырып кайтып китәләр икән. Тагын бер хәбәр колакны сыйпап үтте: әлеге авылда өр-яңа кара мотоцикл да күренә башлаган...

Кыскасы, мотоциклым нәкъ шулдыр, дигән уй да кереп оялады күңелгә. Барып тикшерергә ниятләдем.

Ләкин... баруын барырсың, йөрүен дә йөрерсең, кин болында күптән югалган кәҗәсен эзләп әвәрә килгән малай сурәтендә күренерсең... Юк, алай

булмый! Ниндидер рәсмилек тә кирәк булыр тикшерену эшләрендә—берәр милиционерны иярттергә кирәктер.

Шул ният белән шәһәрнең милиция башлыгына—полковник Фазыл абый янына киттем. "Абый" диюемнең сәбәбе шунда, милициядән бигрәк сабыр педагогны хәтерләтүче төз бәдәнле, ягымлы чырайлы бу начальник белән шәһәр Советында берничә мәртәбә кинәшкәләп, сөйләшкәләп алган бар иде инде. Һәрхәлдә, үз кеше кебегрәк кабул итәргә тиеш...

Киттем, кердем янына, мотоциклның югалуын, аны табып булу ихтималы җәһәтеннән фаразларымны аңлаттым. Анары:

—Формаль ягы өчен генә булса да минем белән берәр милиционер җибәрсәгез иде...—дидем.

Полковникның йөзенә сәер елмаю чыкты.

—Монда кергәндә кабул итү бүлмәсендә утыручы бер лейтенантка игътибар итмәдеңме?

Игътибар иткән идем шул. Алай гына да түгел, начальник үзендәме, дип тә сораган идем. Чөнки инде эш сәгате беткән, секретаршалар да кайтып киткән минутлар иде бу. Ялгыз гына боегып утыра иде әлеге лейтенант...

—Чыннан да формальлек өчен генә ярар инде ул сиңа... Бер район үзәгендә эшләүче коллегам җибәргән иде аны миңа, "монда миңа ышыкланып кына ята ул, үзенә ал әле, бәлки, әйбәт кенә хезмәт итә калса, фатир да бирер идең үзегезнең матур шәһәрдән", дип... Авызы белән чыпчык тотудан башка гамәлгә ярамастыр, мөгаен... Шулай да алып кит син аны. Нормасы туры килмәсә дә, формасы өстендә бит... Әткәсе лейтенант погонына хәтле тагып җибәргән шул җебекигә...—диде полковник.

Машиналы дустым урамда көтеп калган иде. Теге лейтенант белән арткы утыргычка янәшә урнаштык. Киттек... Көн матур, кояш инде аска таба юнәлгән, тирә-якта урман полосалары, тулышкан башаклы иген басулары. Юл калкулыклар буйлап бер күтәрелә, бер төшә... Рәхәт! ... Алда торган максатны аңлата башладым лейтенантка.. "Мотоциклны урладылар..." дип сүз катуым булды, шырык-шырык көлә башлады. "Без барасы авыл малайлары урлаган булсалар" диеп өлгердем генә, эче катканчы шаркылдады. "Нindirәк жай белән эш итәрбез микән анда?" дигән соравымны "Черт её знает..." дип җаваплады... Өмет өзелде моннан. Җитдирәк булып сөйләшкәндә дә шулай чырык-шырык килеп йөрсә, бу погонлы бәрәнге теге авылда үземнең дә көлкегә калуым бар. Формасының да файдасы тимәячәк... Мотоцикл шунда булган сурәттә дә буш кул белән кайтуым ихтимал. Түздем-түздем дә, әлеге авылга унлап чакрым калгач, машинаны туктаттырдым. Машинадан чыктым. Лейтенантны да чакырып чыгардым:

—Әйдәле, Мокрицкий, әнә тегендә—агачлыкта иркенләп көйрәтик бер. Киңәшеп тә алырбыз шунда...

Юлдан үтеп-сүтеп йөрүче машиналардан да күрмәслек итеп, агачлар арасына ук кердем. Әлбәттә инде лейтенат та минем эзгә басып килә. Тәмәкеләрне кабызгач, тегенә кырыслык һәм җитдилек белән:

—Начальнигың белән якын дус икәнне, аның белән на "ты" икәнемне абайладыңмы син, ул безне озатып җибәргәндә?—дидем.

Көтелмәгән сораудан хәтта гәүдәсе үрә катты моның.

—Шулай булгач, сиңа да, миңа да чишенергә туры килер хәзер!

Шулчак үз тавышыма да игътибар иттем: чын приказ кебек яңгырады ул. Боеруым кырыс полковникныкыннан ким булмагандыр... Егетнең күз алдына әллә нинди галәмәтләр килде сыман—тотлыга башлады:

—А... а... за... за-чем?..

—Шулай кирәк!

—А... а ш-што бу-будем де-делать?

—Син минем киемнәрне киярсең, ә мин синекеләрне! Авылда минем

милиционер булып йөрисем, тикшерүне дә үзем алып барасым килә. Ә син бер сүзсез тынлап кына йөрерсең яки тик утырырсың машинада.

—Ә начальник белсә?!

—Белмәячәк! Белсә дә сиңа бер авырлык та килмәячәк!

***

Машина янына мин—милиционер, ә теге миңа ияргән малай рәвешендә килеп җиткәч, минем холыкны, гадәтләрне шактый белергә өйрәнгән шофер да аптырап калды сыман. Ләкин дәшмәде. Шул рәвешле без авылга килеп кердек. Ике-өч йортны үтүгә үк юл уртасында басып торучы яшүсмергә игътибар иттем. Чөнки яхшы беләм: авылда чит яки яна мотоцикл бер генә мәртәбә үткән булса да, ул инде мондый яшүсмерләр күзенә чалынмыйча кала алмый. Машинадан төштем дә, безгә текәлгән малайга, бире кил, дигәндәй, сүзсез генә бармак изәдем. Малай, шикләнә-шикләнә атлап, каршыма килеп басты. Тегенең карашы кырыс йөземә текәлеп беткәч, кырт кына сорап куйдым:

—Теге фәлән номерлы кара мотоциклны кая куйдыгыз?

Ык-мык итте дә, гаепле кешедәй аклана башлады:

—Нет, дядя милиционер, не я украл этот мотоцикл... Я видел только...

—Мин бит "син урлагансың" димәдем. Синең әйбәт егет икәнең әллә каян күренеп тора. Кайда дип кенә сорадым...

—Беренче көннәрдә генә бар иде аның номеры. Алып ташлаганнар инде аны. Ул әнә теге йортның өйалдында тора. Ике атна чамасы... Васька үзе өйдә юк ул, шәһәрдәге ГПТУда укый...

—Син дә шул тирәгә бара тор. Күздән югалма,—дидем дә, ул күрсәткән йортның өйалдына керә башладым. Мотоцикл анда юк иде... Ул арада өйдән бөрешеп-бөкрәеп беткән карчык чыкты. Сәлам дә биреп тормастан, капыл гына сорап куйдым әбидән:

—Здесь, бабушка, черный мотоцикл стоял. Куда он делся?!

—Не знаю. Никогда не видела никакого мотоцикла,—ди әби.— Ышанмавымны күреп, татар әйтмешли, нәҗесен дә ашардай булып, чукына-чукына ант итә.—Ей Богу, никогда здесь мотоцикла не было!

Оятсыз чыраена текәлеп тордым да сиксәннән үткән карчыкның, кистереп әйттем:

—Эх, бабушка, гөнаһлы булып, оныгыңны караклыкка өйрәтеп китәсең бит бу дөньядан!—дип, чыгып та киттем. Чөнки инде мин ул мотоциклның авылда икәненә, тапмый кайтмаячагыма иман китергән идем.

Урамга чыксам, теге малай янына тагын ике малай килеп баскан. Атлап та тормастан тагын бармак изәдем. Инде, каршыма басып, өчәү текәлде йөземә.

—Әби әйтә, ул мотоциклның кая киткәнен белмим, ди. Сез беләсездер бит? Васька кемгәдер биреп калдырган, күрәмсең...

—Юктыр, биреп калдырмагандыр,—диешәләр малайлар, баскан урыннарында таптангалап.—Ул аны дядя Гриша белән ике көпшәле мылтыкка алыштырмакчы иде... Алыштырганнардыр инде...

—Нинди дядя Гриша ул?

—Ул җәйләүгә савымчыларны йөртә, аларга ризык ташый. Кайтып җитәргә тиеш инде. Карангы төшә башлагач кайтып җитә ул. Тетя Валя өйдәдер. Ул беләдер...

—Ә Валя кем? Әнисеме?

—Юк, хатыны. Алар беренче майда гына өйләнештеләр әле... Икесе генә торалар...

"Дядя Гришаның" капка төбенә җиткәндә, каршыга егерме яшьләр тирәсендәге сылу чыгып басты. Бик терегә, эшчән жанга охшаган. Йөзенә, килеш-килбәтенә сокланып тордым да:

—Их, сенлем, бик матур икәнсен. Ирен дә үзең кебек әйбәттер... Тик менә, авыр булса да әйтми булмый, иренне алып китәргә туры килмәгәе!

—Ә ни өчен?—диде чибәркәй, чаялык һәм гөнаһсыз караш белән.—Аның, минемчә, бер жинять тә кылганы юк.

Мин югалыбрак калган кыяфәт һәм йомшаклык белән үз сүземне әйттем:

—Шулаен-шулайдыр да бит... ни бит... кара мотоцикл сездә бит!

—Ә-ә!.. Шикләнгән идем шул аны—кара мотоциклны күргәч, урланган түгел микән, дип... Ләкин ул урламады бит аны, мылтыкка алыштырды. Күренми дә әле ул мотоцикл бу көннәрдә... Кая куйгандыр?

Ул арада бөркәүле йөк машинасының якынлашып килүе күренде. Бу инде, һичшиксез, Гриша булырга тиеш. Тиз генә теге чибәркәйгә әйтеп куйдым:

—Кереп кит, сенлем! Ирләрчә икәү генә сөйләшербез киявен белән.

Аның артыннан капка ябылуга, кабинадан сикереп ире төште.

—Ни бар монда?

Мин, кайгыга баткандай, җавап бирми тордым да һәр сүземне санап кына сөйли башладым:

—Менә, Гриша дускаем, хатының Валя белән сөйләшеп алдык әле. Шундыен да матур кызга өйләнгәнсен—күреп туймаслык. Үзенне дә бик уңган егет дип сөйлиләр авылда. Тәртипле егеткә охшагансың... Шулай да берничә ел аерым яшәргә туры килер сезгә, пожалуй!

Егет каушады:

—Ник?! Закон бозганыбыз юк безнең.

—Ләкин без эзләргә чыккан кара мотоцикл синдә икән бит, брат! Әле, урланган әйбер буларак, яшереп тә куйгансың бугай. Ихатаңнан тапмадык...

Гриша бөтенләй кыстатмады, боргаланмады. Хатыны кебек үк якты карашын төбәп, барысын да әйтеп бирде.

—Мин урламадым аны. Мылтыкка алыштырдым, кызыгып... Урланган булуын абайлап, яшереп тә куйдым шул... Виноват, конечно...

—Әйе, гаепле син,—дидем.—Хәзер инде мотоциклны күрсәтсәң дә ярый. Кая ул?

— Монда гына. Әйдәгез, күрсәтәм.

Бәрәңге бакчасының башында печән чүмәләсе тора икән. Янына житү белән, Гриша аның бер читен күтәрде. Эһ! дигәнче минем ай чамасы "биләмдә йөргән" мотоциклымны, яткан жиреннән торгызып, бастырып та куйды. Номерсыз. Баксаң, замок зажигания дигән нәмәрсәсе дә юк икән. Фарасының ян тишегеннән ике чыбык кына чыгып тора.

—Номеры юк иде инде аның. Ә теге кабызгычы миндә—өйдә. Анысын хәзер үк урынына куям... Скажите пожалуйста, что за это мне грозит?

Инде куерып баручы караңгылыкка игътибар иттем дә, кайтып китәр вакыт житүен чамалап, сүзне түгәрәкләдем:

—Бүген соң инде, Гриша. Анысын сөйләшербез... Иртәгә иртән үк, шушы мотоциклга атланып, фәлән урамдагы фәлән нумерлы йортның алдына килеп бас, штубы дип, үземне машинада көтеп утыручы лейтенат белән шофер тарафына тәпиләдем. Арттан хатыны куып житте:

—Әйтегез инде, зинһар, иртәгә кире кайтырмы ул? Мин бик борчылам бит...

—Артык борчылма, сенлем. Ләкин аны, иртәрәк уятып, минем янга озатырга онытма.

Минем янга бер килеп, бер китеп йөргән, мотоциклның табылганын да белеп торган Мокрицкий (фамилиясен үзгәрттем, билгеле. Кем белә, бәлки ул майор, полковник кебегрәк кешедер хәзер—кызармасын, хур булмасын инде...):

—Шулай да, минем форманы киеп йөрүегез турында полковникка ычкындырмагыз инде,—дип үтенә башлады, бер-ике чакрым үтүгә.

—Ә син, полковникны мин милициягә барып житкәнче күрсәң, бравый офицерларча чартлатып рапорт бирә тор: "Мотоциклны таптым, приказыгызны үтәдем!" дип әйт.

—Ничек?! Сез таптыгыз бит аны!..

—Мин әйткәнчә җавап бир! Сүзебез бер булсын начальнигың янында!

Төн үткәч, көн башлангач, подъезд төбендә Гриша көтеп тора иде инде. Мотоцикл да, чүмәлә астында сыланган ләпектән арынып, чип-чиста булып, янында балкып тора.

—Мина нишләргә хәзер?—ди Гриша, башын игән, аптыраган хәлдә.

—Сиңамы?.. Син, Гриша, мылтыгынны теге карак малайдан ал да, шуның белән гүзәл хатыныңны чит-ят күзләрдән саклап яшә...

Әлбәттә инде, Гришаны озатуга ук, полковник янына киттем.

—Ярдәмегез өчен зур рәхмәт, Фазыл абый, егетең ике-өч сәгать эчендә тапты да бирде. Аңа да тагын бер мәртәбә рәхмәтемне җиткерсәгез икән...

—Алдамыйсыз кебек... Гаҗәп!

—Бер дә гаҗәп түгел. Тыштан гына ачык авыз булып күренә икән ул... Ә инде мотоциклны урлаган унбиш яшьлек ГПТУ малаен монда чакыртып мәшәкатьләнәсе дә юк... Аны лейтенант болай да каты кисәтте.

Сүз уңаенда әйтеп үтим инде: икенче көнне үк кабинетыма йөзе балкып киткән лейтенант килеп җитте. Сумкасыннан коньяк, ике шоколад чыгарды. Баксаң, полковник сафка тезелгән милиционерлар алдында рәхмәт белдергән икән егеткә!

—Бу әле минем мондый зур рәхмәткә беренче мәртәбә лаек булуым,—диде, авызын ерып.

... Юк... теге мотоциклга утырмадым мин кабат... Ничек кенә матур булмасын, ул миңа чит кулларда кәшәләнеп кире кайткан чәчбикә булып тоелды... Җирәндем.

... Әйе, яшь чагымның дуамаллыгы, башбаштаклыгы булды бу милиционерны чишендерүем. Әле аннан соң да законга сыймый торган тагын бер гамәл кылып ташладым мин яшьлек юләрлеге белән: 1978 елның ямьсез сентябрендә, кара төндә, бер прокурорны урлап, кара урман аланына алып киттем... Монысын да язасы килә килүен. Ләкин аныңчы адвокатларым белән киңәшәсе бар: шул кадәр гомер үткән булуга карамастан, берәр статья табып, картаймыш көнемдә төрмәгә тыгып куймагайлары!..

*25 май, 2007 ел.*

***Редакциядән:***

**Быелның 16 февралендә сатирик язучы, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе Фәнзаман Батталга 70 яшь тулды. Аны юбилее белән котлыйбыз, саулык-сәламәтлек, яңа иҗат уңышлары телибез.**



Эльвира
Һадиева

# ТӘРӘЗЛӘРНЕ АЧТЫМ

## Гафу

**Җилфер-җилфер уйный буран,**
**Син аныкы бүген.**
**Сөйгәнем дип әйтә алмыйм—**
**Ялган кирәк түгел.**

**Җемелдәшеп, шат йолдызлар**
**Күзләреңә бага.**
**Мин синеңчә карый алмыйм—**
**Нигә сиңа ялган?**

**Тылсым тулы икәү кайта,**
**Йөрәгеңдә чың ла:**
**Көздә кайчак буран була—**
**Туңма, кичер, аңла!**

***

**Кулга кул—**
**Бу көзгә бергәләп, курыкмый...**
**Офыкта бер сызык,**
**Таңмы ул, ярыкмы?**
**Башкалар карасын**
**Яндырып яңадан.**
**...Янәшә атларга:**
**Син дә мин—**
**Җанга җан!**

Эльвира ҺАДИЕВА—*яшь шагыйрә, Казан дәүләт университетының татар филологиясе һәм тарихы факультеты талибәсе. Шигырьләре көндәлек матбугатта даими басылып килә.*

## Өндәү

Сусавыма шифа тапмыйм:
Ниләр кылдың минем белән—уят!
Һәр тәрәзә саен сәбәп:
Сабыр яңгыр күпнокталар куя...

Саташылган сагыш белән,
Адашылган күзләр туган көндә—
Беләм, ләкин
Күпнокталар коя яңгыр,
Тик йөрәкнең бер тынышы—өндәү!

## Беләм

Бу Казанның һәр сулышы,
Һәр керфеге сине хәтерләтә,
Һәм көтәдер түләү:
Бер елмаю өчен әрнүләтә...

Ә мин риза, хыял тулы
Бәгыремне алсын кубарып ук!—
Синсезлектә нигә хыял?!
Әмма Өмет...—
хыяллардан югары Күк!

## Кышкы Казанга өмет

Бары Сез...
Мин Сезгә башкача дәшалмам!
Аерып,
Арада күпмеләп яшь калган.
Хыяллар:
Сездә бар, бар миндә—игездер.
...Күк никтер Казанга
Ак күлмәк кигездә.
Бу буран
Сөюне күмгәндә елармы?
Кисешә бер мәлдә
Елларны, юлларны?

Ә Казан—мең СҮЗСЕЗ һәм Сезсез—ап-актан.
Бары Сез...
Барыбер яратам!

## Үсмер

Тәрәзләрне ачтым,
Гыйнвар җиле
Пәрдәләрне тирбәп кинәндерсен...
Язылмаган шигырьләрдә калган язмыш
Әкрен-әкрен карлар булып килә бирсен.

Кала бирсен ярлара кұперләр дә—
Син Ярымда тынычлык һәм сагыну күрәм.
Әрнер якын төшләрендә башка бит без,
Нигә кояш мизгел саен—тоям—сүрән?

Тәрәзләрен ачам төшнең, гыйнвар җиле
Пәрдәләрен йолкып төшерсенче.....
Яшьләремне сиңа сылтамыйм да,
Син бит син ул, ә мин... үсмер, көнче.

Ә шулай да, биеккәрәк, биеккәрәк,
Учларымда бер төс—ундүртенче!..

## Бөркетләр очырган шәхескә

Тоҗым-тоҗым булып хәтер кала,
Еллар түгел, тарих исе учта...
Туфан, имеш, канат җиле лә бу
Бөркетләрнең—бер оядан очкан!

Елмаерга сусап калган йөрәк,
Ул күзләрдә язмыш юлын санар...
Бәхет үзе, эзләреңдә булса
Аклык төсе тулы җылымса кар!

## Алар

Алар безне инде танымас та,
«Ялгыша бит» диеп инде әйтмәс...
Сулык-сулык килеп ята күңел,
Аһ, ымсытты бигрәк көмеш ятьмә...

Аһ, ымсытты бигрәк көмеш ятьмә:
Ярдан йолдызларны саныйк, дидек.
Ул кичләрдә БӘХЕТ идек әле,
Яшьлек—яшел түгел, яшьле түгел—
Ап-ак!
Җете ихлас көлмәк кидек...

Ап-ак, җете ихлас көлмәк кидек...
Алар безне ул кич танымады.
Ә таныгач, әрнеттеләр—каты:
Ак күлмәктә... йөрәк эзе калды!

Нурихан
Фәттах

# БЕРЕНЧЕ ШИГЫРЬ КҮК БАЛАЧАК...

ИСТӘЛЕКЛӘР

## 22. Беренче шигырь һәм беренче тәнкыйтьче

Өченче класста укыганда кыш көне, елга аръягындагы чыршылыкта чаңгы шуып йөрдем дә, кышның матурлыгыннан, чаңгы шууның рәхәтлегеннән тәэсирләнеп, "кыш" дигән шигырь яздым. Беренче шигырь. Безне шагыйрь булырга агитлаучы кеше булмады, ахрысы. Шулай да мин бит укучы—шигырьнең нәрсә икәнлеген генә чамалыйм. Беренче шигырьне беркемгә күрсәтеп тормадым, тоттым да Янавылга, "Октябрь юлы" дип аталган район газетасына җибәрдем. Басуын басмадылар. Хат та килмәде бугай. Тик минем район газетасында кулы гарип бер кеше каршысында утырганым бар. Ул миңа шигырьнең ничек булуы, ничек язылуы турында сөйләде кебек.

Кыш көннәрендә уенга чыгарга җай булмаганда мич башына менәм дә, төрле җырлар, шигырьләр язып утырам, рәсемнәр ясыйм. Ул чакта иң зур кытлык—кәгазь кытлыгы. Мәктәптә дәфтәрне саклап кына, исемлек белән генә бирәләр. Кайда нинди кәгазь туры килә, шуны блокнотсыман итеп кисәсең дә, тегәсең дә, рәхәтләнәсең язып.

Бишенче класста мин Янавылда инәкәй янында тордым. Монда укучылар да күбрәк, тормыш та җанлырак, шау-шулырак. Шигырь язуны, рәсем ясауны ташлаган юк. Киресенчә. Казаннан "Яшь Ленинчы" газетасы, "Пионер каләме" журналы килә. Аларның һәр номерын сагынып, зарыгып көтеп аласың. Минем шагыйрьлеккә әлегә беркемнең игътибар иткәне юк. Үзем дә шаулап йөрмим. Бары үзем өчен генә язам.

Шулай бервакытны "Яшь Ленинчы"да бөтенләй көтмәгәндә минем бер кеп-кечкенә мәкалә, дөресрәге, гап-гади бер хәбәр басылды. Безнең Янавыл татар урта мәктәбе Үзбәкстандагы ниндидер мәктәпне социалистик ярышка чакырып хат язды. Бөтен мәктәп балаларын озын коридорга җыеп безгә шул турыда аңлатканнар иде. Беркемгә әйтмичә әлеге вакыйга турында мин "Яшь ленинчы"га язып җибәрдем. Газетага минем шул хәбәрне басканнар. Иң элек мәкаләне укытучылар күреп алганнар, ахрысы. Ул чакта мәктәпнең завучы Баямый абый Дусметов иде. Гел елмаеп торган, чибәр, ачык йөзле бу кеше татар әдәбияты укыта. Тагын озын коридорга укучыларны җыйдылар да, бөтенсе алдында "Яшь ленинчы"дагы "мәкалә"не кычкырып укып чыктылар. Минем инде түбә күккә тиде. Шуннан соң мин канатланып Баямый абыйга үземнең шигырь дәфтәрләрен күрсәтергә булдым. Юк, ул, ахрысы, үзе сорап алды. Укытучылар бүлмәсендә озак кына миңа нәрсәдер аңлатып торды. Күрәсең, ул минем күңелне күтәргәндер. Аның белән сөйләшкәннән соң мин тагын да дәртләнебрәк язарга тотындым. Минем шигырьләр стена газетасында да басыла башлады. Озакламый мине стена газетасының художнигы

*Дәвамы. Башы 2008 елның 10нчы санында.*

итеп сайладылар. Өлкәнрәк классларда әдәбият түгәрәге эшләде. Анда шулай ук мин башлап йөрдем. Сигездәме, тугыздамы, хәтта кулдан язылган әдәби журнал да чыгардым. Журналның да, газеталарның да төп иҗатчысы, дөресрәге, кара эшчесе үзем булдым. Баямый абый сугышның беренче елларында ук фронтка китте һәм Хәниф абыйлар кебек, башка бик күпләр кебек, кире әйләнеп кайта алмады. Мин белгәндә Баямый абый инәсе һәм сеңлесе Гайшә апа белән тора иде. Аның беренче хатыны үлгән булган. Лера исемле бер кызлары калган. Баямый абыйның инәсен без "әби" дип йөрттек. Менә шул Әби, Янтыктагы безнең Яшәби кебек, барысын да үз тирәсенә җыеп, карап торды. Сугышның иң авыр елларында да ул сыер тотты. Якындагы һәркем аннан сөт алды. Без алар белән дус-тату яшәдек. Гайшә апа да, балалар да безгә карата аеруча ягымлы булдылар. Кайчан кермә, әбинең самавыры кайнаган булыр. Әле дә исемдә, унынчы класста имтихан биреп йөргәндә, иртән иртүк кереп әбиләрдә чәй эчәм дә, имтиханга китәм. Казанда укып йөргәндә дә аларга үзебезнең туган өйгә кайткан кебек кайта торган идем. Туган өй... Булды микән минем берәр вакыт туган өем!

## 23. Скарлатина

Бик бәләкәй чагымда мин кызамык белән чирләгәнмен. Бик каты ятканмын. Биткә тимгел-тимгел кызыл таплар чыккан. Мине азган дип уйлап, ул чагында миңа "мин" сүзе кергән яңа исем кушканнар. Мулла кушкан яңа исемем Минлемөхәммәтнурихан булган. Мине көн дә үлә инде бу дип көтеп торганнар. Ләкин нишләптер мин үлми калганмын. 1941 елның көзендә, караңгы бер кичтә көтмәгәндә тагын чирләп киттем. Җылы өйдә, дөресрәге, казан астында туктаусыз утын яна торган җылы кухняда, палас җәелгән иркен сикедә гадәтемчә шигырь язып утырганда нишләптер баш авырта башлады. Йокы да килгәндәй итә. Шул ук вакытта—күз алдында!—кул аркасына кызыл таплар чыга башлады. Шигырь язуны туктатырга туры килде. Ул вакытта өйгә врач чакыру дигән нәрсә юк. Шулай ук ашыгыч ярдәм машинасы чакыру да юк. Ни өчен дисәң, ул чакларда андый машиналар әле тумаган. Ничек булса булгандыр—икенче көнне мине больницага алып бардылар. Шунда калдырып кайтып та киттеләр. Мин чирләү белән, күрше Хәфизә апа ары-бире чаба башлаган. Врачларга да ул алып барган, больницага да ул калдырып кайткан. Аларның үзләренең дә өй тулы бала-чага. Укымышлы кеше буларак, минем авыруның йогышлы икәнлеген алар, күрәсең, яхшы белгәннәр. Шуңа күрә үз балаларын саклау йөзеннән дә тырышканнардыр дип әйтергә була. Моңысы аның мәсьәләнең бер ягы гына. Мәсьәләнең икенче ягы—ул күршеләр бик ярдәмчел кешеләр иде. Мин бүлнистә ятканда Хәфизә апа көн дә минем янга килеп йөреде, ашарга китерде, хәлне белеште. Әгәр якында гына алар булмаса, күрәсең, мин инде ычкынган да булыр идем. Инәкәй, үзе әйтмешли, ул чакта аңсыз булган, күп нәрсәгә игътибар итмәгән. Мин аның да минем янга килеп, мыштым гына җылап утырганын хәтерлим. Хәлләр ул вакытта чыннан да җыларлык булган. Мин скарлатина белән чирләгәнмен. Температура кырык бергә җиткән. Саташканмын, килгән кешеләрне танымый башлаганмын. Бу юлы да мине үлә дип көткәннәр. Ләкин, үч иткәндәй, мин тагын да исән калганмын. Ул чактагы баш авыртуны, хәлсезлекне, авыздагы ят тәмне мин әле дә хәтерлим кебек. Аннары мин кычкырып сөйләшә торган, кергән саен үзе белән салкын алып керә торган озын буйлы рус врачын хәтерлим, миңа бирелгән даруларны хәтерлим. Иң серлесе менә шул дару. Бар ышаныч шунда. Ул вакытта дарулар кечкенә кәгазь пакетка салынган була торган иде. Пакетны сүтәсең дә, вак тоз сыман ак порошокны теленә саласың. Порошок тешкә тисә, шыгырдавык тавыш чыга. Күрәсең, Тукай заманнарыннан калган аспирин булгандыр инде ул. Үпкә авырулы Тукайга шуны бирә торган булганнар. Ул чаклардагы бөтен дару-дәва шул. Аннан соң—авыруларны тазалардан аерым урнаштыру. Үлсәң—кайгы, үлмәсәң—ярый. Табигый сайланыш. Күпмедер вакыттан соң мин хәлләнә башладым. Килгән кешеләрне дә таныйм, тамакка да ашыйм. Бераз хәлләнү белән өйгә кайтаруларын сорый башладым. Укуым калган өчен кайгырам. Минем өчен ул—иң зур кайгы. Көннәрдән бер көнне инәкәй, иске шәлгә, сырмага төреп, бәләкәй чанага утыртты да алып кайтып китте. Мин югында кыш булган, җиргә ап-ак кар яуган. Иң гаҗәбе—кар. Ап-ак, күзне чагылдыра. Кайтуын кайттым

өйгә, шулай да укырга йөрерлек түгел. Әле һаман хәл юк. Классташым Мәгъсүм минем янга килеп, миңа дәресләр өйрәтеп йөрде. Ул чакларда шулай бер-береңә ярдәм итү гадәте бар иде. Скарлатинадан соң мин, инәкәй әйтмешли, жинеләеп калдым. Юкка-барга үртәләм, холыксызланам. Мин чирләгән елны безнең класс житәкчесе Рима апа иде. Мин янадан укырга йөри башлагач, Рима апа бөтен классны базар янындагы фотографиягә кәртечкәгә төшәргә алып барды. Фотограф безне, буйга-ингә карап, үзе белгәнчә тезеп чыкты. Мин иң артка эләктем. Минем иң алда, Рима апа янында буласым килде. Шул турыда әйткәч, Рима апа мине якламады. Холыксызланып кайттым да киттем. Ул елларда бөтен класс белән төшкән бер генә фотом да юк. Нинди кызганыч! Скарлатина минем сугыш елларындагы беренче сынавым булды дип әйтергә була. Беренчесе, ләкин соңгысы түгел. Сигездәме, тугыздамы укыганда военкомат кушуы буенча поликлиникага тикшерелергә кердем. Армиягә алынасы малайларны шулай карап-тикшереп торалар иде. Ак халат кигән терапевт—монсу йөзле, саргылт чәчле яшьрәк маржа кызы чишенергә кушты да, үпкәне, йөрәкне тыңлады, каккалады-суккалады да, ахырда киңәш итеп: "Яхшырак ашарга кирәк",—диде. Ул елларда мондый киңәш мыскыл белән бер иде. Мин берни аңламадым. Шулай да маржа кызы көлмәде бугай. Йөзе һаман боек, моңсу. Ул вакытта миндә туберкулез булган. Врач миңа "туберкулез" дигән сүз ычкындырган булса, куркудан мин, ихтимал, аяк сузган булыр идем. Бит Тукайны караган доктор, анда туберкулез икәнен белгәч, шагыйрьнең йөзенә бәреп, "савыгуга өмет юк", дигән. Бу, билгеле, Тукай белән чагыштыру түгел, бу бары бер мисал гына. Үтергән дә тел, тергезгән дә тел, ди халык. Иң кыен чакларымда мин яхшы кешеләргә туры килгәнмен—шуны әйтәсе килә. Үземнең кайчандыр үпкә чире белән чирләвемне мин бик күп вакыт үткәч кенә белдем. Ләкин ул вакытта инде үпкәдәге таплар беткән булган. Куркыныч "туберкулез" миңа берничек тә тәэсир итә алмады.

1956 елда бөтен дөньяда грипп чире котырды. Грипп миңа да эләкте һәм мин тагын үлә язып калдым. Ун елдан соң, 1966-67 елның кышында көтмәгәндә тагын аяктан егылдым. Монысына үзем гаепле. Тыштан кергән салкын кефир шешәсен жылынсын дип кызу плитә янына утыртып куйдым. Ул артыграк жылынып киткән. Кефир эремчексыман булып өскә калыккан, яшькелт-соргылт сыекчасы аста калган. Моңа игътибар итеп тормадым, шешәне болгаттым да, янадан кефир ясап, эчеп жибәрдем. Күп тә үтмәде, эч авырта башлады, температура күтәрелде, рәт китте. Тик торганда, "таза" баштан урынга ятарга туры килде. Ярый әле хатын медик—ул шундук чарасын күрә башлады. Температураны төшерү өчен антибиотиклар бирде, пенициллин кадый башлады. Күрәсез, бу инде теге еллардагы кебек кәгазь пакеттагы шыгырдавык "тоз" гына түгел. Монда хәзер фәлән дә төгән. Никадәр алга китте " безнең" медицина!

Ләкин нәрсә генә эшләсәк тә, температура да төшми, хәл дә яхшырмый. Шулай берничә көн дәвалап карагач, хатын бер таныш докторын—эчке авырулар белгечен алып килде. Яшь доцент жентекләп сорашты да алып китте больницага. Анда тагын иң атаклы белгечләр карадылар, тикшерделәр дә операциягә салырга кирәк диделәр. Ярып карамыйча нинди чир икәнен белеп булмый икән. Күңел тартмады. Киттек без кайтып. Шуннан соң хатын янача, яна дарулар белән дәвалый башлады, тагын да дәрәжәлерәк белгечләргә мөрәжәгать итеп карады. Юк, берни ярдәм итми. Хәл начарланганнан начарлана бара. Авылга, инәкәйгә хат яздык. Ул кышны Казанга килмәскә, авылда кышларга ниятләгән иде. Безнең хатны алгач та кыш уртасында Зәйкәт белән икәүләп килеп төштеләр.

Уйланып ята торгач, мин башка бер авыру вакытында үзем кулланган "күренексез" генә даруны искә төшердем. "Медицина" белән киңәшкәч, шул даруны эчә башладым. Хәл шундук яхшыра башлады. Соңыннан хатын сөйләде: бер врач хатынның да утыз яшьләр чамасындагы ире шундый ук серле "эч авырту" белән чирләгән. Төрлечә тикшереп карап та, диагноз куя алмагач, белгечләр моны да ярып карарга булганнар. Ярганнар һәм теге иптәш шуның белән китеп тә барган.

Ул кышны мин ике ай чамасы урын өстендә яттым. Озакламый аякка бастым. Шулай итеп, без тагын исән калдык.

Безнең балалык, безнең яшьлек үтә кыен чакка туры килде. Ачлык, мохтажлык, кысынкылык һәм төрлечә кыерсытылу безнең беренче юлдашлар булды, һәртөрле

салкын тиюләрнен, көтелмәгән күнелсез хәлләрнен исәбе- хисабы булмады.

Безнен яшьтәшләрнен кайберләре ачлыктан үлде, кайберләре авырып, кайсы берсе бәла-казага юлыгып үлде. Без менә исән калдык. Ничек итеп? Еш кына мин шул турыда уйланам.

Кеше дөньяга көрәшче булып туган. Бер бик акыллы иптәш әйткәнчә, хезмәтне өзелеп яратуы нәтиҗәсендә түгел, бәлки тумыштан ук көрәшче булган өчен генә кеше дүрт аяклап йөрүдән сон ике аяклап йөрү бәхетенә ирешкән. Гомер буена кеше ерткыч хайваннар белән көрәшкән, үзен чолгап алган һәртөрле кыргый көчләр белән көрәшкән. Шул ук вакытта ул үз-үзе белән дә, үзенен якыннары белән дә көрәшкән. Көрәш төрле рәвештә булган. Бер очракта ул кулына күсәк тотып дошманына каршы сугышка ташланса, икенче очракта ягымлы сүз белән алдырырга тырышкан. Шулай итеп, гасырлар буена кешенен холкы-фигыле формалашкан, рухы чыныккан. Мул, иркен тормышта көрәш рухы, көрәш инстинкты йомшарырга, томаланырга мөмкин. Кыйнап, тормыш безнен рухны ныгытты, көрәш инстинктын чарлады. Ин кыен, ин авыр вакытларда мин, билгеле бер ноктага житкәч, үземне янадан тугандай хис итә башлыйм. Каяндыр мина яна көч, яна дәрт килә: туктаусыз өстән басып торган, анны-зиһенне томалап торган газапка, авырлыкка каршы баш күтәрәм. Дөресрәге, минем тынычсыз акылым көрәш башлап җибәрә. Кайчагында мин үземдәге менә бу үзгәрешне үз күзем белән күргән кебек булам. Акыл башта нечкә генә яктылык нуры булып тоела, әкренләп ул көчәя һәм бер заман гөлт итеп китә. Зиһен яктыра, фикер ачыклана. Жину шул була. Шулвакыт син үз хастанны жинеп, сикереп торып аякка басасын, йә очынып элек көчен житмәстәй эшкә тотынасын.

Ижат кешесенен бөтен гомере менә шундый көрәштән, жинүдән, ачышлардан гыйбарәт. Ләкин рухи көрәш ижат кешесенә генә түгел, һәркемгә кирәк, һәрвакыт кирәк. Авырудан исән калу өчен генә түгел, кайчагында тормыштагы гап-гади тоелган каршылыкны, кирелекне, ансызлыкны жинеп чыгу өчен дә безгә рух көче, акыл көче кирәк.

## 24. Ул дәһшәтле сугыш елларында

Баштарак без сугышны бик тиз бетәр дип уйладык. Гәзиткә дә шулай яздылар. Гадәттәгечә, безнен илне кызыл кирпечтән өелгән стена итеп, Гитлерны исә шул стенага башы белән килеп бәрелгән бер диванасымак итеп ясыйлар иде. Чынлыкта ул алай ук булып чыкмады. Сугыш шактый озакка сузылды.

Беренче айларда сугыш авырлыгы бөтенләй сизелмәде. Бары тик урамда кайбер таныш кешеләр күренмәде дә, көн саен марш атлап йөрүчеләр күбәеп китте. Аннан соң кичләрен ут яндыру тыелды. Янавылның электр станциясе болай да начар эшли—әледән-әле ут сүнә. Электр станциясе тимер юл буенда. Ут сүнүгә, ут булмауга күнегергә дә була. Ин кыены ачлык.

Кыенлыклар ин элек базардан башланды. Күз алдында базар бушап калды, магазиннар булган запасларын сатып бетерделәр яисә жыеп-яшереп куйдылар. Базарда ит-сөт, ашлык бәясе бик нык күтәрелде. Янавылда хәлләр бик нык авырлашкач, без инәкәй белән Янтыкка, яшәбиләр янына кайтып киттек. Бу хәл кырык икенченен кышында булды. Укырга янадан үзебезнен класска кердем. Алтынчының яртысыннан алып, җидене тәмамлаганчы ТБУмында укыдым. Жидедән сон тагын Янавылга киттем. Билгеле, инәкәй белән киттек. Ул үзенен элекке эшенә урнашты.

Шулай итеп, өе табылмаган коштай әле анда, әле монда йөрдек.

Авылдан да, Янавылдан да безне беркем куаламады. Безне бары ачлык куалады.

Ачлык турында күп язылган. Ана хәзер бернинди яна нәрсә өстәп булмас кебек. Шулай да ачлык турында әйтми калсам, безнен "балачак" дип аталган әрнүләрнен-газапларнын күпмедер өлеше юкка чыгар иде сыман. Сугыш дүрт ел барды. Киеренке дүрт ел эчендә без кыл өстендә булдык. Жину өчен без сонгы тамчы каныбыз калганчы тырыштык. Безнен чыдамлык-тырышлык шартлап сынар дәрәжәгә житте. Үзебезнен нәрсә өчен тырышканны, нәрсә өчен газап чиккәнне без бик яхшы анладык. "Без" ул "мин" генә түгел. "Без" ул—халык. Бөтен ил, бөтен халык. Һичьюгы ул елларда мин белгән, мин күргән, тойган халык.

Киеренке сугыш дүрт ел барды. Дүрт елның шаукымы кырык елга сузылды.

Сугыш башланган елны да, сугыш алдыннан да авылда иген бик уңды. Хезмәт көненә ашлык күп бирелде. Ул елларда колхоз хезмәт көненә ашлык кына түгел, башка төрле "натура" да бирә иде. Ул чакларда колхозчыга ит-сөт, йон, бал, яшелчә биргәннәрен мин әле дә хәтерлим. Яшәби дә, апа да колхозда тырышып эшләделәр. Аларның хезмәт көннәре шактый күп булды. Тәгаен күпме булгандыр, әйтә алмыйм. Ләкин алар ул яктан зарланмадылар. Колхозчыларга арыш, бодай, солы кебек ашлыкларны, яшелчәне ат белән өй борынча таратып йөрделәр. Кайберәүләрнең ашлык салып кую өчен лар, бура ише нәрсәләре булмый—андыйларга ашлыкны туп-туры ишегалга гына аударып китә торган булганнар имеш. Колакка шулай чалынып калган.

Кырык икенче елны безнең якларга Көнбатыштан качаклар, күчерелгән кешеләр килә башлады. Күбесенчә Мәскәүдән, Ленинградтан булды бугай. Язга чыгу белән алар төркем-төркем булып авылларда йөрделәр. Төрле кием-салымнарын, йорт әйберләрен пешкән эпигә, бәрәңгегә алыштырдылар. Аларны бездә "минәйт" дип атадылар. Бик борынгы заманда да болгарлар төньяк халыклары белән товар алыша торган булганнар. Ул чактагы сатучылар-алучылар бер-берсен күрмәгәннәр. Берәүләр әйберләрен калдырып киткән, икенче якныкылар кеше югында килеп, калдырган әйберне алган да, шуның өчен үз товарын калдырган. "Минәйт"тә кеше бер-берсен күрә, сөйләшә, тик бер-берсенең телен генә рәтләп белми. Минәйтләр гадәттә материя кисәге, эчке күлмәк, ыштан, тузган бишмәт кебек нәрсә чыгарып күрсәтә. Авыл кешесе күнеленә ошаганын ала да, бер бөтен эпи бирә, бәрәнге-фәлән бирә. Базарда да шул ук күренеш. Куылып килгән шәһәр кешеләре ашап булмый торган нәрсәне ничек тә азыкка алыштырырга тырышалар. Базарда күбесенчә он, ашлык, ярма була. Мәскәү, Ленинград кешесе онны, тартылмаган ашлыкны ничек кулланырга белми. Аңа бары хәзер ашарга кирәк. Пешерергә аның миче, казаны, савыт-сабасы да, утыны да юк. Барысын да каяндыр табарга, сатып алырга, ялынып-теләнеп алырга кирәк.

Мәскәү, Ленинград кешеләрен әкренләп урнаштыра башладылар. Аларның күбесе авылларга таралды. Бездә дә алар унлап-унбишләп кеше калды. "Минәйт"ләр бер генә җәй йөрделәр, ахрысы. Икенче җәйне алар күренмәделәр. Бу вакытта инде алар яңа урында, яңа тормышка җайлаша башлаганнар иде бугай. Аннан соң авылның үзендә ашау ягы такырайды.

Авылда ирләр бөтенләй диярлек калмады. Әледән-әле куалап яшь, таза атларны шулай ук фронтка озаттылар. Авылда—карт-коры да, хатын-кыз, бала-чага. Ат фермасы яртылаш бушап калган. Басулар вакытында сөрелмәде, чәчелмәде. Монарчы атлы эштә бары тик ирләр генә йөри иде. Хәзер бөтен эш хатын-кыз җилкәсенә төште. Бер язны апаларны сука башы тотып җир сөрергә өйрәттеләр, печән вакыты җиткәч, печән чабарга өйрәттеләр. Апаның сукранулары, беләкләре сызлаудан зарланулары истә калган. Печәнне яшьрәк хатын-кыз, өлкән яшьтәге ирләр чапты, җыярга безне—үсмерләрне, карт хатын-кызларны алып чыктылар.

Уракка бөтен авыл чыга. Уру, сугу—иң җаваплы эш. Урылганны-сугылганны элеваторга илтеп тапшыру—тагын да җаваплырак. Элеваторга шулай ук апалар, тазарак хатыннар, үсмерләр йөри. Авыр капчыкларны күтәреп арбага салу, аны тиешле җиренә илтеп җиткерү, бушату үзе мең газап. Бигрәк тә буыны ныгымаган үсмерләр, хатын-кызлар өчен.

Көндез апалар сөрүдә, чәчүдә, уракта йөрсәләр, иртән иртүк таң тишегеннән уятып аларны окоп казырга алып баралар. Алар казыган окоп эзләре әле дә ындыр артында беленеп тора. Баштарак анда озынча булып балчык өеме кызарып ятты. Аннан соң аны чүп басты, балчык өеме бер заман ишелеп төште—элекке окоп чокыры батынкы җир булып калды. Ашлык сукканда, элеваторга ашлык ташыганда ул елларда кешеләр гомумән икешәр-өчәр смена эшләделәр. Бигрәк тә апаның шулай көн-төн эшләгәне истә калган. Көне буена ул урак ура яисә көлтә бәйли, кич көтү кайтканда өйгә кайтып тамак ялгаштырып ала да, аягындагы чабатасын да салып тормыйча, яңадан чыгып китә. Монысында инде ындыр табагына. Анда алар кул белән әйләндереп ашлык җилгәрәләр, Яңавылга элеваторга алып китәргә капчык тутыралар. Бары шуннан соң гына күпмедер йоклап алалар да, таң ату белән—яңадан эшкә.

Басудан ашлыкны исән-имин жыеп ала алсан, суктыра алсан, жилгәрүен сонынннан да жилгәрергә була. Жилгәрү кыш буена дәвам итә. Барлык эш кулдан эшләнә. Кайбер авылларда өлгергән иген шул көе жир өстендә утырып калды. Безнең "Очкын" колхозында да апалар кайсыдыр елны кар яугач солы, бодай урып йөрделәр.

Авылда кеше бернинди ялсыз эшләде. Жәй көннәрендә коеп янгыр яуганда гына кеше бераз ял итеп ала. Ләкин печән, урак вакытында коеп яуган янгыр бер көнне сөенеч булса, икенче көнне кайгыга әйләнә. Чабылган, жыелмаган печән бурсыр инде, урылган ашлык кызар инде, бурсыр инде дип кеше ут йота башлый. Менә шундый бер-берсен алыштырып кына торган, берсе өстенә икенчесе өелеп кенә торган кызу эш вакытында кешенең үз хужалыгы, үз мал-туары турында уйларга да рәте калмый. Бар эшне без башкарабыз. Без—бала-чага, карт-коры. Ләкин без чынлыкта көндәлек вак-төяк эшләрне генә башкарабыз. Кышка үз малын өчен печән, салам әзерләү, утын әзерләү бөтенләй диярлек юк. Көннәр суыта башладымы, карлы таудай булып олы кайгы алга килеп баса—өйне ничек жылытырга да, көтүдән туктаган ач малларны ничек туйдырырга? Шундый чакта бәләкәй чана тартып әрәмәгә утынга китәсен, якындагы эскерткә саламга китәсен. Монда шулай ук—без.

Апалар, әйткәнемчә, кыш житү белән—амбарда. Ашлык жилгәрәләр, капчык төйиләр, элеваторга ашлык озаталар. Язга чаклы шулай. Ашлык тулысынча сугылып, жилгәрелеп, озатылып беткәнче—көн-төн эштә. Өй хәлләре турында ул бездән ишетеп кенә белә. Менә бер заман сугу, жилгәрү, озату эшләре тәмам була. Амбарлар буп-буш. Анда күпмедер чәчүлек өчен калдырыла. Колхозчыга бер грамм бирелми. Әледән-әле районнан вәкил килә, комиссия килә—карап, тикшереп кенә торалар: ашлыкны әрәм-шәрәм итмиләрме, әрәм тамакларга урлап ашлыкны таратып ятмыйлармы ?... Алай-болай берәр йомшак күнелле председатель үз халкына хезмәт көне башыннан, әйтик, йөз грамм, йөз илле грамм әремле арыш яисә бурсыган бодай тарата икән, мондый жинаять турында икенче көнне үк районга хәбәр барып ирешә. Авылда председательнен якын дуслары житәрлек. Һәртөрле шымчыларнын, озын колакларнын да, Аллага шөкер, бетеп торганы юк. Икенче көнне милиция-фәлән килеп төшә дә, гуманист председательне алып та китәләр.

Район гадәттә фәлән вакытка фәлән тонна ашлык тутырам дип йөкләмә ала. Ләкин ул аны вакытында үти алмый. Шул чакта инде хәллерәк колхозларга өстәмә план килеп төшә. Шулай да, каян алып түләргә өстәмә планны? "Карале, синен бит анда фәлән тонна сайлап куйган арышын, бодаен бар лабаса!", яисә "Сугылмаган өч-дүрт кибәнен шул көе". Ләкин ул чәчүлеккә дип калдырылган. Рөхсәт белән. Иптәш Галиев рөхсәте белән. Шуннан иптәш Галиевкә шалтыраталар. " Район планны тутырырга тиеш!"—ди иптәш Галиев (артык кызмыйча ).

Берни эшләп булмый. Янавылга янадан олаулар агыла. Бу юлы инде амбарлар чып-чын мәгънәсендә бушап кала.

Язга чыккач, янадан мәхшәр башлана. Апалар капчык күтәреп, бәләкәй чана тартып Янавылга элеваторга китәләр. "Хөкемәт" безнен колхозга рәхим-шәфкать күрсәткән—үтичкә орлык биреп тора икән. Көз көне бише белән түләргә. Биргән чагында, бар чагында тизрәк алып калырга кирәк.

Чәчү вакыты житкәч, тагын кайгы—атларнын сабан тарту түгел, үзләрен күтәреп торырлык та хәлләре юк. Аларга лапас түбәсендә яткан иске саламны ашаталар. Ләкин жир өстендә ат авызына эләгерлек үлән чыкмыйча торып, аларга барыбер хәл керми. Жирне сыер белән сөрәләр. Сукага һәр хужалык үз сыерын алып чыга. Кайбер жирләрдә кешеләр үзләре сабанга жигелеп тарта икән дигән сүзләр дә ишетелгәләде. Шулай да безнен якта андый нәрсә булмады.

Мал өчен дә, кеше өчен дә ин авыры—язгы айлар. Көздән әзерләп куйган әзме-күпме бәрәнге дә, он да, ярма да бетә. Печән юк. Жир өстенә әле чыгып булмый—бата. Урманда шулай ук берни юк. Тирә-як бераз кипшерү белән, кеше иске бәрәнге жирендә казына башлый, кыштан калган башакны жыя. Ләкин кар астында калып язга чыккан башакта кеше өчен зарарлы матдә барлыкка килә икән. Монарчы кеше андый фәнни ачыш ясамаган булгандыр. Сугыш елларында кышлаган башак орлыгы ашап үлүчеләр булды. Шундый башакны жыймаска,

ашамаска кушкан өндәмәләр чыкты. Андый өндәмәләрне клуб, контора, магазин ишекләренә, коймаларга ябыштырдылар.

Черек бәрәңгедән үлүчеләр булмады. Киресенчә, черек бәрәңге ул елларда бик күпләрнең җанын саклап калды. Черек бәрәңгедән соң яшел үлән чоры башлана. Уйсу җирләрдә, чишмә, елга буйларында камышсыман яшь кыяклар чыга. Бераздан кузгалак, какы, юа күренә башлый. Шулай итеп, ялганып китәсең.

Ашлык өлгергән чак—үзе бер бәйрәм. Арышны яшькелт килеш уып, олашага җәеп салалар да, мунча ягып, мунчада киптерәләр. Кипкән ашлыкны киледә төяләр. Ярма сыман нәрсә барлыкка килә. Ничек телисең, шулай аша. Тик ашлыкны чи килеш ашарга гына кушмыйлар—күбенеп үләрсең, диләр. Колашада ашлык киптерү турында шулай да шаулап йөрергә ярамый. Берәрсе барып чакса, бетте баш. Ул елларда бер кесә арыш, борчак өчен дә өчәр ел, бишәр-алтышар елга утыртып куйдылар. Ни генә булмасын, урак өсте житү белән ярым үлек кешегә җан керә. Колхоз фәлән грамм ашарга бирсә, кеше икеләтә-өчләтә тырышып эшли башлый.

Безнең өйдә иң тырышы, иң тынгысызы яшәби булды. Ул бер көн колхоз эшеннән калмады. Кая кушалар—шунда бара. Мин аның чирләп, салгашып ятканын, эштән баш тартып калганын хәтерләмим. Җәйле-көзле ул барлык халык белән бергә—кырда-басуда эшли, кышка керү белән йә фермада мал-туар карый, йә ашлык җилгәрүдә катнаша. Шулай да андый авыр эшләргә яшьләр—апалар, апа ишеләр йөри. Яшәби контор тирәсенә, клубка җыелышларга барырга ярата. Бик кыен чакларда әле берәрсенә барып, ялынып, йөз суын түгеп берәр бидерә бәрәңге, берәр кило чамасы он алып кайта. Еш кына ул капчык күтәреп иртән иртүк басуга китә. Кыш дип тормый, яз дип тормый. Кыш көне ындыр табагы урынында көздән калган кибәк өемнәре була. Машина иләге алып барып, яшәби шул кибәк өемен янадан иләп чыга, җилгәрә һәм күпмедер ярым ач, ярым тук солы, карабодай бөртекләре күтәреп кайта да, шул ук көнне диярлек тегермәнгә бара. Шәһәрдә хәзер карабодай боткасы дисәң үлеп китәләр. Минем аңа әз генә дә исем китми. Минем авыздан әле дә яртысы кибәктән торган карабодай күмәче тәме килә сыман.

Бер көнне яшәби теге очтан бик сөенеп кайткан. Кемнәрдер элмә ашыйлар икән. Шундук бу җыенды да, Көек-җылга әрәмәсенә элмәгә китте. Язгы пычрак чак. Басуга аяк басарлык та түгел. Күп итеп элмә алып кайткан бу. Элмә ул караманың бер төре. Тик аның кабыгы караманыкына караганда йомшаграк була. Аны гадәттә яшь малга—бәрәннәргә ашаталар. Без дә элмә кабыгын, чистартып, тураклап казанга салдык. Бик озак кайнаттык. Өметләнеп көтәбез тәмле элмә боткасын. Ләкин аксыл лайлалы ботканы авызга алырлык түгел. Шулай да, башкалар ашагач, ашадык без дә. Эч тулды. Бары тамак кына туймады.

Авылда җәй көне, көз көне күңеллерәк. Урманда, болында, басуда ялманырга ни дә булса табып була. Колхозда эшләгән кешегә әзме-күпме паегы була. Дәүләткә ашлык тапшыру яхшы барганда, тапшырылганның унбиш процентын колхозчыга бүлеп бирәләр. Урак вакытында эшләгән хезмәт көненә, шулай итеп, күпмедер ашлык алырга була.

Ләкин Яңавылда эшләр бик кыен. Яңавыл колхоз да түгел, шәһәр дә түгел—ялманырга җире-басуы да юк, шәһәрдәге кебек ныклы тәртибе дә юк. Шулай да эшләгән кешегә анда әзме-күпме паек бирәләр. Бер елны нишләптер паек инәкәйгә генә бирелде. Соныннан инәкәй сөйләде: буфетчы хатын, имеш, минем паекны үзенә алып барган. Эшләгән бер кешегә өч йөз грамм пешкән эпи була ул паек дигән нәрсә. Эшләмәгән кешегә—йөз илле грамм. Мине шул йөз илле граммнан да мәхрүм иттеләр. Инәкәйгә бирелгән шул өч йөз граммны икегә бүләбез дә көненә ике мәртәбә аш пешерәбез. Шуңа чөгендер яфрагы салабыз.

Кырык беренченең көзендә, ахрысы, безнең күршедә генә, кысан, караңгы бүлмәдә Ленинградтан килгән карт укытучылар торды. Өй янындагы уч төбедәй түтәлгә алар чөгендер түгел, кәбестә утыртканнар иде. Ак сакаллы физика укытучысы көн дә тәлинкәгә салып, бер зур кәбестә яфрагы алып керә. Шул чагында мине очратса, унайсызланган сыман елмаеп, ”витамин, польза“ дип сөйләнеп ала. Мин әле ул вакытта “витамин”ның, “польза”ның нәрсә икәнен дә белмим. Мин бары тамак туйдырырга кирәклеген генә беләм.

Янавылның Эткенәвыл ягында, калкулыкта, басу уртасында ит комбинаты бар иде. Анда төрле яктан куалап мал китерәләр, көне-төне дигәндәй сугым суялар. Янавылның иң бәхетле кешеләре шунда эшли. Бер язны, кырык өчтә, ахрысы, безнең белән бер бүлмәдә торучы хатыннар—балалары белән Казан ягыннан килеп чыккан Майшәкәрләр каяндыр ишетеп кайтканнар: суелган малның калдык-постыгын туп-туры шунда чокырга, киртә буена чыгарып ташлыйлар икән. Икенче көнне киттеләр болар капчык күтәреп ит комбинатының чүплегенә. Инәкәй дә китте болар белән. Күп кенә койрык, колак ише нәрсәләр күтәреп кайттылар. Яхшылап югач, көйдергәч, озак кына кайнатып пешергәч, патшаларга да тәтеми торган менә дигән аш булды.

## 25. Ялгызнарат

Мин сигездә, тугызда укыганда безнең хәлләр аеруча авыр булды. Читтән кеше килеп тулу сәбәпле, торак ягы чиктән тыш кыен. Тамак ягы аннан да кыенрак. Бер елны, мин тугызга күчкәч, ахрысы, инәкәй мәктәптән балалар бакчасына күчте. Монда аның хәле әзме-күпме жиңеләйде, ләкин минеке тагын да авырлашты. Балалар бакчасының үз эшчесе торырга аерым бүлмәсе юк. Инәкәйгә кухняның бер почмагын бирәләр, дөресрәге, шунда йокларсың дип рөхсәт итәләр. Шул ук кухняда тагын Польшадан качып килгән поляк татар хатыны тора. Аның Жәжебикә дигән кызы бар. Олырак малаена урын юк. Ул кайдадыр, кемдәдер тора. Мин дә шундый хәлдә калдым. Көндезге вакытым мәктәптә үтә. Укудан чыккач, качып-посып кына кухняга керәм дә, берәр почмакка, өстәл кырыена утырып, калдык-постык ашыйм. Шуннан соң начальство күргәнче дип тизрәк чыгып китәм. Кичкә кадәр йә базарда, ыстансыда йөрим яисә “Сталин клубы”ның китапханәсенә кереп утырам. Анда, газета-журнал укыйм, китап укыйм. Кухняга бары кунарга гына кайтам. Ул вакытта тәрәзә янындагы өстәл бушап калган була. Бер башында мин дәрес хәзерлим, икенче башында Жәжебикә утыра. Нидер яза-сыза, рәсем ясый. Шунда ук юан гына поляк татары утыра. Ул татарча белми, урысчасы да такы-токы. Ләкин “бисмилла” итә дә, әледән-әле уфтана, көрсенә. Үзенең Польшада торып калган өен, хужалыгын, байлыгын сөйли. Инәкәй белән алар бик дус яшәделәр. Инәкәй соңыннан сөйләде: ул хатынның исеме дә татарча булган—әллә Әминә, әллә Мәдинә—хәзер инде онытылган. Икәүләп алар догалар укыйлар икән. Ул вакытта мин нишләптер инәкәйнең сүзенә ышанып житмәдем. Каян килеп Польшада татар булсын?! Күп еллар үткәч кенә мин чыннан да анда Алтын Урда чорыннан калган татарлар яшәвен белдем.

Шул кышны Шамил абый Дускаев мине Янавыл МТСының партком секретаре белән таныштырды. Секретарьнең исеме-фамилиясе хәтердә калмаган. Бик ягымлы, ачык чырайлы хатын иде. Шамил абый безнең география укытучысы. Зур гәүдәле, жилсенгән битле. Бик тиз кызып китә, йөргәндә ничектер як-якка чайкалып, ава-түнә йөри. Болай үзе бик яхшы күңелле. Мине ул аеруча якын күрде. Никтер армиягә алынмаган. Нindидер авыруы бар бугай.

МТСка стена газетасы чыгарырга, төрле лозунглар-фәләннәр язарга кирәк икән. Мина шуны тәкъдим иттеләр. Мин бик теләп риза булдым. Эшләгән өчен нәрсә дә булса түләү турында сүз булмады. Шулай да әйтеп куйдылар: яз көне берәр бригадага учетчик итеп жибәрербез, диделәр.

Ул елларда авылда иң бай кеше—тракторчы, комбайнчы. Трактор бригадасының учетчигына да тракторчыга түләгән кебек түлиләр: бер хезмәт көненә өч кило ашлык. Колхоз дәүләткә түләп бетергәч тә, эшләгән өчен МТСка, тракторчыларга түләргә тиеш. Түләү мәжбүри. Трактор бригадасында эшләгән кешенең хезмәт көне беркайчан жилгә очмый.

1945 елның кышы шулай күңелле яңалыклар белән узып китте. Менә яз житте. МТСтан авылларга трактор бригадалары кузгала башлады. Мине Ялгызнаратта эшләячәк унберенче бригадага учетчик итеп билгеләделәр. Бу вакытта әле мәктәптә уку бара. Укуны ташларга туры килер микәнни? Директор да, укытучылар да минем хәлне бик яхшы аңлыйлар, белгеле. Трактор бригадасына эшкә китүгә беркем каршы килмәде. Күрәсең, барысын да Шамил абый жайлагандыр инде. Укуны ташлау булмас, имтихан тапшырырга кайтырсың, диделәр.

Шулай бер көнне иртүк тордым да, инәкәй юлга дип пешергән өч-дүрт бәрәңгене куенга кыстырдым да, Ялгызнарат авылына китеп бардым. Тракторлар, кешеләр инде шунда булырга тиеш. Минем әле аларны да, Ялгызнарат авылын да күргәнем юк. Ялгызнарат Яңавылдан унике-унөч чакрым көньякта, Борай, Уфа ягында. Анда туп-туры таш юл бара. Яңавылдан чыгып бераз юл киткәч, сул якта, таш юлдан берике чакрым читтә Эткенәвыл күренеп кала, аннан соң тагын да бераз юл киткәч, Шудымари дигән мари авылы күренә. Шуннан соң инде туп-туры Ялгызнаратка барасың да керәсең.

Язгы көн җылы. Аяк астында җепшек кар лычкылдый, чана табаны эзләреннән су ага. Зәп-зәңгәр күктә аксыл болытлар йөзә. Кары эреп бетмәгән язгы басулар җылыда, яктыда тын гына оеп яталар. Ара-тирә баш очыннан каргалар очып үтә. Юлда беркем юк—каршыга да, арттан да беркемнең килгәне күренми. Әкияттәге кебек тынлык, әкияттәге кебек япа-ялан. Ерак офыкларга карап, тәэсирләнеп-хозурланып, лач-лоч атлап, юл уртасыннан бер үсмер малай бара. Өстендә яшкелт кыска сырма. Солдат сырмасы. Галифе чалбар. Шулай ук солдат чалбары. Аягында калын табанлы ботинка, билендә киң каеш. Солдат каешы. Башында ясалма мехлы иске бүрек. Нечкә муенын яшел солдат гимнастерка якасы урап алган. Барысы да солдатча. Бары маңгаенда йолдызы гына юк. Бәләкәйрәк булса, бәлки, бүрегенә йолдыз да кадап куяр иде. Ул чакта иң яхшы, иң "модный" кием—солдатча киенү. Солдатның иске-москысын алып киенмәсәң, ул чакта анның рәтле киеме дә юк.

Үзалдына елмаеп күккә, җиргә—бөтен тирә-якка сокланып баручы чандыр "солдат " ул—мин. Галифе чалбар зур, салынып төшкән кесәләре җилфердәп бара. Бил каешы иң соңгы тишегенә кадәр тартып каптырылган. Күзләр як-якка карана, күңелдә бер генә уй—пешкән бәрәңге. Күптән инде суынып өлгергән, шикәрләнгән шул бәрәңге тәмен мин әле дә тел очында тоям кебек.

Төштән соң икеләрдә-өчләрдә барып җиттем Ялгызнаратка. Таш юл авыл уртасыннан үтә. Як-якта өйләр. Берән-сәрән кешеләр күренә. Абзар янында, кояшта сыерлар күшәп тора, кош-корт тавышлары ишетелгәли. Иң элек колхоз конторасын эзләп таптым. Барып кердем дә, үземнең кемлегемне әйттем. Мине тракторчылар фатирына өйрәтеп җибәрделәр. Бардым. Бер ишегалда ике йорт. Йортның берсе бер якта, икенчесе икенче якта. Уртада бары киртә генә юк. Берсендә ялгыз карчык тора, икенчесендә—аның яшь, чибәр килене. Ике кызчыгы бар. Кортканың улы сугышка киткән. Тракторчылар кортка өендә. Йөзе бик үк ачылмый торган, кырысрак-төксерәк һәм шактый тулы гәүдәле бу кортка нишләптер мине бик үк яратмады. Бәлки миңа гына шулай тоелгандыр, бәлки, анның гомумән холкы шундый булгандыр. Ни генә булмасын, анның килене безгә карата ягымлырак булды.

Өе әллә ни зур да түгел. Шунда без алты кеше торабыз. Безнең бригадада тәгәрмәчле ике трактор, СТЗ--ХТЗ. Дүрт тракторчы, бригадир һәм мин. Безнең унберенче бригада комсомол-яшьләр бригадасы дип атала. Безгә көн саен диярлек "Комсомольская правда" килә. Мин газета укып, тракторчыларның белемен арттырырга—аларга политинформация ясарга тиеш. Аннан соң минем, әлбәттә, үземнең төп эшем дә җитәрлек. Ягулык склады тулысынча минем карамакта.

Трактор бакларына мин керосин, бензин салам, кирәк чакта басуга автол, нигрол, солидол алып барам. Смена башланыр алдыннан һәм смена беткәч, һәркемнең багындагы керосинын үлчим, күпме ягулык бетүен исәплим. Һәркемнең сөрелгән, тырмалган, чәчелгән җирен үлчәп барам. Гектар исәбен чыгарып, биш көнгә аерым кәгазь тутырып, МТСка бухгалтериягә отчет илтеп тапшырам. Отчет кәгазенә, эшләгән эш белән бергә, тотылган ягулык, үтәлгән процент һәм тиешле хезмәт көне теркәлә. Минем үз атым, арбам бар.

Тракторчыларның икесе кыз кеше, икесе җегет кеше. Кызларның берсе—Мамилә, икенчесе С... онытканмын. Җегетләрнең берсе Фәсиз, икенчесе—Муллаян. Алар белән мин беренче көнне үк уртак тел таптым. Без гомумән дус-тату яшәдек.

Бригадирыбыз хатын-кыз. Башкалардан өлкәнрәк. Бите шадра. Исеме онытылган. Бары кайбер гадәтләре генә истә калган. Никтер ул кычкырынырга ярата. Юк кына нәрсә өчен дә кызарынып-бүртенеп тиргәшергә тотына. Ул елларда әзме-күпме башрак булган һәркем кычкыра. Колхоз председателе Гайнетдинова кычкыра, колхоз бригадирлары кычкыра. Фермада кычкыралар, амбарда кычкыралар. МТС

директоры Гончаренко шулай ук эшчеләргә кычкырырга ярата. Кино карасаң, анда шулай ук акырыш та бакырыш. Сугышта "Ура" кычкыралар икән, ансы тәбигый. Ләкин гап-гади көндәлек эштә гап-гади кешеләр бер-берсенә кычкыралар, палатага килеп кергән профессор авыруларга кычкыра, ир белән хатын бер-берсенә кычкыра. Кинода бары иптәш Сталин гына тыныч, салмак сөйли. Ни әйтсән дә ил атасына кычкыру килешми. Мин дә бер заман ата булдым. Ләкин, дөресен әйтим, кычкырган чакларым күп булды. Тәрбиясезлек, тотнаксызлык, күрәсең, безгә менә шул чаклардан йогып калган.

Ялгызнаратның колхоз председателе районда иң алдынгылардан санала. Ире якындагы бер авылда—Каймашада, ахрысы, шулай ук председатель, малае да кайдадыр колхоз председателе. Кызы белән үзе монда Ялгызнаратта бер хатында фатирда тора. Яхшы атка гына утырып йөри. Башында күн бүрек, аягында галошлы кара итек. Инбашында калын сумка. Бригадирлар сумкасы. Тавышы көр. Бер кычкырып җибәрсә, ирләр дә шып була. Карышу юк, сүз көрәштерү юк. Иптәш Гайнетдинова шулай дип әйтте, иптәш Гайнетдинова болай дип әйтте—- авызына гына карап торалар.

Анын фатир хуҗасы—бик чибәр һәм бик тәмле телле яшьрәк хатын еш кына минем амбарга килә. Килгән саен кулында яшел чәйгүн. Ул сорап та, үтенеп тә тормый, ничектер бик тә ягымлы итеп, эретеп бер-ике сүз генә әйтә. Мин аңа берсүзсез кәрәчин агызып бирәм. Алай эшләргә ярамаганлыгын бик яхшы аңлыйм, чөнки кәрәчиннең һәр литры исәптә. Ләкин ялагай, ягымлы, чибәр хатынның теләгенә каршы берни эшли алмыйм.

Басуга эшкә чыгу белән, минем өчен киеренке тормыш башланды. Иртә таннан караңгы төшкәнче мин—басуда, тракторлар янында. Йомшак җиргә бата-чума җир үлчим, берәр йомыш белән тиз генә авылга барып киләм. Бөтен бригада белән торам, бөтенесе белән ятам. Башны мендәргә төртү белән, шундук йокыга чумасың. Кайчагында юлда, басуда йоклап китәсең. Бигрәк тә Янавыл белән Ялгызнарат арасында йоклата. Арбада җинелчә тирбәлеп барганда сизми дә каласың. Бер заман күзеңне ачып карадың исә, ат адымын бөтенләй әкренәйткән яисә юл читенә чыгып үлән чемченә башлаган була.

Янавылга кайткач, мин инәкәй янына кереп чыгам. Имтиханнар тапшыру вакыты җиткәч, ешрак керергә, озаграк торырга туры килә. Имтиханнарның берсенә дә мин әзерләнә алмадым. "Бишле"не миңа болай гына куйдылар. Немец теле укытучысы " болай гына" куясы итмәде, ахрысы. Алдан ук ул миңа ныклап әзерләнергә кушты. Мин үзем дә аңлыйм—немец теле иң авыры. Чит телдән курку, күрәсең, безнең канга сеңгән. Чит телдән курку ул тел хуҗасыннан куркуга кайтып кала. Без, билгеле, немецтән хәзер курыкмыйбыз. Безнекеләр көн-төн хәзер аның үзен тукмыйлар. Укыганда без еш кына: "Нигә кирәк ул безгә немец теле?!" дип кычкырынырга тотынабыз. Андый чакта укытучы: "Дошманны җиңү өчен аның телен яхшы белергә кирәк",—дип җавап бирә.

Эш арасында мин бары шул немец теленнән генә әзерләнгәнсыман иттем. Буш вакыт булдымы, дәреслекне ачам да, һич хәтердә калмый торган килеш төрләрен ятларга тотынам. Ярты бит чамасы укыйм да, йокыга китәм. Ялгызнаратта Гайсина дигән укытучы бар иде. Кемдер әйтте, аның олы кызы Мәскәүдә ниндидер институтта укый имеш. Немец телен шул кыз бик шәп белә икән. Имтиханга әзерләнергә булышмас микән дип күреп сорадым мин моннан. Булышырмын, диде. Нишләп ул җәй башында авылга кайткандыр, әйтә алмыйм. Ул елларда институтларда уку иртәрәк бетте микән әллә? Бәлки, берәр ничек итеп ялга гына кайткан булгандыр. Бер-ике мәртәбә, эштән соң, кич белән бардым мин аларга немец теле дәреслеге тотып. Нәрсәдер өйрәнеп тә азапландым бугай. Ләкин кайдадыр Мәскәүдә укый торган чибәр кызның күпереп торган кара чәче, ак чибәр йөзе генә күз алдында калган. Гайсиннар гомумән бик чибәр заттан иде. Ул кызны соңыннан беркайчан күрмәдем—Мәскәүдә үзе белән укыган бер грек егетенә кияүгә чыккан дип ишеттем. Сеңлесе Люция, ахрысы, аннан да чибәррәк иде. Мин университетта укыганда бер-ике елдан ул да география факультетына керде. Бер-ике мәртәбә мин аның янына барып та йөрдем бугай. Ләкин гашыйк булырга батырчылык, йөрәк җитмәде. Чиктән тыш гүзәл, чибәр иде Люция.

Ленинградтан килгән немец теле укытучысы мина дүртле куйды. Куйса куйгандыр инде, әлләни исем китмәде. Унынчыга исән-имин күчтем, мина шул житкән.

Ялгызнаратта мин көзгә кадәр эшләдем. Бер көнне бричкага ике ат жигеп, бишалты капчык он, ашлык төяп, Янавылга кайтып киттем. Нинди бәхетле, нинди горур идем мин ул чакта! Берүзен бер йөк ашлык алып кайт әле—кем булдыра ала андый эшне?! Кайтып керүгә иң элек ишегалды балалары йөгерешеп килде. Элек тә ат белән кайткан саен мине еракта ук балалар көтеп алалар иде. Алар шаулашып-кычкырышып мина капка ачалар, капкадан кергәч тә, атны туктатып мин аларны арбага утыртам. Андый чакта балаларнын куанычы эчләренә сыймый! Бу юлы да, ишегалга килеп керү белән, барысы да арбага ябырылды. Гайшә апанын өч-дүрт яшьлек Илгизе капчык өстенә үк менеп утырган. Ат кузгалып китү белән нишләптер бу егылып калды. Ярый әле атларны туктатып өлгердем—беткән иде Илгиз. Авыр тәгәрмәч Илгизнен өстеннән генә чыгып киткән булыр иде.

Минем баеп кайтуга ул инәкәй сөенде, ул күршеләр сөенде! Икенче көнне Янтыктан Яшәби килеп житкән. Ул елны алар бик бетеренгәннәр, шешенгәннәр. Соныннан инәкәй сөйләде: син баеп кайткач, бөтен күрше туйды, диде. Яшәбиләргә, Уразы чибәрттәйләргә дә ашлыкны инәкәй потлап-потлап кына биргән. Күпмесендер үзебездә калдырган... Ләкин ансын да теге Казан ягыннан килгән Майшәкәрләр урлап-турлап бетергәннәр. Ул чакта без алар белән һаман бергә тора идек бугай.

Сугыш бетү турындагы хәбәрне мин Ялгызнаратта ишеттем. Кояшлы матур көн. Нindидер йомыш белән конторга килдем. Ишектән каршыга бригадир чыгып килә. Бүтән вакытта ул гел ачулы була, һәрвакыт кемгәдер, нигәдер ачуланып, тузынып йөри. Бүген нишләптер елмаеп чыгып килә бу. Күрде дә мине, иң якын дустына сер сөйләгән кебек "Сугыш беткән !"—диде.

Мондый хәбәр ишеткәч, мина күнелсез булып китте. Ничек инде беткән? Мөмкин түгел! Сугышнын сонгы елында без бары куанычлы хәбәрләр белән яшәдек. Безнекеләр көн дә алга баралар, әле бер шәһәрне алалар, әле икенчесен алалар. Көн дә жиңү, көн дә тантана. Минем шатлык баштан ашкан. Бәлки, башкалар алай ук шатланмаганнардыр. Ләкин минем аларда эшем юк. Сугыш беткән, димәк, моннан сон жиңүләр дә, тантаналар да булмаячак.

Беренче тәэсир шулайрак булды. Бу беренче тәэсирдән мин бик акрынлап арындым. Әйе, сугыш бетте, без жиңдек, ләкин жиңү куанычы барыбер тиз генә килмәде. Ачлы-туклы, ярлы тормыш элеккечә дәвам итте. Бик озак дәвам итте. Жиңү турындагы хәбәре белән, язгы басулары, яшел ужымнары һәм кара киемле тракторчылары белән Ялгызнарат минем күнелдә мәнге уелып калды. Ялгызнарат тагын башка яклары белән дә бик нык истә калды. Самавыр төбендә генә утыра торган теге ялгыз кортка безне чынлап та яратмады, ахрысы. Жәй урталарында без икенче фатирга чыктык. Фатир хужасынын исеме хәтердә яхшы калган—Шәргыя. Чепи күзле, бик үк әдәпле, бик үк чиста булмаган бер хатын шунда. Көннәрдән бер көнне мине эзләп Яшәби килеп төште. Егерме-утыз чакрым жирне жәяү килгән. Сине күрергә килдем дигән булды. Минем эшләп йөрүемә сөенгән булды. Чынында исә мине күрергә генә килмәгән. Ул, күрәсен, минем берәр ничек булышуымны өмет иткәндер. Мин ничек булыша алам инде ана? Мин үзем бәндәгә бәндә. Колхозның әле үзенә дә берние юк—ашлык өлгермәгән.

Ялгызнараттан Яшәби бик нык хәтере калып, җылап кайтып китте. Соныннан сөйләде—Шәргыя аны бик тупас каршылаган, өстәл янына да чакырмаган, төнгә урын да жәеп бирмәгән. Ул шунда кайдадыр чоланда, кеше аяк астына ятып йоклаган. Яшь чакларында алар нишләптер таныш булганнар. Шәргыя безнең якка килен булып төшмәде микән? Әллә сон ул үзе безнең Янтык ягы кызы булды микән? Ни генә булмасын, Яшәби белән алар элекке танышлар икән. Танышлар, якыннар, хәтта туганнар кайчагында шулай бер-берсенә карата гамьсез, кансыз булалар.

Ул елларда инәкәй дә шуна охшаш хәлгә юлыга. Бу хәлнен дә бер очы янә Ялгызнаратка килеп кагыла. Мин Казанга укырга киткәч, ахрысы, ул Күчтәвылда урак урырга яллана. Ул елларда ашлык бик уныш, колхозның исә үз көче белән генә ерып чыгарлык хәле булмаганда, читтән уракчылар яллый башлаганнар иде. Ялланып уручы колхоз житәкчеләре белән алдан ук килешеп куя. Колхоз гектарына фәлән пот түләргә сүз бирә. Арышның гектарына, гадәттә, бер-ике, кайчагында өч

пот түләнә Арыш урагына төшү белән, Янавылның ач халкы якын-тирә авылларга эш эзләп китә. Безнең шулай Пермь өлкәсе ягына, урыс авылларына эш эзләп чыкканыбыз булгалады. Бер елны инәкәйләр белән Тукаш дигән урыс авылында арыш урдык.

Мин Казанда чагында инәкәй, үземнең килен булып төшкән авылым дип якынга, Күчтәвылга гына бара. Председатель моны якты йөз белән каршылый, күпмедер онга язу бирә дә үзе басуга алып барып уракка куша. Фатирга инәкәй үзенең бианасы, үги кызлары торып яткан элекке үз өенә урнаша. Кайнанасы белән алар бик тиз уртак тел табалар, жылый-жылый элекккеләрне искә төшерәләр. Ләкин үги кызларның һич кенә дә йөзләре ачылмый. Болар мона казан астына ягып умач пешереп ашарга да рөхсәт итми башлыйлар. Утынны бетерәсең, суны бетерәсең дип үги аналарын өтеп кенә торалар. Бу елларда алар инде үсеп буйга житкән була. Беркемнән курыкмый торган батыр чаклары. Килмешәк булып, теләнче булып килгән үги анадан куркып торыргамы соң?! Юк инде, булмас! Безнең инәй Күчтәвылда торып калырга, өйне үзенә алырга кайткан дип уйлыйлар болар. Шуннан, көннәрдән бер көнне, турыдан-туры шул турыда әйтеп, өйдән куалап чыгаралар. Инәкәй нишләсен—чыгып китә иске-москы төенчекләрен күтәреп. Барып керә үзенең күптәнге танышларына, Фатих бабайларга. Анда моны ачык йөз белән каршылыйлар. Шулай да Күчтәвылда моның юлы уңмый. Бер көнне ул, эшен ташлап, үзе кебек бер хатын белән Ялгызнаратка китеп бара. Анда да арыш урагына яллана. Көзгә кадәр эшли. Ана шактый күп ашлык тиясе була. Урак беткәч, колхоз бухгалтеры әйтә: "Салиха апа, озакламый председатель алышыначак, аласы ашлыгынны алып кал"—ди. Яңа председатель яллануларга карата ничек булыр—беркем белми. Яллаңып урган кешеләргә биреләсе ашлыкны бухгалтериядә законлаштыру өчен сатып биргән итеп язалар. Яллау-коллау безнең алдынгы социализм илендә катгый рәвештә тыела!

Бухгалтер инәкәйгә тиз арада йөз илле сум акча табып китерергә куша. Акча сорап инәкәй Күчтәвылдан килен булып төшкән Мәгъзниягә бара. Шундый-шундый хәлләр, ди, бер-ике көннән китереп бирермен, ди. "Бетмәс монда хәерчеләр!" дип, Күчтәвыл килене инәкәйне тиргәп чыгара. "Үзе мичтән яңа эпи чыгарган. Тезеп куйган. Башларым әйләнеп китте", дияр иде инәкәй шул турыда сөйләгәндә.

Менә шул. Йөз илле сум акчаны таба алмый инәкәй Ялгызнаратта. Алай итә, болай итә дә, берни барып чыкмагач, Янавылга кайтып китә. Бер-ике көннән йөз илле сум күтәреп килә бу, ләкин ул вакытта инде председатель алышынып өлгергән була. Яңа председатель элекке председатель өчен, имеш, җавап бирә алмый. Җәй буе ачлы-туклы бил бөгеп эшләгән кешеләрнең күбесе шулай авызларын ачалар да калалар.

Бу турыда инәкәй әледән-әле сөйләде. Үлгәнче сөйләде. Ялгызнаратта алынмый калган арышларымны төшләремдә күрәм, диде.

Ин ахырда үги кызлар—Фәүзия белән Нәкыйбә турында да бер-ике сүз теркәп калдырасы килә. Олысы—Фәүзия дигәне гомер буе саран булды, гомер буе акча җыйды. Ничәнчедер елны Күчтәвылны ташлап бу Карманга күченә, элеваторга эшкә керә. Шунда кияүгә чыга, аннан Янавылда болар өй алып керәләр. Янавылда сыер тотты, сыерының һәр тамчы сөтен акчага әйләндерергә тырышты. Бу вакытта мин Казанда укыйм, кайтканда-киткәндә моны базар тирәсендә очраштырам. Бервакыт бу үзләренә чакыра башлады. Кермисен, онытгың, безне туган итмисен, фәлән-төгән, ди. Бик кыстагач, мин кергәли башладым. Яңадан туганлашып киттек моның белән.

Сөт-катык сату белән генә канәгатьләнмичә, өй белән дә булаша башлады бу. Күпмедер файда калдырып, иске өен сатты да, яңаны алды, аныснн да сатып, ахырда Нефтекамскига күченеп киттеләр болар. Ире эчте, шуның аркасында китеп тә барды. Начар ашау аркасында үпкә чире белән чирләп, олы кызы да дөнья куйды. Гомер буе бармак арасыннан сыгып җыйган малының, инәкәй әйтмешли, игелеге булмады: газ плитәсеннән ут чыгып, шартлап, бөтен өе янып бетә дә, бер заман бу коры таякка кала. Алай да пыяла банка эченә салып куйган саклык кенәгәсе исән кала. Тиенләп җыйган акчасы, имеш, җиде мең булган.

Нәкыйбә Колмак авылына кияүгә чыкты, аллә җиде, аллә сигез малае булды.

Ире исерек килеш машинасы белән авып һәлак булды. Балалары төрлесе-төрле якка таралашып беттеләр. Нәкыйбә берүзе бер өйдә торды да калды. Соңыннан Фәүзия дә, Нәкыйбә дә, аларның балалары да инәкәй янына килеп-китеп йөределәр. Үги булсалар да үз балаларым, диде инәкәй. Өч көннән артык кинә тотарга ярамый дип исәпли иде ул. Алар миңа да килгәләделәр. Казанга. Йомыш белән дә, болай да. Мин дә булдыра алган кадәр ачык йөз күрсәтергә тырыштым. Ләкин бернинди уртак сүз сөйләшеп булмый торган Фәүзия белән дә, Нәкыйбә белән дә әлләни борчак пешмәде. Туган исәпләнелсәләр дә, арада бик зур аерма ята. Хәзергесе турында сөйләшеп, фикер алышып булмый, элеккеләрне искә төшерәсе килми. Аларның күбесенчә русча сөйләшә торган балалары белән шулай ук берничек тә теш агартып булмый. Мин инде инәкәй кебек изге була алмадым. Күрәсең, беркайчан да булып булмас. Аерылу, таркалу, дошманлашу күз алдында бара, адым саен бара, һәр өйдә, гаиләдә бара.

## 26. Пулат. (Сөялгәнсең чатта баганага)

Әткәйнең биш сеңлесе була. Яшь чагында шаяртып, мактанып:" Миннән бай кеше юк. Миннән башка кемнең тагын биш сеңлесе бар?!" дип әйтергә ярата торган булган, имеш. Сеңелләрнең барысы да кияүгә чыгалар—берсе Күчтәвылга, икенче берсе Айбуләккә, өченчесе Гөтбергә, дүртенчесе Пулатка, бишенчесе, иң кечесе—Көеккә. Күчтәвылдагы Майҗиан дигәне әле дә, ягъни 1988 елда да исән. Инде туксанга якынлашып килә бугай. Тимергали абый шуның малае була. Әткәйнең барлык туган-тумачалары белән дә аралашырга ничектер җае булмады. Мин бары Күчтәвыл Тимергали абыйларны яхшы беләм дә, Пулатларны яхшы беләм. Күчтәвылдан, Янтыктан читтәгеләр минем өчен ничектер чиг-ят булып калдылар. Хәер, юк, бик үк алай да түгел. Бәләкәй чакта минем Гөтбергә дә, Айбуләккә, Көеккә дә барганым бар. Беркадәр дәрәҗәдә аларның тормыш хәлләрен дә, балаларын да беләм кебек. Тик шулай да иң якыны—Пулат.

Пулат Янтыктан көнбатышта, өч-дүрт чакрым ераклыкта. Калкулык артында гына. Ушия дигән елгага коя торган бер чишмә буена утырган. Бер урамы калку яр башында, икенче урамы чишмәнең икенче ягында, тигезлектә. Зур түгел, күп булса йөз-йөз илле йорт. Карурман Пулатның ындыр артына килеп терәлә. Чыршы, каен, шомырт, балан. Ушия буенда—болыннар, әрәмәләр. Җире таулы-ташлы. Иген игү өчен рәтле түгел. Кайбер төштә кызыл балчык, кайбер төштә—ком. Елга буендагы, диңгез буендагы кебек. Җәй көне аяк батып тора. Үзе калкулык башында. Миңа еш кына татарның әкият геройлары—шүрәлеләр, дию пәриләре шушы Пулат урманнарында, Ушия буйларында яшәгәндер кебек тоела. Диюләрне алдаган төлке дә нәкъ Пулатта, ындыр артындагы чыршылыкта йөргәндер сыман, күлне күккә асам дип куркыткан батыр малай да кайдадыр шунда Пулат ягында булгандыр кебек. Пулаттан бер-ике чакрым читтәрәк, Ушия елгасында зур тегермән бар иде. Пулат тегермәненә бөтен тирә-як килә торган иде. Урман арасында, су-камыш янында көн-төн шаулап, дөбердәп утырган тегермән миңа кайчандыр дөньяның сихри бер үзәге булып, туклык һәм бәхет чыганагы булып тоела торган иде. Минем "Тегермәндә" дип аталган иң беренче хикәям менә шул Пулат тегермәнен күз алдында тотып язылган.

Безнең әткәй дә яшь чагында Пулат тегермәненә йөргән, инәкәй дә шул якларда булган. Иң элек алар шул якта танышканнар, ахрысы. Инәкәй Күчтәвылга килен булып төшкәч тә Пулат белән ара өзелмәгән. Кемнәрдер аша сөйләшеп-килешеп, әткәй үзенең Гылмехаят исемле сеңлесен Пулатка Билал дигән кешегә кияүгә бирә. Инәкәй килен булып килгәндә, Гылмехаят әле Күчтәвылда була. Әткәйләрнең тынычсыз өендә Гылмехаят яшь Салиханың иң якын сердәше була. Гылмехаят Пулатка кияүгә киткәч тә алар дуслыкларын онытмыйлар—барышып-килешеп торалар. Әткәй үлгәч тә бу дуслык бозылмады. Гылмехаят әткәйнең иң яраткан сеңлесе була. Күрәсең, Гылмехаят тә әткәйне якын иткәндер. Ул аны "абзый" ди, инәкәйне "җиңгәй" ди. Соңыннан ул аларны гел искә алды, бары яхшы яктан гына искә алды.

Билалны Яңавыл ягында белмәгән кеше юк. Аны Хуҗа Насретдин урынына йөртәләр, мәзәк итеп сөйлиләр. Аның әлләни мәзәк эшләре дә юк, ләкин төрле

кызык хәлне еш кына Билалга япсарырга яраталар. Заманына күрә ул укымышлы булган, мәҗлесләрдә берәр кызык сүз әйтеп куйган, көлдергән. Аннан соң аның нииндидер сәер гадәтләре дә булган. Инәкәй сөйли торган иде: бер елны бу алышынып өеннән чыгып китккән, сукасын елгага агызган, имеш. Яшь хатынын ташлап, нишләптер Күчтәвылга килеп чыккан. Әткәй белән инәкәй моны җайлап, үгетләп кире Пулатка кайтарып куйганнар. Нишләптер аны сугышка да алмадылар. Ул шулай ук колхозда да эшләмәде—күбрәк тегерманче, урманчы булды. Хәзер инде мин уйлыйм—колхозга керүдән котылырга теләп йөрмәде микән ул алмашынган кешегә салышып?

Ни генә булмасын, мин белгән Билал җизнәй алмашына торган кеше түгел иде. Эшчән, тырыш, булдыклы. Искечә дә күзе күрә, яңаны да дөрес чамалый. Килгән-киткән кеше белән аралашып яши. Калын тавышлы, шаяртып сөйләшергә ярата. Башка авылдан, Янавылдан аларга кеше еш килә—утынга, агачка, урман чистартырга, печән чабарга. Кайчан барма, Билал җизнәй урманда, болында булыр—диләнкә күрсәтергә киткән йә булмаса анда "болай гына" карап кайтырга киткән. Ишегалды иркен. Мал-туар асрый, корт асрый. Сугыш елларында хәтта ат та тотты бугай әле. Яшереп түгел. Рөхсәт белән. Урманчыларга рөхсәт ителде. Безнен кебек кыш көне кар ерып утынга йөрми—җәйдән әзерләп куелган каен утыны бер кышка түгел, өч кышка җитәрлек.

Янтыкта, Янавылда чакта мин аларга еш бардым. "Кунакка" бардым. Мине, билгеле, чакыручы юк. Барам да керәм күземне тондырып. Әткәйнең сеңлесен мин "әбестәй" дип атыйм. Җизнәй минем килгәнгә әлләни куаныч белдерми, бары әбестәй генә якын күрә. Шулай да аларда күңелле. Аларның дүрт балалары булды. Олы кызлары Мәдәния миннән зуррак, икенче балалары Әхнәф бер-ике яшькә кечерәк. Без күбрәк Әхнәф белән уйныйбыз. Бер кышны магазиннан ана чын коньки алганнар. Минем андыйны төшемдә дә күргәнем юк. Конькиның бер сыңарын мин тагам, икенче сыңарын Әхнәф тага. Шул кышны урамда ат юлында сыңар конькида шуып рәхәтләндем үзем дә!

Аларның тагын Ганс дигән малайлары да бар иде. Нимескә каршы сугыш барган елларда немецчә Гансны Даниска алыштырдылар. Данис соңыннан эчкечелеккә бирелгән, кайдадыр Себер ягында торып калган бугай. Әхнәф хәрби хезмәтне сайлады. Салават шәһәрендә нииндидер заводта янгын командасы начальнигы булды, майор дәрәҗәсенә ирешә һәм гомергә шунда җир читендә төпләнеп калды.

Һибә дигән кече кызлары сугыш елларында туды. Мин белгәндә Әбестәй бик чибәр хатын иде. Уртадан калкурак, җыйнак гәүдә. Ак чырай, йөзе озынчарак. Сызылып торган кара каш, кара чәч. Һибә Әбестәйгә охшаган. Мин аның иң яшь чагын, иң чибәр чагын беләм. Балкып, нур чәчеп торган шомырт кара күзләр, күпереп торган кара чәч, шикәрдәй ап-ак тешләр, алсу иреннәр. Әкиятләрдә сөйләнелә торган пәри кызлары кебек, шигырьләрдә мактала торган сихри гүзәлләр кебек чибәр иде ул. Заманында аны берәр сынчы ташка күчерә алса, минем сеңлем Һибәнең дә сыны-кыяфәте хатын-кыз гүзәллегенең мәңгелек бер үрнәге була алган булыр иде. Минем әткәй кара чәчле, зәңгәр күзле булган. Күрәсең, ул каяндыр икенче бер нәселдән, аның сеңлесе—икенче нәселдән булган. Хәзер инде мин уйлыйм—безнең Әбестәй токымы, күрәсең, борынгы гүзәлләр иленнән килгәндер. Күпме батыр егетләр, күпме чибәр җегетләр күз атмагандыр да, күпме батыр ирләр даулашмагандыр Әбестәйләр, Һибәләр нәселеннән булган сылу кызлар өчен! Борынгы рәссамнәр, сынчылар Атлантида алиһәләрен нәкъ менә безнең Әбестәйләр, Һибәләр нәселеннән булган хатын-кызларга карап ясаганнардыр сыман тоела. Илленче елларда бер кышны Казаннан Янтыкка кайткач, Пулатка киттем. Элеккечә хәл белергә, "кунакка". Барып керсәм, яшь кенә кыз чыпта үреп тора. Дөресрәге, чыпта тасма үрә. Тасманың үрелгән башы ишек янагындагы кадакка эләктерелгән, икенче башы, пумала сыман булып, идәнгә салынып төшкән. Ул елларда безнең якларда "Заготконтора" ни өчендер шундый чыпталар суктыра, киптерелгән тал кабыгы, фәлән-төгән җыя иде. Шуна күпмедер акча бирәләр иде.

Кызның өстендәге киеме әйтеп-сөйләрлек түгел—саләмә дә саләмә, ул да саләмә. Шул саләмәгә юкә чүбе буялып беткән. Идәндә, аяк астында юкә төргәге, үрелгән чыпта тасмалар аунап ята. Тетелеп төшкән киеме аша кызның яшь тәне күренеп тора.

Мин килеп керү белән, мине танып алу белән, каушап калды, елмайган булды. Кызарып, ачык изүенә үрелде. Нindидер өн чыгарды да, мунчаласын ташлап, гөлбәч ягына кереп китте. Бераздан үзенең рәтлерәк күлмәген киеп чыкты, кул биреп, "Нурихан абыкаем" дип исәнләште. Бала вакытында ул мин килгәч таяктай нечкә беләкләре белән, ястык мамыгына баткан пумала башы белән муенга сарыла торган иде.

Икенче көнне ул мине авылдан чыкканчы озатып барды. Көн буранлы иде. Янтыкка кадәр озат дисәм, бер уйламый ияреп барган булыр иде. Озат димәдем. Ул мина бик кызганыч тоелды. Юл буена мин аның язмышы турында уйладым.

Ул елларда теләсә нинди авылда шундый хәлгә юлыгасың. Ачлык, мохтаҗлык бугаздан эләктереп алган да, һич җибәрергә исәбе юк. Сугыш елларында да кытлык күрмәгән Билал өендә дә шундый хәерчелек булгач, башкалар турында әйтәсе дә юк. Берәүләр шулай чыпта суга, икенче берәүләр чабата ясап сата. Кая барма, һаман шул ук тамак кайгысы. Кайберәүләр, авылда рәт булмаячагын күбеп, читкә китеп баралар.

Бер-ике елдан мин тагын бардым Пулатка. Һибә унны бетергән. Элеккегә караганда чибәррәк, элеккегә караганда кыюрак күренде. Ләкин күнелендә һаман нindидер тынычсызлык бар. Менә ул унны бетерде. Буй җиткән кыз. Шәһәргә китеп институтка керергә ул хыялланмый да. Институт ул кемнәрдер башкалар өчен. Аңа табигать кушканча яшәргә кирәк. Кияүгә чыгарга да, үз оясын корып, балалар үстереп кешечә яшәргә кирәк. Җегетләре юктыр дип әйтә алмыйм. Ләкин бернинди киләчәге күренмәгән ач-ялангач авылда ничек итеп оя корырга да, ничек итеп яшәргә кирәк? Кешеләр туктаусыз бер-бер артлы каядыр китәләр. Ашлык хәзер авылда түгел, шәһәрдә үсә. Кайдадыр Себердә, Воркута—Урта Азия якларында. Әхнәф инде күптән Салават шәһәрендә. Һибә шунда китәргәрәк уйлаштыра, ахрысы. Шулай да туган ягын да ташлап китәсе килми бугай. Соныннан ишетеп белдем: киткән ул абыйсы Әхнәф янына. Абыйсы янында, Салават шәһәрендә ул утын складына эшкә кергән, кемгәдер шунда кияүгә чыккан, балалары булган. Башта ул, билгеле, абыйсы, җингәсе янында торган. Кияүгә чыккач, берәрсенең почмагында кысылып-җәберләнеп торгандыр да, бик озак ялынып, кимсенеп йөргәннән соң бер кумытлы квартир алгандыр. Бәлки алар хәзер чын күнелдән бәхетледер. Ире эчеп алкашка әйләнмәгән булса.

Ул бәхетледер. Аның кебек бәхет эзләп бәхеткә ирешә алмаган күпме кызлар—күпме яшь, чибәр кызлар туган авылларын ташлап читкә киттеләр! Кая гына барып чыкмады, нинди генә хәлләргә юлыкмады безнең татар кызлары! Сугыштан сонгы Казанны, йортларны башлыча унҗиде, унсигез яшьлек кызлар салды, юлларны, урамнарны алар төзекләде. Иске Казанның баткак урамнарына асфальт җәю өчен карьердан ташны алар чыгарды, урамда йорт салганда цемент балчыгын алар болгатты, авыр кирпечләрне алар күтәреп ташыдылар. Без университетка укырга барганда, укудан кайтканда түбәсе ябулы грузовикларга төялеп татар кызлары узып китте. Бөтен шәһәрне шаулатып алар "Ай-ли алмагачлары!" дип кычкырып җырлап үттеләр... Безнең бер атаклы фольклорчыбыз хәтта гәзиткә язып чыкты, имеш зәвыксыз кызлар халык иҗатын ярлыландыралар—алар шул "алмагачларын"нан башканы белмиләр дә.

Халык иҗаты бик нык байый—төрләнә башлады. Казан урамнарында татарча җырлау түгел, хәтта татарча сөйләшкән дә ишетелми.

Шул ук илленче елларда Казанга газ керә башлады. Сасы исле битумны кайнатып торбаларны кулдан хатын-кыз буяды. Канауларны, траншеяларны казуда шулай ук алар катнашты.

Хәсән Туфан, күрәсен, Себердә сөргендә чагында тимер юлда лом, чүкеч күтәреп эшләүче кызларны кызганып, шигырь язган. Мин поездда узып киттем сина карап кул болгап. Син елмаеп калдың. Елмаерга түгел, еларга кирәк иде сина, ди шагыйрь әлеге кызга эндәшеп!Тимер юл буенда лом күтәреп, чүкеч, көрәк күтәреп эшләп яткан ул кызларны мин дә әз күрмәдем.

1952 елнын җәендә мин дә ерак Себергә, Тобол шәһәренә бардым. Төмәнгә кадәр поезд белән, Төмәннән Тоболга пароход белән. Поездда юл буена татарлар белән сөйләшеп, гөр килеп бардык, Күбесе хатын-кыз. Безнең яклардан "Агыйделнең

аръягына" бәхет эзләп баралар. Иртышка барып чыккач, исем китте. Кайсы гына пристаньга туктама, яр буенда тагын—кызлар. Татар кызлары. Кычкырып сөйләшәләр, көлешәләр, жырлыйлар. Тик монда инде "Ай-ли алмагачлары"! ишетелми. Сал сүтәләр, агач сөйрәтәләр, йөк төйиләр. Өсләрендә—тупас сырма чалбар, аякларында тупас итек, ботинка.

Минем икенче хатынның апасы Роза ундүрт яшеннән туган өен ташлап, бәхет эзләп читкә чыгып китә. Анда сугылып, монда сугылып йөргәннән соң Абакан—Тайшет тимер юлын төзүчеләргә барып кушыла. Такта вагонда тора, булачак тимер юл өеменә вагоннардан таш бушата, төрле хәлләргә юлыга. Бандитлар төркеменә эләгә.

Янтыктагы безнең бер өй аша күрше Урта-бабайның кызы Нәрисә уналты яшеннән кемнәргәдер ияреп Ысбирлауга китә, ниндидер заводка эшкә керә. Заводтамы, цехтамы авария булгач, тәне пешеп, жәрәхәтләнеп больницага эләгә. Урта-бабай Нәрисә янына барып кайтты. Нәрисәнең хәле бөтен авылга беленде. Аны берничек тә дәвалый алмыйлар икән. Көн дә укол кадыйлар һәм. . . тиресен кисеп алалар икән. Үзе янына керүче ак халатлы кешеләрне күрсә, чыркылдап кычкыра, качарга тырыша икән. Урта-бабайны күргәч бу "Калдырма, алып кайт!" дип әтәсенең муенына сарылган. Урта-бабай алып кайтмаган. Ул сукырларча законга һәм медицинага ышанган. Нәрисә шунда мәңге торып калды.

Инәкәйнен сеңлесе "Апа" колхоз оешкан көннән башлап көн-төн колхозда эшләде. Хрущев заманында колхозларны совхозга әйләндерделәр. Совхозга әйләндерү белән генә авылның тамагы туймады. Мин апаны үземнең янга Казанга алдырдым. Ул минем янда ике-өч ел торды да, кире авылга кайтып китте. Ошамады ана Казан. Ул авылдан китеп торган арада совхоз эшчеләренә пенсия бирә башлаганнар. Апага пенсия бирмәячәкләре беленде. Аның элек колхозда эшләгән еллары пенсия өчен стаж булып исәпләнелми икән, чөнки ул совхозга керү өчен гариза бирмәгән, имеш. Аның мона бик нык хәтере калды. Ул мондый нәрсәне гомумән аңлый алмады. Аның бөтен гомере шул Янтыкта, колхозда көне-төне эштә үтте. Чәчәктәй яшьлеге шушында юкка чыкты. Шулай була торып та аны шул ун тәнкәме, унбер тәнкәме пенсиядән дә мәхрүм иттеләр. Мин аңа хәлдән килгәнчә булышып, ярдәм итеп тордым, ләкин Казанга син чакырып алдың, шуның аркасында пенсиясез калдым дип еллар буе мина үпкә саклады.

Чит жирләрдә кызларның кайберләре үзләренә оя корды. Булдыра алганнары үз татарына, булдыра алмаганнары башка милләт кешеләренә чыкты. Ләкин күпме кызлар шәһәрдәге кысан, тынчу, күнелсез баракларда, тулай торакларда жыелып калдылар. Жырлый-жырлый эшкә бардылар, жылый-жылый картайдылар, тупаслbackandылар, гарипләнделәр. Минем шундый баракларга кергәнем бар, саргайган, ямьсезләнгән боек йөзләрне күргәнем бар.

Минем тагын шундый сүзләр ишеткәнем бар: сугыш вакытында да, сугыштан соң да озак еллар дәвамында безнен яшь кызларны Урта Азия якларына илтеп. . . сата торган булганнар.

Мин еш кына үземнең яшь чактагы дус һәм таныш кызларны искә төшерәм, аларның өметләнеп баккан күз карашларын, чишелеп китеп ычкындырган ярату сүзләрен искә төшерәм. Ул чакларда мин аларга карата салкын, дорфа булганмындыр кебек. Никтер аларның барысы да ялгыз калгандыр һәм аларның ялгызлыгына бары мин генә гаеплемендер кебек Шул чагында бөтен күнелне әрнү, үкенү һәм кызгану хисе билэп ала. Сөялгәнсен чатта баганага...

*Дәвамы киләсе саннарда.*



Адлер Тимергалин

# АЛЛА

### ФӘЛСӘФИ УЙЛАНУЛАР

*Минем каршымда торган кыен бурыч менә мондый: тел белән аңлатуга бирелми торганны сүздә сурәтләү; акыл ирешмәсне аңга сыйдыру.*

Герман Гессе

*Аңлатып була торган булса, Алла Алла түгел инде.*

Сомерсет Моэм

*«Мине Җирем дә, Күгем дә сыйдыра алмас, мәгәр Мин колымның кальбенә сыярмын.»*

1906 елның 30 июлендә Лев Толстой үзенең көндәлегенә түбәндәге сүзләрне язып куйган: «Алла бармы? Белмим. Шуны беләм: минем рухи асылымның кануны бар. Бу канунның чыганагын, сәбәбен мин Алла дип атыйм.»

Табигать фәннәре буенча галимнәр, теге яки бу фәнне тирәнрәк белгән саен, динне, иманны кире кага торган дәлилләрне күбрәк таба дип уйлаучылар байтак. Чынлыкта исә фән үзеннән-үзе галимне беркайчан да алласызлыкка алып бармый. Чын галим,—биологмы, физикмы яки математикмы ул,—әйләнә-тирә дөньяның чиксезлегенә, дөньядагы тәртипнең искиткеч оешканлыгына, максатчанлыгына, анда мәгънәсез бер генә нәрсәнең дә булмавына торган саен ныграк ышана. Бу тәртипнең очраклы рәвештә генә урнаша алмавына кире каккысыз математик дәлил бар, аны ихтималлык теориясе бирә.

Галимнәрнең эзлекле, мантыйкый фикер сөреше ахыр чиктә аларны бөтенесен колачлый торган көчкә—Аллага ышануга китерә.

Герман галиме Динард, дөньякүләм танылган галимнәрнең бер төркеменнән фикерләрен сорашып, мондый нәтиҗәләргә килә: галимнәрнең 20се нинди дә булса дини карашны якламаган, 242 галим Аллага ышана башлаган, фәкать 20се генә дин белән кызыксынмауларын таныганнар. Шулай итеп, галим-голәманың 90 проценты—дингә ышанучылар һәм бик азы гына дәһри-атеист булган. Өстәвенә, соңгылары дингә ышанучы хезмәттәшләренә карата берниндиә дә ихтирамсызлык күрсәтмәгәннәр.

Дин һәм фән һич тә бер-берсенә каршы системалар түгел, табигать белгече булган хәлдә дә табигатьтән өстен көчләргә ышанырга мөмкин икән. Алар—фән һәм дин—бер үк медальнең ике ягы гына, һәм, баксаң, алар бер-берсеннән башка яши дә алмыйлар.

---

Адлер ТИМЕРГАЛИН (1931)—*язучы-фантаст, галим. "Пәһлеван кабере", "Космостан кунаклар", "Кабул булсын теләгең" һ.б. китаплар, астрономия, физика, техника терминнары сүзлекләре авторы. Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Фән—кара пессимист, ул бу дөньяның максаты һәм мәгънәсе юк дип саный, дин исә—якты оптимист, ул дөнья яратылышында олуг максат күрә һәм хәтта шушы принципы белән генә дә фәнне яна эзләнүләргә этәрә, асылда фәннең яшәешенә мәгънә бирә («Пәйгамбәр» мәкаләсеннән—А.Т.). «Бу ике дус, берсенә чөнки берсе аларның тин, Бертигез тәгълимнәре дә: берсе дөнья, берсе—дин»,—ди Тукай, бәләкәй Апуш "пәйгамбәр".

Материя белән рухны капма-каршы кую дөрес түгел. Рух төшенчәсе, әйтик, тереклек яралу, фикерли белүче аләм кавеменең килеп чыгышы, илһамлану, төштә фәнни ачыш ясау, пәйгамбәрләргә вәхи килү һ.б. кебек бүгенге материалистик фәннең теше үтми торган мәсьәләләрне җинел хәл итә. Тәкъдир (язмыш һәм ихтыяр) турында Ислам философиясе белән материалистлар арасында барган бәхәсләргә дә урын калмас дип өметләнергә кирәк.

Әлбәттә, фән белән динне килештерергә талпынулар элек тә булган. Мәсәлән, бөек Иоганн Кеплер Алланың кодрәтен тикшерүне һәм аны аңлауны максат итеп куеп, дини традицияләрне һәм фәнни белемнәрне синтезларга омтылган. Ләкин күп очракларда галимнәрнең фәнни тикшеренүләре аларның иманыннан аерым яши. Һәрхәлдә, аларның фәнни шөгыленда дин йогынтысы чагылмый диярлек (Ньютон, Кеплер һ.б.).

Бөтен дөньяга танылган микробиолог Луи Пастер: «Әгәр бүген минем белемем кичәгегә караганда күбрәк икән, бу инде минем Аллага ышануым да кичәгегә караганда артыграк дигән сүз»,—дип яза.

Бөек рус физиологы Иван Павлов та дингә нык ышанган кеше була.

Даһи Эйнштейнның: «Фәнни эзләнүләрнең иң олуг нәтиҗәсе—Аллага ышану»,—дигән сүзләре белән югарыда әйтелгәннәргә йомгак ясарга мөмкин.

«Алла» сүзе безгә гарәп теленнән кергән, Тәнре, Хода(й), Хак мәгънәсендә. Еш кына Аллаһы Тәгалә, Аллаһы Сөб(е)ханә вә Тәгалә, Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә, Хак Тәгалә, Тәнре Тәгалә, Ходай Тәгалә, Аллаһы Хак, Хак сөбхан кәмал кебек эпитетлар белән әйтелә һәм языла. Дини әдәбиятта Тәгалә, тәбарәкә, сөбханә эпитетларын да баш хәрефтән язу кабул ителгән. Аллага карата «Җәнабе Аллаһ», «Җәнабел-Хак», «Җәнабе Тәгалә» дип тә әйтәләр.

«Алла» сүзе яһүдләргә дә аңлаешлы. Иврит телендә алла—«элоха» (ягъни аллаһ, илаһи).

Татар телендәге чыганакларда Алла, тәнре мәгънәсендә борынгы төркичәдән изи/иди, уган, Һомай (Умай, Ымай, Омай, алтай телендә—Май), фарсыча Ходаванд(ә), Пәрвәрдигяр—халык кылучы, яраткучы, гарәпчә Йәздан (Язьдан)—барлыкка китерүче, Раббе, мәгъбүд (табыну заты, пот, санәм) кебек сүзләр дә еш очрый.

Материалистик карашлар буенча, Дөньяның башы да, ахыры да юк һәм аның яшәеше Алла ихтыяры белән берничек тә бәйләнмәгән, ягъни материалистлар үзләренең Дөнья төзелеше һәм аның барлыкка килүе турындагы теорияләрендә (гипотезаларында) Алланың зарурилыгын танымыйлар, аны тулаем инкяр итәләр. «Ләкин һәрбер система, хәтта иң катлаулысы да, һәрвакыт ниндидер бер система барлыкка китерүче принципка нигезләнгән була. Бу принцип әлеге системаның үсешен һәм эшчәнлеген билгели торган барлык күпсанлы, эзлекле кануннарны алдан ук тәгаенләп куя.» (Н. Ү. Әхмәров. «Аң һәм Дөнья» мәкаләсе, «Novitas» журналының 7нче чыгарылышы, Казан, 2001, рус телендә). Моны без үзгәрешләрне алдан ук программалаштырып куя торган алгоритм, ягъни кагыйдәләр чылбыры дип аңлыйбыз. Бу алгоритм Исламдагы Язмыш, Тәкъдир, Кадер төшенчәсенә якын, ләкин, ихтимал, ул ана тәнгәл түгелдер, Дөнья яшәешендә ниндидер очраклы вакыйгаларга да, ихтималлык теориясендәге «могҗизалар»га яки катастрофалар теориясендәге бифуркацияләргә, революцион борылыш һәм сикерешләргә дә урын кала торгандыр. Ләкин барлык бу очраклы һәм шул ук вакытта зарури тайпылышлар язмыш тактасына—Ләүхелмәхфузга теркәлгән булырга тиеш,—монысы Ислам өчен бәхәссез.

Башка тәгълиматларда әлеге аслән принципны Алла дип, Дао, Абсолют, Абсолют идея, Бөтендөнья җаны, Гакылел-күлли (ягъни Гомум акыл, Бөтендөнья гакылы), Изге рух, Пневма (соңгысы грек сүзе, ә керәшеннәрдә бу төшенчә «Изге Тын» дип

бирелә, руста—Святый Дух), Беренчел сәбәп, Логос һ. б. терминнар белән атыйлар. Мөселманнар өчен дә илаһи китап булган Библиядә (Тәүрат—Тора аның бер өлеше): «Ин әүвәле Сүз булган. Бу Сүз—Алла дигән сүз» диелә (Логос шушы инде). Без бүген бу Сүзне «Информация» мәгънәсендә дип аңлыйбыз. Калган бөтен нәрсә шушы Сүздән пәйда булган. (Безнең фаразыбызча, Информация Энергиягә һәм Энергия Материягә әверелә ала. Шул ук вакытта андый күчешләр кире тәртиптә булырга да мөмкин, бу мәсьәләгә тагын әйләнеп кайтырбыз әле.)

Ә материалистлар Алла төшенчәсеннән уттан курыккандай куркалар, ләкин аның урынына алмашка берни дә тәкъдим итмиләр. «Алла юк» һәм вәссәлам. Бөтендөнья сәгатен кем, кайчан борып җибәргәндер,—түң мангайлы матдиуннарны бу кызыксындырмый. Дөресрәге, алар бу хакта баш ватып тормыйлар. Хәлбуки, Н. Ү. Әхмәров әйткәнчә, система төзүче ниндидер гомуми принциптан башка Дөнья яши алмый. Бу принципны Алла дип атамыйча, башка бер термин кулланган да, асылда, эчтәлеге һәм колачлаган күләме буенча, ул Алла төшенчәсенә охшаган булачак.

Без алга таба бу мәсьәләгә дә әйләнеп кайтырбыз, ә хәзергә безне Алла төшенчәсенә иҗаби (позитив) карашлар кызыксындыра.

Ин абруйлы хәдисләр җыентыгы «Сахихел-Бохари»да теркәлгән бер хәдистә «Ин-ин әүвәлдә Аллаһы Тәгалә генә бар иде. Аннан башка һичкем һәм һичнәрсә дә юк иде»,—диелгән («Кәналлаһу вә ләм якүн гайруһу фил әзәл». Ишми ишанның «Игътикадта ахыргы вакытта пәйда булган фикер-сүзләр темасына лекцияләр һәм фикер алышулар» китабы буенча—Казан, «Иман» нәшрияты, 2000; гарәпчәдән татарчага Д. Шаймурзин тәрҗемә иткән).

«Пәрдә» (70) сүрәсенең 54нче аятендә: «Тәхкыйк, Раббыгыз—Аллаһ алты көн эчендә җирне вә күкләрне төзеде, сонра боерыгы Гарешкә карарланды»,—диелә (тәфсирчеләр фикеренчә, монда «көн» («йаум») дигәндә «период, этап» күздә тотыла). Дөнья яратылышы мәсьәләсе «Аңлатылды» (41) сүрәсенең 9, 10 һәм 12нче аятьләрендә җентекләбрәк сөйләнә.

Коръәни Кәримнең «Умарта кортлары» сүрәсендә 40нчы аятьтә Аллаһының бөтен мәхлукатны яраткучы булуы ачык әйтелгән: «Без бер нәрсәнең булуын теләсәк, ул нәрсәнең бар булуы өчен «Бар бул!» дип әйтүебез җитә, һич кичекмичә бар булыр.»

«Терлек» сүрәсенең 103нче аяте: «Аллаһы Тәгаләне күзләр колачлый алмас, Аны күрергә бернинди күз кадир булмас, бәлки Аллаһның карашы бөтенесен колачлар, Ул үтәли күрүче һәм һәрнәрсәдән хәбәрдар» ,—дип раслый.

«Тимер» сүрәсенең (57) 3нче аятендә: «Ул—Аллаһ һәр нәрсәдән элек бардыр, вә һәр нәрсәдән соң да бардыр, Ул бакыйдыр, Аның бетү ихтималы юктыр, барча галәмне төзүе белән Аның барлыгы ачыктыр, вә Аның сыйфаты яшерендер, Аның сыйфатын һичкем белә алмас. Вә Ул һәр нәрсәне белүчедер»,—диелә («Коръән тәфсире» буенча, ә ул Мөслим хәдисләренә нигезләнгән).

Могтазиләләр тәгълиматында «Аллаһтан башка мәңгелек берни дә юк» дигән гыйбарә принцип итеп алынган.

«Садир»—гарәп сүзе, чыгучы, башланучы; эманация мәгънәсендә. Ислам философиясендәге бу термин дөньяның үзеннән өстен илаһи Абсолюттан туу процессын аңлата. Әл-Газали (1058/59—1111) Аллаһның Галәмгә эманациясе—садир Аллаһның табигатенә хас мәҗбүрият кенә түгел, чөнки Аллаһның дөнья яратылышындагы роле беренче этәрештән генә тормый һәм моннан соң да яшәеш сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләренә генә кайтып калмый дип саный. Аллаһ һәр мизгелдә яңадан-яңа сәбәпләр чылбырын тудырып тора һәм вакыйгаларның гадәти агышына һәр мизгелдә үзгәреш кертә ала.

Ислам мистиклары (суфилар) садир дигәндә галәмнең исәпсез-сансыз сурәтләрендә Аллаһның мәңгелек чагылышын күздә тотканнар. Бихисап саннар тезмәсе (1, 2, 3 һ. б.) берәмлектән чыккан шикелле, яшәешнең бөтен төрлелеге дә илаһи Абсолюттан чыга. Суфилар тәгълиматы садирның сәбәбен һәм хәрәкәткә китерүчесен Аллаһның гыйшык омтылышында күрә. Аллаһыда киләчәктәге «тышкы» яшәешнең (заһирның) яралгысы була һәм Аллаһы үзен читтән торып күзәтергә һәм өйрәнергә омтыла. Гыйшыкның табигате үк үзенә объект таләп иткәнлектән, илаһи Абсолют галәмнең конкрет барлыкларын тудыра. Аларына да үзләренең чыганагына гыйшык тоту хас, бу

гыйшык алардан абсолютка һәм камил яшәеш югарылыгына күтәрелүне таләп итә.

«Асылда сөю, гыйшык, мәхәббәт тойгысы—Аллаһының бер сыйфаты» («Суфичылык серләре» китабыннан). Хәтерлисездер, Тереза-ананың мәшһүр девизы—«Дөньяны мәхәббәт коткарыр» дигән сүзләр. Бу девиз Федор Достоевскийда очрый торган «Гүзәллек дөньяны коткарыр» девизыннан күчләрәк. Ләкин Достоевскийдагы гүзәллек төшенчәсенең дә асылда Аллаһка барып тоташканлыгын онытмаска кирәк. Суфичылыкта Аллаһ—«хөсни мотлак», ягъни абсолют гүзәллек. Аллаһ халык кылган һәр нәрсә гүзәл, ләкин Аллаһтан рухи ерагая барган саен, бу гүзәллек кими. Гомумән, суфилар һәр нәрсәдә илаһи гүзәллекнең чагылышын күрәләр, ягъни алар карашынча, дөнья—илаһи сәнгать галереясы кебек («Суфичылык серләре»).

Исламияттә Аллаһы «Мөсәббибел-әсбаб», ягъни Сәбәпләр сәбәбе дип исәпләнә, шуна күрә аның өчен вакыйгалар агышында бернинди дә сер булмый.

«Аллаһ кешеләрнең үткәндәге барча эшләрен һәм алдагы барча эшләрен белер, кешеләр Аллаһ белеменнән һичнәрсәне колачлый алмаслар, мәгәр Аллаһ белдергәнне генә белерләр» («Бәкарә» сүрәсе, 2:255).

Платон (яна эрага кадәр 428 яки 427—348 яки 347) Бәхет яки Бердәмлек идеяләрен еш кына Алла белән тәңгәлләштерә. Аның фикеренчә, Алла (демиург) формасыз материяне формалаштырып, дөньяны, жанны һәм космосны тудырган.

Шәрыкчәләтеп олылап әйтсәк, Сократ хәким (грек философы, яна эрага кадәр 469—399) кешенең жанында Алладан да өлеш бар дип исәпләгән.

Көнчыгыш аристотелизмы вәкиле Ибне Сина (Әбүгалисина, 980—1037) Алланы бөтен дөньяның «беренчел сәбәбе» дип аңлата. Аның фикеренчә, бер Алла гына абсолют яшәешкә ия, ә калган бөтен нәрсә фәкать ихтимал гына, алар Алла аркасында гына пәйда була. Бүген без моны дөньядагы бөтен нәрсә Алла тарафыннан программалаштырылган дип аңлыйбыз.

«Аллаһы Тәгалә бардыр, барлыгы һичбер затка мохтаж түгелдер. Үзеннән-үзе бардыр. Барлыгының әүвәле дә, ахыры да юктыр, ягъни дөнья мәхлукате кебек әүвәлдә юк булып, соңрадан бар булган түгелдер. Вә һәм ахыры да, бер юк булачак та түгелдер. Бәлки даимән бар булачактыр.»

«Ул Аллаһы Тәгаләнең мәхлукаткә һичбер җәһәттән охшашлыгы юктыр. Аны һичбер нәрсәгә охшатмак мөмкин түгелдер. Аллаһы Тәгалә гәүдәле зат түгелдер. Аның бер рәвеше вә сурәте юкдыр. Һичбер урында да, һичбер тарафта да түгелдер. Аның сыйфатларының кәйфиятләре (үзенчәлекләре, рәвешләре) безгә мәгълүм түгелдер. Вә дәхи Аллаһы Тәгаләдә ашау-эчү, ару, йоклау кеби эшләр дә юкдыр. Аллаһы Тәгалә үзе һичбер затдан тугъмамышдыр. Вә андан да һичбер зат тугъмамышдыр.» (Болары Әхмәтһади Максудиның «Гыйбадәте Исламия» китабы буенча).

Кәй-Кавус бин Искәндәр үзенең улына багышлап язган мәшһүр «Кабуснамә» китабында әйтә: «И угыл, шөйлә белгел ки, хак Сөбханә вә Тәгаләнең барлыгы заһирдә вә яшерендә, жирдә вә күктә булган нәрсәләр белән дәлилләнеп, гакыл белән беленер. Әмма Аллаһы Тәгаләнең зат шәрифе тәсаувыр гакылдан еракдыр, ягъни Аллаһы Тәгалә андый микән, мондый микән дип күнелгә килгән кузаллауларның һәммәсеннән читтәдер. Әмма Аллаһы Тәгаләне танымак теләсәң, әүвәл үзеңне үзең таны, үз хәлеңнән хәбәрдар бул. Аның өчен һәркем үзен таныды, Хак Тәгаләне таныды. Бу сүздән максат шулдыр ки, син беленмешсең, ул белгүчедер, ягъни син нәкышьсең, ул нәккаштыр.»

Төрки суфи шагыйрь Аллаһияр (1616—1717) үзенең «Сөбател-гажизин» китабында:

*Колак-күз бәндәгә хаҗәт булганда,*
*Һичкайсына мохтаҗы юк Ходама.*
*Кешеләр сөйли алмас авыз-телсез,*
*Хода гына һич боларга мохтаҗсыз.—*

дип яза. (Тәрҗемә Ф. Яхинныкы.)

Гарәп шагыйре Лябид: «Аллаһыдан кала бөтенесе ялган түгелмени?» дигән соравы белән күпләрне сокландырган.

Мәшһүр фарсы суфи шагыйре Гаттар Фәрид әд-Дин (1150 ел тирәсе—1220) «Кошлар әңгәмәсе» исемле аллегорик поэмасында барлык җанварларнын хуҗасы Сәмругны эзләргә чыгып киткән кошлар турында сөйли. Юлда аларга Эзләнү, Мәхәббәт, Белем, Читләшү, Берләшү, Баш әйләнү һәм Һәлакәт үзәннәрен кичәргә туры килә. Менләгән коштан бары утызы гына максатка ирешә. Ниһаять, кошларны Сәмруг хозурына алып керәләр һәм шунда алар анарда үзләрен күрәләр (анын исеме дә «Утыз кош» икән). Сәмруг тел белән сөйләмичә генә аларга хакыйкатьне ача: «Минем бөеклегемнең кояшы—көзге. Һәркем анарда үзен, үзенең гәүдәсен һәм җанын бөтен ваклыкларына кадәр аермачык итеп күрә. Сез утыз кош һәм бу көзге сезгә утыз кошны чагылдыра, әгәр кырык, илле кош булса, алар да анда үзләрен күргән булырлар иде. Һәм хәзер сез тәмам үзгәргән булсагыз да, үзегезне элек булганыгызча күрәсез... Ләкин мин утыз кош кадәрле генә түгел. Мин—чын Сәмругнын асылымын. Данлы һәм бәхетле көенчә минарда юк булыгыз, һәм сез миндә үзегезне табарсыз.» Шуннан сон кошлар кояштагы күләгә шикелле анарда эреп югалалар.

Гомумән, илаһият фәненә суфилар керткән өлеш гадәттән тыш зур. Суфичылыкны формаль гакыл (интеллект, фәһем), ягъни мантыйк һәм өлге буенча гына фикерләп хакыйкатькә ирешү мөмкинлеген кире кага торган практик эшчәнлек дип тә карарга мөмкин.

Шәрык мистиклары иң югары, гали чынбарлыкнын сизеп-тоеп була торган объект түгеллеген, башкаларга сөйләп аңлатып була торган объект та түгеллеген кат-кат тәкрарлыйлар. Суфилар илаһи зат чагылыш таба торган дөньянын фәкать күренмә, уйланма, ирреаль нәрсә булуы турындагы фикерне үстергәннәр. Белгәнебезчә, бу фикер инглиз галиме Джордж Беркли (1684—1753) хезмәтләрендә дәвам иттерелә. Артур Шопенгауэр (1788—1869) да әйберләрнең безнең аңыбыздан тыш һәм ана бәйсез рәвештә яшәве турындагы фикерне мәгънәсезлек дип саный.

Тулаем алганда, суфичылыкта өч юнәлеш бар. Беренчесе—монистик юнәлеш, монысында суфи үзен Аллаһыга тиңләштерә («Мин—Ул имди») икенчесе—пантеистик юнәлеш, монысында суфи Галәмгә таралган Аллаһы белән кушыла («Бөтенесе—Ул имди»), өченчесе—синкретик юнәлеш, монысы әлеге юнәлешләрнен икесенә дә нигезләнә («Мин—Бөтен чынбарлык имди», ә «Бөтенесе—Аллаһы имди», ягъни «Бөтенесе—Ул имди»). Беренче ике юнәлешне сурәтле итеп аңлата торган ике мисал бар. Беренчесе—«Күбәләк һәм шәм». Күбәләк үзенең мәхәббәтендә магнитка тартылгандай шәмгә омтылып, анын ялкынында яна һәм үзе дә утка әйләнә. Аллаһыга омтылган кеше дә, бәдәне янып, Аллаһы белән кушыла, анын белән тәнгәлләшә. Икенчесе—«Тамчы һәм океан». Тамчы океанда эреп югала; Аллаһы белән берләшергә омтылган кеше дә бөтен табигатькә таралган Аллаһыда эреп бетә.

Йосыф Баласагуни безгә борынгы уйгыр телендә шигырь белән язылган «Котадгу белек» китабынын авторы буларак мәгълүм. Китабын ул 1069 елда язып тәмамлаган. Әсәрнең исемен «Бәхет турында белем» дип тәрҗемә итәргә мөмкин.

Бу әсәрендә Баласагуни Аллаһынын берлеге һәм Анын дөньядагы барча әйберләргә кадәр үк булганлыгы турында яза.

Ислам теологиясендә Алла—«Гакылел-күли», ягъни Гомум акыл.

Әл-Гарәби язганча, әш-Шәех әл-Әкбәрнең иҗатында кеше һәм Аллаһ концепциясе түбәндәге бер риваятькә нигезләнә (ул риваять турыдан-туры Аллаһнын Үзенә нисбәт ителә, ләкин Коръәндә теркәлмәгән): «Мин яшерен хәзинә булдым һәм нәмәгълүм идем. Шул чагында Минем танылашым килде, шуңа Мин мәхлукатны барлыкка китердем, адәмнәргә ачылдым, һәм алар Мине таныдылар». Кешегә дип билгеләнгән дөнья һәм кеше үзе әнә шулай, шушы максат белән барлыкка китерелгән.

Борынгы грек галиме, математик, философ Пифагор Самосский (яна эрага кадәр VI гасыр) беренче булып Галәмне Космос дип, кешене исә Микрокосм дип атап, ул (кеше) Макрокосмнын барлык хасиятләрен чагылдыра дип санаган. Анын карашлары без бераз сонрак тикшерәчәк голографик дөнья идеясе белән бик әйбәт яраша. «Алла бер, һәм ул, кайберәүләр уйлаганча, дөнья төзелешеннән читтә түгел, бәлки тулаем бөтен күк даирәсендә тора, барлык яратылмышларны күзәтә, ул барлык гасырларнын «катнашмасы» һәм үз көчләре вә үз гамәлләренен иҗатчысы. Алла—бар нәрсәнен башлангычы, ул күк чырагы һәм Галәмнен атасы, барлык нәрсәләрнен акылы һәм

жанланышы, барлык әйләнеш-әверелешләрнең хәрәкәте»,—дип язган Пифагор. Монда «барлык гасырларның катнашмасы» дигән сүзләр бик мөһим. Димәк, Пифагор барлык заманнар—үткәннәр, бүгенгеләр һәм киләчәк—бер үк вакытта яшиләр, алар Аллада берләшкәннәр дип саный. Эйнштейн да: «Үткән заман, бүгенге һәм киләчәк заманнар арасындагы аерма, гәрчә бик ышандыргыч булып тоелса да, фәкать иллюзия генә»,—дип исәпли.

Ислам динендәге могтәзилә юнәлеше тарафдарлары да яраткучы зат белән яратылмыш арасында аерма күрмиләр. Буддизмда субъект белән объектны, рухны һәм материяне капма-каршы кую юк. Дөрес, буддиларда хәлык кылучы һәм һичшиксез бөек зат буларак Алла да юк дип исәпләнелә.

Суфичылыкта Аллаһы—«Галәми әкбәр» (Макрокосм), ә камил инсан—«Галәми әсгар» (Микрокосм). Камил инсанда Аллаһынын исеме, сыйфатлары һәм фигыльләре тәгал чагылыш таба. Габделкәрим Жили камил кеше—«Хакнын һәм шулай ук халыкнын чагылышы» дип раслый. Димәк, камил кеше—үзе бер дөнья һәм ул башка барлык дөньяларны сыйдыра. Матди яктан караганда, адәм—Аллаһнын кечкенә генә бер мәхлугы, ә мәгънә күзлегеннән караганда, ул—зур һәм катлаулы бер дөнья. Ул Аллаһ сыйфатларынын һәм исемнәренең чагылышларыннан (тәҗәлли) тора. Шуна күрә кешедә барлык төр халәтләрне табарга мөмкин.

«Кеше үлгәч, галәмнен бер күзе йомыла»,—ди герман философы, физик һәм психолог Густав Теодор Фехнер (1801—87).

Камиллек турында әл-Газали сүзләрен әйтми калсак, фикерләребез тулы булмас иде. Ул: «Аллаһы бөеклегенен асылын зарурандә анлый алмаячагын белгәч, кеше үзенен камиллек ноктасына ирешкән була, анын максаты да нәкъ менә шул»,—дигән.

Чын шагыйрьләр дөньякүләм информация кырына тоташу сәләтенә ия ахрысы. Хәер, үтә сизгер шагыйрь күнеле бөтенләй башка—тискәре информация кырына да тоташырга мөмкин.

Сәгыйть Рәмиев «Мин» шигырендә:

*«Мин!» димен мин, «мин» дидисәм,*
*Миңа бер зур көч кирә,*
*Аллалар, шаһлар, кануннар*
*Булалар бер чүп кенә,*—дип яза.

Сәгыйть Рәмиев шикелле үзенне Аллаһка каршы кую акылга муафыйк түгел. Бу шигырь рухланган, илһамланган кешенең үзен чиксез кодрәтле итеп тоюын дөрес сурәтли торгандыр, бәлки. Әмма монысы Илаһтан ингән көч түгел, ул, ихтимал, Иблис коткысы гына булыр. Һәрхәлдә үзен Аллаһ белән янәшә, ягъни аерым кую Анар шәрик катнаштыруга тин.

Гавриил Державиннын «Я червь—я бог» («Мин жир корты—мин Алламын») дигән сүзләрендә хакыйкать бар шикелле.

Аллага ышану—могҗизага ышану дигән сүз.

Чыннан да, дөньяда могҗиза бар нәрсәме, әллә юкмы? Могҗизаны очраклылык дигән нәрсә белән, ягъни ихтималлык теориясенә нигезләнеп анлатырга маташулар булды. Бу яктан «Паскаль дәлиле» («Пари Паскаля»—«Паскаль бәхәсе») дигән нәрсә кызыклы. Бу бәхәснен асылы түбәндәгедән гыйбарәт. Алла йә бар, йә юк. Гакыл бу мәсьәләдә берни дә хәл итә алмый. Комарлы уеннардагы кебек, монда да унай һәм унайсыз (кулай һәм кулай булмаган) шансларны чамалап карарга һәм үзенә отыш чыксын өчен унай (нульдән зуррак) «математик көтем» дигән нәрсәне тәэмин итәргә тырышырга кирәк. Алла бар дип уйлаганда отыш чиксез зур—мәнге дәвам итә торган олуг ләззәт; ә бәхәстә без куйган «акча»—җирдәге бәхетләр ничек кенә зур булмасыннар, барыбер чикләнгән күләмдә генә. Менә шушы нәрсә әлеге бәхәстә кайсы як тарафдары булырга кирәклекне аермачык күрсәтә инде... (Г.А.Габинский буенча).

Әйтик, могҗиза кылу пәйгамбәрләргә дә хас, ә кәрамәтне әүлияләр да эшли ала. Әлбәттә, могҗиза да, кәрамәт тә илаһи чыгышлы, тик пәйгамбәрләр белән әүлияларга илаһилык сыйфаты бирү көферлек булыр иде. Ләкин пәйгамбәрләрнең могҗиза эшли алуына ышанмау да көферлек була.

Шулай да мөселман теологлары Аллаһы тарафыннан пәйгамбәрләр ярдәмендә ясалган акыл җитмәстәй (гаҗиз итә торган) могҗизаны изге кешеләр (әүлиялар, ягъни вәлиләр) ярдәмендә ясалган кәрамәтләрдән аерып карыйлар. Асылда иллюзионист Кио фокусларына төшенеп булган кебек, кәрамәтләрне рациональ нигездә аңлатып һәм кабатлап була, ә чын могҗиза фәкать Алладан гына инә.

Без өч үлчәнешле дөньяны гына беләбез, бу үлчәнешләр: бер-берсенә перпендикуляр юнәлештәге озынлык, киңлек һәм биеклек (тирәнлек). Фәндә дүрт һәм артыграк та сандагы үлчәнешләре булган дөньялар теоретик яктан тикшерелә. Математика күзлегеннән караганда, дүрт үлчәнешле дөньяда, мәсәлән, һәр яктан ябык бина эченә үтеп керергә, кичәге көнгә кайтырга һ.б. «могҗизалар» эшләргә мөмкин. Гадәттә дүртенче үлчәнеш итеп асылда психологик төшенчә—вакыт алына.

Суфиларга үлчәнешле һәм үлчәнешсез дөньялар төшенчәсе мәгълүм булган. Мәсәлән, Руми: «Сез үлчәнешле дөньяга карыйсыз, ләкин сез бернинди үлчәү булмаган урыннан килгәнсез»,—ди. Үлчәнешсез дөнья дигәннән, әлбәттә, матди дөньяны түгел, бәлки рухи дөньяны аңларга кирәк.

Вакыт-заман һәм вакыт агышы дигән төшенчәләр, асылда, кеше психологиясенә генә хас. Бәс, дөнья Аллаһының голографик сурәтеннән гыйбарәт икән, анда вакыт төшенчәсенең кирәге булмый. Бу сурәттә кичәге, бүгенге, иртәгәге көн дигән нәрсә юк. Алар бердә барысы бергә яшиләр (нәкъ менә югарыда телгә алынган класс тактасындагы кебек: андагы мәгълүматлар, әйтик, төрлесе төрле вакытта язылган булсалар да, һәммәсе бергә яши һәм аларны ап-ак тактадан уку өчен фәкать язылу вакыты буенча гына аерырга мөмкин).

Вакыт төшенчәсенең кеше аңына гына бәйле булуы Ислами риваятьләрдә дә чагыла.

Мәгълүм булганча, Мөхәммәд пәйгамбәр мигъраҗ төнендә күкләргә ашкан. Бу кичәдә ул фәрештәләрне вә җәннәтләрне, күкләрдәге төрле гаҗәеп вакыйгаларны күрә. Ривайәттә сөйләнгәнчә, Аллаһы белән очрашу вакытында Хак Тәгалә аңа 99 мең сүз әйтеп өлгергән. Хәзрәти Мөхәммәд үзе Хак Тәгаләгә 90 мең сүз әйткән, шуларның утыз мене өммәте өчен, утыз мене хаслар (гали кешеләр) өчен, ә калганнары исә сер булып кала. Мәккәдән китеп кире әйләнеп кайтканчы күзәтелгән барлык шушы хәлләр күз ачып йомган арада булып алганнар. Кайтып төшүенә Мөхәммәд пәйгамбәр әле ятагының суынып та җитмәгәнлеген, ә чыгып киткәндә ялгыш аударган кувшиннан суның агып чыгарга өлгермәвен күргән. XX гасырда релятивизм (чагыштырмалылык теориясе) белән таныш кеше боларга гаҗәпләнми инде.

Суфилар илаһи зат чагылыш таба торган дөньяның фәкать күренмә, уйланма, ирреаль нәрсә булуы турындагы фикерне үстергәннәр.

«Ихлас» сүрәсен (112нче сүрә Коръәннең ахырында ук диярлек) укып карыйк:

1. Әйт, әй Мөхәммәд: «Ул—Аллаһ һич тиңдәше вә охшашы булмаган ялгыз бер генә Аллаһыдыр.

2. Һичнәрсәгә, һичбер мәхлукка ихтыяҗы юк, бәлки һәр мәхлукның хаҗәтен үтәүче Аллаһыдыр.

3. Ул һичкемне тудырмады һәм һичкемнән тудырылмады.

4. Вә һичкем Аңа тиң булмады.»

Аллаһ турындагы карашларында Исламият менә шушыларга нигезләнә.

Урта гасырларда Көнбатыш философлары да Алланың атрибутлары (әс-сыйфат) турында сөйләгәндә югарыдагыга охшаш фикерләр әйтәләр. Мәсәлән, алар фикеренчә, Алла—үзеннән-үзе яшәүче зат, ул барлык нәрсәләрнең сәбәбе, бөтенесен белүче, бөтенесенә кодрәте җитүче, мәңгелек, гади, чиксез, иң олы сәгадәт һ. б.

Томас Морның (1478—1535) хыялый «Утопия»сендә дә халыкның күпчелеге бердәнбер, үлемсез, үлчәүсез, аңлап һәм белеп бетергесез Аллага табына, бу зат кешенең гакыл мөмкинлекләреннән югары, ул бөтен галәмне үзенең гәүдә-тәне белән түгел, бәлки куәте белән тотырган дип саный.

Немец философы мистик Беме Якоб (1575—1624) фикеренчә, Алла белән табигать тәңгәлләр, Алла бөтен табигатьтә һәм кешенең үзендә турыдан-туры катнаша.

Парижда философия һәм теология укытучысы булган хөр фикерле еретик Амальрик

(Амори) Бенский (яки Шартрский, 1206 елда вафат), пантеист буларак, түбәндәгеләрне яза: «Дөньяда бөтен нәрсә бердәм, чөнки бар булган бөтен нәрсә—Алла ул». Кеше—Алланың бер кисәкчеге. Амальрикның батыйль (бозык) фикерләрен тарату 1215 елда папа тарафыннан тыелган.

П. Тейяр де Шарденның (1881—1955) дини-фәлсәфи системасында Алла (Омега) галәмнең (универсумның) ахыргы максаты. Омега-алла—универсумның мәркәзе, аны үсеш юлына этәреп, юнәлеш бирүче көч. Шарден фикеренчә, Омега-алланың дөньяга ясаган йогынтысы табигать кануннарына һәм сәбәплелек принцибына каршы килми.

Ләкин дөньякүләм диннәрдә Алланы еш кына кеше (гадәттә ак сакаллы карт) сурәтендә итеп күз алдына китерәләр. Мондый антропоморфизмны берничек тә дәлилләп булмый. Христианнарда «Изге троица» («Триада», «Изге өчлек», «Өчләмә») төшенчәсе бар. Ул Алланы («Бог-отец»), аның улы Иисусны (Гайсәне) һәм «Изге рух»ны бер зат итеп берләштерә. Мондый өчлекне акылга сыйдыру кыен, әйтик, Лев Толстой аны күз алдына китерә алмый һәм ана ышанмый. «Изге өчлек», гомумән, аңлатылмас сиррият (серлелек) исәпләнә. Христиан дине «өчлек» төшенчәсен Платоннан алган диләр (Поль Гольбах). Христианнарда «Изге өчлек»не кире кага торган еретик секта да булган, аны антитринитарийлар сектасы дип атаганнар, ягъни «өчлек» төшенчәсе җинел генә урнашмаган. Дөрес, моны бүгенге фән күзлегеннән карап нигезләргә омтылышлар да юк түгел. (Мәсәлән, космик аппаратларны галәмдә ориентлаштыру буенча белгеч, Ленин премиясе лауреаты академик Б. В. Раушенбах. Кызганычка каршы, аның бу темага кагылышлы хезмәтләрен матбугатта очратырга туры килмәде, ихтимал, алар әлегә дөнья күрмәгәннәрдер. Шулай да, томанлы гына өзекләрдән Раушенбах материяне, энергияне һәм информация дигән нәрсәне берләштерергә тырышкан сыман аңлашыла.) Коръәндә исә христианнарның Иисусны һәм Мәрьям-ананы аллалаштырулары гаепләнә. Ислам фәкать бер Аллаһыны гына белә, шуңа күрә Гайсә пәйгамбәрнең Алла улы булу ихтималы да кире кагыла, гомумән Аллаһыга ширек катыштыру каттый рәвештә инкяр ителә. «Аллаһ—өчнең берсе диючеләр, дөреслектә, кәфер булдылар. Тиндәше вә охшашы булмаган Аллаһтан башка һич Илаһи юк. Аллаһ—өчнең берсе диючеләр шул сүзләреннән тыелмасалар, ягъни тәүбә итмәсәләр, әлбәттә, аларны рәнҗеткүче газаб тотачак.» («Маидә» сүрәсе, 5:73.)

Алланың кыяфәте турында мәрхүм папа Иоанн Павел II (Чын исеме Карол Войтыла, 1920—2005) Аллада «ак сакаллы картны түгел, бәлки үзендә ирләрнең дә, хатын-кызларның да кыяфәтен берләштергән затны күрергә кирәк» дип исәпли иде.

Борынгы төркиләр мифологиясендәге Умай алланы да җисемле итеп күзалламаганнар. «Шулай итеп, Умай дигән алланы билгеле бер җисми кыяфәттә күз алдына китерергә мөмкин түгел; ул бөтен кешелек дөньясына бөртекләп, күзәнәкләп чәчелгән. Һәр кешедә аның бер очкыны, бер нуры бар; шул очкын, шул нур югалса, сүнсә, кеше дә сүнә, үлә...» (Г. Гыйльманов, «Татар мифлары»). Ягъни Аллаһ турында Исламга хас карашларның орлыклары борынгы төрки халыкларда булган инде.

Дөрес, Исламиятта дә Аллаһының тәне-җисеме бар дип санаучы дин галимнәре (антропоморфистлар) булган, аларны мөҗәссимитләр дип атаганнар. Суфичылыкның бөек вәкиле әл-Гарәби, мәсәлән, үзенең «Гакылның сыйфатлары» дигән хезмәтендә Аллаһыны материаль булмаган кыяфәттә күрергә тырышмаска кирәк, дип яза. «Аллаһыны хатын-кыз сурәтендә күрү иң мөкәммәле»,—ди ул. Әмма биредә әл-Гарәби асылда Аллаһының гүзәллеген күздә тота. Икенчедән исә, җисемсез затны күз алдына китерү мөмкин түгел бит.

Түбәндәге сүзләр фарси телле суфи шагыйрь Мәүлана Җәлалетдин Руминың хакыйкый чынбарлыкны (асылда Аллаһыны) эзләвен чагылдыралар: «Мин хачны да, нәсариларны да кямилән тикшердем. Хачта Ул юк иде. Мин һиндуси гыйбадәтханәдә һәм борынгы пагодада булдым, тик анда да Аның эзләре юк иде. Мин Һиратка һәм Кандаһарга тикле бардым. Мин эзләдем. Астта да, өсттә дә юк иде Ул. Тәвәккәлләп, Каф тавына барып җиттем, әмма анда да Ганка кошын гына таптым. Кәгъбәгә киттем. Анда да Ул юк иде. Мин Аның турында әбугалисинадан белештем, әмма Ул әбү Гали ибн Сина фәлсәфәсеннән югарырак иде...Шуннан мин үз кальбемә күз салдым. Мин Аны шунда күрдем, ә башка бер генә җирдә дә Ул юк иде...»

Руминың соңгы фикере түбәндәрәк, дөньяның һәм бөтен яратылышның голографик сурәт булуы турында әйтеләчәк гипотеза белән бик әйбәт яраша.

Кайбер көнбатыш философлары Иблисне Аллаһның антиподы—капма-каршысы итеп куйгалыйлар. Ислам моны кире кага.

Хәзерге заман физикасында гадәттән тыш катлаулы мәсьәләләрне интуитив-күзәтү юлы белән чишәргә омтылыш суфичылыкка һәм тагы да борынгырак Шәрык философиясенә нигезләнә. Философ һәм физик Фритьоф Капра, мәсәлән, үзенең «Физикада дао» дигән хезмәтендә («Дао физики»—Исследование параллелей между современной физикой и мистицизмом Востока, рус телендә 1994 елда басылган) беренче бүлекне «Бүгенге физика—«Кальбле юл» түгелме?» дип башлый һәм түбәндәгеләрне яза: «... күп кенә көнбатыш философиясе тармакларында мистицизм элементлары бар. Без бүгенге физика нигезләре белән охшашлыкны һиндуизм Вәдәләрендә, «И Цзин»да һәм будди сутраларда гына түгел, Гераклитның күпләгән өземтәләрендә, Ибне Гарәби суфичылыгында һәм яки кабиләсе сихерчесе дон Хуан тәгълиматында да күрәбез.»

1838 елда Шекә авылында вафат булган мелла Яхья бине Сәфәр бине Арслан әл-Бәрәзәвинең шәкерте, Зәбир исемле фикер иясе Аллаһы турында түбәндәгеләрне яза: «Бөек Алла—алты (!) тарафта түгелдер, галәм тышында һәм эчендә дә түгелдер, янәшәдә булучы һәм ерак булучы да түгелдер, аралашып торучы һәм үтеп китүче дә түгелдер, бер булучы һәм күп булучы да түгелдер. Аның һичнәрсәгә охшашы юктыр, димәк, аннан башка вәҗибел-вөҗүд юктыр. Аннан башка мәгъбүдел-гыйбад юктыр. Аннан башка тереклекне булдыручы юк, һич аңа тиң һәм аннан өстен нәрсә юктыр. Бөек Алланың сыйфатлары затка бәйләнешле дә, затыннан башка да түгелдер. Сыйфатларының да һич нәрсәләргә охшашлыгы юктыр. Гыйлеме барча тереклек иясен эченә алгандыр, ягъни эченнән һәм тышыннан чолгагандыр. Гыйлеме барлык тереклекнең эчендә дә һәм тышында да биргәдер. Гыйлеме барча тереклекне бер-бер артлы үтәдер. Барча тереклекнең эчендәгесе һәм тышындагысы мәңгегә бөек Аллага мәгълүмдер, ә безнең аңыбыз Аллаһы Тәгаләгә ирешмәс. Безгә үзебезнең көчсезлегебезне белеп, Ходага бәндәчелегебезне белү һәм гыйбадәт кылу тиешледер.»

Исламияттә Аллаһының кайда булуына—координаталарына нисбәтле «Ля мәкян» дигән термин да бар. Ул Алланың эпитеты булып йөри. Аның мәгънәсе—урыны билгеле булмаган (һәр җирдә булган). Хуҗа Әхмәд Ясәви (1105/1103?—1166): «Нәфсем үлеп, ля мәкянгә аштым менә» дигәндә Аллаһының, димәк, һәр җирдә булуын һәм шул ук вакытта атап күрсәтерлек бер җирдә дә түгеллеген күздә тота. Алла өчен «вакыт»-«заман» категориясе дә булмый. Ягъни аның өчен «булган», «була» (хәзер бар), «булачак» дигән төшенчәләрнең мәгънәсе юк, кичәге, бүгенге, иртәгәге дигән сүзләр дә артык, чөнки алар һәммәсе бергә, бер үк мизгелдә яшиләр, алар фәкать безнең аңыбызда гына төрле мизгелләргә, сәхифәләргә аерыла. «Хаҗ» сүрәсенең (22) 47нче аятендә «Раббың хозурында көннәр сез саный торган көннәрнең мең елы кебек озындыр» диелгән, ягъни вакыт категориясе Эйнштейндагыча чагыштырма зурлыкка гына ия булып чыга.

Суфичылыкта, физика фәнендәге кебек, вакыт (заман, ань) һәм мәкян (урын) төшенчәләре бик мөһим. Аллаһка ирешкәннәр өчен вакыт һәм урын мәсьәләсе юкка чыга, ань-и даим генә кала, ягъни мизгел мәңге дәвам итә.

Шуны да әйтик, «ля мәкян» төшенчәсе хәзерге физикада актив кулланыла. Мәсәлән, атом төше тирәсендә әйләнеп йөрүче электроннарның анык бер мизгелдәге координаталарын күрсәтеп булмый. Киресенчә, бу координаталар аныклана барган саен әлеге торышның кайсы мизгелдә булуын төгәл билгеләү мөмкинлеген югалтабыз. Чынлыклап карасаң, бу принцип үзе генә дә Аллаһыны гадәти күз белән күрү һәм күзәтү мөмкин түгеллеген аңлау өчен җитә.

«Каф» сүрәсенең 16нчы аятендә: «Без аңа [кешегә] җилкә тамырыннан да якынракбыз» диелә. Яки менә «Сыер» сүрәсенең 186нчы аятеннән: «әгәр бервр бәндәм Миннән сорар булса, Мин, әлбәттә, аңа һәрвакыт якынмын»,—ди Аллаһ.

Мелла Яхъя әл-Бәрәзәвинең түбәндәге сүзләре мәгълүм: «Бөек Алла барча тереклек белән биргәдер, әмма бу илаһи көч—һичбер тереклеккә катнашмаучы, бернигә дә хаҗәте төшмәүче зат. Барча тереклекнең эчендә һәм тышында ни бар—барчасы бөек Аллага мәгълүмдер. Бөек Алла һичнәрсәгә охшамаган, һичбер урынга мохтаҗ түгел. Барча тереклек бөек Алланың нурында коенадыр һәм ул юк итүчедәдер. Барлык

галәм бөек Аллаһдан башка гади бер бушлыктыр. Әмма игътибар белән карасаң, буш та түгелдер. Бөек Алла барлык галәмнән чистадыр. Ләкин бергәләшүдән бәхәссез азаттыр. Әлеге бергәләшүдән азат булуы кәеф һәм һиммәт сүзләреннән арттадыр ки. Бергәләшүдән бәхәссез азат булуына безнең фикер һәм гыйлемебез ирешмәс. Бөек Алла безгә якындыр, әмма безнең аңыбыз аннан ерактыр.» (Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» китабы буенча, текст Ә. Хәйруллин тәрҗемәсендә.)

«Аллаһның барлыгы ачык булса да, Ул—яшерендер. Без Аның чын халәтен белә алмыйбыз. Ул хәзрәти Мусага тауда күренүгә Муса пәйгамбәр һушыннан язган.» («Дога китабы», Анкара, 1995.)

Суфичылык күзаллавында Аллаһы (аның сыйфатлары һәм гамәлләре) дингез белән, ә калган бөтен нәрсә шул дингездәге дулкыннар белән тиңләштерелә. Ягъни дөнья Аллаһының үзгәреш процессында гына чагыла. Анда җисми нәрсә юк. «Дингез дулкыннары»ның физикадагы «кыр» төшенчәсенә охшашлыгы күзгә ташлана.

Югарыда телгә алынган авторлар үз карамакларында булган белемнәр һәм терминология нигезендә Аллаһыга гомуми характеристика биргәннәр.

«Дөньядагы бөтен нәрсәнең, шул исәптән кешеләрнең дә асылын Хак тәшкил итә. Бөтен нәрсә Аллаһ белән бәйле, бөтен нәрсәнең асылы—бер, бары тик алар матди галәмгә килгәч төрле кыяфәт алганнар» (Әлфинә Сибгатуллина, «Суфичылык серләре», 1998).

Суфичылыкта Аллаһ—«хөсн-и мотлак», ягъни абсолют гүзәллек. Аллаһ хәлык кылган һәр нәрсә гүзәл, ләкин Аллаһтан рухи ерагая барган саен, бу гүзәллек кими бара. Гомумән, суфилар һәр нәрсәдә илаһи гүзәллекнең чагылышын күрәләр, ягъни алар карашынча, дөнья—илаһи сәнгать галереясы ул («Суфичылык серләре»).

Түбәндә Аллаһының күркәм исемнәре бирелә (әл-Газали һәм әл-Иҗигә нигезләнгән һәм мәгънәләре кайбер башка чыганаклар белән дә яраштырылган исемлек).

1. Аллаһы (Аллах)—Алла, Аллаһу, Ходай, Тәңре (Аллаһы Тәгалә, Ходай Тәгалә, Хак Тәгалә).
2. әр-Рәхман—Аяучы, Шәфкать иясе.
3. әр-Рәхим—Рәхимле.
4. әл-Мәлик—Патша, Мәлик (Кыямәт көненең хуҗасы).
5. әл-Коддус—Мөкатдәс, Изге.
6. әс-Сәлам—Тыныч (Иминлек бирүче зат).
7. әл-Мөэмин—Тугры (Ышаныч бирүче зат).
8. әл-Мүһәймин—Саклаучы, Химаяче.
9. әл-Газиз—Куәтле зат (Җинелүләргә дучар булмый торган зат).
10. әл-Җәббар—Куәт иясе.
11. әл-Мүтәкәббир—Олуглanучы (Һәр эштә өстен зат).
12. әл-Халикъ—Хәлык кылучы (Барча галәмне яраткучы).
13. әл-Бари—Бар итүче.
14. әл-Мусаувир—Сурәт бирүче (Бөтен нәрсәгә шәкел бирүче).
15. әл-Гаффар—Ярлыкаучы, Кичерүче.
16. әл-Каһһәр—өстенлек кылучы (Бөтен көчләрдән өстен зат).
17. әл-Ваһһаб—Бүләкләүче.
18. әр-Рәззак—Ризыкландыручы.
19. әл-Фәттах—Җиңүче; Рәхмәт капкаларын ачучы.
20. әл-Галим—Белеп торучы (Белемендә иң өстен зат).
21. әл-Кабиз—Кысучы (Җан алырга әмер бирүче).
22. әл-Бәсит—Табын җәюче (Ризыкны һәм хаятне мул итеп бирүче).
23. әл-Хафид—Хур итүче, Түбәнгә иңдерүче.
24. әр-Рафиг—Күтәрүче.
25. әл-Могиз—Көч бирүче, Куәтләндерүче.
26. әл-Музыйлл—Түбәнсетүче.
27. әс-Сәмигъ—Барын да ишетүче, Ишетеп торучы.
28. әл-Бәсыйр—Барын да күрүче, Күреп торучы.
29. әл-Хәким—Мәхкәмәче (Тугры хөкем итүче).

30. әл-Гадел—Гадел.
31. әл-Ләтыйф—Яхшылыклы (Бәндәләргә йомшаклык кылучы).
32. әл-Хәбир—Хәбәрдар (Барыннан да хәбәре булган зат).
33. әл-Хәлим—Түземле (Бәндәләргә җәза бирергә ашыкмаучан зат).
34. әл-Газим—Олуг.
35. әл-Гафур—Барын да гафу кылучы.
36. әш-Шәкүр—Шөкер итүче.
37. әл-Гали—Барыннан югары, Бөек.
38. әл-Кәбир—Олуглыклы.
39. әл-Хәфиз—Саклаучы.
40. әл-Мукыйт—Ризык бирүче.
41. әл-Хәсиб—Хисаплаучы (Бөтенесенең санын белүче зат).
42. әл-Җәлил—Бөеклек иясе.
43. әл-Кәрим—Юмарт.
44. әр-Рәкыйб—Күзәтеп торучы.
45. әл-Мөҗиб—Догаларга җавап бирүче.
46. әл-Васигъ—Һәркайдагы.
47. әл-Хәким—Хикмәт иясе.
48. әл-Вәдүд—Сөюче.
52. әл-Хак—Хакыйкый, Чын.
53. әл-Вәкил—Вәкаләтле, Канат астына алучы.
54. әл-Кави—Көчле.
55. әл-Мәтин—Какшамас.
56. әл-Вәли—Дуст.
57. әл-Хәмид—Данлыклы, Мактаулы.
58. әл-Мухсый—Исәпкә алучы, Санаучы.
59. әл-Мөбдиг—Башлаучы (Һәр нәрсәне матдәсез, коралсыз, үрнәксез бар итүче, башлап җибәрүче).
60. әл-Мугый—Кайтаручы (Барча галәмне хәяттән соң юк иткән һәм тергезгән зат).
61. әл-Мухйи—Җанландыручы, Тергезүче.
62. әл-Мумит—Үлем җибәрүче (Үлемне бар кылып җан алдыртучы).
63. әл-Хәййү—Мәңге яшәр зат.
64. әл-Каййүм—Үлемсез зат.
65. әл-Важид—Һәрвакыт булучы зат.
66. әл-Мажид—Затлы.
67. әл-Вахид—Охшашы булмаган зат, Шәриксез зат.
68. әл-Әхәд—Бердәнбер, Тиңдәшсез.
69. әс-Самад—Мәңгелек зат.
70. әл-Кадир—Киң кодрәтле.
71. әл-Мукътәдир—Һәр нәрсәгә көче житүче.
72. әл-Мокаддим—Алга этәрүче, Алдан урын бирүче.
73. әл-Муәххир—Артка чигерүче (Шелтә һәм газап бирүдә хөкемен кичектереп торучы зат).
74. әл-Әүвәл—әүвәлге зат.
75. әл-Ахир—Ахыргы зат (Барча мәхлукат юкка чыкканда да бер үзе кала торган зат).
76. әз-Заһир—Күренекле.
77. әл-Бәтыйн—Яшерен.
78. әл-Вали—Идарә итүче.
79. әл-Мутәгали—Иң югары, Бөекләр бөеге.
80. әл-Бәрр—Бәндәләрне сөючән (Бәндәләргә мәрхәмәтле зат).
81. әт-Тәүвәб—Тәүбәне кабул кылучы.
82. әл-Мунтәкыйм—Үч алучы (Гөнаһлы бәндәләргә гаделлек белән җәзасын бирүче).
83. әл-Гафу—Гафу кылучы, Ярлыкаучы.

84. әр-Рәүф—Йомшаклык кылучы, Бәндәләрне кызганучы.
85. Маликел-Мөлек—Патшалык патшасы (Бөтен байлыкның хуҗасы).
86. Зөлҗәлал вә-л-икрам—Бөеклек вә юмартлык иясе.
87. әл-Мукъсит—Гаделлек кылучы, Гадәләтле зат.
88. әл-Җәмигъ—Җыючы (Кыямәт көнендә барча мәхлукләрне хөкем алу өчен җыючы).
89. әл-Гани—Бай (Аның байлыгы бирү белән һич кимемәс).
90. әл-Мугъни—Баетучы (Бәндәләрен байлык белән сынаучы зат).
91. әл-Мәнигъ—Тыючы зат.
92. әд-Дарр—Зыян кыла алучы (Бәндәләрен сынау өчен бәла-каза китерүче зат).
93. ән-Нәфигъ—Изге теләкле, Мәнфәгать бирүче.
94. ән-Нур—Нур (Бәндәләргә яктылык бирүче).
95. әл-Һади—Туры юлга күндерүче.
96. әл-Бәдигъ—Уйлап табучы (Мисалы булмаган нәрсәләрне яраткучы).
97. әл-Бакый—Мәңге юкка чыкмас зат.
98. әл-Варис—Варис (Бөтен мирасның хуҗасы һәм аны юмартлык белән бәндәләренә бирүче).
99. әр-Рәшид—Тугры (Бәндәләрен туры юлдан алып баручы).
100. әс-Сабур—Сабыр (Сабырлыкта тиңе булмаган зат).

Исемнәрнең тәрҗемәләре шактый якынча һәм шартлы, чөнки һәркайсының мәгънәсендә нечкә төсмерләр бар һәм аларны гарәпчәдән башка телдә төгәл итеп бирү, ихтимал, мөмкин дә түгелдер. Тик шулай да күркәм исемнәрнең мәгънәләре Аллаһының сыйфатларын (атрибутларын) ачыклыйлар һәм аның затын аңларга ярдәм итәләр.

Башлыча суфилар арасында Аллаһының иң бөек, төп исеме (әл-исмел-әгъзам, исме әгъзам) булуы турындагы фикер яши. Ул исем фәкать пәйгамбәрләргә генә (мәсәлән, Сөләйман һәм Гайсә ибне Мәрьямгә) билгеле булган, ләкин Коръәннең бу исем телгә алынган урыннарына караганда, ул Аллаһы, әл-Хәййү, әл-Каййум, Һуа исемнәренең берсе булырга тиеш.

Мөселман тәсбихендә әл-әсма әл-Хөснәдәге күркәм исемнәр санынча төймәләр була. 100нче иң эре төймә—«шаһданә» (халык телендә тәсбихнең «мулласы» яки «мәрйәманасы») әл-Исмел-әгъзамга туры килә дип санарга мөмкин. Шуны да әйтеп китик, шигый авторлары арасында Аллаһының исемнәре мең дә бер дип исәпләүчеләр дә бар.

Суфичылыкның «вәхдәти вөҗүд» тәгълиматы буенча, җир йөзендәге бөтен барлыклар Аллаһы исемнәренең мазһарлары, чагылышлары гына.

Мөселманнар арасында бу исемнәр тылсым көченә ия дип каралган һәм аларны хәтта мөселман булмаган кешеләр дә ятлаганнар. Мәсәлән, «өч диңгез арты»на сәяхәт иткән рус сәүдәгәре Афанасий Никитин хатирәләрендә (XV гасыр) бу исемнәр дә телгә алына (инде ватанына әйләнеп кайткан авыру Афанасий Никитин шушы күркәм исемнәрне җан бирер алдыннан саташып кабатлый).

Урта гасырларда Көнбатыш философлары да алланың атрибутлары турында сөйләгәндә югарыдагыга охшаш фикерләр әйтәләр. Мәсәлән, алар фикеренчә, Алла—үзеннән-үзе яшәүче зат, ул барлык нәрсәләрнең сәбәбе, бөтенесен белүче, бөтенесенә кодрәте җитүче, мәңгелек, гади, чиксез, иң олы сәгадәт һ.б.

Физикадан хәбәрдар булган кеше кайбер илаһи сыйфатларның «кыр» (поле) дигән субстанция хасиятләренә охшашлыгын ачык күрә, ләкин, әйтик, магнит яки электр кырларын да, электромагнитик кырны да, гравитация кырын да «Алла» белән тәңгәлләштереп булмый.

Соңгы вакытларда матбугатта «информация кыры» төшенчәсен еш очратырга туры килә. Игезәк балалар, бигрәк тә бер күкәй күзәнәктән яралганнары арасында гомер буе яши торган серле элемтә, шулай ук физик экспериментта бер үк атомнан атылып чыккан электроннар арасында (күпмедер вакыт?) саклана торган бәйләныш кебек күренешләр безне дөньяда информация кыры булырга тиеш дигән фикергә этәрә.

Чынлап та «информация» дигән нәрсә масса һәм энергия төшенчәләре белән бер

рәттә, тик югарырак баскычта торганга охшый. Дөрес, информация кырына әлегә анык билгеләмә бирелмәгән, аны томанлы гына күз алдына китерәләр. Ләкин, жентекли башласак, масса һәм бигрәк тә энергия төшенчәсенә бирелә торган билгеләмәләр дә берьяклы бит, без аларга, ул сүзләргә күнеккән генә, ә бу әле без аларны ахыргача анлыйбыз дигән сүз түгел. Әгәр дә информация кыры яшәешнен, бөтен матди чынбарлыкнын ин югары дәрәҗәсе булып чыкса? Әгәр материаль дөньядагы барлык нәрсәләр, барлык объектлар шушы информация кырынын безнен аныбыздагы чагылышлары, проекцияләре, сурәтләре, мазһарлары гына булып чыкса? Әгәр без үзебез дә шушы бөтенесен колачлый торган, бөтен нәрсәдән хәбәрдар кырнын бөртекләре, күзәнәкләре, үзенә бер төрле психик голограммалар гына булып чыксак? Фактта бу фараз дин белән фән, идеализм белән материализм арасындагы упкынны юкка чыгара. Бу—политеизм түгел, чөнки политеизм дөньядагы һәр нәрсәне Аллага тинләштерә, әлеге фаразыбыз исә «Алла—һәр нәрсәдә» дип кенә раслый, ягъни ул һәрнәрсәдә Алланын чагылышын гына күрә. Шул ук вакытта ул язмыш, тәкъдир төшенчәсенә дә ачыклык кертә. Әгәр без—үзебез уйлаганча, акыл һәм ихтыяр ияләре—Алланын голографик чагылышлары икәнбез, беренчедән, безнен барлык киләчәгебез Алла кулында һәм алдан ук билгеләнгән булып чыга, икенчедән исә безнен һәр ихтыяри адымыбыз да Алла ихтыяры һәм гамәле дигән сүз. Бу фараз кеше ихтыяры һәм гамәлләрен өчен җаваплылык дигән нәрсәләрне юкка чыгара түгелме? Юк, чыгармый, чөнки Алланын башка голограммасында, башка шәхестә димәк, ихтыярнын юнәлеше капма-каршы булырга да мөмкин, ә Алла, әлбәттә, үз-үзенә каршы хәрәкәт итмәскә тиеш. Югыйсә дөньяда тәртип белән гармония калмас, фәкать хаос кына хөкем сөрер иде яки, әгәр ихтыяр көче векторлары капма-каршы якларга юнәлгән бертигез ике «бәйләмнән» торса, дөньядә хәрәкәт тукталып, абсолют нуль, ягъни үлем хөкем сөрер иде.

Кыскасы, кешегә ихтыяр хокукы калдырылган һәм адәм баласы кылган гамәлләре өчен үзе җаваплы. Шәхси җаваплылык тойгысы Алладан инә.

Садә материализм тарафдарлары дөньяны фотография принцибына корылган рәвештә күз алдына китерәләр, ягъни без дөньянын үз күзләребез белән (яки төрле техник җайланмалар ярдәмендә) күргән яки тойган өлеше турында объектив мәгълүмат алабыз дип уйлыйлар. Бу фикернен Вл. Ульянов-Ленинньн «Материализм һәм эмпириокритицизм» дигән китабында аеруча күпертелгәнлеген, авторнын оптикада ачышлар ясаган философ Джордж Берклига карата әйткән дорфа сүзләрен искә төшерик. Бүген исә галимнәр Берклинын сүзләренә ныграк колак салырга мәҗбүр. Материаль дөньянын фәкать безнен аныбызда чагылган нәрсә генә булуын, ягъни гади электр сигналларыннан башка нәрсә түгеллеген ул түбәндәге сүзләр белән әйтә: «Без материянен барлыгына ышанабыз, чөнки тойгыларыбыз ярдәмендә аны күрәбез һәм сизәбез. Ә чынлыкта исә безнен тойгыбыз—фәкать аныбыздагы уй-фикерләр генә.»

Әгәр фоторәсемнен яртысы ертып ташланган булса, без анда югалган информацияне берничек тә кайтара алмыйбыз. Ә менә голорәсемнен исән калган яртысында да үзе турында барлык информация сакланган була. Яртысында гына түгел, чирегендә дә һәм вак-вак кисәкләрендә дә объект турында тулы мәгълүмат теркәлеп кала. Голорәсемдә бөтен галәм сурәтләнгән дип фараз итик. Әгәр безнен кулыбызда шул голограмманын кечкенә генә бер өлеше булса да, без тулаем бөтен галәм турында мәгълүмат ала алабыз дигән сүз. Хәер, без үзебез дә шушы голорәсемнен бер өлеше, элементы бит. Рәсем дигән сүз, әлбәттә, чынбарлыкны чагылдырмый. Рәсем бит яссы бер эз, сурәт кенә. ә голорәсем безнен күз алдында күләмле чын җисем рәвешендә пәйда була (кайчагында музейларда да кыйммәтле экспонатнын үзе урынына анын голосурәтен генә «куялар»).

Галәми «информация кыры»нда бөтенесе дә бар дип фараз итәргә мөмкин: анда дөньяда булган, булуы мөмкин булган, адәм башына килгән, хыялда яки төштә күренгән яки хәтта булу ихтималы юк дип саналган барлык нәрсәләр, алар турындагы идеяләр тупланган. Галәми информация (идея) кырын өсте-өстенә яза-яза акбурга буялып беткән һәм акшарлаган кебек булган класс тактасы белән чагыштырып булыр иде. Мондый тактага барлык хакыйкатьләр, дәреслекләрдәге барлык формулалар, барлык телләрдәге барлык китаплар—әле иҗат ителмәгәннәренә чаклы—берсе өстенә берсе язылган... Ягъни анда кешелеккә мәгълүм барлык информация теркәлгән, хакыйкатьләр

генә түгел, ялган яки ялгыш дип санала торган информация дә шушы «абсолют аклык» (әгәр телисез икән, «абсолют караңгылык») эченә күмелгән. Мәгълүм булмаган нәрсәләр дә шунда. Ләүхелмәхфуз дигәннәре шушы түгелмени? (Дөрес, «ләүхелмәхфуз»ның билгеләмәсендә «дөньяда булган һәм булачак» нәрсәләр телгә алына).

«Калмады сурәт, бары тәбдил ителде Мәгънәгә, әүрелеп Мәгънәгә, дөнья сәҗдә кылды Мәүлага»,—ди Г. Тукай «Мигъраж» дигән шигырендә. Шагыйрь зәмин (урын) һәм заман (вакыт) төшенчәләре калмаган мизгелдә асылда материянең идеягә—информациягә, мәгънәгә әверелүе турында әйтергә тели. Шөбһәсез, мондый мизгел кеше зиһенендә—бигрәк тә пәйгамбәрләр, суфилар һәм шагыйрьләр күңелендә әсәрле чагылыш таба.

Охшаш фикергә без Нури Арслановта да тап булабыз: «...Шул таңда, шул гаҗәп бер мизгелдә Рухым ашты «мин»нән,—Мин матдәдән кинәт мәгънә булып Күтәрелдем җирдән»,—дип яза шагыйрь-философ.

Информация материальләшкән һәм энергияләшкән вакытта физик дөньяда, әлбәттә, галәти яки гадәттән тыш җисемнәр һәм күренешләр барлыкка килә, ягъни без дөньяда, энергиянең матдәгә һәм киресенчә әверелешләре белән бергә, информация—энергия—матдә күчешләре дә мөмкин дип саныйбыз. Бу күчешнең кире тәртиптә бару ихтималын да кире кага алмыйбыз.

XIX гасырда яшәгән немец галиме Кронакер: «Алла натураль саннар рәтен иҗат иткән, ә калган бөтен нәрсә адәм кулы белән эшләнгән»,—дип белдерә. Кызыклы фикер. Әгәр «адәм кулы белән эшләнгән» дигәнне «адәм башындагы чагылыш кына» дип аңласак, ул бүгенге фәнни карашларга туры килә.

Ислам динендәге могтәзилә юнәлеше тарафдарлары да яраткучы зат белән ятатылмыш арасында аерма күрмиләр. Буддизмда субъект белән объектны, рухны һәм материяне капма-каршы кую юк. Дөрес, буддиларда халык кылучы һәм һичшиксез бөек зат буларак Алла да юк дип исәпләнелә.

Голографик дөнья идеясеннән мөһим бер нәтиҗә чыга: димәк, без чиксез һәм төкәнмәс информация мохитенең кечкенә генә бер өлеше булсак та, шушы информацияне үзебез теләгән күләмдә/Алла юл куйган кадәр колачлый, үзләштерә һәм аңлый алабыз. Кыска гына итеп әйткәндә, без Алла белән очраша алабыз, без илаһи кәлимәне (сүзләрне, төшенчәләрне) аңларга һәм кулланырга сәләтле.

Танылган поляк язучысы һәм философы Станислав Лемның «Лимфатер формуласы» дигән фантастик хикәясендә безнең аңыбыз һәм күзаллауларыбыз магнит язмасының гәүдәләнеше генә түгелме икән? дигән олы сорау куела.

Аллаһ—бер Китаптыр, Дөнья—Аның сәхифәләредер, ә безләр—шундагы хәрефләрмездер. Аллаһ Бу Китапны Үзе язадыр, Үзе үк укыйдыр һәм Ләззәт табадыр, Аның Максуды—шулдыр. Бу фикерне минем «Юл чаты» дигән хикәямдә бер борынгы болгар кешесе язып куйганлыгы әйтелә. Асылда минем Аллаһ турындагы күзаллауларым шушы фикердә тупланган. Хикәя язылып ун ел чамасы вакыт үткәч, мин даһи Исаак Ньютонның «Библия генә түгел, бәлки бөтен Галәм Алла файдаланган яшерен язма ул» дигән фикеренә тап булдым.

Мин беренчелеккә дәгъва кыла алмыйм.

Югарыда сөйләнгәннәрнең барчасын Георг Вильгельм Фридрих Гегель фикере үзендә бер йомгак итеп берләштерә кебек. «Бөтендөнья рухының иң югары абсолют максаты—үз-үзенә кайту. Күктә һәм җирдә булып тора торган—мәңге булып тора торган—бөтен нәрсә, алланың яшәеше һәм вакыт-заман барышында вакыйг булган һәр нәрсә рух үзен аңласын, үзен үзе объект итеп алсын (күзәтсен), үзен тапсын өчен эшләнә, шуңа юнәлгән. Рухның иң бөек казанышы үзен аңлауда»,—дип язган бөек Гегель. Алдарак әйткәнебезчә, Гегельгә кадәр охшаш фикер суфичылыкта ук күзәтелә инде.

Борынгыларның «Үз-үзеңне бел!» дигән фикере әлеге югары хакыйкатьнең бер өлеше, бер бөртеге генә. Соңгы очракта ул аерым шәхескә кагыла, ягъни аерым кеше тормышының мәгънәсен ачып бирә.

Станислав Лемның «фикерләүче океаны» әнә шушы бөтендөнья рухын сәнгать чаралары белән сурәтли.

Мөселман теологлары Аллаһы тарафыннан пәйгамбәрләр ярдәмендә ясалган акыл житмәстәй (гажиз итә торган) могжизаны изге кешеләр (әүлиялар) ярдәмендә ясалган кәраматләрдән аерып карыйлар. Ягъни кәраматләрне рациональ нигездә аңлатып һәм кабатлап була, ә чын могжиза фәкать Аллалан гына.

Коръәннен «Маидә» сүрәсендә 17 нче аятьтә (Крачковский тәржемәсендә 20нче аять): «Жирдә, күкләрдә һәм араларында булган бөтен нәрсә Аллаһ байлыгы, Аллаһ үзе теләгән нәрсәне хәлык кылыр, Аллаһның һәрнәрсәгә көче житә»,—диелә.

Бу сүзләрдә безне «араларында булган бөтен нәрсә» дигән төшенчә кызыксындыра. Әлбәттә, Коръән текстын примитивлаштырып аңлаганда, монда жир белән күк арасындагы һава, болытлар, планеталар, йолдызлар һәм башка материаль жисемнәр һәм системалар турында сүз бара торгандыр дип фараз итәргә дә мөмкин (бу төшенчә 44 сүрәнең 7нче һәм 38нче аятьләрендә, 50 сүрәнең 38нче аятендә дә кабатлана).

Ләкин әлеге жисемнәр барысы да күктә бит!

Урта гасырлардагы астрономик күзаллаулар Шәрыктә дә башлыча Птолемейның геоцентрик теориясенә нигезләнгән була һәм күкләр тугыз кат итеп күз алдына китерелә: Жир тирәсендә жиде «планета» (Ай, Меркурий—Гыйтар, Венера—Зөһрә, Кояш—Шәмс, Марс—Мәрих, Юпитер—Мөштәри, Сатурн—Зохәл, Кәйван, Туфрак йолдыз) әйләнеп йөри торган сфералар, аннары кузгалмас йолдызлар сферасы һәм иң югары тугызынчы сфера. Әлеге жисемнәр барысы да күкләрдә урнашканнар, күк белән жир арасында түгелләр. Монда Аллаһ хәлык кылган «арадагы нәрсәләр»не рухият дөньясы, рухлар дөньясы, фактта информация кыры дип аңлау акылга муафыйк.

Суфилар фикеренчә, кешенең жаны «бәрзәх» дигән башка дөньяда яши. Унайлы шартлар булганда жаннар төштә яки өндә кешегә күренергә дә мөмкин икән. «Бәрзәх» турындагы күзаллау да гомуми «информация кыры» төшенчәсе белән бик әйбәт яраша һәм тормышта булып торган бик күп сәер хәлләрне, раст килгән төшләрне, кинәттән туган фәнни ачышларны һ.б.ны аңлатырга юл ача.

Диндә Аллаһы жирдәге дөньяны һәм жиде кат күкләрне, жәннәтне һәм жәһәннәмне бар итүче, фәрештәләрне һәм адәмнәрне хәлык кылучы дип карала. Ул кешеләргә табигать байлыкларын бүләк иткән һәм алардан файдаланырга өйрәткән. Ул аларга төрле әйберләрнең исемнәрен әйткән, ягъни телләрен ачкан. Ул һәр кешенең язмышын алдан ук билгеләп куя.

Адәмнәргә Аллаһыны оныту кебек кимчелек хас, шуна күрә Аллаһы алар арасына вакыт-вакыт пәйгамбәрләр жибәрә. Аларның беренчесе Адәм галәйһиссәлам. Ибраһим, Муса, Гайсә дә пәйгамбәрләр. Пәйгамбәрләрнең иң соңгысы—Мөхәммәд галәйһиссәлам.

Дин тарихына, дини философия үсешенә күз салу белән, Алла турындагы карашларны суфилар (Шәрык суфилары гына түгел, Көнбатыш суфилары да) һәм язучы фантастлар үстергәнлеге күзгә ташлана. Гомумән, суфичылык белән шагыйрьлек һәм фантастика арасында тирәнтен сәбәби бәйләнешләр бар. Аларны колачлы фәлсәфи нигезләр һәм илһами алдан күрүчәнлек (пәйгамбәрлек) тә якынайта.

Ахырда берничә логик табышмак, асылда «мантыйкый тозак»лар турында сөйлисем килә.

Материалистлар диндарларны «аяктан ега» торган бер сорау бирергә яраталар: «Аллаһы Тәгалә үзе күтәрә алмаслык таш ярата аламы?»—дигән усал сорау ул. Янәсе, әгәр Алла андый таш хәлык кыла алмаса, димәк, ул кодрәтле үк түгел, хәлык кыла икән—димәк, күтәрергә көче житмәгәч, янә Алланың кодрәте чикләнгән булып чыга. Бу сорау корректлы куелмаганга, аңа жиңелчә генә жавап бирергә дә ярый (иң әүвәле—әлеге сорау Аллаһны куллары булган һәм нәрсәне дә булса тотып «күтәрә» ала торган зат итеп күз алдына китерә, хәлбуки Ислам мондый күзаллауны тулаем кире кага). Әйе, Алланың кодрәте шулкадәр киң ки, хәтта ул үзе күтәрә алмаслык ташны барлыкка китерергә сәләтле, ләкин Алла өчен аст яки өст дигән нәрсәләр юк, шулай да ул әлеге таштан тыш булган барлык нәрсәне—бөтен галәмне, безнең күзлектән караганда, әлеге таштан түбәнгәрәк күчереп куя ала һәм, шул рәвешле, таш югары күтәртелгән кебек була, ягъни мәсьәлә тел тидергесез төгәллек белән хәл ителә. Бу чишелешне мин беренче булып тәкъдим итәм дип өметләнәм. Мондый чишелеш «Йәсин» сүрәсенә берничек тә каршы килми («Көн фәякүн»—«Бул!» дию белән үк

бөтенесе була мәгънәсендә; «Ногмани тәфсире»ндә: «Аллаһ бер нәрсәнең бар булуын теләсә, ул нәрсәгә фәкать бар бул дип әйтер һәм ул нәрсә бар булыр.»)

Менә тагын бер логик парадокс.

Аллаһы Тәгалә үзе юк итә алмаслык нәрсәне бар кыла аламы?

Монысы принципта яна башваткыч, һәм аны беренче очрактагы кебек Ньютон физикасы нигезендә генә хәл итеп булмый—Эйнштейннан ярдәм сорарга туры килә.

Әйе, Алла соныннан үзе юкка чыгара алмаслык нәрсәне дә барлыкка китерә ала. Ләкин әлеге яратылмыш нәрсәне юк итү зарурлыгы килеп чыга калса, Алла вакыт агышын кире чигереп, әлеге яратылмыш дөньяда булмаган мизгелне генә кире кайтара һәм теге нәрсә яки кемсә юкка чыга, хәтта бу факт үзе дә инсаннар хәтерендә сакланмый... Әлбәттә, Аллаһы әлеге яратылмыш нәрсәне юк итәрлек көче булган затны да ярата алыр иде, ләкин мәсьәләнең мондый чишелеше корректлы түгел (моны беренче парадокска карата да кулланып була).

Тагы да катлаулырак сорау кызыклы: Алла үзе кебек үк кодрәтле затны яки затларны барлыкка китерә аламы? Дөньяның голографик төзелеше турындагы идея бу сорауга урын калдырмый, чөнки Алла хәлык кылган һәр нәрсә, голорәсем элементы буларак, Алланың үзенә тиң. Димәк, Алла үзе кебек кодрәт ияләрен хәлык кылган инде. Ләкин шулай да алар Аллага шәрик түгел, алар бер Алланың чагылышлары гына. Ислам буенча, Аллаһның—кеше акылы ирешмәстәй, аның асылын аңлап бетермәстәй зат икәнен күздә тоту зарур. Әйтик, бер тамчы су, химик хасиятләре ягыннан җир йөзендәге барлык диңгез-океан суларына тиң булса да, тамчы белән океан арасындагы аерма бәхәссез бит. Без белгән нәрсәләрдә «Алланың үзенә тиң» булу адәми затларга кәбирләнергә мөмкинлек бирми, чөнки Алла без белмәгән һәм белә дә алмаган хасиятләргә ия булырга тиеш. Кеше Аллаһка тиң булса да, Аллаһ кешегә тиң түгел.

Э. Ренан (1823—92) куйган сорау барысыннан да уздырып җибәрә сыман. Әгәр алла бөтенесен дә эшли ала икән, димәк ки, аның бар булмаска да кодрәтеннән килергә тиеш, югыйсә чыннан да Алланың потенциаль мөмкинлекләре чикләнгән булыр иде, ягъни алдан ук куелган шарт—барлык потенциаль мөмкинлекләр аллада актуальләшә (гамәлгә керә) дигән принцип белән капма-каршылык килеп чыгар иде,—ди ул. Мин шушындый ук сорауны моннан 30-35 еллар элек (Э. Ренанны белмәгән килеш) бер фантастик хикәямдә куйган идем, менә хәзер аңа үзем үк җавап эзлим.

Аллаһ үзенең тулы голограммасына тәңгәл булырга тиеш дигән принциптан чыгып, әлеге сорауга җавап табарга тырышыйк. Бу голограммада, беренчедән, Алла катнашлык кылмый торган галәмнәр дә булырга мөмкин, ягъни үз ирекләренә куелган ул «суверен» галәмнәрне «Алласыз» дияргә була. Яки хәтта, Э.Ренан әйткәнчә, алланың «юклыгын» да фараз итеп була, әмма Алланың голосурәтләре, тулаем алганда, аның үзенә тиң булганга, потенциядә Алла идеясе барыбер эзсез югалмый һәм голосурәттәге орлыктан Аллаһ кабат реальләшә.

Аннары, Аллаһның «юклыгы» асылда ул яраткан бөтен дөньяны юкка чыгарганга, без, күз алдыбыздагы дөньяның фикерләүче әһелләре, шушы гүзәл дөнья белән хозурланып, аны Аллаһның барлыгын күрсәтә торган иң беренче һәм иң мөһим дәлил дип исәпли алабыз түгелме?

Һәрхәлдә мин бу парадоксны Ренан әфәнденең «Алла» идеясен «ябып куя торган» куркынычлы бер «ачыш»ы дип санамыйм.

Борынгы грек философы Эпикур (яңа эрага кадәр 341—270), алланың кодрәте турында уйланып, мондый бер фикер әйтә: «Фәкать өч төрле генә булуы мөмкин: 1) Алла җир йөзендәге явызлыкны бетерергә тели, ләкин көченнән килми; 2) көченнән килә, ләкин бетерергә теләми; 3) бетерергә дә тели, көченнән дә килә.»

Коръәнне тәнкыйть итүе белән мәшһүр татар язучысы Гариф Гобәй борынгы фикер иясенең бу сүзләрен «диварларга алтын хәрефләр белән язып» куймакчы. «Әгәр алла явызлыкны бетерергә тели, ләкин хәленнән килми икән, димәк, ул чикләнмәгән кодрәт иясе түгел. Әгәр хәленнән килеп тә бетерми икән, ул үзе—явызның да явызы. Инде һәм бетерергә тели, һәм хәленнән килә икән, явызлык нигә бетми, явызлыкны нигә бетерми?»—дип, Эпикурның фикерләрен кабатлый безнең бүгенге философ. «Чыннан да, ул чакта алла сугышларны, суешларны, хәерчелекне, көчләүне, төрле бозыклыкларны, җир тетрәү, су басу кебек афәтләрне, дөньяны баскан интектергеч

чирләрне нигә бетерми? Менә бу зирәк акыллы, гаять тә урынлы сорауга 1700 ел буена һичбер дин башлыгының җавап бирә алганы юк әле. Һәм булмас та, аңа җавап бирү берничек тә мөмкин түгел»,—дип яза Гариф Гобәй.

Хикмәт бит шунда: Гариф Гобәй санап киткән каза һәм афәтләр болар шәхсән үзләренә кагылган һәм шул замандагы кешеләр күзлегеннән караганда гына бәхетсезлек. Иртәгесе көнне туган яңа буыннар менә башкача карарга тиешләр, чөнки асылда алар кичәге бәхетсезлек аркасында гына дөньяга килгәннәр. Һәм шуңа күрә бәхетлеләр... Кичәге фаҗигале тарихны белүләре һәм кызгану хисенә ия булулары белән дә бәхетле алар. Капма-каршылык шундый. Бәхет һәм бәхетсезлек, яхшылык һәм явызлык—болар психологик категорияләр, Алла бу тойгыларны,—плюсен дә, минусын да,—берьюлы кичерә дияргә мөмкин, чөнки безнең хис-тойгыларыбыз барысы да анардан.

Битараф аллалар галәм һәм кешеләр тормышына катнашмый дип санаган Эпикурның фәлсәфәсе дә каршылыклы, ләкин ул адәми бәхет ачкычын таптым дип ышанган.

Алланы ябып куеп булмый. Чөнки дөньядагы бердәнбер хакыйкать—ул да булса—Алла (Идея, Информация, Мәгънә).

Тәсаувыфта «Аллаһ» сүзендәге һәр хәреф эчке мәгънәгә ия дип карала. Гарәпчә язылышта «Аллаһ» сүзе «әлиф»тән, ике «ләм»нән һәм «һа» хәрефләреннән тора. «Әлиф» алып куелса, «лиллаһ»—«Хак өчен» мәгънәсе, беренче «ләм» алынса «ләһү»—«Аның өчен» мәгънәсе, икенче «ләм» дә алынганда «Һу»—«Ул» мәгънәсе кала.

Дөресен әйткәндә, мондый «грамматика» миңа бер фикри уен сыман гына тоела, әмма ул барыбер «Алла» идеясенә хезмәт итә торган «күнегү» дип уйлыйм.

Альфред Наке дигән галим: «Фән бер адым алга киткән саен, алла бер адым артка чигенә»,—ди.

Юк, Аллаһ чигенми. Ул да янә бер адым безгә таба атлый. Нәтиҗәдә без Аллаһка якынлаша барабыз.

Аллаһ идеясе һич тә бер «революцион еврей» әйткән «әфьюн» түгел. Бу идея Анабызның күкрәк сөте кебек туклыклы һәм шифалы. Ул безне каршылыклы дөнья кануннары белән килештерә.

«Фәтхулла хәзрәтләре» хикәясен мин (классикларга ияреп): «Керләнгән дөньяны мәхәббәтле Гакыл коткарыр» дигән сүзләр белән тәмамлыйм.

Аллаһны сөюебез белән без илаһи Сәмруг кош көзгесендә үзебезне дә сөябез.

Аллаһны сөю белән Аллаһтан курку арасында математик тигезлек билгесе куярга мөмкин.

Әгәр кальбеңдә Аллаң юк икән, анда әхлак та юк.

Киресе дә дөрес.

Адәми зат өчен Алла—әхлак ул.

♣

Тәфкил
Вафин

# МӘКРУҺЛАР

Янгилде авылы, 1852 ел. Мөхәммәтсабит белән Мәхүпжамалның беренче балалары дөньяга килә. Ул ир бала була, бабалары Мөхәммәтсафа исемне үзе куша: "Мөхәммәтсадыйк булырсың, улым",—дип, исем кушу мәҗлесенә килгән кунакларга ишеттереп бәбинең колагына әйтә.

Мөхәммәтсафа бабай үз нәсел шәҗәрәсенә ир бала өсталүенә аеруча сөенә.

Икенче балалары Мәхүпкамал 1855 елда туа. Аннары Бибикамал (1858) һәм төпчекләре—әтиеменең әтисе Мөхәммәтсафа туа. Әбинең әйтүенчә, 1864 елда булырга тиеш. Мөхәммәтсабит белән Мәхүпжамал балаларының дүртесен дә Янгилде авылының Сатмыш авылына чыгып китә торган урамындагы кырый йортта табып үстерәләр.

## Авыл зурая

Янгилде авылы халкының яртысы—урыслар. Бу хәл мәкруһларны контрольдә тоту өчен поплар һәм патша хөкүмәтенә аеруча унай була. Авылдашларның берсе генә булса да үзенең мөселманлыкка кайтуы турында белдерсә, поплар тарафыннан җавап чарасы күрелә. Андый тәвәккәл мәкруһның әүвәл чәчү җирен тартып алалар. Әлбәттә, мондый эшне Зөя каласыннан килеп эшлиләр. Өяз полиция идарәсеннән жандармнар, хәтта атлы казаклар китерәләр. Мәкруһка түли алмаслык күләмдә салым салалар. Аның атын, сыерын алып чыгалар, буйсынмаганнарны кыйныйлар.

Мөселманга кайткан керәшеннәр "ислам дәфтәренә" керә алмаганнар. Указлы муллалар поплар тарафыннан алдан ук кисәтелеп куелган булалар. Православие динендә саналган Янгилде мәкруһларыннан "ислам дәфтәренә" теркәлгән кеше табылса, бу хәлне башкарган мөселман руханиларын йә Себер, йә төрмә көтә торган була.

Сугыш еллары. Озын кышкы кичләрдә ир-атлар (яше, карты, бала-чага), каравыл өенә килеп, сөйләшеп утыралар иде. Бигрәк тә картлар үзләренең аталары, хәтта бабалары сөйләгәннәрне сөйләргә ярата иделәр. Җәлил абзый сөйләгәннәр истә: "Минем әтине, никрут булып житкәч, Зөя каласына башка иптәшләре белән бергә чакыра торган булганнар, солдат булырга әзерләгәннәр. Сафка тезеп, урысча фамилияләрен кычкыралар икән. Җавап бирүче юк. Офицер, берничә мәртәбә кычкырып та, дәшүче булмагач, татарча исем-фамилияләре белән дәшәргә мәҗбүр була икән. Никрут, үз исемен ишетү белән, бар көченә "Я" дип кычкыра икән".

Явыз Иванның халыкка каршы юнәлтелгән сәясәте аркасында фәкыйрьлек төбенә төшкән урыслар, туган якларын ташлап, Урта Идел, Түбән Кама буйларына—элеккеге ханлыкның уңдырышлы җирләренә агылалар. Русия мәмләкәтенең дошманы саналган татар игенчеләре, шулай итеп, ул чакта ачка какланган йөзләрчә мең урыс крестьяннарын үлемнән коткаралар. Чөнки колонизаторлар бай игенчелек традицияләре булган, гасырлар дәвамында ашланган туфраклы төбәккә килеп утыралар.

Казан тирәсендә 40-50 чакрым әйләнәдә татар авыллары бөтенләй юкка чыгарыла—бушап калган татар җирләренә урыслар килеп тула. Әйтелгәнчә, урысларны татар авылларына күчереп утырту XIX гасырда да дәвам итә. Шундый ысул белән күченеп килгән урыс гаиләсен мәкруһның ут күршесе итеп, соңгысын тулысынча урыска әйләндерү нияте өстенлек итә. Янгилде—әлеге максатны

*Дәвамы. Башы 2008 елның 11нчы санында.*

тормышка ашыру өчен сайлап алынган татар салаларының берсе.

1742, 1772, 1818, 1834 елларда уздырылган ревизия мәгълүматларына күз салсак, Янгилде авылында халыкның саны 125-130 кешедән артмавын күрербез. 1834 елда авылда, әйтик, нибары 19 гаиләдә исәпләнгән, 125 кеше (53 ир-ат һәм 72 хатын-кыз) яшәгән. 1850 елда уздырылган халык санын алу мәгълүматлары буенча, 16 ел эчендә Янгилде авылында яшәүчеләрнең саны 2,5 мәртәбә арткан. Халыкның бу дәрәҗәдә үрчүе мөмкин түгел. Димәк, Янгилде халкы күчеп килгән урыс крестьяннары хисабына ишәйгән.

Янгилде авылының алгы урамында татарлар яшәсә, урысларга урын чишмәнең өстәге ягыннан бирелә, соңыннан ул урамны "Каравыл урамы" дип атыйлар. Аларга ул урам гына җитми, Зөя өязенең җир бүлеге чиновниклары килеп, арттагы урамның өске ягын да урысларга бүлеп бирәләр. Бу—авылның ин яхшы җирләре. Татарларга да ир-ат башыннан җир бүләләр, ләкин ул кишәрлекләр урман белән капланган. Җир алган татар агачларны төпләп, казнага тапшырырга тиеш була.

Әтинең бертуган Хәбирә апасы сөйләгәннән: "Мина Ләйли әби болай дип сөйли иде: Бурышлы тавы урманында, хәтта төннәрен шунда кунып ятып, җәй буе агач төбе чыгара идек. Имән агачларын турап урман каравылчысына—стрелокка тапшыра идек. Бөтен гаиләбез җәй буе ат белән төп чыгарып, ике дисәтинәне чәчүлек җиренә әйләндердек".

Патша хөкүмәте күченеп килгән урысларга зур булышлык күрсәтә, аларны татарлардан—булачак авылдашларыннан саклыйлар. Авылда тәүлек әйләнәсенә жандармнардан торган кизү куела.

Идел буйлап төзү материаллары белән саллар килә башлый. Салларны Зөя елгасы буйлап агымга каршы бурлаклар сөйрәп кертә. Борындык авылыннан озын арбалар белән бүрәнәләрне Янгилде авылына ташыйлар. Яңа нарат бүрәнәләрдән урысларга йортлар житкерәләр. Алар барысы да охшаш була. Тәрәзә нәкышләре һәр йортта бер-берсен кабатлыйлар. Йортларның түбәләре калай, сирәк очракта гына такта белән ябыла, аларны сурик буявына буйыйлар.

Рәсәйнең башка губерналарыннан урысларны татар авылларына күчереп утырту көткән нәтиҗәне бирми—урыслаштыру барып чыкмый. Киресенчә, урыслар татарлар арасында яшәп, берничә елдан соң татарчага өйрәнеп житәләр. Ул гынамы, урыс күршеләр, яңа татар күршеләренең унай гамәлләрен күреп, аларны гаиләләренә сеңдерергә тырыша башлыйлар, балаларын шул рухта тәрбиялиләр...

## Иманын саткан җан

Зөя өязе авылларында керәшен татарлары, мәкруһлар арасында да төрле кешеләр яшәгән. Араларында диннәрен саткан җаннар да очрый. Андыйлар, куркаклыклары аркасында, әләкче, гайбәт таратучы, шымчы булганнар, попларның мөселманнарга каршы оештырылган вак-төяк чиркангыч йомышларын үтәүдән ерак китә алмаганнар. Мәкруһлар да, поплар да аларны ике яклап файдаланганнар. Шуның өчен әлеге куштаннар мәкруһларга әллә ни куркыныч тудыра алмаганнар.

XIX гасырның алтмышынчы елларында патша хөкүмәте, поплар һәм башка кара көчләр керәшеннәрнең күпләп мөселманлыкка кайтуларына төрле ысуллар белән комачаулыйлар.

Православие диненнән мөселманлыкка кайтуга өндәүчеләрнең исемнәре өяз халкына да, хөкүмәткә дә, попларга да билгеле була. Соңгылары аларны урыс исемнәре белән беләләр. Мәсәлән, Мөхәммәтсабит (Сабит) Шәрәфетдинов, Әбраретдин Рәхмәтуллин, Габделхәбир Зиннәтуллин, Хәкимулла Талипов—"Василий Иванов из деревни Янгильдино", "Иван Петров, Антон Иванов и Николай Никитин из деревни Азбаба". Кара көчләргә аларның житәкчесе Чәчкаб авылы ишаны Габделлатыйф Алкин икәнлеге дә мәгълүм була.

Ислам диненә хыянәт иттерү нияте белән мәкруһлар арасына килеп кергән керәшен авылдашлар, ачыктан-ачык православие динен мактап, мөселман динен яманлап, мәкруһларны православиеда калырга өндиләр, исламнан биздерергә тырышалар. Алар авылдашлары арасында кайсы мәкруһ мөселман никахы белән

өйләнгән, кайсысы баласын чукындырудан яшереп ята, кем мәетне татар зиратына җирләгән, кем үзенең урыс исемен танымый, сүгенгәндә генә исенә төшерә һәм куллана—барысын да рәсми хакимиятләргә, чиркәү руханиларына житкереп торалар. Аларның исемнәре соң булса да фаш ителде. Үз куллары белән язган шикаятьләре, хатлары Татарстан Милли архивында саклана.

Сугыш чорын, 9-10 яшьлек чагымны бүгенге кебек хәтерлим. Әмәйгел әбиемә тагылып йөрим. Әби дә, узган гомере турында мина сөйләгәндә, картларга хас булганча миннән: "Улым, мин нәрсә турында сөйли идем әле?"—дип сорап куя иде.

Әби хәләл җефете Мөхәммәтвафа (әтиемнең әтисе) һәм аның әтисе Мөхәммәтсабит (әбигә каената) турында сөйләргә ярата иде. Шулай, беркөнне әбигә мондый сорау бирдем: "Әби, нигә безнең Сабит бабайны Себергә сөргенгә җибәргәннәр?" Әби болай диде: "Улым, Сабит бабаның ике каенише бар иде, Гыйлаҗи белән Минаҗи. Алар икесе дә Татар Әҗәлесе авылында яшәделәр. Мин аларны хәтерлим әле". Шуннан мин менә ниләр белдем. Алар икесе дә Мәхүпҗамал әбинең (бабам Вафаның әнисе) энеләре була. Сабит җизнәләре белән аларны дин аера. Сабит бабай, төрле мәсхәрәләүләр, кыйналуларга да карамастан, керәшен авылдашларын иманлы итәргә тырыша. Ә каенише Гыйлаҗи һәм аңа ияргән Минаҗи, муеннарына тәре тагып, Семен һәм Савелий Степановлар булып, "отпавшийларны" (мәкруһларны) православие динендә тотар өчен җан аталар.

Гыйлаҗи Татар Әҗәлесе авылыннан кода Садретдин Ибраһимовның, Мәхүпҗамал кызыннан кала, беренче улы була. Ул иркә үсә. Православие белән кызыксына. Паново чиркәвендә еш була. Энесе Минаҗины да үзе белән ияртә. Минаҗи—Садретдиннең икенче улы. Бу икәү Паново чиркәве каршында Ильминский варислары оештырган школада укый. Уллары чиркәү тәрбиясе алсалар да, әтиләре Садретдиннең исе китми, "Белемнең беркайчан да, беркемгә дә комачаулаганы булмады",—дип җавап бирә торган була.

Сабит, апалары Мәхүпҗамалга өйләнгәндә, тирә-яктагы авылларның базарларыннан эзләп табып, шул каенишләренә ачылмалы-ябылмалы пәке бүләк иткәнен хәтерли. Каенишләре Сабитка ияреп Татар Әҗәлесеннән Янгилдегә киләләр. Ул аларны бертуган энеләре кебек ярата, алар исә җизнәләрен абыйлары кебек якын итәләр. Гыйлаҗи белән Минаҗи көннәр буе Имәлле елгасында балык каптыралар, бисмилласыз ашарга утырмыйлар, әмма соңыннан кяфергә әйләнәләр.

Әтиләре Садретдин Ибраһимов улларының мөселманлыкка кайтуларын таләп итә. Ахыр чиктә ялынып, ялварып карый, ләкин файдасы булмый. Улы Гыйлаҗи хәтта ки поплар, бигрәк тә Колангы побы Виктор Охотин белән дуслаша, попларга булыша, Татар Әҗәлесе, Янгилде, Чүкри-Алан авылы мәкруһларына селкенергә дә ирек бирми, Паново, Колангы чиркәүләре приходларына кергән авыл кешеләре турында попларга хәбәр итеп тора, Коръән эзләтеп мәкруһларның өйләренә тентү ясата. Паново чиркәвенә матди яктан да булышлык күрсәтә.

Татар баласы, мөселман гаиләсендә туып-үскән Садретдин улы Гыйлаҗетдиннең православие диненнән котылып мөселман диненә кайттык дип шатлана-шатлана гыйбадәт кылган мәкруһларга каршы чыгуы акылга сыймаслык хәл.

Гыйлаҗи Казан архиепископы Антоний белән яхшы мөгамәләдә була. Хәтта дуслашып та китәләр. Дус булмасалар, төн уртасында архиепископның тәрәзәсен шакып, йокысыннан уятып өенә керә алыр идеме, ә ул кергән. Тәүлекнең теләсә кайсы вакытында Зөя өязе исправнигы Лавровның да кабинетына йә өенә барып керә алган. Вице-губернатор Розовта да кунак була алуы билгеле. Вице-губернаторга язган "Докладная записка"сында Гыйлаҗи үзе туып-үскән Татар Әҗәлесе авылы кешеләреннән яклау сорый. (ТР МА.- Ф.1.- Тасв.3.- Сакл.бер.228). «Авылдашларым мине яратмыйлар, мина Паново чиркәве побы ышаныч күрсәткән өчен, чиркәүгә булышканым өчен мине куралмыйлар. Мәсәлән, күптән түгел чиркәү тирәсен койма белән әйләндереп алдым. Авылдашларым мина кагыгалар, чөнки минем ике аягым белән православиедә нык басып торуым аларга ошамый»,—дип зарлана ул.

Татар Әҗәлесе халкы җыенда Гыйлаҗине авылдан куарга дип карар чыгара. Гыйлаҗи шунда ук Казанга китә, мировой посредникны табып, җыен карарын юкка чыгарта. Җае да килеп тора, андый карарны закон көченә кертү өчен авылда

яшәүчеләр 500дән дә ким булмаска тиеш икән. Ә Татар Әҗәлесендә 300 кеше генә яшәгән. Хәер, карарны барыбер үтәмәгән булырлар иде.

Архиепископ Антоний Гыйлаҗидән килгән "Докладная записка»ны укып чыгу белән әйтеп торып губернатор исеменә хат яздыра. «Гыйлаҗи алган йөкләмәләрен намус белән үти, жаны-тәне белән православие диненә бирелгән. Авылдашлары тарафыннан гаделсез кыерсытылган, яклауга бик мохтаж... Губернатор Галиҗәнапләре, керәшен татары Семен Степановны православие дине хакына үз канатыгыз астына алсагыз иде. Кичекмәстән күмәк көч белән Семен Степановны яклап тәгаен чаралар күрергә кирәк»,—дип яза архиепископ.

Милли архив документларында ни сәбәпледер Минаҗи (Савелий Степанов) исеме очрамый. Күрәсең, ул абыйсы Гыйлаҗи янында ярдәмче ролен генә башкаргандыр.

Губернаторга Зөя өязенең 2нче участогы мировой посреднигы да хат юллый. Ул үзенчә Гыйлаҗинең чын йөзен ачарга омтыла. Гыйлаҗинең Татар Әҗәлесе авылында яшәгән туганнан туган абыйсы Әхмәтша (Николай Иванов) караклыкта, закон бозучылыкта, эш урынын явызларча файдалануда гаепләнә. Эше судта була. Мировой посредник Гыйлаҗине абыйсын яклар өчен генә православие диненә көчен кызганмыйча хезмәт итә дип уйлый. Губернаторга ул болай дип зарлана: "Барлык керәшен татарлары христиан динен тоткан булып, кеше алдында йолаларын башкарган булып маташалар, ә күнелләре белән алар мөселманлыкта. Намазларын калдырмыйлар, качып укыйлар. Ураза тоталар. Чәчләрен кыралар. Татар киемнәрен, түбәтәйләрен салмыйлар. Рус телен белмиләр, бигрәк тә хатын-кызлар. Хәтта үзләренең христиан исемнәрен дә белмиләр, белергә дә теләмиләр. Беркайчан да чиркәүдә булганнары юк. Кыскасы, бу кыргыйларны төзәтер өчен бер генә чара бар. Ул да булса—аларны, кечкенә-кечкенә төркемнәргә бүлеп, урыс авылларына тарату. Көнчыгыш халкы киемнәрен кияргә рөхсәт итмәү. Бу хәлгә урыс крестьяннары чыдап тормаслар... Мондый хәл шулай кабатланып килсә, төзәтә алмаслык зыян киләчәк. Болай дәвам иткәнче, аларның үз диннәрен калдыру хәерлерәк».

Православие диненә армый-талмый хезмәт иткән өчен архиепископ Антоний Гыйлаҗигә көмеш тәре бүләк иткән. Тегесе аны бер дә салмаган, зур горурлык белән йөрткән. Муенында шул тәре булганга Гыйлаҗи, үзе әйтмешли, теләсә кайсы дәүләт учреждениесенең ишеген тибеп кенә ачкан. Гыйлаҗи Янгилде, Татар Әҗәләсе авыллары мәкруһларының йортларында ислам дине китапларын эзләтеп хисапсыз тентүләр үткәртә. Хәер, тентү ясаучылар мәкруһларда борынгы заманнан бирле сакланып килгән дини булмаган китапларны да яндырганнар.

Гыйлаҗи һәр авылда шымчылар булдыра. Авыл кешесе шымчылар күзенә күренмичә генә күрше авыллардагы туганнарына-танышларына да барып килә алмаган. Андыйларны, становойга хәбәр итеп, «кара исемлеккә» теркәп куйганнар.

Авыл халкы Гыйлаҗинең үзен дә күзәтү астында тота башлый. Янгилдедән Татар Әҗәлесенә кайтканда, Сатмыш авылы янындагы Бәхтияр чокырына төшкәч, Янгилденең берничә егете куак арасыннан чыгып, аны атыннан сөйрәп төшерә дә, ярыйсы гына дөмбәсли. Муеныннан чылбырлары белән бергә көмеш тәресен тартып алып, жиргә күмеп куялар. Бу турыда мина 2004 елда 99 яшьлек Хәбирә апа сөйләде.

## Габделлатыйф Алкин

XIX гасырның икенче яртысында Чистай, Спас, Зөя, Тәтеш, Чабаксар, Цивильск өязләрендә бөтен Казан губернасын шаулаткан хәлләр була. Керәшеннәрне агартучы мөселманнар һәм мөселманлыкка кайткан керәшеннәр (мәкруһлар) халыктан тиенләп акча жыялар. Жыелган акчаны Россия императорына, Төрек солтанына, губернаторларга хатлар язу өчен сарыф итәләр. Керәшеннәрне кире ислам диненә кайтырга өндәүне Тәтештә--А. Әлмөхәммәтов, А. Сәмитов, Ш. Шәмсетдинов, Цивильскида—М. Миргазов, Лаешта—Ш. Рәхимов, Кайбычта—М. Шәрәфетдинов, Зөя өязендә Г. Абдюшев оештыра. Тәтеш, Зөя, Буа, Сембер өязләрендә берничә мең чукындырылган татар, янадан ислам диненә кайтырга рөхсәт сорап, императорга

гариза юллыйлар. 58 сумга төшкән бу гаризада түбәндәге юллар бар: "...как деды наши и прадеды были в магометанской вере, а ныне не известно по каким причинам и обстоятельствам проведено крещение в греческое исповедание, а потому по проживании в татарских деревнях не той не другой веры не исполняем, а более привержены к мусульманской вере, а потому, Великий Государь, к тебе прибегаем, как чадолюбивому отцу верноподданных сотвори суд и милосердие и повели нас оставить в магометанской вере".

Әлбәттә, гариза канәгатьләндерелми, ә менә хакимиятнең берничә мең кеше исеменнән гариза язуны оештыручыларны эзләп табуны таләп иткән күрсәтмәсе буенча урыннарда эш киң колач белән җәелеп китә. Алар табыла. Ларион Иванов (Югары Аткозино (Мушки) авылы), Василий Иванов (Мөхәммәтсабит, Янгилде авылы) 30 мәртәбә камчы белән суктырыла. Михаил Васильев та (мөселман исеме мәгълүм түгел) 30 камчы ала һәм гаиләсе белән Тобол губернасына сөргенгә сөрелә.

Бу вакыйга 1867 елның 22 апрелендә Зөя өязе исправнигының Казан губернаторы исеменә җибәргән рапортында чагыла:

"Рапорт

Русские крестьяне деревни Янгильдиной, староста Алексей Иванов Ефим Сафронов, Андрей Григорьев, Алексей Иванов, Лаврентий Кириллов, Гавриил Леонтьев, Фёдор Иванов, Андрей Васильев, Пётр Иванов, Алексей Сафронов, Михаил Гавриилов, Никита Степанов, Архип Фёдоров, Фёдор Феоктисов подтвердили показания Ивана Иванова (Шәрәфетдин.- Т. В.), Леонтия Григорьева из деревни Татарский Азалей, крестьянина Семёна Степанова (Сабитнын каенише Гыйлажи—Т. В.) присовокупив, что главные действующие лица к совращению крещенных татар в магометанство в деревнях Янгильдиной и Чукри-Алановой были одножители их Иванов Иван и сын его Василий, которые в 1866 году с них собрали по 70 копеек с души за ходотайство о переходе в Могаметанство, оставив эти деньги, как они полагают, у себя личности.

Эти весьма влиятельные между крещенными татарами, в особенности Василий Иванов как исполнитель воли отца своего ожесточившие крещенных татар против них, русских, надеясь на свою многочисленность, они грозят по приговору послать в Сибирь почему ходотайствуют Ивановых удалить из среды их и тем водворить мир и спокойство между ними и крещенными татарами и потому заключил сектанта Василия Иванова по явке из отлучки отправить в город Свияжск для содержания при полицейском управлении впредь до особого распоряжения Господина Начальника губернии. Чрезь старосту дер. Янгильдиной на каковой предмет и дать ему приказ и пакет в полицейское управление адресованный, о чем с представлением его дознания и двух постановление донести Господину Казанскому Губернатору.

Свияжский уездной исправник (подпись)"

Каменный Брод авылы мәкруһлары Аит Сәитов җитәкчелегендә, мөселманлыкка кайтырга рөхсәт сорап, губернаторга дүрт мәртәбә үтенеч хаты язганнар. Рөхсәт бирү урынына вице-губернатор Г. Розов А. Сәмитовны кулга алырга кушкан. Ләкин аны тота алмаганнар. Авылларда Эчке эшләр министрлыгының махсус шымчылары югарыда искә алынган кешеләрнең кайчан һәм кая китүләрен, күпме акча җыюларын тиешле урыннарга җиткереп торганнар. Вице-губернатор Г. Розов, миссионер Ильминский, губернатор аппаратының тылмачы морза Дәүләткилдиев 1866 елның 1 октябрендә Зөя өязе З. Кошман авылында тирә-яктагы авыллардан керәшеннәрне (күбесе мәкруһлар) чакырып, зур гына җыелыш оештырып карыйлар. "Котырту"да имам Габделлатыйф Алкинны гаеплиләр. Имеш, ул халыктан җыеп, зур күләмдә акча туплаган, ярдәмчеләре белән һәр авылда христианлыктан мөселманлыкка күчәргә өндәгән. Янәсе, Төркия солтанына ике илче җибәрелгән. Имеш, ул: "Әгәр дә патша хөкүмәте мөселманнарны кыерсытса, керәшеннәрнең янадан мөселманлыкка кайтуына каршы килсә, солтанның Россиягә сугыш белән килүен көтәбез. Император исеменә язылган хат хәзергә җавапсыз. Шуңа күрә керәшеннәр урыс руханиларына буйсынырга тиеш түгелләр, попларны авыллардан куарга, өйләргә кертмәскә кирәк",—дип өндәгән.

Казанда губернатор шымчылары куну йортында императорга һәм төрек солтанына хат язу, киңәшләшү вакытында тугыз кешедән торган төркемне кулга алалар. Төркиядән килгән сәүдәгәр Номен Кушаев бу эштә гаепле дип сорау алуга тартыла, ләкин соңыннан ул аклана. Чынлыкта аның Зөя өязенә кергән Салтыган, Норлат авылларында туганнары Индиковлар яшәгән икән.

Казан губернаторы күрсәтмәсе буенча башка "коткы таратучы"ларны берәм-берәм кулга ала башлыйлар.

Алкин айлар буе Иске Чәчкабка кайтмый, Спас, Лаеш, Чистай якларында халык арасында була. Апрель аенда исә Тау ягының катнаш авыллары Янгилде, Салтыган, Аккужа кебек салаларда күренгәли башлый. Бу хакта шымчылар Зөя өязе приставына хәбәр итәләр.

1866 елның көзендә бу төбәктә зур түрәләрнең булуы кайбер муллаларны һәм аларның аркадашларын өркетә. Танай авылы мулласы Мөхәммәтша Әминов, азанчы Фәхретдин Әлмөхәммәтов, Мамадыш авылыннан мулла Шәмсетдин Мөхәммәтшәриповлар куркып калалар, ә менә Чүти авылыннан Биксолтан Уразгильдиева (Мәхмүт Мургашевның әнисе), Буа авылыннан Гайнетдин мулла нык торганнар. «Себер китсәк китәрбез, ләкин вафат булганнарны мөселманча күмәбез»,—дигәннәр.

Габделлатыйф Алкинның эшчәнлеге нәтиҗәсендә 1865-67 елларда 1721 керәшен христиан диненнән читләшә һәм бу хәл губернаторны да битараф калдырмый. Тирә-як өязләрдә, волостьларда Алкинны эзли башлыйлар һәм губернатор исеменә рапортлар, әләкләр җибәреләә. Мәсәлән, берсендә түбәндәгечә язылган: «Хөрмәтле государь Николай Яковлевич! Сез Галиҗәнапләргә түбәндәгеләрне житкерүне үземнең вазифам дип саныйм. Дөрес чыганаклардан алынган мәгълүматлар буенча, керәшеннәрне янадан мөселманлыкка кайтаруга өндәүче Кошман волостендагы Чәчкаб авылының моннан 30 еллар элек азанчысы булган Абзый-Латыйф булуы беленде. Аның тәгълиматы гади халыкка гына түгел, муллаларга да көчле тәэсир итә. Нигездә ул, Латыйф-сектант, мөселман дине белән бөтен христиан динен берләштереп, халыкларга яңа тәгълимат тарата һәм урындагы полициядән дә берничә мәртәбә ничектер котылып кала. Үзенең көрәштәшләрен арттыра.

Сез Галиҗәнапләргә тугрылыклы, Сезгә баш июче мировой посредник.

1867 ел, 30 март. №377".

Казан губернаторы 1897 елның 1 апрелендә Зөя өязе полиция башлыгына гадәттән тыш хат җибәртә һәм Чәчкаб кешесе Абзый-Латыйф җәһәтендә кичекмәстән тикшерү эшләре башларга боера. Шул ук вакытта губернаторга хәбәр килә: Алкин фикердәше Василий Иванов (Мөхәммәтсабит) ярдәмендә Янгилде һәм Чүкри-Алан керәшеннәреннән 40ышар тиен акча жыйган. Бу акча император исеменә хат язу өчен кирәк, диелгән. Жыелышта ышанычлы вәкилләр сайланган: Ташкичү авылыннан—Аит, Чүтидән—Мәхмүт, Чабаксар өязе Әлмәт авылыннан—Гыйззәтулла, Татар Әҗәлесеннән Максим Петров һәм Иван Григорьев (боларның чын исемнәре мәгълүм түгел). Жыелышта Аккужа (Азбаба) авылыннан Әбраретдин Рәхмәтуллин (Иван Петров), Габделхәбир Зиннәтуллин (Антон Иванов), Хәкимулла Талипов (Николай Никитин), Янгилдедән Мөхәммәтсабит Шәрәфетдинов (Василий Иванов) катнаша. Бу хәлләрнең хаклыгы турында Татар Әҗәлесе авылыннан керәшен татары саналган старшина Николай Иванов, Фәткулла Фәйзуллин һәм шул ук авылдан татар Биккенә Сәфәров гуаһлык итә. Алкинның авылдашы, 70 яшьлек мөселман татар Нәзир Зәетов, Төркия солтанына ике вәкил китүен, император тыңламаса, аның тиздән Казанга килеп урысларны куачагын, императорның керәшеннәрне янадан мөселманлыкка кайтару турында фәрман чыгарачагын, Алкинның Түбән Кошман авылында—Латыйф Сәләхов, Чәчкабта Степан Петров атлы аркадашлары булуын сөйли". Алкин мин сөйләгәнне белсә, миңа яшәргә көн бирмәс, аны кулга алганны Чәчкаб авылы белсә, бик зур тавыш, сугыш чыгачак һәм яшереп калачаклар»,—дип тәкрарлый ул. Аннан бу мәгълүматны куркытканнан соң гына алалар.

1867 елның 30 апрелендә Алкинны берни дә булмагандай "дусларча" 2нче стан приставы аша Зөя өязе идарәсенә чакырталар һәм Зөя төрмәсенә ябып куялар.

Губернатор 1867 елның маенда Зөя полиция башлыгына 3829нчы боерыгын җиткерә. Аның эчтәлеге мондый: Христиан диненнән мөселманлыкка кайтуда гаепле итеп, Габделлатыйф Алкинны, халык арасында хурлыкка төшереп, бүтән телен ачмаслык итеп, керәшеннәрнең каршылыгын тәмам бетереп зур җыен үткәргәннән соң, Турухан ягына олыктыру өчен Казанга озатыгыз.

Шушы боерыкны үтәү йөзеннән өязнең бөтен тирә-як авылларыннан Зөягә муллаларны, керәшеннәрне, мәкруһларны җыялар. Барабаннар кагып, халык алдына богауланган Габделлатыйф Алкинны чыгаралар. Ике атлы казак, бер унтер-офицер, сигез солдат саклавында, барабаннар кага-кага, бөтен шәһәр буйлап пристаньгә илтәләр. Җыелышкан халык алдында полиция башлыгы, аның ярдәмчесе, төрмә башлыгы һәм надзирателе чыгыш ясап, губернаторның боерыгын игълан итәләр. Алкинның Себергә куылачагын, әгәр керәшеннәр мөселманлыкка күчүләрен дәвам итсәләр, аларны да шулай ук Турухан якларына олактырачакларын әйтәләр һәм үзләре дә Алкинны пристаньгә кадәр озата баралар. Шушы җыен турында пристав һәм өяз исправнигы губернатор исеменә 1867 елның 6 маенда 473нче хат җибәрәләр, халыкның шау-шу куптармыйча гына авылларына таралуларын әйтәләр.

Башта Алкин белән бергә җигелеп йөкне тарткан, әмма куркуга төшкән Танай авылы мулласы Мөхәммәтҗан Әминов, Мамадыш-Әкил муллалары Шәмсетдин Мөхәммәтшәрипов һәм Шәмсетдин Шәрәфетдинов, Зур Кошман мулласы Шәрәфетдин Фәхретдиновлар үз мәхәлләләрендәге мөселманнарны, мәкруһларны Зөягә җибәргәннәр. Ни өчендер Кошман волосте писаре Николай Филиппов-Соколов һәм старшина Федор Сычуев Алкин ягында булганнар. Шул ук вакытта Колаңгы побы Виктор Охотин да керәшен балаларын чукындырмавын Алкин исеме белән бәйләмичә, турыдан-туры Эчке эшләр министры Розинга хат җибәргән һәм керәшеннәрнең мөселманлыкка кайту сәбәбен аларның үз әби-бабаларына тугрыклы булулары белән аңлаткан.

Зөя өязе исправнигы, Алкинны тикшерүен тәмамлап, 2 майда янә бер рапорт тапшыра. Югары Осланнан Иделнең икенче ягына—Казанга чыгарганда Габделлатыйфны улы Сөнгатулла каршы ала һәм Юнысовларны, Апанаевларны күрүе, аларның киңәше буенча әтисенең чирләгә сабышырга тиешлеге, шуннан соң аны хастаханәгә салачаклары һәм бер-ике атна эчендә государь императорга хат яздырып, җавабын да алып, һичшиксез Себергә озатудан коткарып калачаклары турында әйтә. Конвойны озатып барган, татар телен яхшы белгән Алексей Медведев бу хакта ишеткәнлеген хәбәр итә.

Димәк, Алкинның дошманнары гына түгел, дуслары, фикердәшләре дә күп булган. Чыннан да, төрмә табибы һәм экспедиция җитәкчесе Богданович аны хастаханәдә калдыра. Ләкин губернатор, Зөя өязе полиция башлыгыннан әлеге хәбәрне алгач, Богдановичка Алкинны тиз арада билгеләнгән урынга җибәрергә боера. Үз чиратында ул губернаторга арестантларның Түбән Новгородка килергә тиешле махсус баржа белән шушы көннәрдә, ягъни 14 майда озатылачагын вәгъдә итә һәм Габделлатыйф Алкинны чираттагы экспедиция белән, бернинди суд карары чыгармыйча гына, сөргенгә озаталар Ул Енисей губернасына җибәрелгән була. Шуннан югары даирәләргә үзенең судсыз-нисез сөргендә ятуы хакында күп мәртәбәләр хәбәр җиткерә. 1871 елның 26 апрелендә император исеменнән килгән 2247нче хат Казан губернаторына тапшырыла, аңардан Алкинны янә Казанга кайтару хакында нәрсә уйлавын хәбәр итү сорала. «Габделлатыйф Алкин бик тырыш кеше! Православиедән мөселманлыкка кайтаруда ул гына гаепле. Аның һәрбер өяздә, волостьта, авылда көрәштәшләре бар. Аны кайтару мөселманлыкка кайтуны тагын да көчәйтәчәк һәм бу христианлыкны ныгыту урыннардагы администрациянең эше генә дигән агитациягә юл ачу булыр иде»,—җавап шундый була.

Габделлатыйф Алкинның туган ягына кайту-кайтмавы төгәл генә ачыкланмаган. Тикшеренүләр дәвам итә. Аның соңгы елларда Санкт-Петербургта яшәве хакында имеш-мимешләр бар. Кайбер чыганакларда Турухан краеннан сөргеннән кайтмавы әйтелә.

## Алкинның ярдәмчеләре

Казан губернаторы 1867 елның 6 маенда Эчке эшләр министрлыгына 146нчы, яшерен хатын җибәрә, анда болай диелә: «Мин, Казан архиепискобы Антоний киңәшен тотып, аларның (мәкруһларнын—Т. В.) кайберләренең ничек итеп Алкин агитациясенә бирелүләрен ныклап тикшердем. Шулар арасыннан берничәсенең «Шул магометанский святоша» Алкинга хезмәт итүләрен ачыкладым... «Алкинның беренче ярдәмче Василий Иванов (Мөхәммәтсабит Шәрәфетдинов—Т. В.)— "святоша" Алкин үзе Зөя өязеннән Чистай өязенә чыгып киткән арада аның вазифаларын башкарган. Акхужа авылыннан Әбраретдин Рәхмәтуллин (Иван Петров), Габделхәбир Зиннәтуллин (Антон Иванов), Хәкимулла Талипов (Николай Никитин), Салтыган авылыннан мулла Тажетдин Мөхәммәдъяров—боларның бишесенең дә главный возмутитель, совратительләр икәне күренеп тора.

Санап киткән керәшен татарлары, авылдашларын һәм тирә-як, хәтта Тәтеш өязе керәшеннәрен православиедән ваз кичеп мөселман диненә чыгарга котырталар. Аларның башларын бутап, ялгыш юлга этәрәләр. Үзләренең исемнәре русча булуына карамастан: «Без, «мәкруһлар», җаныбыз-тәнебез белән Мөхәммәд өммәтләре», диләр. Кайсыберләре православиегә күчеп тә, мөселманлыкка кайтасылары килмәсә дә, Алкин тәэсире белән православиегә каршы киләләр. Алкин үзенең чыгышы белән гади крестьян гына булса да, аның акчасы күп. Ул булган акчасын керәшеннәрне мөселман диненә чыгаруга сарыф итә ди. Алкинның һәрбер авылда шымчылары бар. Алар аша ул тузга язмаган гайбәтләр тарата. Янәсе, керәшен татарлары ике илчене төрек солтанына зур гозер белән җибәргән, барлык татар халкын үз канаты астына алуын сораганнар. Янәсе, төрек солтаны татарларны Төркиягә кабул итеп, Рәсәйгә сугыш ачачак. Әлбәттә, бу хәл тиз арада булачак. Төрек сугышчылары урысларны Казан губернасыннан куачаклар, шуннан соң татарларга куркыныч бетәчәк. Урыс патшасы яңа указ кабул итәчәк, керәшеннәр үз диннәре, мөселманлыкка күчәчәкләр. Алкин керәшеннәрнең былтыр Высочайший исеменә бирелгән, мөселманлыкка кайтуны сораган хатына җавап килгәнчегә кадәр попларга, христиан руханиларга буйсынмаска, хәтта «өйләренә кертмәскә кирәк», дип өнди. Алкинның мондый чакыруы аның ярдәмчеләре, Акхуҗадан—Антон Иванов (Габделхәбир), Николай Никитин (Хәкимулла), Иван Петров (Әбраретдин), Янгилдедән Василий Иванов (Мөхәммәтсабит) тарафыннан күтәреп алына. Соңгы вакытта чиркәүгә бармыйлар, басу капкасы, чишмә яннарындагы иконалар каршында гыйбадәт кылмыйлар. Янәсе, Высочайшийдан мөселман диненә кайтырга рөхсәт булачак. Урыс хөкүмәте, Казан губернасы буенча православие диненнән мөселман диненә күпләп кайтулар Мөхәммәд диненә кайтырга өндәүчеләр, ягъни котыртучылар (подстрекатели отпавших крещенных татар) этаплап Көнчыгыш Себергә, Турухан краена чиратлап озатылып торсалар да, татар мөселманнарының үз ата-ана, ата-бабалар диненә күпләп кайтулары дәвам итә...»

Жирле хакимиятләр һәм поплар бу хәлләрдән соң аз гына булса да хәлне йомшартырга тырышалар. Алар югарыдагыларга ялган мәгълүматлар бирәләр. Ришвәткә алданып, чиркәүгә килүчеләрнең саннарын күпертеп күрсәтәләр. Үлгәннәр татар зиратына җирләнмәде, никахларның күбесе православие, ягъни чиркәү законнарына таянып башкарылды дип берсен-берсе алдыйлар. Яңа туган татар балаларга да «святое крещение ясап, «крестный отец», «крестная мать» билгеләп, чукындыру чиркәүләрдә башкарылды дип түрәләренең башларын бутыйлар. Бу хакта Казан архиепискобы Антонийга да житкерәләр. Антоний икеләнеп тормый, өязләрдә, волостьларда һәм чиркәү приходларында тикшерүләр алып бару өчен комиссияләр билгели. Комиссияләрне губерна буйлап командировкаларга җибәрә. Антоний карамагында булган чиркәү әһелләре руханиларны үз карамакларына алалар. Нәтиҗәдә бер-берсен тикшерәләр. Зөя өязе православиедән мөселман диненә кайтучыларның күплеге белән аерылып тора. Бер Янгилде авылында гына да мөселманлыкка кайтучыларның саны 154 кешегә житә. Антоний бу мәкруһларны янадан православиегә кушу нияте белән бирегә каты куллы саналган, Зөя өязенең Богородский соборының протоиерее Петр Фальковны җибәрә. Фальков архиепископ

Антонийга Янгилде авылындагы хәлләрнең дөреслеген раслап хат җибәрә *(ТР МА.—Ф.1.—Тасв.3.—Сакл. бер. 228.—Б. 125.).* Архиепископ Фальков хаты белән танышкач, 1867 елның 29 июлендә Казан губернаторына донос яза: "80 йорттан торган Янгилде авылының яртысында урыслар яшиләр. Чукындырылган татарлардан 154 кеше 2-3 ай эчендә православие диненнән төшеп, Мөхәммәд диненә кайтканнар. Петр Фальков тырышлыгы белән 14 ирне һәм 19 хатын-кызны—барлыгы 33 җанны яңадан православиегә күчердек. Протириерей Фальковка шактый гына көч куярга туры килә...» Әлбәттә, архиепископ Антоний Фальковның нинди көч куйганын белә. Фальков Казаннан бер дистәдән артык жандарм алып килә. Башта Колангы чиркәве побы белән каравыл өе янында җыен җыя. Теге 154 кешене яңадан православиегә кушылырга үгетләп карый. Файдасы булмагач, куркыту-янау юлына баса. Алай да барып чыкмагач, мәкруһ авылларының берничәсенә "тәре походлары" оештыра. Бу түбәндәгечә гамәлгә ашырыла. Башта чукындырырга дучар ителгән мөселман тирәягыннан, басып торган җиреннән, чишмәләреннән, котүдәге сыерыннан, өеннән, өстенә кигән киемнәреннән, җиккән атыннан, урамда үсеп утырган өянкеләрдән читләштерелә—аларга поп су бөркеп чыга. Әлбәттә, бу жандармнар, приставлар күзәтүе астында эшләнә. Аннан соң үгетләү башлана. Шулай да, әйткәнемчә, Янгилде авылындагы 154 мәкруһның 33ен генә җиңә алалар. Алары да күңелләрендә мөселман булып кала.

Янгилдедән соң Фальков поп Владимирский белән Ульянково авылына (хәзер Кайбыч районы составында) килә. Бу авылда бер генә мәкруһны да кире православиегә куша алмыйлар. Шул ук көнне Фальков, руханилар Владимирскийны, Сухорецкийны һәм становой приставны ияртеп, соңгы берничә ай эчендә халкы мәкруһларга әверелгән Олы Кайбыч авылына килә *(кара: ТР МА.—Ф.1.—Тасв. 3.—Сакл. бер. 228.—Б.125).*

Әлбәттә, П. Фальковны Олы Кайбычта да сагынып көтеп торучы табылмый. Авылда карт-корыдан гайре беркем дә булмый. Халык печәнгә төшкән. Шул сәбәпле, авыл старостасы тарафыннан оештырылган җыенга бик аз кеше килә. Алай да Фальков буш кул белән кайтмый, шымчылары һәм жандармнар ярдәмендә 11 мәкруһны тотып, чиркәүгә алып бара һәм, үзләре әйтүе буенча, «православие диненә кушалар». Бу 11 кешенең 5есе генә урыслар таккан исемнәрне хәтерли, башкалары оныткан булалар. Аларга, камчылар белән урысча исемнәрен исләренә төшереп, кат-кат кабатлатып, чиркәү кенәгәсендә яңартып язып куялар.

Протоиерей П. Фальков Олы Кайбычтагы нәтиҗәләргә генә риза булмый, гаепне чукынучыларның үзләреннән эзли. Янәсе, яңадан чукынырга теләүчеләр миссионерларга булышмаганнар, комачаулаучыларга каршылык күрсәтә алмаганнар. Ул уңышсызлыкны отставкадагы солдат Иван Яковлев (чын мөселман исеме мәгълүм түгел) белән аның ике улыннан күрә. Фальков Казан архиепископы Антонийга болай дип яза: "Отставной солдат Иван Яковлев, который имел большое влияние на своих одножителей, запрещал им склоняться на их увещания. О таких действиях отставного солдата и сыновей его донесено местным священником уездному исправнику". Хатында ул Зөя өязе мәкруһларын яңадан православиегә кушуның уңышсыз булуын да бәян итә. Шул ук вакытта документның хисап тоту өлешендә бөтенләй башка төрле мәгълүмат бирелә. Әлбәттә, саннарның андый нәтиҗәсен командировкадан кайткан чиновник отчеты дип аңларга гына кала. Антоний: «Всех же в Свияжском уезде из отпадших крещенных татар в магометанство присоединены им, протоиереем Фальковым, с приходским духовенством к православию 263 души обоего пола и посвящена святым крещением 11 младенцев»,—дип раслый. Әлбәттә, бу күрсәткечләр губернатор алдында аклану өчен генә китерелә, алар күпертелеп бирелә. Фальков Зөя өязендәге мәкруһларны православиегә күндерү вазифасын гына үтәми, ул өяз житәкчеләренә, чиркәү руханиларына күрсәтмәләр дә бирә. Аның уйлавынча, мәкруһларның мөселман динендә калуны сорап императорга язган хатларына җавап алынганчы аларны православиегә яңадан кушу мөмкин булмаячак. Архиепископ Антоний да мондый нәтиҗәгә килә: "Все отпавшие крещенные татары везде заявляли, что дело их о переходе в магометанство еще не решено и на прошения их отказа еще не последовало, в доказательство того

ссылались на то, что их поверенные в настоящее время находятся в тюрьмах в ожидании себе решения. Необходимо созвав из каждой деревни, где есть крещенные татары, отпавшие от православия к магометанству, в местное волостное правление пятидворных и сельских старост, объявить в присутствии всех членов правления с подписного о том что в просьбе их перехода в магометанство отказано и самая просьба их как не законная возвращена назад".

Алкинны сөреп кенә эш бетми әле, аның яраннары, агитаторлары кала. Православие диненнән мөселман диненә кайтучыларның саны арта бару аларның тырышлыгы нәтиҗәле булуын күрсәтә. Зөя өязе мәкруһлары арасында алып барылган эшнең башка өязләрдәгегә караганда да көчлерәк булуын хакимият тә таный. Зөя өязенең Городище авылы татары Гыйсмәтулла Әхтәмов белән Аккужа авылыннан мәкруһ Ларион Петров (чын исеме мәгълүм түгел) Алкин иректә чакта ук тирә-як авылларны йөреп чыгып, икеләнүчеләрне миссионерларга каршы торырга өйрәтәләр. Алар өндәве белән янадан исламга кайтучыларның киләчәктә берсе дә икеләнмәгән, мөселман диненә бервакытта да тап төшермәгән.

Түбәндә саналачак шәхесләрнең чын, мөселман исемнәре мина мәгълүм түгел, алар барысы да тәвәккәл, батыр кешеләр булганнар: Фока Андреев, Егор Фролов, Григорий Яковлев (Карамасар авылыннан), Евдоким Феодоров, Павел Тимофеев, Максим Михайлов, Иван Михайлов, Сергей Никитин (Югары Аккужа), Федор Игнатьев, Степан Игнатьев, Моисей Павлов ("деревни Шигаевой"), Артемий Гаврилов ("деревни Имелля Буртасы"), Федот Семенов, Егор Васильев, Иван Михайлов ("деревни Сатламышевой"). Урыс хөкүмәте тарафыннан рәнҗетелеп, миссионерлык эшенең ачысын татыган бу бабалар рухы безнең барыбыздан да олы ихтирам һәм дога көтә. Алар «замечены в подстрекательстве, в склонности к упорству и как сами они стремятся к магометанству» дип күрсәтелә. Шул "җинаятьләр"не күздә тотып, архиепископ Антоний губернаторга мондый киңәш бирә: "...было бы очень полезно всех подстрекателей и агитаторов выслать из места жительства туда, куда найдет нужным правительство" *(ТР МА.—Ф.1.—Тасв.3.—Сакл. бер. 228.—Б.131).*

Керәшен татарлары арасыннан хак дингә өндәүчеләр артканнан-арта бара. 63 гаиләле Сатмыш авылында 62 гаилә мөселманлыкта булсалар, бердәнбер Иван Михайлов гаиләсе керәшеннәр булып санала. Ул гаилә 1834 елда "үз теләге" белән чукындырылган була. Менә шул керәшен Михайлов та Иван Алкинның агитаторы булып китә.

Казан губернаторы 1867 елның 6 маенда Эчке эшләр министрына юллаган 146нчы хатында болай ди: "Алкин агитациясе турында мина Казан архиепископы Антоний донос ясаган иде инде. Зөя өязенең керәшен татарлары күптән православиедән төшеп калганнар, алар тыштан гына православие динендә булган булып кыланалар, ә күңелләре белән Мөхәммәд динендә, шуңа күрә «магометанский святоша»дан котылмый торып хәлне үзгәртеп булмаячак". Губернатор күрсәтмәсе: «Признав настоятельно необходимым немедленно удалить Алкина из места жительства как весьма опасного ловкого совратителя крещенных татар, я на основании секретного предписания Вашего Превосходительства от 28 января 1867 имея в виду, что Алкин включен в список лиц предназначенных к выселению из Казанской губернии и что он по сохранившимся сведениям по настоящее время находится на свободе, сделал распоряжение о немедленном выселении его из места жительства в Туруханский край Восточной Сибири. Но как с удалением Алкина останутся приверженцы его, из совратителей в магометанство наиболее влиятельные из крещенных татар: Антон Иванов (Габделхәбир Зиннәтуллин), Николай Никитин (Хәкимулла Талипов), Иван Петров (Әбраретдин Рәхмәтуллин), Василий Иванов (Сабит Шәрәфетдинов)..."

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# БЕЗ КИЛМЕШӘК ТҮГЕЛ!

*Башкорт милләтчеләре соңгы елларда Башкортстанны 130дан артык милләт яшәгән төбәк дип түгел, ә "башкорт иле" дип саный һәм шуны һәркемнең аңына дыңгычлап тутырырга тырыша. Барлык житәкче вазифаларга башкорт милләтле туганнарыбыз тәгаенләнә, алар, һәр өлкәдә, һәр эштә башкаларның төшенә дә кермәгән өстенлекләргә ия. Ә калган халыклар биредә килмешәк һәм башкорт туганыбызга биредә яшәткәне өчен рәхмәт укып кына, шөкер кылып кына торырга тиеш булып чыга. Ә татарлар Башкортстан шартларында хакимияткә йә сайлаулар алдыннан тавыш өчен генә, йә халык исәбен алганда башкорт санын арттыру өчен генә кирәк.*

*Әлбәттә, башкорт булу Башкортстанда советлар чорыннан ук отышлы иде. Шуна күрә дә кайбер татар зыялылары, башкорт булып язылып, үз тормышларын шактый жайлады. Шул ук шагыйрьләрне, сәнгать әһелләрен генә алсак та, алар башкортча ижат итәргә мәжбүр булды. Әйе, Башкортстанда башкорт булып йөрү электән дә мактаулы иде. Ләкин соңгы егерме елга якын вакыт эчендә башкорт булып язылу һәм башкортка хезмәт итү аеруча көчле хуплауга лаек була башлады. Чөнки башкортлаштыру рәсми хакимият дәрәжәсенә менгән зур сәясәткә әверелде.*

*Башкортстан шартларында татарга милләт буларак бетү яный. Бу һич кенә дә арттыру түгел. Гәрчә Башкортстан житәкчеләре, жае чыккан саен, республикада һәр милләткә үзен саклау, үстерү өчен барлык шартлар тудырылган дип шапырынырга яратса да. 2007 елда Уфада татар гимназиясе өчен дип төзелеп бетеп килүче бина жимерелде. Татар эшкуары Рамил Бигнов бинаны, Габдулла Тукай исемендәге татар гимназиясе булачак дип, татар милли оешмалары карамагына тапшырган иде. Әмма Уфада татар балаларына уку өчен мөмкинлекләр болай да житәрлек дип, аны өч көн эчендә жимертеп ташладылар. Дүрт катлы бина сыктап-елап гөрселдәп ауды.*

*2008 елгы уку елы башланганда, Бәләбәйдәге данлыклы татар гимназиясе дә каты басымга дучар булды. Хәер, аның директоры Нурмөхәммәт Хөсәенов мона кадәр дә берничә ел дәвамында һәртөрле хәсетлекләргә каршы көрәшеп, әллә күпме мәхкәмәләрдә жиңеп чыккан иде. Әмма хакимият мөмкинлекләре белән сынар директорның көче бермени инде?.. Республикадагы бу бердәнбер чын мәгънәсендәге татар гимназиясе сәнгать юнәлешендә эшләүче белем учагы иде. Хәзер ул менә шул сәнгать юнәлеше статусыннан мәхрүм ителә. "Бәләбәй шәһәре хакимияте белән гимназия арасында әлеге статусны саклау турында килешү булуга да карамастан, безне бу дәрәжәдән мәхрүм итә башладылар,—ди гимназия директоры Нурмөхәммәт Хөсәенов.—Шуның аркасында без 10 мөгаллимне кыскартырга мәжбүр булдык. Әле тагын берничә кешене кыскарту таләбе куелды. Моны мин безнең гимназияне кысуның яңа бер ысулы дип күрәм".*

*Башкортстан татарлары үз-үзләрен саклауда башка бер жирдән дә ярдәм көтә алмый. Татарстандагы татар оешмалары да, андагы рәсми хакимият тә биредәге милләттәшләрне яклап сүз әйтми.*

*Башкортстан татарларының егермегә якын жәмәгатьчелек оешмасы вәкилләре 2008 ел азагында менә шундый шартларда бергә жыелып, үзләренең киләчәктәге максат-бурычларын барлады, фикер алышты.*

*Элек милли мәсьәләләрдән читтәрәк торган эшкуар Рамил Бигнов Башкортстанның татар милли оешмаларын бер йодрыкка туплау жәһәтеннән зур эшләр башкарды. Башкортстан татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе, республиканың Татар конгрессы башкарма комитеты рәисе урынбасары Р. Бигнов үз халкы хакына вакытын да, акчасын да жәлләмәде, татарны яклаганы өчен иң яман "дошман"га әйләнде. Юкса, хакимнәргә "ләббәйкә!" дип кенә торса, үз милләтенә арты белән борылса, иң бай кешеләрнең берсе булыр иде. Ләкин, олы шәхес буларак, Рамил әфәнде көрәш юлын сайлады. Уфада үткән теге жыенда исә ул Башкортстанда гаделлекнең жиңәчәгенә ышануын, татар белән башкорт халкы*

*арасында чын дуслык һәм бер-береңә таяныч булу хисенең ярарачагына ныклы өметен белдерде. Соныннан журналистлар белән аралашканда, Рамил Имамәгъзам улы Башкортстан татарларының киләчәк язмышы турындагы сорауларга җавап бирде.*

**—Рамил әфәнде, "сез бу ел республика татар җәмәгатьчелек оешмалары эшчәнлеге өчен иң кыен елларның берсе булды, дигән идегез. Моның сәбәпләре ни?**



—Сәбәпләр бик гади—һаман да хакимиятнең аяк чалуы. Моңа берничә генә мисал китерү дә җитә. Башкортстан Татар милли-мәдәни мохтариятен һаман да булса теркәтә алмыйбыз. Шул ук вакытта республикадагы Татар иҗтимагый үзәген дә ябып куйдылар. Иҗтимагый үзәк еллык хисап бирмәгән, рәсми теркәлү үтү өчен документлар тапшырмаган дигән кебегрәк буш сәбәпләр таптылар. Шуннан менә килик Башкортстан татарлары конгрессы башкарма комитеты эшчәнлегенә. Моңарчы республикада иң легитим, ягъни хакимиятләр ягыннан танылган шушы шактый дәрәҗәле оешманы да таралу хәленә диярлек китерделәр. Моның да сәбәбе бик гади—аның элекке рәисе Рушан Галләмов һәм башкарма комитетның кайбер әгъзалары ошамады республика җитәкчелегенә. Шуннан соң башкарма комитетны эчтән җимерергә тотындылар.2007 елның декабрь аенда без Татар конгрессының чираттагы корылтаен үткәрдек һәм аның яңа идарәсен сайладык. Ләкин аны да танымадылар. Хәзер инде шундый сүзләр дә ишетелә, имеш, өстәге абзыйлар Конгрессның чираттан тыш корылтаен үткәрергә һәм анда үзләренә ошаган башкарма комитет сайларга исәплиләр икән. Ләкин шуны аңларга кирәк, әгәр татар проблемалары хәл ителми икән, күпме генә яңа Татар конгрессы оештырсаң да, файдасы булмаячак. Дөресрәге, файдасы түрәләргә генә була. Ә татар мәсьәләләрен хәл кылырга теләүче чын милләтпәрвәрләр барыбер каршылык күрсәтергә мәҗбүр була.

**—Башкортстан Татар конгрессы башкарма комитетының соңгы бер утырышындагы төп сөйләшү мәгариф өлкәсендәге хәлләр, татар мәктәпләре тирәсендәге вәзгыять турында барган иде. Анда сез Башкортстанда татар теленә дәүләт теле статусы бирелмәсә, татар мәгарифе тиздән үлемгә дучар булачак, дидегез...**

—Кемнәрдер бу мәсьәләне көн тәртибеннән төшерергә, оныттырырга теләсә дә, әлеге вакытта да, алдагы көндә дә Башкортстан татарлары өчен иң мөһим мәсьәлә, киләчәк язмышны хәл иткән зур проблема булып кала ул тел статусы. Мәгълүм ки, Башкортстан Президенты Мортаза Рәхимов биш ел элек, президент сайлауларында беренче турда җиңә алмагач, икенче турда татарларның тавышын алу өчен, татар теленә дә дәүләт статусы бирү мәсьәләсен хәл кылырга вәгъдә иткән иде. Әмма бу тәнгәлдә бармакка бармак та сугылмады. Башкортстан татар җәмәгатьчелеген әлеге хәл бик борчый. Ил президенты исеменә, шулай ук Башкортстан президенты Рәхимовка бу хакта дистәдән артык хат һәм мөрәҗәгать җибәрелүгә дә карамастан, әлеге проблеманы күрмәмешкә салыштылар.

**—Тел статусы хәл ителмәсә, Башкортстанда татар мәктәпләренең язмышы да аяныч булачак диюне нәрсә белән дәлилләп була?**

—Моңа дәлилләрне тәгаен саннар белән китереп була. Хәтта Сталин хакимлек иткән елларда да Башкортстанда 1530 мәктәптә татар телендә укыту алып барылган. Ә бүгенге көндә республикада татар балалары ана телләрендә белем алган мәктәпләр саны нибары 350гә калды. 2002 елгы халык исәбен алудан соң алар аеруча тиз кими. Ни өчен дигәндә, җанисәп алу барышында хисапсыз алдашулар аркасында, саф татар районнарындагы милләттәшләребез дә "башкорт" дип яздырылды. Илеш, Дүртөйле, Чакмагыш кебек саф татар районнарында 70-90 процентка кадәр халык башкорт санала хәзер. Ә инде алар "башкорт" икән, димәк, нигә әле алар үзләренең "ана телен" өйрәнергә тиеш түгел—мәсьәләне шулай куя хәзер башкорт милләтчеләре һәм республика Мәгариф министрлыгы түрәләре.

Сезгә мәгълүм инде, Башкортстан Дәүләт Җыелышы депутатлары республиканың мәгариф турындагы канунына үзгәрешләр кертте. Аңа нигезләнеп, Башкортстан

мәктәпләрендә укучы барлык милләт балалары да башкорт телен дәүләт теле буларак өйрәнергә тиеш. Шулай итеп Башкортстандагы барлык милләт балалары да башкорт телен мәҗбүри өйрәнә башлады. Бу яналыкка Башкортстан татар җәмәгатьчелек оешмалары баштан ук ризасызлыгын белдерә килде. Ни өчен дигәндә, татар теле белән башкорт теле бер-берсенә шулкадәр охшаш ки, татар балаларына башкорт телен махсус өйрәнеп тору да кирәкми. Аннан сон башкорт телен татар мәктәпләрендә дә кертү татар теле дәресләрен киметә. Гомумән, башкорт телен укыту татар балаларынын телен бутауга китерә. Татар баласы юньләп ни татарчаны, ни башкортчаны белмәячәк.

**—Ләкин Мәгариф министрлыгы хезмәткәрләре башкорт телен укыту татар теле дәресләре исәбенә алып барылмаячак дип белдерә ич.**

—Бу беренче карашка гына шулай. Соңгы өч елда республикада татар телендә укытучы мәктәпләр саны 160ка кимегән. Ә татар телен һәм әдәбиятын өйрәтү исә 200гә якын мәктәптә тәмам туктатылган. Татар теленә мөнәсәбәтнең ни дәрәҗәдә икәнлеген белү өчен гимназияләр санын гына чагыштырып карау да җитә. Республикада дүрт татар гимназиясе бар. Шул ук вакытта башкорт гимназияләре 50дән дә артып киткән хәзер. Хәер, Мәгариф министрлыгы мәгълүматларына караганда, бездә татар гимназияләре дә 11гә җиткән икән. Ләкин бу—күзгә карап алдашу. Моны хәтта безнең Татар Конгрессы башкарма комитеты утырышына бер килүендә Мәгариф министрлыгы белгече Флүсә Назаргулова да таныды. "Кайбер лицейларны, мәктәпләрне тартып-сузып гимназияләр ясарга тырышабыз"—дип серне чишә ул. Чынлап та, ниндидер аграр лицейларны "татар гимназияләре" дип атыйлар. Ләкин алар һич кенә дә милли гимназия таләпләренә җавап бирми.

**—Мәгариф җитәкчеләре раславынча, татар гимназияләре ачу өчен балалар җитешми икән.**

—Чеп-чи ялган бу. Чөнки, нишләп әле башкортлар татардан байтакка аз булып та, алар дистәләгән гимназия ача, ә татар гимназияләре өчен татар баласы җитмәсен ди. Милли гимназияләребезне арттыруга милләтпәрвәр эшкуарларыбыз да өлеш кертә алыр иде. Әмма бу игелекле эшкә дә аяк чалалар. Мәсәлән, мин үзем шәхси ширкәтем өчен төзетә башлаган, гомум мәйданы 2 мең квадрат метрдан артык булган бинаны татар гимназиясенә бирергә карар иткән идем. Әмма хакимият шуны төзетеп бетерүгә каршы чыкты. Башта, Уфада татар гимназияләре бар инде, кирәкми ул, дип белдерделәр. Аннан сон бина санитар таләпләргә җавап бирми дигән сылтау таптылар. Соңыннан, бина рөхсәтсез төзелә дип, аны җимереп үк ташладылар. Хакимиятнең басымы астында мин Башкортстандагы барлык бизнесымны сатарга мәҗбүр булдым. Мине хәзер төрле нахак гаепләр тагып, җәмәгатьчелек алдында карага буяп, республикадан китәргә мәҗбүр итмәкчеләр. Әмма хаклык өчен көрәштә бер адым да артка чигенергә исәп юк. Республикада күп кенә татар милли оешмалары җитәкчеләре йә куркытылып беткән, йә инде очсызга сатып алынган, монысы да сер түгел. Бу шартларда безгә, киресенчә, үҗәтләнеп көрәшергә кирәк.

Мәгариф өлкәсендәге хәлләрнең кискенлеге мәктәпләргә генә кагылмый. Югары уку йортларындагы татар теле һәм әдәбияты бүлекләренә дә тискәре йогынты ясый ул. Башкортстан югары уку йортларындагы татар бүлекләренә укырга керүчеләр елдан-ел кими. Быел да Башкортстан дәүләт университетында, Башкортстан дәүләт педагогия университетында көндезге бүлеккә дә конкурс аз булган. Читтән торып уку бүлегенә алдагы елларда татар талипларын алу бөтенләй дә туктатылырга мөмкин. Килүче юк дип. Татар мәктәпләре бетеп барганда аларның саны кими, әлбәттә.

**—Милли мәнфәгатьләрне яклау, төрле мәдәни чаралар оештыру өчен хәзерге заманда бик күп акча кирәк. Бу җәһәттән Башкортстан татар оешмалары дәүләт ягыннан ярдәм сизәме?**

—Ниткән ярдәм ди ул, аяк чалмасалар да рәхмәт әйтер идең әле. Бер генә мисал китерәм. Бөтендөнья Башкортлары корылтае башкарма комитеты өчен республика хөкүмәте тарафыннан 20ләп кешегә хезмәт хакы түләүле штатлар булдырылган һәм алар Уфа үзәгендәге иң матур бер бинада утыра. Аларга башкортлар яшәгән төбәкләргә бару өчен командировка акчалары түләнә, төрле техника, компьютерлар сатып алу өчен матди ярдәмнәр бүленә. Шул ук вакытта Башкортстан Татар конгрессы башкарма комитеты әллә күпме вакытлар үз эш урыны булмыйча иза чикте. Аптырагач, үзебезнең акчага бер бинада өч бүлмәне арендага алырга туры килде. Аны да төрлечә басым ясап тартып алдылар. Ә инде ниндидер сәфәрләргә

хөкүмәт ягыннан татар оешмаларына акча бүлү дигән нәрсә ике ятып бер төшкә дә керми. Монда инде үзебезгә генә ышанырга. Минем үземә дә көн саен диярлек ярдәм сорап мөрәҗәгать итәләр: йә нинди дә булса мәдәни чара оештырырга, йә Казанга барырга, йә милләт зыялыларына ярдәм итәргә дип. Кулдан килгәнчә ярдәм итәсең инде. Ләкин болай гына милләтне күтәреп буламыни?

Татар җәмәгатьчелек оешмаларына ярдәм итү түгел, дәүләт карамагындагы кайбер мәдәни учакларыбызга да үгисетеп карау гадәти күренеш бит бездә. Республиканың миллионнан артык татары тиешле салымын түли, ә үзенә кирәген сорап та ала алмый. Без ничә еллардан бирле инде Уфа үзәгендәге УЗЭМИК Мәдәният сараен республиканың татар сәнгать әһелләренә тапшыруларын сорыйбыз. Без хәтта ул Сарайны, бюджеттан бер тиен дә алмыйча, үзебез тотарга да әзер. Ләкин шушы гозеребезгә дә колак салучы юк. Мәсьәләне уңай хәл итүдә Татарстанның да ярдәме тия алыр иде. Ни өчен дигәндә, Татарстан белән Башкортстан арасында үзара дуслык һәм хезмәттәшлек турында килешү бар.

Бу ел Башкортстан татарларына киң мәгълүмат чаралары өлкәсендә дә уңай үзгәрешләр алып килмәде. Республика телевидениесендә һаман да шул атнасына 20 минутлык "Рәйхан" тапшыруы белән канәгатьләнергә мәҗбүрбез. Радиода да татар проблемалары хакында тапшырулар ишетермен димә. "Татарстан—Яңа гасыр" телевидениесен дә безгә кертмиләр һаман. Шул ук вакытта Башкортстанның "Юлдаш" каналын Казанда рәхәтләнеп карыйлар, беркем каршылык күрсәтми. Әле менә шул каналның тапшыруларын Россиянең тагын 7 төбәгендә күрсәтә башлау өчен ярдәм бүленүе хакында хәбәр ителде.

**—Әлеге сөйләшүдән чынлап та Башкортстан татарларына һәммә нәрсә көрәш аша гына бирелә икән дигән фикер туа...**

—Аңлаган кешегә бу дөрестән дә шулай. Әлбәттә, авылларда авыр хезмәт белән гомер кичерүче гади милләттәшләребез, шәһәрләрдә яшәгән күпчелек татар халкы, үзенең бүгенгесен генә хәстәрләп, якын киләчәктәге ачы язмышын күз алдына да китерә алмаска мөмкин. Моның өчен күпмедер әзерлекле булу кирәк. Аннан, һәр кеше көрәшче дә була алмый. Ләкин милләтнең үзаңы булырга тиеш. Ә инде үзаңны тәрбияләүдә нәкъ менә татар милли оешмалары һәм татар зыялылары зур эш башкара ала һәм башкарырга бурычлы да.

Без хәзер бер нәрсәгә ныклап инандык—Башкортстан татарларының язмышы бары тик аларның үз кулында гына. Алар бары тик үзләренә генә таяна ала. Моңа кадәр әле без, бербөтен татар халкының зур гына өлеше буларак, күзебезне рухи мәркәзебез Казанга төби идек. Әмма өметләр акланмады һәм акланмас та кебек. Татарстан җитәкчелеге безнең ярдәм сорап мөрәҗәгать итүләрне, аһ-зарларыбызны ишетмәмешкә салыша. Сәбәбе аңлашыла инде, Башкортстан хакимияте белән араларны бозасылары килмидер. Ике тугандаш республиканың рәсми даирәләре сирәк кенә очрашканда, кочаклашып, бер-берсенә җылы сүзләр әйтешеп аерылышалар да ул, тик Башкортстан татарларының проблемалары гына читтә кала. Ярый инде, Татарстанның рәсми җитәкчелегенең Башкортстан түрәләренең хәтерен җибәрәсе дә килмәсен ди. Ләкин бит әле безнең Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты да бар, Федераль Татар милли-мәдәни мохтарияте дә эшләп килә. Алар бит безнең мәсьәләләр белән турыдан-туры кызыксынып торырга тиеш...

Ләкин мин ышанам, мондый хәлләр озакка бармас. Башкортстан татарлары да, башка милләтләрнең җәмәгатьчелеге дә үз хәлен аңлау дәрәҗәсенә җитәр һәм таләпләрне катырак куя башлар. Бәлки әле республика җитәкчелегенә дә милләтләрнең чын дуслыгы өчен хәстәрлек күрүче яңа буын шәхесләр килер. Татар халкы да, чуашы, марые, удмурты да Башкортстанда тиңнәр арасында тиң булып, милли-мәдәни ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерерлек ирекле тормышта яшәүгә лаек. Һәм бу шулай булыр да. Һәрхәлдә, моңа бик тә ышанасы килә. Әгәр Башкортстанда бары тик башкорт халкы гына "беренче сортлы" булып, башка милләтләр, шул исәптән татарлар да кимсетелү хәлендә калдырыла икән, безгә андый "чәчәк аткан" республика кирәкми. Без моңа риза түгел. Демократик илләрдә, Америкадамы ул, Австралиядәме, татар беркайчан да югалмый, үз талантын ачу мөмкинлекләрен ала. Башкортстан да бервакыт шундый төбәккә әйләнер дип өметләнәбез.

**Фәнис ФӘТХИ** әзерләде.
*Уфа.*

# ФАКТЛАР ДӘФТӘРЕННӘН

## Онытмас борын

60нчы елларның башларында булса кирәк, Ташкенттан Казанга Шакир Мөхәммәдъяров килеп чыккан иде. Көннәрнең берендә Хәсән Туфанга барган. Читтән килгән кунак янына сөйләшеп утырырга дип Хәсән агай мине дә чакырган иде. Сөйләшү күп нәрсәләр турында, бик кызыклы булды. Шакир картның хәтере гаҗәп яхшы иде. Ул сөйләгәннәрдән ике нәрсә минем хәтердә калды.

Беренчесе. Тукайның үләреннән алда гына язган "Мөхәррирга" исемле шигыренең Гаяз Исхакыйга багышлап язылган булуын Шакир абзый укып күрсәтә-күрсәтә безгә исбат итте. (Югыйсә без ул шигырьне Йосыф Акчурага багышланган дип йөри идек.) Соңыннан Сәйфи ага Кудаш та Гаязга багышланган булуын раслады.

Икенчесе: Гаяз патша охранкасыннан яшеренеп, качып йөргән чагында берничә шаһит алдында хатыныннан аерылган. Бу хәл җәй көне Идел өстендә кимәдә булган. Гаяз үзенең аерылырга теләвен патша хөкүмәте эзәрлекләгән кеше булуы белән, кулга алына-нитә калса гаиләсенә берниндн авырлык төшмәсен өчен дип аңлаткан.

Шаһитларның берсе Шакир Мөхәммәдъяров булган.

***

Садыйк Дәүләткилдиев кайчандыр юстиция органнарында эшләгән кеше. Хәзер пенсиядә, безгә урам аша гына тора. Менә шул кеше кичә мине урамда туктатып, Сәйдәш турында түбәндәгеләрне сөйләде:

- Сәйдәшне мин беренче мәртәбә 1947 елны, мина туган тиешле Булгаковлар семьясында күрдем. Ул аларга еш кына килеп йөри икән. Ашадык-эчтек. Хуҗа хатын минем алда Салихтан кечкенә кызын музыкага өйрәтүне сорады. Салих риза булды һәм кызны өйрәтер өчен Булгаковларга даими килеп йөри башлады. Акча алмый, бушка өйрәтә иде. Ләкин хуҗа ханым аны килгән саен аш һәм аракы белән сыйлый торган иде... Салих гүя сый өчен генә йөри кебек тоелды миңа. Ахырда түзмәдем, ул киткәч, хуҗаларга әйттем: "Ярамый бу эшегез,—дидем,—шундый зур, хөрмәтле кешене, аның йомшаклыгыннан файдаланып, аракыга яллау—оят!"—дидем. Хуҗа хатын: "Ул бит дәресе беткәннән соң гына ашап-эчә",—дип акланырга тырышты. Ире минем белән килешкән кебек тә булды, ләкин хатыны: "Ул өйрәнгән, аңа кирәк",—дип һаман үз сүзендә кала бирде...

Артист Зәйни ага Солтановны күмгән чакта булды бу... Мин дә үз машинамда зиратка барган идем. Артистны күмделәр, халык таралып бетте... Зираттан чыксам, капкадан бераз читтәрәк Сәйдәш ялгызы гына басып тора. Менә культура министры Хаҗи Рәхмәтуллин, машинасына утырып, Салих яныннан узып китте—Салих баш иеп калды. Министр артыннан ук Вәлиди,[1] Язучылар союзының машинасына утырып, кузгалып китте. Салих аңа да баш иеп калды. Ләкин аларның берсе дә: "Әйдә, Салих абый, утыр, алып кайтабыз" дип әйтмәде. Шуннан соң мин Сәйдәш янына бардым да: "Әйдәгез минем белән, теләгән җирегезгә илтеп куям",—дидем. Ул рәхмәт әйтеп минем яныма кереп утырды. Кузгалып киттек. Ә бераздан борылып карасам, Сәйдәшем әкрен генә җылап бара! Ни булды сезгә, минәйтәм, ә ул бары: "Хурлык, хурлык!" дип кенә әйтә алды. Шулай да мин аның ни өчен җылаганын аңладым. "Төкерегез сез аларга, Салих абый, алар сезнең кисеп ташлаган тырнагыгызга да тормый!"—дидем. Ләкин ул башка бер сүз дә әйтмәде.

**Әмирхан ЕНИКИ**

[1] Салих Вәлиди—Татарстан Язучылар берлегенең җаваплы секретаре—Ред.

Әхмәт
Рәшит

# ҺӘРКЕМНЕҢ... ҮЗ СУКМАГЫ

ХАТИРӘЛӘР

## Болгавыр заман

Укыганда, тормыш шулай расписаниедә язылган кебек җай гына, төгәл генә бара иде әле. Без инде моңа күнеккән, төн уртасында уятып теләсә нинди сорау бирсәләр дә, буталмыйча, тотлыкмыйча җавап кайтарырга өйрәнгән—безне юлдан яздырып, күз буяп, иманнарыбызны какшата алмаслар шикелле иде. Сәер бит, тарихтан имтихан биргәндә миңа, билетымда Иван Грозный үлеп, Романовлар династиясе тәхет тота башлаган чор—болгавыр заман турындагы сорау тора иде. Мин нишләптер ул дәверне әйбәт беләм булып чыкты. Ялган Дмитрийлар, Шуйскийлар, Борис Годуновлар чоры бу. Аннан, бөтенесе тәртипкә салынып, бу хакимлек өч йөз елдан артык чагыштырмача шактый тыныч дәвам иткән. Егерменче гасыр башында исә илдә ниндидер аңлаешсыз буталчыклыклар килеп чыккан...

Әйе, табигатьнең үз кануннары бар. Ул синең календареңа төкереп тә бирми. Тарихчы һәм географ Лев Гумилевка багышланган “Ике гасыр арасында” дигән поэмамда аның пассионарлык теориясенә мөкиббән киткән идем. Хәтергә төшерик: ул билгеләмә буенча, “пассионарлык—ул кешеләрдә биосфера белән бәйләнешле тере матдә энергиясенең гадәттәгедән күбрәк булуы”,—дип искәрмә дә ясаган идек. Үзең үк әле күптән түгел генә “Аң” журналында күргән “Шәрык йоклый” картинасы турында тел тибрәттең түгелме соң?!

Безнең бу җәмгыятьтә кануннар гел-гел үзгәреп тора. Ләкин яхшы якка гына түгел бит. Моннан егерме еллар элек “Родина” кинотеатры янында крем белән ботинкамны ялтыраттырган идем. Ул “Чистка обуви” дигән хананең хуҗасы, беләсеңме, кем булып чыкты?! Ас-си-ри-ец! Аларның кемнәр икәнен әйбәт беләбез—тарих дәреслекләрендә Ассирия дигән куәтле дәүләт, аның беркемгә дә баш ими торган горур халкы турында шактый тулы язылган. Менә шушы дөньяда дан тапкан халыкның бер вәкиле тар гына будкада, минем пычрак ботинкамны чистартып утыра. Аңлыйсыңмы син шуны?.. Бу бит нонсенс, бернинди мантыйкка да сыймый. Казанда алар кавеменнән 200ләп кеше яши икән, үзара аралашалар, кайберләре шул борынгы телләрендә сөйләшәләр дә... Шунысы гаҗәп: бу безнең Татарстан җиренә ничек килеп чыкканнар алар—монысын мин аңлый алмадым.

Билгеле, бер халыкны икенчесе белән чагыштырып булмый. Аның әллә нинди, аңлатып булмый торган сәбәпләре бар. Әнә, Японияд булуым вакытында Токиода яшәүче Таминдар әфәнде Мөхит бик кызык сүз әйткән иде. “Мин сәүдәгәр кеше буларак, дөньяны аркылыга-буйга йөреп чыккан кеше. Беркайда да урам себерүче, чүптә казынучы, кеше ботинкасын чистартып көн күрүче татарны очратмадым”,—дигән иде ул. Нишләп андагы татар әлеге шул ассирияле хәленә төшмәгән соң?..

Күрәсең. Милләт белән милләт арасында да аерма зур. Кайсыдыр ил берничә мең тарихы булган цивилизациягә ия, ә кайсыдыр, чүлмәкчедән күрмәкче, дигәндәй, цивилизациянең суррогатын да цивилизациягә санап йөри. Әле кайчан гына “Без дөньяда иң гадел җәмгыять төзибез”,—дип һәр мөнбәрдән, һәр урам чатыннан лаф ора идек, юлбашчыларга мәңгелек, мәңгелек кенәме, хәтта кояш гомере тели идек.

---

*Дәвамы. Башы 2008 елның 8нче санында.*

Хәзер юлбашчылар да юк... иман—идеология дә юк... хәтта алга чакырып торган байрак та юк... Югыйсә әдәбиятыбызның аксакалы Мәҗит Гафури:

*Хөрлек, тигезлек—*
*Аның шигаре.*
*Һәммә байрактан*
*Тора югары,—*

дип данлаган иде аны.

Минем "Барабыз..." дип башланган бер шигырем дә егерменче гасырның беренче чирегендә хакимлек иткән шул фикерләргә җавап рәвешендә язылды шикелле. Кайбер юлларын гына искә төшерик.

*Өзелгән заманнар чылбыры—*
*Уй үзгә, көч бүтән, юл башка;*
*Каршыда Гамлетча дилемма:*
*Булырга яисә... булмаска.*

*Кайда соң мәңгелек тугры юл?*
*Туасы буыннар ни эшләр?*
*Соң, безнең арада юкмыни*
*Пәйгамбәр булырдай кешеләр?*

*Барабыз...*
*Каядыр барабыз—*
*Төзәлми күптәнге ярабыз;*
*Җир тулы—адашкан адәмнәр.*
*Барабыз...*
*Барабыз...*
*Барабыз...*

Әйе, барабыз шул... Беркемнән дә юл-фәлән сорамый гына барабыз—тик кая барганыбызны гына белмибез. Әнә яһүдиләр Муса пәйгамбәр артыннан ияргәннәр—ул аларны 40 ел буе, күңелләрендә коллык галәмәтләре онытылып беткәнче чүл буйлап йөрткән, әле кичә генә гыйш-гашрәттә, бирәнлектә, кансызлыкта көн күргән Эллада уллары кайчандыр үзләре үк таш ыргытып куган Мария углы Гайсә артыннан ияргәннәр. Ташларга, агачларга, үләннәргә илаһи дип караган гарәпләр, Мөхәммәт галәйһиссәлам байрагына ышыкланып, Иранны, Гыйракны, Мисырны, Алжирны, хәтта Испания һәм Франциянең кайбер төбәкләрен яулап алганнар, анда Ислам динен урнаштырганнар. Дөньяга ни өчендер Карфагеннарны җимерерлек Ганнибаллар, "яса" кануннарын башка мәмләкәтләрдә дә урнаштырырга хыялланган Чыңгызханнар, бар җир шарына хуҗа булырга омтылган Тимерләнләр үз кагыйдәләрен кылыч ярдәмендә урнаштырырга теләгән Атиллалар, пәйгамбәребезнең җәсәден коткарабыз, дип әллә ничә тапкыр алданып Фәләстинә тарафларына "тәре походлары" оештырган Европа хакимнәре, коллар булып колларны көрәшкә күтәрә алган Спартак, инквизиция утларында янган "алтын акыллы" адәмнәр, әледән-әле кабынып торган җидееллык, утызьеллык, йөзьеллык кан коешлар, һәртөрле Наполеоннар, Гитлерлар, Муссолинилар, Чаушескулар, Пол Потлар?..

Ә Ленин, Троцкий, Сталин... Алар да фәрештә затыннан түгел. Ленин бабаң язган һәр күрсәтмәсенең икенчесендә: "расстрелять", "расстрелять", "расстрелять"... Ә Троцкий?! Паникага бирелгән өчен, фәкать адәм баласына хас булган икеләнгән өчен генә дә тезелеп торган солдатларның һәр унынчысын аттырган. Дошманны түгел, үзебезнекеләр, дип саналганнарны... Кызылларны... Ә Сталин? Аның корбаннары миллионнар белән санала.

Без халыкны "тарихны хәрәкәткә китерүче көч" дип атап, зур хата җибәрмибез микән? Нигә соң, әйтик, ничә гасырлык цивилизациясе булган, дөнья мәдәниятенә әллә нинди пәһлеваннар биргән немец халкы тарихның ниндидер бер чиген үткәндә, нәкъ менә Гитлерны байрак итеп сайлаган, аның ахмак идеяләрен яклап үлемгә барган? Тарихка күңелең белән күз салсаң аңларсың—беренче бөтендөнья сугышыннан соң, Версаль килешүе буенча, әллә никадәр колонияләреннән колак каккан, эшсезлектән, тормыш авырлыкларыннан интеккән, мәсхәрәләнгән, хәтта таланган шундый мескен хәлендә нишләргә тиеш иде соң Германия? Тормышның яхшыруын вәгъдә иткән, хәтта күпмедер яхшыруына да ирешкән Гитлерны үз итмичә,

кемне үз итсен ул?! Митингларда тәти сүз сөйли алган Эрнст Тельманнарнымы?

Россиядә дә шул ук хәл бит. Хәзерге надан сәясәтчеләр ул патшаларны, ул императорларны никадәр генә изге итеп күрсәтергә теләсәләр дә, ышандыргыч, кире каккысыз дәлил китерә алганнары юк. Әйтик, шул ук Романовларнын кайсын фәрештәгә тиңләп була? Исәпсез-хисапсыз сугышларда күпме кешенен башына житкән Петр Беренчеме, көненә икешәр-өчәр күлмәк алыштырган, гайрәтле ирләрдән туя белмәгән Екатеринамы. Европада ул чор өчен иң гадел Конституция язган декабристларны аттырган, Себерләргә сөргән Николай Беренчеме, хөр фикергә киртә салган Александр Өченчеме, азгын холыклы Распутин белән әшнәләшеп яшәгән Николай Икенчеме? Кайсы фәрештә аларнын?! Өстәвенә чын мәгънәсендә урыс та түгел бит әле алар. Тикшерә башласаң, урыс каны бер-ике процент кынадыр әле аларда! 1905 елның январенда Сенат мәйданында меңләгән кешеләрне, 1912 елда Лена шахталарында ачтан интеккән халыкны аттырган, Антанта алдында яхшатланыр өчен генә миллионлаган халкын сугыш утына куып керткән Николай Икенчене дә инде Изгеләр рәтеннән санамакчылар. Валлаһи, бу ахмаклыкның чиге-чамасы юктыр.

Ә шәхес культы чорындагы коточкыч вакыйгалар мона кадәр булган гаделсезлекләрнең бер нәтиҗәсе түгелмени? Мостай ага Кәрим әйткәнчә, золымны залим, залимне золым тудыра гына түгел, золым үзе дә золымны тудыра. Крестовниковлар, Булавиннар, Разиннар, Пугачевлар чорында идеологиянең вакыйгаларга бернинди катнашы юк. Кешечә яшәп булмый—шуның белән вәссәлам!.. Һәм ул сәнәккә тотына, мөмкин булса, кулына утлы корал ала, алпавыт утарларын яндыра, үзе күрәлмаган әрәмтамакларны аса, кисә...—авыр тормышының үчен ала. Шулай итеп бер золымны икенче золым барлыкка китерә. Ә революция юлбашчылары—шул форсаттан файдаланучылар—бу баш күтәрүләргә сыйнфый төс биреп, аны теоретик яктан аклаучылар, гомуми буталышка юнәлеш биреп торучылар гына. Алар үзләре беркемне дә асмаган да, кисмәгән дә—һәрхәлдә куллары канга буялмаган.

Мин бу очракта татар халкының шул болгавыр чорда үзен ничек тотканы турында гына уйланам, анын гамәлләрен аңларга тырышам. Әйтик, фажигале 1552 елда 50 мең татарга ни өчен, Иван Грозный гаскәре сафында торып, үз милләттәшләренә каршы сугышырга кирәк булган?

Менә мин аңлыйм. Әдәбиятыбыз классигы йөртелгән Галимҗан Ибраһимов унынчы елларда ук иҗат иткән "Безнең көннәр" романын соңыннан яңа заманга яраклаштырып, үзгәртеп яза. Әле анын анысы бер хәл... Янына хәл белергә дип кенә кергән элекке каләмдәшенә, усал гына итеп: "Әле сине тотып атмадылармыни?!"—дигән җан өшеткеч сорау бирә ул. Һади Такташ исә (!) татар халкының гына түгел, бөтен төрки халыкларның хакын хаклап йөргән, хәтта дөньядагы барлык изелгән, кол ителгән халыкларга да байракчы булган Мирсәет Солтангалиевкә "Син дошманым минем" дип кизәнә, җан дусты Гадел Кутуй "җидегәнчелек"тә шикләнелгәч, анын өстенә әллә нинди гаепләр белән ташлана. Ә Кави Нәҗми? Ә Нәкый Исәнбәт? Хәзер сүздә генә булса да... демократия бит—архивлардан әллә нинди яшерен кәгазьләрне табып алалар.

Татарстан радиосында баш редактор булып эшләгән чорда минем кулга бер әләк хаты килеп керде. Радио тарихын кандидатлык диссертациясе итеп язарга жыенган, КГБ архивларындагы материалларны да өйрәнгән бер журналистым бирде миңа аны. Әле Киров үтерелмәгән, репрессияләр чоры башланмаган. Әле календарьларда—1932 ел гына. Шул хатта утызынчы еллар башында исән булган барлык язучылар диярлек санап чыгыла. Кайсы революциягә чын күңелдән бирелгән, кайсы аңа болай, күз буяр өчен генә кушылган, кайсы буржуаз карашларны яклаган, кайсынын төпле идеологик нигезе булмаган... Хатның авторы кем дип уйлыйсын?! Бөтенебез мөкиббән китеп укыган, классигыбыз саналган... Хәсән Туфан. Миңа кайбер кешеләр аны матбугатка чыгарырга да киңәш иткәннәр иде. Ләкин нигә?..

Без Хәсән ага белән байтак еллар дустанә мөнәсәбәтләрдә идек. Үзе үлгәч, истәлекләр дә язып чыктым. Чын мәгънәсендә шагыйрь, яшәү мәгънәсен философларча аңлаучы зур шагыйрь иде ул! Анын соңгы чор иҗаты, кайбер конъюктур әсәрләре булса да, олпат иде, иң зур эстетик таләпләргә дә туры килә иде. Безнең күп тапкырлар ачыктан-ачык сөйләшеп утырганыбыз булды. Бервакыт

мин аннан нишләп гел-гел яшел кара белән язуының сәбәбен сорадым. Ул, әйтергә микән, әйтмәскә микән, дигән шикелле уйланып торды да: "Беләсеңме, Әхмәт, минем өстән Черек Күлгә әләк яшел кара белән язылган иде",—диде. Мин тагын төпченә башладым, "Ул әләкне кем язганын белдегезме соң?"—дип сорау бирдем. Ул, икеләнеп торды да, "Шәйхи Маннур..."—диде. Мин: "Хәзер аның белән, бернәрсә булмагандай, якын дус булып йөрисез бит..."—дип гаҗәпләнүемне белдергәч: "Тора-бара бөтенесен анларсың әле... Заманы шундый иде бит аның..."—дип кенә куйды. Без башка беркайчан да бу темага кире кайтып сөйләшмәдек.

## Томаннар аръягындагы хыял

...1953 елда юлбашчы үлде, дип кенә, җир дә тетрәмәде, күк тә күкрәмәде. Кешеләр шулай берничә көнлек кайгыны кичереп, күз яшьләрен сөрттеләр дә, гадәти шөгыльләренә керештеләр. Тормыш шул җаена салынган килеш дәвам итте дә итте.

Ә мин үземнән башта кайнаган уйларымны йөгәнләргә тырышып карадым. Ләкин вакыт үткән саен элекке белән бүгенге арасындагы упкын тирәнәя генә бара иде. Аннан... башка сәбәпләр дә булгандыр. Шуна күрә өченче курсны инде тәмамлыйм дигәндә, имтихан һәм зачетларны тапшырмау гына түгел, хәтта курс эшен дә эшләмичә, инглиз теленнән "внеаудиторка" нормаларын да үтәмичә, матди хәлемнен авырлыгын сылтау итеп, университеттан китеп торырга булдым. Ләкин гаризамда "С правом восстановления" дигән сүзләрне кыстырырга онытмадым. 1957 елда безнен группа тагын өч кешегә кимеде. Гулагларнын ачы шулпасын чөмереп кайткан Аяз Гыйләҗев, өченче курсны безнен белән укыды да, беренчедә укыган авылдашы Нәкыяга өйләнеп, тормыш йөген тарта башлады—редакциягә эшкә урнашты. Шактый дуамал холыклы Фасих Хисмәтуллин (шул ук Фаяз Дунай), үзен тәмам әзерлекле санап, журналистика өлкәсен сайлады. Безнен белән ярыша-ярыша газеталарда мәкаләләр дә, шигырьләр дә языштырган Мокатдәс Юсупов та шул юлдан китте. Анарчы группа Фәүзия Борһанова һәм Мәгыйшә Мосавирова белән хушлашкан иде. Мин инде бу вакытта матбугат әһелләре арасында шактый абруй казанган, тәҗрибә туплаган, хәтта "Совет әдәбияты" (хәзерге "Казан утлары") кебек мәртәбәле журналда аллы-артлы ике санда шигырьләремне бастырган, газета-журналларда гына түгел, радиодан да тавышымны ишеттергән "яшь каләм остасы" идем. Шуна күрә үз-үземә ышаныч зур, борын да шактый югары күтәрелгән, һәрхәлдә, нинди булса да берәр редакциягә урнаша аласыма тамчы да шикләнми идем. Ләкин беренче мөрәҗәгать иткән җиремдә ук конфуз килеп чыкты. 16 нчы хәрби заводнын парткомында мине башта әйбәт кенә каршылаганнар, республика матбугатында басылган мәкаләләремне бик җентекләп карагач, мин әдәби хезмәткәр урынына гына дәгъва итсәм дә, редактор булырга кодалаганнар иде. Бер атнадан килергә куштылар. Килдем. Ләкин партком секретаренен карашы 180 градуска үзгәргән булып чыкты. "Син, егетем, бик үк ышанычлы кеше түгел икәнсен,—дип дипломатиясез генә башлады ул сүзен,—без монда белешкән идек, белешмичә булмый, безнен предприятиенен нинди икәнен беләсендер. Университеттагы кешеләр, партизан, диләр сине. Әле беренче курста укыган чагында ук заемга язылу компаниясен өзмәкче булгансын... нинди дә конференциягә сайланып, анда катнашудан баш тарткансын... җәмәгать эшләрендә катнашмый, теләсә нинди тузга язмаган сүзләр сөйләп йөри, диләр..."

Мин коелдым да төштем. Нәрсә әйтим—бөтенесе дөрес... Әйтәләр иде шул аны—бергә укыган һәр биш кешенен берсе КГБ стукачы дип. Партком секретаре хәтта мин инде үзем онытkan нәрсәләрне дә белә торган булып чыкты.

Мина, кабинет ишеген тышкы яктан ябып, чыгып китүдән башка чара калмады.

Казандагы редакцияләр шыплап тутырылган, ә район җиренә минем үземнен барасы килми иде. Аптырагач, Семейгә туганнар янына барып урнашырга булдым. Анда, берәр рәт чыкмасмы, дип майлы буяу белән рәсемнәр дә ясап маташтым (җидееллыкта мәктәп стенгазетасын рәссам буларак та үзем бизи идем бит!)—тик беркемне дә кызыксындыра алмадым. Университетны тәмамлагач, Уфадагы "Кызыл таң" газетасы редакциясенә эшкә урнашкан (хәзер инде ул КДУда татар әдәбияты

профессоры) Марсель Бакиров белән яхшы мөнәсәбәттә идем мин—тәвәккәлләп киттем шунда. Редакторлары Алмаев дигән кеше икән. "Бер буш урын бар безнең, уйлашырбыз",—диде. Без өлкән сабакташым белән редакция каршындагы бакчага чыгып утырдык. Марсель сораша. "Нишләп алай университет хәтле университетны ташлап китәргә булдың әле?.."—ди. Авыз тишек бит, тик тормый. Күрәсең, кайбер канәгатьсезлекләремне дә әйткән булганмындыр. Әмма минем "разночинец" (бу кушаматны миңа А. Гыйлаҗев таккан иде) фикерләрен әңгәмәдәшем хупламаган булып чыкты—мине шул бакчада калдырып, төшке ашка китеп барды. Ә берәр сәгатьтән Алмаев янына керсәм, өскә салкын су койдылармыни?! "Без сине эшкә ала алмыйбыз икән, ул урын турында башка кеше белән сөйләшенгән булган..." Фәлән-фәсмәтән. Мин тагын ярык тагарак янында торып калдым. Алай да вай, болай да вай—кая барсаң да, кара сакалың артыңнан калмый шул. Янәдән, Казанга кайтып, каникуллар вакытында студент халкыннан бөтенләй бушап калган урамнарда киләп сарып йөри башладым. Нәрсәдер эшләргә, бу билгесезлектән чыгарга кирәк иде. Жизни кешедән шактый унайсыз булса да, ялварулы хат яздым... "SOS, коткарыгыз!".

Шулай тагын Семейгә барып эләктем. Сеңел ул вакытта тимер юл вокзалы ресторанында официантка булып эшли, миңа да жизнигә ярдәмче "шабашник" булып, мичләр чыгарышып йөрергә генә калды. Акча ярыйсы төшә—беткән баш беткән, дип, күңел бик тартмаса да, тотындым шул пычрак балчык эшенә. Ә көзгә таба бәхет елмаеп куйды тагын—Семейдә кыска сроклы тимер юлчылар курсы ачтылар. Гади генә кара эш дисәләр дә, таләпләре шактый зурдан булып чыкты. Күзең башка җан ияләре күрмәгәнне дә күрергә тиеш. Төрле хәрефләр, саннар, геометрик фигуралар, төрле-төрле төстәге фонда чак-чак беленерлек булса да, шул хикмәтле китап битен ачуга син анда нәрсә сурәтләнгәнне шунда ук әйтергә тиеш. Бүлмәнең бер почмагына басып, нindидер сүз әйтәләр—син ишетеп, шуны кабатларга тиеш. Әллә нәрсәләр иснәтәләр—шунда ук аның нәрсә исе икәнен чамаларга тиеш—йә янган ис, йә сарымсак исе, йә хушбуй исе, дисең инде. Космонавтлыкка сайлыйлармыни?! Ул заманнарда таләпләр бик зурдан иде шул—укырга теләүчеләрнең уннан берсе генә бу комиссиядән үтә алды. Укыдык. Имтиханнарын бирдек. Без, "өлкән кондуктор" дигән дәрәҗә алып, Семипалатинскидан Рубцовскига яки икенче тарафка—Алейская станциясенә кадәр товар поездларын озатып йөри башладык. Аякта киез итек, өстә телогрейка өстеннән толып, калын итеп сырган чалбар, кулда петардалар, факел-шәмнәр, төрле төстәге флагчыклар, сигнал бирү фонаре, тагын әллә ниләр тутырылган сумка... Поездның соңгы вагонына як-яклап, һәм сигнал яктырткычы итеп куела торган, керосинлы өч лампа һәм... "башмак" дигән шактый авыр тимер кисәге. Анысын, поезд юлда туктап калса, көпчәк астына куярга кирәк. Ул нәмәстәкәйләрнең тулай авырлыгы, һичшиксез, бер поттан артып китә иде.

Шулай да ярата идем мин ул эшне. Син утырган соңгы вагон астыннан тасма булып рельслар сузылып чыга, тәгәрмәчләрнең тигез, бер ритмда шакылдавы, юл буенча тезелеп киткән, тимер юлчылар үзләре генә аңлый торган күрсәткечләр, локомотив узуга, күзендәге яшел төсне кызылга алыштыручы светофорлар, янәшә юлдан каршы якка таба баручы паровозның нәкъ менә син утырган вагон яныннан узганда, сау булыгыз, дигән шикелле, озын итеп кычкыртып куюы нindидер күңелдә романтик хис тудыра, көпчәкләр шакылдаган жайга тамбурда тыпырдап барасы килә иде.

Себер ягы бит (тимер юл үзе дә Турксиб дип йөртелә)—еш кына зәмһәрир суыклар толып эченә дә үтеп керә, каршы искән җилләр хәтта поездның йөрешен акрынайта. Андый чагында җиргә төшеп, ташбака кебек өстерәлеп барган поезд җаена җәяүләп атлыйсың. Кыймылда инде, дигән шикелле буферларына суккалап куясың. Ә ул ашыгырга уйламый да. Без көньяк юнәлешендә 32 мең, Новосибирск ягына таба 28 мең тонна йөк ташыйбыз: агачлар, ташкүмер, нефть, тракторлар, машиналар, цемент, сумала, такталар, кислоталар... Ә кайчакта бөтенләй буш вагоннар—"порожняк". Безгә бигрәк тә авыр составлар ошый—ике паровоз (ул вакытта тепловозлар бик аз иде әле) тарткан поезд 50—55 мең тонналы өстери—шуңа карап безнең хезмәт хакы да арта иде. Бәләкәй тукталышларны сызгыртып, сәлам биреп кенә үтә торган "скорый"ларга да, һәр станция саен диярлек вагоннарын

өләшеп йөргән "сборный"ларга да кызыга идек без. Ә соңгы пунктка барып житкәч, сине кайнар душ, кунакчыл ашханә һәм йомшак караватк көтә—кире якка кузгалганда, син инде әйбәтләп ял иткән, йокыңны туйдырган булырга тиеш. Йокы дигәннән, ана бик нык игътибар итәләр иде. Аракы эчү, исерү турында сүз дә булуы мөмкин түгел, чыраеңда арыганлык галәмәтләре булса да, сине юлга чыгудан катгый рәвештә тыялар иде.

Белмим, хәзер таләпләр ничектер?.. Хәер, инде жилкәләренә авыр-авыр фонарьлар асып, котыпка жыенган шикелле кат-кат киенеп йөрүләр бетте бугай. Ул өлкән кондуктор дигән вазифа да хәзер тимер юллар тарихында гына калды шикелле. Теге чакларда минем эчне пошырганы, мөгаен, баш кондукторның, тиешле кәгазьләр (һәр вагонга аерым документ тутырыла иде бит!) салган күн сумкасын кочаклап, машинист, аның ярдәмчесе һәм кочегар белән гәп сата-сата жылыда барып та, минем—янәсе, шундый "образованный кешенең" бер ялгызы ачык тамбурда жилләп йөрүеннән булгандыр. "Узловой" станциягә житеп, составны башка бригадага тапшыргач, аннан да битәр, әйбәтләп ашап-эчеп, бераз черем итеп тә алгач, "нәчәлниккә" булган ул ачулар басыла төшә иде. Әмма кире юлга кузгалгач, шул ук рәнжү вә каргышлар янәдән баш калкыта да, кабаттан күңелне моңсу уйлар биләп ала иде. Биләмәслек тә түгел: муен тирәсен һәръяклап чуан басты. Суык бабай, калын киез итек аркылы үтеп кереп бармакларны чеметә. Толып булып толыбын жылы тотмый. Үзәкләргә үтәрдәй континенталь климат салкыны ул якларда!

Ә шулай да ул эшемне ярата идем—сонрак шул чакларны сагынып "Паровозлар белән хушлашу" дигән шигырь дә яздым әле.

*Юл читенә басып карап торам,*
*Ә күңелдә шундый моң, сагыш!*
*Таныш паровоз күк сузып-сузып,*
*Ерак калган яшьлек, бир тавыш...*

Гажәп тә, күпмедер дәрәжәдә сәер дә иде ул Семей дигән кала! Бабаларым турында сөйләдем бит әле. Мөгаен, казакъ балаларына сабак бирү өчен кыш айларында шушы ерак тарафларга килеп йөргән Бәхтияр бабам да бу шәһәрне читләтеп үтмәгәндер. Ул чорларда биредә сигезләп татар мәктәбе булган бит—музейларын карагач, башта мин гажәпләнеп тә куйган идем. Казакъларның үзләренә—нибары берәү. Казакъ әдәбияты классигы Абай Кунанбаев, күрәсең, татар мәдрәсәләренең берсендә укыгандыр. Шигырьләрен заманында үзебезчәгә тәржемә иткәндә, мин аның байтак кына саф татар сүзләрен һәм безнең халыкка хас әйләнмәләр куллануына игътибар иткән идем. Шагыйрь Равил Фәйзуллин белән 1987 елда М.Аузовның тууына 90 ел тулу тантаналарына баргач, андагы галимнәр дә шундыйрак фикер әйттеләр. Казакъ халкының бу ике бөек улы, төрле дәвер кешеләре булсалар да, шул бер үк Чыңгыз тау итәкләрендә туып-үскәннәр. Ниндидер тылсымы бардыр, күрәсең, бу жирләрнең—минем биредә яшәвемә утыз ел гомер үткәч, бу якларны тагын күрергә насыйп итте.

...Мин янадан Казаныма кайттым. Элекке сабакташларым инде диплом эшләрен язарга, егетләр хәрби лагерьга барып практик әзерлек курсларын үтәргә—запастагы офицер булырга, ә группадагылар исә алдан чамалап куйган урыннарда хезмәт юлын башлап жибәрергә тиешләр иде. Мин килеп кушыласы группа студентлары, миннән күп дигәндә бер генә яшькә кече булса да, күбесе мине әйбәт белсә дә, яңа коллективка ияләшү жиңелдән булмады. Шулай да мин алар арасыннан үземә фикердәш булырдайларын—Н. Хисамовны, Ш. Садретдиновны, Р. Зәкиевне, Ф. Сафиуллинаны, Ф. Хисамованы якынрак итә идем бугай.

Лекцияләр, семинарлар, зачетлар, имтиханнар, ара-тирә театр-концертларга, кинотеатрларга оештырылган культпоходлар, "Татарстан яшьләре" (ул элекке исемен—"Яшь сталинчы"—үзгәрткән иде инде!) газетасы каршындагы әдәби түгәрәктә Х. Туфан, Ә. Фәйзи, С. Баттал, Ш. Мөдәррис, Г. Хуҗи кебек өлкән буын шагыйрьләр белән очрашулар, яна әсәрләребезне укып үзара сүз көрәштерүләр, язучыларның Г. Тукай исемендәге клубындагы кызыклы очрашулар, ижат секцияләрендәге бәхәсләрдә катнашулар—менә шулай нәрсә белән булса да мавыга-мавыга, көн артыннан көн үтә торды. Шигырьләр дә, мәкаләләр дә язылды. Кызлар

артыннан йөгерергә дә инде шактый остарган идек. Элеккечә җебеп тору юк—туры килсә, чибәркәйләр кочагында йоклап та кайткалый идек. Болай гына, гөнаһсыз гына...

Минем "Беренче мәхәббәт" дигән җырым бар. Исемен әйтмим—хәзер тормышта инде ул. Актаныш ягы кызы. Өч елга якын дуслашып йөрдек без аның белән. Шул чорда күпмедер вакыт мин аны югалтып та тордым—очучы абыйсы һәлакәткә очрап, авылына кайтып киткән булган икән. Университетның бишенче курсында укыганда, бервакыт миңа бер хат килеп төште. "Әле кичә генә радиодан тавышыңны ишеттем—син исәнсең икән бит. Мин, ниндидер Әхмәт дигән кеше баскычтан егылып төшеп, үлгән, дигән хәбәр ишеткәч, синсең дип уйлаган идем. Шул көннән бирле еламаган көнем булмады" дип язган иде ул.

Аннан ул тагын Казанга килде—без кабат очраша башладык. Аралар бозылып китүнең сәбәбе җитди дә түгел шикелле иде. Ул университетның журналистика бүлегенә керергә җыена иде—ә матбугатта басылып чыккан бернәрсәсе юк. Миңа аның өчен бер-ике мәкалә сырлап бирү берни тормый да бит инде. Кирелегем килдеме, идеалист ахмаклыгы башыма китереп суктымы—"Нишләп үзең язмыйсың, сина кереп укыйсы бит" дип дорфарак сүз ычкындырдым. Ул елый-елый китеп барды. Мин исә аны юатыр сүз тапмаганмын.

Мин аны тагын өч елдан соң очраттым. Ничектер шулай телестудиягә эшкә барам. Каршыга ул килә. Җилкәсенә простыняга төргән зур гына бөктәр күтәргән. Ул да туктап калды, мин дә... Бер сүз әйтә алмыйча үзара карашып тик торабыз. Аның күзләрендә шундый моң... Кайдандыр, минем арттан бер ир кешенең дорфа тавышы ишетелде: "Нәрсә терәлеп каттың анда?". Бер сүз дә әйтә алмыйча, шунда ул кузгалып китте. Мин дә юлымны дәвам иттем. Бу соңгы очрашуга инде кырык еллап вакыт үтте. Онытырга да кирәктер. Тик онытып булмый шул. Әлеге дә баягы композитор Сара Садыйкова нык канатлар куйган "Беренче мәхәббәт" җыры да онытттырмый аны.

Хәзер кайчакларда уйлап-уйлап та куям: бәлки вакытында бергә кушылган булсак, бәхетле дә яши алмас идек, ызгышып, талашып та беткән булыр идек. Шунысы сөенечле: гомеремнең мәрхәмәтле һәм бәхетле бер таңында балкыган шул нур һаман да җанны җылытып тора.

## Сикәлтәле сукмаклар

Дипломымның темасыннан да, җитәкчемнән дә уңдым мин. Инде аспирантура тәмамлап, филология фәннәре кандидаты дигән фәнни дәрәҗәгә диссертация яклап, факультетның декан урынбасары булып эшли башлаган Мансур Хәсәнов миңа "Ан" журналында эстетика мәсьәләләре" дигән тема тәкъдим итте. Бу—унынчы еллар басмасы; революциягә кадәр чыккан башка газета-журналлар кебек үк аз өйрәнелгән, яңа шигырь, хикәя, роман-повестьлардан өзекләр бирү белән генә канәгатьләнмичә, үз сәхифәләрендә сәясәт, театр һәм рәсем сәнгате турында да шактый кызыклы мәгълүматлар урнаштырган Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ж. Вәлиди, К. Тинчурин, С. Сүнчәләй, С. Җәлал исемнәре үзләре генә дә игътибарны җәлеп итеп тора иде. Мин көннәремне университет каршындагы Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең әле кайчан гына фикердәшем, сабакташым булган Альберт Фәтхи эшләгән сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә үткәрә башладым. 1912 елдан 1918 елга кадәр гарәп хәрефләре белән басылган журналны актарып чыгу да күп вакытны сорый иде. Аңлашылмаган сүзләр очраса, кайчандыр без "аяклы энциклопедия" дип йөрткән уникаль дустыбызга мөрәҗәгать итә идек. Иске имля укыр өчен башта шактый җайсыз булса да, тора-бара күнектем, хәтта кайбер шәрикъларыма "фәнни консультация" дә бирә башладым.

Җитәкчем "Сиңа оппонентның усалын—Гали Халитны билгеләгәннәр, сак бул!.."—дип кисәтсә дә, диплом яклау уңышлы үтте.

Шулай да минем бу фәнни хезмәтем "сәяси хата" эзләүчеләр күзенә чалынган булып чыкты—аның бу кадәресен күп гомерләр үткәч кенә белдем. "Мәгариф" нәшрияты 2005 елда "История Казани в документах и материалах. XX век" дигән калын гына китап чыгарды. Анда архив киштәләреннән яки "җиде йозаклы" яшерен сейфлардан алынган җиде йозләп чыганак тупланган. Менә шунда 650 нче

номер белән ТАССР Министрлар Советы каршындагы дәүләт куркынычсызлыгы комитетының бүлек мөдире Максютов белешмәсеннән өзекләр китерелә. Н. Фәттах, Ә. Кәримуллин, Р. Нафыйков, Х. Курбатов кебекләрнең фәнни хезмәтләрен тискәре бәяләгәннән соң, ул университет студентларының диплом эшләренә хөкем чыгара—Ф. Миннуллин, Н. Хисамов, Ш. Садретдинов, Х. Зарипов һәм башкаларны мисал итеп китерү белән беррәттән, минем хакта "Студент А. Рашитов, при выполнении дипломной работы на тему "Вопросы эстетики в журнале "Ан" ("Сознание") прочитал 40 произведений и статей дореволюционной литературы, в которых проповедуется теория "чистого искусства", а вопросы национальной культуры излагаются путанно, с неправильных позиций" дип яза. Нишлим соң, бу хакта белми йөрүем хәерлерәк булгандыр. Чөнки диплом имтиханнарын тапшыру да, хәрби лагерьга барып солдат шулпасын чүмереп кайту да узды.

Югары уку йортын тәмамлауны бәйрәм итеп йөргән Сабан туе көне иде бу. Без бөтен сабакташлар М. Горький исемендәге ял паркына җыелдык. Кирәк бит шунда килгән бер чибәр кызга игътибар итәргә! Кирәк бит... Мин Равия исемле кызый каршына басып тел тибрәтә башладым, Ш. Садретдинов аның иптәш кызының башын әйләндерергә кереште. Кызлар, әлбәттә, бездән мөкиббән иде. Бу очраклы очрашу дәвам итәр дә, минем тормышка шактый йогынты ясар дип ул чакта кем уйлаган аны?! Актаныш кызы белән ачуланышкан, башка кызлар белән әле танышырга өлгермәгән чак бит—үзем дә... ике күзем. Яна танышым шактый өлгер булып чыкты—йә берәр иптәшенең туган көненә чакыра, йә берәр җиргә ял итәргә алып бара. Кайчагында ачуланышып араны өзәргә йөрсәк тә, ул мине эзләп таба. Аннан тагын элеккечә дәвам итә иде.

Мин эшкә Апас район газетасына билгеләнгән идем—КПСС Өлкә Комитетының пропаганда бүлегендә, туган якларыма якынрак булсын иде, дигәч, шунда җибәрергә булдылар.

Август уртасында мин Апаста идем инде. Каршылавын әйбәт каршыладылар—"подъемный" дигәннәрен дә түләделәр. Редакциядә минем белән ачылып сөйләшер кеше берәү генә: былтыр Алабуга пединститутын тәмамлап килгән Индус Сирматов кына булып чыкты. Ул хатлар бүлеген житәкли. Редактор Хөснулла Шәфигуллин һәм җаваплы секретарь Галим Шәйхиев әле Казандагы партия мәктәбенең соңгы курсында укып йөриләр, авыл хуҗалыгы мөдире Фәрит Габдрахманов та октябрь башларында шул ук уку йортының "очный" бүлегенә китеп барды. Редактор урынбасары Роза Адаматова—элекке баш редактор Фатыйх абзый кызы—партия бүлеген алып бара, редакция эшендә бик аз катнаша иде. Җыен җитәкчеләр арасында югары белемле ике "эш аты"—Индус Сирматов белән мин генә.

Иң беренче эш итеп миңа врач В.Рыжовның "Ашказаны һәм эчәк авырулары" дигән мәкаләсен тоттырдылар. "Сөреп чыктым" мин моны. Җаваплы секретарь: "Булып чыкмаган бит бу, егетем" ди. Икенче кат эшкәрттем. Анысы да ярамый Галим абыйга. Минем инде тәмам ачу чыга башлады—республика газеталарында да мин язган мәкаләгә бернинди төзәтмә кертмиләр иде югыйсә. Шуннан башны кашып уйлап тордым да, иң беренче вариантны кертеп бирдем. Җаваплы секретарь хәйләкәр генә елмаеп: "Менә бит, булдыргансың",—дип куйды. Менә ничек—мине юри шулай кат-кат сыныйлар икән.

Бер айдан Индус укытучы хатыны Дания белән (алар студент чагында ук өйләнешкәннәр) җәйге ялга китеп барды. Чит-ят җир, сөйләшеп утырырдай танышлар әлегә юк—мин шулай итеп бөтенләй ялгыз калдым. Эш сәгатьләре беткәч тә, үз-үземне кая куярга белмичә аптырый идем.

Шундый күңелсез көннәрнең берсендә Казанга, шул яңа танышым Равиягә шылтыратырга булдым. "Якшәмбе көнне Казанга барам әле, өйдә буласыңмы?"—дидем. Ул шатланып риза булды. Ә анда Казанда, Һади Такташ урамындагы торакта, "кияү егетен" көтеп торганнармыни?! Өстәл тулы ниг ъмәтләр, аракы да шәраб. Бүлмәдә олы яшьтәге бер апа гына бар иде. Ул, чыгып киткәндә, Равиянең колагына: "Кара аны, ычкындырма!" дип күрсәтмә бирергә дә өлгерде.

...1961 елда, өлкән улым Бәхтияр тугач, без Казанга күчеп кайттык. Мин инде язмышыма күпмедер дәрәҗәдә күнгән, һәрхәлдә күңелем ул кадәр ераккә омтылмый да иде. Татарстан телевидение һәм радиотапшырулар комитеты рәисе Михаил Филиппович Долгов, мине студент вакытымнан бирле әйбәт белгәнгә күрә, эшкә

урнашу мәсьәләсендә кыенлык тумады. Әле ул гынамы, ул хәтта мине радиога баш мөхәррир итеп тә куймакчы иде. Минем партиясез булуым гына (ул чакта зур урын биләү өчен КПСС члены булу мәҗбүри шарт иде) комачаулады. Әле бөтенләй таныш түгел яна өлкәдә—моннан ике ел элек кенә ачылган телевидениенең яшүсмерләр һәм балалар редакциясендә эшли башладым. Андагы иҗади йөкнең татарчасын беренче көненнән үк берүзе тартып барырга мәҗбүр булган Әнәс Хәсәнов белән без бик тиз уртак тел таптык—миңа телевизион тапшырулар әзерләүнең кайбер серләрен генә түгел, хәтта шактый катлаулы кинопроектор белән ничек эш итәргә кирәклеген дә ул өйрәтте.

Яна эш урыны, яна һөнәр. Монда да сынатмаска кирәк иде. Мин мәктәп һәм пионер тормышы белән мавыгып китеп, бик илһамланып, эшкә керештем. Башка темаларны ничек яктырта алганмындыр, әмма "Безнең календарь" дигән тапшырулар циклы минем өчен үзенә күрә бер "конек" булды. Фәлән елда фәлән галим туган, фәлән җирдә фәлән вакыйга булган, фәлән шагыйрьнең яки әдипнең түгәрәк датасы... Бер карасаң, аларны бер җепкә тезеп тә булмый шикелле. Әмма бик тырышсаң, була да икән. Мин тапшыруны композицион яктан бер бөтен итеп корырга, төрле вакыйгаларны, шәхесләрне үзара бәйләргә һәм шуның һәммәсенең уртак бер фәлсәфәсен табарга тырыштым. Тәҗрибәм уңышлы чыкты. Летучкаларда ул тапшырулар һәрвакыт унай бәягә лаек булды. Апрель аенда гына бер "ски" килеп чыкты. Сценарийда яшүсмерләргә мөрәҗәгать иткән "...Син Чкаловлар, Коккинакилар, Гагариннар кебек булырсың, ләкин Америка майоры Клод Итерли кебек яна Хиросималарга бервакытта да атом бомбасы ташламассың" дигән җөмлә бар инде анда. Менә шул фикер КПСС Өлкә Комитетының идеология буенча секретаре М. З. Тутаевка ошамаган булып чыкты. Республика радио һәм телевидение хезмәткәрләренең һәм районнардагы радиоинформаторларының зур киңәшмәсендә ул аны зур сәяси сукырлык дип атады, Хрущевның Греция журналистларына: "Әгәр бу ил АКШның атом коралларын үз территориясендә урнаштырса, без борынгы Элладаның ул антик мәдәни истәлекләре юкка чыгар дип карап тормаячакбыз, тиешле отпорны бирә белербез" дигән сүзләрен иң зур дәлил итеп китерде.

Югары дәрәҗәдәге бу чиновник трибунадан әйткән сүзләрнең нәтиҗәсе озак көттермәде. Телерадиокомитет рәисенең миңа рәхмәт белдерү һәм икеләтелгән гонорар түләү турындагы күнелемә хуш килгән әмере иртәгәсен белдерүләр тактасында юк иде инде. Әле ул гына да түгел, мина хәтта гадәти гонорар да түләнелмәде. Әле ярый шундый "зур сәяси хата" өчен үземә шелтә чәпәмәделәр.

Эшемнән мин һәрвакыт ләззәт табам, хезмәттәшләрем белән көн саен аралашып рухи яктан баеп барам, кемнәндер нәрсәгәдер өйрәнәм—һәрхәлдә иҗади үсеш кичерә бара идем.

Кызыклы кешеләр байтак эшли иде анда. Өлкән редакторыбыз Әнәс Хәсәнов бу эштә беренче чирканчыгын тоярга өлгергән—башкаларга да аның тылсымлы әлифбасын өйрәтә алырлык тәҗрибә туплаган иде. Редакциянең художество җитәкчесе, соныннан төрле театрларда эшләп, Тукай бүләге кебек мәртәбәле исемгә лаек булган, төрле мактаулы дәрәҗәләргә ирешкән Гали абый Хөсәенов, хәзер инде бөтен илгә танылган режиссер Станислав Говорухин, баш мөхәррир вазифасын башкарган тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин, шагыйрьләр һәм прозаиклар Рөстәм Кутуй, Рабит Батулла, Рахмай Хисмәтулла, Кави Латыйп, Индус Сирматов һәм тагын бик, бик күпләр—хәер, бөтенесен санап бетерәсеңмени?!—минем якын хезмәттәшләрем булдылар.

1963 елда мине Ленинградка телевидение хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү курсларына җибәрделәр. Андагы коллегаларның әзерлеге бик күпләрне, хәтта кайбер чит ил журналистларын да көнләштерерлек иде.

Мине Ленинград үзенең демократик традицияләре белән дә әсир итте. Хәзер, белмим, ничектер, ул чорларда бу "төньяк башкала" мин күргән мәдәни үзәкләрдән бик нык аерылып тора иде. Бередә тарихыбызның үткәне турында да хурлап сөйләмиләр, үз вакытында патшаларга атап салынган һәйкәлләр дә саклана төшкән, идеологик карашлар мәсьәләсендә дә күпмедер дәрәҗәдә либеральлек өстенлек итә иде. Хәтта көнкүрештәге, кешеләрнең үз-үзен тотышындагы зарур кагыйдәләр дә бик матур үтәлә иде. Таныш түгел берәр җиргә барырга кирәк булса, очраган теләсә кайсы җирле кеше тәфсилләп аңлата, вакыты булса, озатып та куя иде. Транспортка

утырасың булса, рәхим итеп сабыр гына чиратынны көтеп тор, чөнки 5-6 минуттан сина кирәкле трамвай, троллейбус килеп житәчәк. Беркем дә гаепләми дә, тавыш та күтәрми. Сабыр төбе сары алтын. Ниндидер эчке рухи нәзакатьлелек бар иде ленинградлыларда!

## Яңадан... Казанда

Нишлисең, Казан безнең язмышыбыз бишеге бит инде ул. Җәйге ялларга кайтканда, дус-ишләргә: "Әй, сезнең ул Казаныгыз..."—дип эредән генә жибәрә идем дә, менә тагын шунда кайтып егылырга туры килде. Эш мәсьәләсе болай шактый жинел хәл ителде ителүен—мин андагыларга чит түгел идем бит. Радио буенча комитет рәисе урынбасары мина һәрвакыт хәерхаһ булган Ф. Фазылжанов та, язмышымның хәтәр мизгелләрендә нык терәк булган Ленар Жамалетдинов та, элекке группадашым Рим Шириязданов та, ерак Пенза яклары мишәрләре арасында фольклор экспедициясенә чыкканда да, хәтта Г. Камал исемендәге академия театры сәхнәсендә университет һәвәскәрләре куйган спектакльдә (Г. Минскийның "Дуслык чишмәсе" әсәрен сайлаган идек без ул вакыт!) бергә-бергә рольләр башкарганда да дусларча мөнәсәбәттә булган, үзе диктор, үзе актер, үзе баш редактор Рим Кәримов та, башка әллә никадәр танышлар да эшли иде анда ул вакытта. Әдәби даирәгә якынаю, ижат кешеләре белән аралашу күптәнге хыялым иде минем. Ә менә гомернең шактый өлеше Парнас тавы тирәсендә түгел, кырларда, фермаларда, буровойларда, промыселларда, жыен тимер-томыр арасында үтте. Бер караганда, мин моңа үкенмим дә. Чөнки студентлыктан чыгар-чыкмас борын жанга берни бирми торган тәти шигырьләр әвәли башлаган "вундеркиндлар"га минем хөрмәтем шул кадәр генә. Алар барыбер яшәешнең асыл мәгънәсенә төшенеп житә алмыйлар, дөньяның кая барганын аңламыйлар, ясалма гербарийлар мохитында гомер сөрәләр. Аларның ниндидер "атаклы", "мәшһүр", "күренекле" исеме алган зур абыйларга һәм апаларга ышыкланып нәрсәдер маташтырулары мине кызыктырмады да, көнләшү тойгысы да уятмады. Ирешсеннәр соң максатларына: дәрәжәле урын да биләсеннәр, орден-медальләр дә таксыннар, лауреат дигән мактаулы исемнәр дә алсыннар... Алсыннар... Шушы житмеш еллык гомер дәвамында мин инде бернәрсәгә дә гажәпләнмәскә өйрәндем. Радиода эшли башлаганда, кайбер лауреатлыкка кандидатларның әрсезләнеп көндәшләрен пычрата-пычрата шул дәрәжәгә омтылуларына ачуым гына килә иде. Гади халык жентекләп тикшереп маташмый бит. Биргәннәрме—биргәннәр. Ә без матбугатта, радиода, телевидениедә эшләүчеләр аның технологиясен нечкәлекләренә кадәр белеп тора идек. Әмирхан Еники белән Нурихан Фәттах, Мөхәммәт Мәһдиев кебек тере классикларны еллар буе чиратның иң азагында тотуларына нәрсә сәбәп булганы беркемгә дә сер түгел бит!

Татарстан радиосының әдәби-драматик тапшырулары редакциясендә эшләү бик күп нәрсәләргә күземне ачты. Әле студент елларымда ук уйлап, фараз итеп, борчылып йөргән кайбер четерекле мәсьәләләрне хәл итү өчен зур мөмкинлекләр туды. Ул вакытта кайбер нәрсәләрне әйтергә дә ярамый иде әле—булачак тапшыруың текстында, мөхәррир, өлкән мөхәррир, баш мөхәррир, комитет рәисе урынбасары имзалары өстенә цензорның, ул вакыттагыча әйтсәк, Главлит вәкиленең кулы һәм мөһере булмаса, аны эфирга чыгара алмый идең. Тапшыруда Хәсән Туфан яки Салих Баттал катнашкан булса, "Бу жөмләсе белән нәрсә әйтергә теләгән инде ул?"—дип мөхәррирнең тенкәсенә тиеп бетәләр иде. Әле ул гынамы?.. Француз язучысы Альфонс Доденың "Туган тел дәресе" дигән хикәясе бар. Сүз Эльзас һәм Лотарингия Германиягә кайтарылгач, мәктәптә француз телен укыту тыелачагы турында гына бара. Сюжеты да бик гади. Бәйләнде генә бит бер заман Главлит шул хикәянең тәржемәсенә! Янәсе, моның белән нәрсә әйтергә телисез?! Татар мәктәпләренең күпләп ябылган, хәтта караңгы татар авылларында да фәннәрне урыс телендә укытуга күчереп маташкан чаклар!

Яңа урында әйбәт кенә эшләп киттем мин. Өйрәнеп азапланасылары да булмады. Бернинди авырлыгын да тоймадым, кыскасы. Әллә студент чагында ук шушы казанда кайнаганга, әллә мина кадәр монда эшләгән Ләбиб Айтуганов, Марс Шабаев, Эльс Гаделев кебек дусларым белән гел-гел аралашып торганга,

сценарийлар язу, тапшыру текстларын раслату, аппаратура белән эшләү үзенчәлекләрен белә идем инде.

Яңа кеше ниндидер яңалык та алып килергә тиеш бит әле. Мин беренче көннән үк үзем яктыртырга тиешле темаларны билгеләп куйдым. Әдәби-драматик тапшырулар редакциясе "Фонотекабыз киштәләреннән", "Театраль викторина", "Шигърият бакчасында", "Авыл офыклары", "Дуслык меридианнарында" дигән яңа цикллар ачып җибәрде. Татар әдәбиятының барлык жанрларын да колачлый иде алар. Шул ук вакытта бөтендөнья һәм рус әдәбияты классикасын яктыртырга да, аерым язучыларның түгәрәк даталарын билгеләп барырга да, республика театрларының яңа спектакльләре белән таныштырырга да тиеш идек. Әлбәттә инде, радиотыңлаучыларның игътибарын халкыбыз тарихына да юнәлтергә кирәк санадык. Бу эшкә бик теләп галимнәребез Миркасыйм Госманов һәм Равил Фәхретдинов алындылар. Бу тапшырулар эфирга, билгеле, бер каршылыксыз гына үтмәде. Без—Рим Кәримов, Рим Шириязданов һәм мин—аяк терәп каршы торгач, түрәләр комачауламау ягын карадылар. Әдәбиятыбызның нинди олы көчләре безнең омтылышларны яклый иде бит!

1971 елда мине Мәскәүгә Бөтенсоюз телевидение һәм радио хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү институтына укырга җибәрделәр. Мондагы мохит бөтенләй башка иде. Балтыйк буе республикаларыннан һәм Кавказ якларыннан килгән мөхәррирләр рәсми сәясәткә бик үк туры килеп бетми торган "көфер" сүз сөйләүдән дә тайчанып тормыйлар иде. Без радио тарихы, тапшырулар методикасы, жанрлары, төрләре, идеологик көрәшнең кайбер аспектлары, радио эшчәнлегендә эстетик принциплар, философиянең әдәбиятка һәм сәнгатькә йогынтысы турында кызыклы-кызыклы әңгәмәләр тыңладык, семинарлар вакытында кызып-кызып бәхәсләшеп тә ала идек. Атаклы диктор Юрий Левитан, язучылар Сергей Смирнов, Аркадий Васильев, философия фәннәре докторы Ю. Борев белән очрашулар хәтергә аеруча тирән уелып калган.

Юрий Левитан безнең өчен әллә кайчаннан ук легендар шәхес иде инде. Аны безнең илдә генә димим, бөтен дөньяда белмәгән кеше булды микән?! Аның уникаль тавышы киң катлау тыңлаучыларга 1931 елдан бирле таныш булса да, ул Бөек Ватан сугышы елларында аеруча популярлык казанды. Бу чорда аның чыгышын көтеп алмаган берәр кеше булды микән?! Юрий Борисович 1936 елда радиодан СССР Конституциясе проектын укуларын, Совинформбюро белдерүләрен, Верховный Башкомандующий приказларын, илкүләм мөһим хәбәрләрне ничек йөрәккә үтәрлек итеп халыкка җиткерүләрен аеруча дулкынланып сөйләде.

—1941 елның 3 июлендә мине Кремльгә чакырып алдылар—И. В. Сталинның халыкка мөрәҗәгатен тапшырырга кирәк иде. Микрофоннарны җайлаган гына идек—Сталинның буйга миннән тәбәнәгрәк булуы ачыкланды. Аптырагач, аның аяк астына калын-калын китаплар тезәргә булдык,—дип көлдереп тә алды.

Сугыш чорында ана ил җитәкчесе белән күп тапкырлар очрашырга туры килә. Тагын бер эпизодны искә төшерде ул.

—Берәр совет шәһәрен фашистлардан азат иткән саен салют бирү гадәте бар иде. Сүзлекләрдә "салютовать" сүзендә басым "ю" хәрефенә төшә. Алай әйтсән, янгырамый гына бит. Мин, кагыйдәләрне бозып, басымны соңгы "а" авазына төшерәм. Мине, рус телен бозасын, дип җыелыш саен тиргиләр. Сталин белән бер очрашу вакытында әйттем шуны, кагыйдәгә туры китереп әйтсәм, тиешенчә янгырамый, дидем. Юлбашчының СССР Фәннәр академиясенә шылтыратып бер әйтүе җитте—мина башка бәйләнмәделәр.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

Рифат
Сверигин

# ГҮЗӘЛЛЕККӘ ЮЛ ЯРГАНДА...

Еллар, чорлар алмашынып торганда да исемнәре җуелмыйча, күп меңләгән укучылары күңелләрендә мәңгегә урнашып кала торган әдипләр була,—аларның әсәрләренә тарих тузаннары да кунмый—андыйлар гел балкып, күңелләрне сөендереп яшиләр дә яшиләр. Мондый язучыларны классик әдипләр дип, ә аларның әсәрләрен классик әдәбият дип атыйлар. Аңлашыла ки, бу сүзләрне олы хөрмәткә лаеклы шәхесләргә һәм аларның үлмәс иҗатларына карата гына әйтергә мөмкин. Шәриф Камал—әнә шундыйларның берсе.

Ул әдәбият мәйданына тормышның, заманның аеруча хәтәр һәм кискен борылышлы елларында аяк басты. Егерменче гасырның тууын бик күпләр зур хыяллар, яңа өметләр, "озакламый кешеләрнең якты, матур таңы атар" дигән тирән ышаныч белән каршы алдылар. Андый өмет-хыяллар ул чакта кемнәрне генә җилкендермәгән һәм канатландырмагандыр!? Шушы рухта иҗат эшенә керешкән Габдулла Тукай һәм Сәгыйть Рәмиев, Дәрдемәнд һәм Нәҗип Думави, Галиәсгар һәм Шәриф Камаллар, Фатих Әмирхан һәм Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимов һәм Гафур Коләхмәтов, Мәҗит Гафури һәм Шакир Мөхәммәтев, Шәехзадә Бабич һәм Мирхәйдәр Фәйзи кебекләр һич тә бер-берсен һәм үз-үзләрен кабатламыйча, ялкынлы карашларын һәм сүзләрен яңалыкка, азатлыкка сусаган халыкка җиткерә алдылар.

Кешелек хокукларын, гади хезмәт кешесенең бөеклеген һәм олы бәхеткә лаек икәнлеге хакыйкатен югары сәнгать дәрәҗәсенә җиткереп язу осталыгы үгет-нәсихәтчелеккә күнегә башлаган татар укучысы өчен зур яңалык иде. Матур әдәбият сүзенең эмоциональ җегәре никадәр көчле икәнлеген егерменче гасыр башында яшәгән укучылар һәм проза сөючеләр ул заманда Галимҗан Ибраһимов һәм бигрәк тә Шәриф Камал әсәрләрендә күреп, гаҗәпләнгәннәр һәм сокланганнардыр. Әдәби сүзнең тәэссири, экспрессив һәм фәлсәфи сыйфатларына, беренчеләрдән булып, нәкъ менә шушы проза осталары күз салды, һәм төп хикмәт, кайберәүләр аңлату буенча, әлеге әдипләрнең билгеле бер әдәби агым, юнәлеш, метод яисә конкрет бер "-изм" тарафдарлары буларак эш итүләрендә түгел, ә укучыга тәэсир итү алымнары даирәсен һәм, гомумән үз иҗатларын һичбер конкрет агым, юнәлеш һ.б. шундый кысалар белән чикләмәскә тырышуларында иде.

Шәриф Камалның әдәби сурәтләр, бизәкләр, төсмерләр, сизелер-сизелмәс деталь-штрихлар, нюанслар белән эш итү осталыгы бүген дә таң калдыра. Үз вакытында замандашларының бик югары бәясен алган "Уяну" /1909/ хикәясе әдипнең әнә шул яңа алымнар гаммасы белән иркен эш итү, укучы күңеленә көчле тәэсир ясый белүнең кызыклы һәм уңышлы тәүге үрнәге иде. Шәриф Камалның беренче хикәя-новеллаларында, һәр очракта диярлек, кешенең эчке халәте белән табигать торышы ниндидер бер аерылмас тыгыз бәйләнештә янәшә куела. Бу очракта да кеше күңелендәге җил-давыл һәм табигатьнең шул мизгелләрдәге тынычсызлыгы аеруча калку чагылдырыла.

"Уяну" хикәясендәге вакыйгалар фаҗигале һәм динамик планда ике тойгы рәвешендә үстерелә: беренчесе—хикәя герое Мусаның үзе кылган вәхшилегенә үкенүе һәм, икенчесе—шул ялгышны һичничек тә төзәтеп булмаячагын аңлый башлавы, ягъни соңга калган уяну ачысы.

Менә шуна күрә дә янгыр яварга тотынгач, "караңгылыктан, әллә кайлардан килеп, эре янгыр тамчылары бер-бер артлы дөбердәп тәрәзәгә бәрелә һәм, гүя, килеп Мусаның йөрәгенә кадала иделәр. Бәлки бу—"йөрәккә кадалучы тамчылар" егерменче гасыр башларында, күп кабатланган мелодраматик гыйбарәдән гайре әллә ни әйбер дә түгелдер, әмма фразаның беренче өлешенә кат-кат әйләнеп карыйсың: "карангылыктан, әллә каян килгән янгыр тамчылары..." Әлбәттә, монысы инде герой күнелендәге шөбһәле шомнын арта баруының беренче билгесе...

Муса күнелендә кинәт яңа хис—кадерен белмәгән мәхәббәтен мәңгегә югалтканлыгын анлау ачысы күтәрелә. Бу урында автор шактый ук натуралистик детальләрне дә эшкә жигәргә кирәк дип таба:

"Гафифә арка өстенә яткан, күзләре түшәмгә текәлгән, куркуы һәм җәрәхәтенең әрнүе сәбәпле булса кирәк, тешләрен кысып, чыраен сытып ята иде. Баш астындагы ак мендәр өстеннән агып киткән ике юл кан сызыклары лампа яктысында күренә иделәр, берсе идәнгә тама, икенчесе—урынга, Гафифәнең астына таба китә иде. Ул көчләнеп:

—Муса, якын кил,—диде.

Муса тезләнде һәм аның кулын битенә куйды. Аның сөйкемле куллары салкын иде". Менә шушы сөйкемле кулларга житкәч кенә Гафифәнең хәле-кыяфәтендәге үтә куркыныч, хәтәр сурәтләр укучы аңында да конкретлашып житә... һәм тагын бер әһәмиятле әйбер: болар барысы да автор һәм укучы күзаллавыннан бигрәк, нәкъ шушы мизгелдә Мусага барып житүе белән әһәмиятлерәк. Рухи уяну башлана:

"...Муса үбеп-үбеп җан сулышы белән аның кулларын җылытмакчы була иде, әмма куллар инде җылынмый иделәр."

Боларны укыгач, замандашларының әсәрне югары бәяләүләре һич тә гаҗәп тоелмый—Шәриф Камал берничә сурәт ярдәмендә психологик киеренке сюжетлы новелла барлыкка китерә алган.

Төзәтеп булмаслык, югалту үкенече темасы "Буранда" /1909/ исемле хикәядә дә кабатлана. Бер караганда, монда "Уяну"дагы кебек кыскалык та, нык, тыгыз оештырылган сюжет та юк кебек.

Мостафа озакка сузылган солдат хезмәтеннән кайтып килә. Бу көнне авылына барып житә алмыйча, ул, үзе белән бергә хезмәт иткән Хөсәен исемле иптәшенең өендә кунарга туктала. Көн буранлы. Мостафаның монда кунак булып ятасы килми—тизрәк үз авылына китәргә ашкына. Әнисенең үлем хәлендә ятканын улы, шулай ук улының менә-менә кайтып керәчәген әнисе тәгаен генә белмиләр. Кайчандыр алар анлаша алмаганнар. Мостафа сүзе һәм игътибарсызлыгы белән ананы рәнжеткән дә. Алай да бәхилләшү, анлашу минутлары булыр дип көтәсең. Ә үлем хәлендәге әнисе "күзләре белән нидер эзли, нидер юксына, кемнедер күрмичә үләсе килми, торып-торып:

—Килмәдеме? ...—дип сорый иде".

Хикәядә менә шушы якын, тугандаш җаннарның һичнәрсәгә карамыйча, бер-берсенә тартылулары әсәрнең үзенә бер төрле төсмерен тудыра. Әмма хикәя көтелгән кавышу белән тәмамланмый. Мостафа газиз анасының әле суынырга да өлгермәгән үле гәүдәсе янына гына кайтып житешә:

"Аһ... Кяшки ул бер генә карасын!..

Ләкин ул инде карый алмый иде... Чөнки әлеге нечкә тармакның чыганакларына карап торган көенчә, очыннан ычкынып киткән иде...

Тышта буран һаман дулый иде".

"Буранда" һәм 1909—1914 елларда иҗат ителгән башка әсәрләре белән /"Бәхет эзләгәндә", "Тормыш көе", "Сулган гөл", "'Эч пошулы", "Чит илдә", "Уяну", "Козгыннар оясында", "Сукбай", "Авыл мөгаллиме", "Акчарлаклар" һ.б./ Шәриф Камал психологик новелла, хикәя, повесть кануннарын бөтен нечкәлекләрендә һәм катлаулылыгында үзләштергәнлеген исбат итте. Бу тәҗрибә алга таба совет чоры елларында әдәбият мәйданына килгән бик күп проза вәкилләренә үзенең шифалы йогынтысын ясап торды. /Кави Нәҗми Ибраһим Гази, Мирсәй Әмир, Фатих Хөсни, Әмирхан Еники һ.б. ларга/. Бу унайдан конкрет әдәби мисалларны

да күп китереп булыр иде. Берсенә генә тукталып китик. Югарыда телгә алынган "Буранда" новелласында булмый калган очрашу язмышның башка ихтималлары яисә вариантларыннан ерак тормый да кебек. Әмма ана һәм аның улы очрашмый, аңлаша алмый калалар—бер-берсен мәңгегә югалталар. Ахыр чиктә язмыш фәкать шушы—тик без белгән үкенечле, фаҗигале вариантны гына калдыра. Мостафаның әнисе өзелгәч, 5-10 минуттан соң өйгә килеп керүе фаҗигане тагын да арттыра.

Әмирхан Еникинең инде гасыр урталарында бөтенләй башка иҗтимагый шартларда иҗат ителгән "Кем җырлады" /1947/ хикәясендә каты яраланып, үлем хәлендәге татар офицеры янәшәсендә генә күрше эшелонда аның сөйгән кызы Таһирәсе аны күрмичә, аз гына читтәрәк басып тора. Биредә үлем белән яшәү арасындагы коточкыч упкын һәм яшь күңелләрне бер-берсенә тарткан саф мәхәббәт гүзәллеге кызның моңлы җыры ярдәмендә генә тоташтырыла. Нәкъ шушы моңлы-җырлы күренеш авторга котылгысыз үлем ситуациясе дәһшәтен ниндидер романтик-психологик төсмерләргә төреп, укучы күңеленә сак кына кагылып, әмма бар тулылыгында җиткерү мөмкинлеген бирә. Әмма бу очракта да без әле генә Шәриф Камал әсәрендә күргән алым кулланыла—аңлашу, күрешү, очрашу якын кебек тоела гына—тик ул инде һич мөмкин түгел. Теге әле генә телгә алынган яшәү белән үлем арасындагы упкын инде аларны мәңгелеккә аерган. Ләкин нәкъ менә шул мираж, шул рәшә—алдавыч янәшәлек сурәте ситуациягә зур фаҗига эффекты алып килә—сугыш афәтләре белән кешелекнең һич тә килешә алмавы хакыйкатен раслый. Болай янәшә куеп чагыштыруларны Шәриф Камал һәм әдәбиятка соңрак килгән прозаик, әдипләребез әсәрләреннән байтак күрсәтеп булыр иде. Әмма төп темадан бик ераклашканчы Шәриф Камалның үз иҗатына әйләнеп кайтыйк.

Әдипнең кечкенә күләмле әсәрләре күп очракта геройның мәйданнан китеп баруы белән тәмамлана. Бу китү аерым өметләрнең, тормыш исәпләренең герой үзе көтмәгәнчәрәк тәмамлануы рәвешендә бирелә. Әйе, тормыш гел җиңүләрдән генә тормый. Шәриф Камал мондый ситуация ярдәмендә, өмет-хыялларның кайберләре җимерелсә, югалса да, алар урынына яңалары килүе, күңелләрдә яңа өметләр кабынуы, тормыш җепләре, йомгаклары никадәр чуалганган булса да, аның очын һәрвакыт эзләргә, табарга кирәклеге һәм шул өмет чаткыларының кеше өчен, аерым алганда "кечкенә кеше" өчен, вакытлыча булса да, яшәү чыганагы икәнлеге хакында сөйли. Бу хакыйкать аның чын реалист язучы икәнлеген тагын бер кат раслый.

Шулай да Шәриф Камалның башлангыч чор иҗатыннан дөньяга карашлары нык формалашкан, ачык һәм хөр максатлы, гел якты идеалларга табынган геройларны эзләргә яисә табарга тырышу артык һәм мәгънәсез эш булыр иде. Алар әле гүя караңгылык патшалыгыннан капшана-капшана чыгу юлларын эзләргә тотынган кешеләрне хәтерләтәләр сыман. Ә эзләнүләр канәгатьсезлектән башлана. Сорауларның һәркайсына ачык һәм төгәл җаваплар да табып булмый әле. Алай да тормышның, яшәешнең, әйләнә-тирәдәге якыннарының, иптәшләреннең хәлләре болай булмаска тиешлеге, моңа артык түзеп торырга ярамаганлыгы хакында кайбер нәтиҗәләр ясарга да мөмкин булыр иде.

Әмма зур нәтиҗәләр ясарга бу иҗат чорында Шәриф Камал үзе дә бик ашыкмый әле. Тик булачак котылгысыз борылыш-үзгәрешләрне якынча сиземләү, борчылу, ниндидер шомлану, нәрсәнеңдер хәвефлелеген көтү, хисләрнең беркадәр аморфлылыгы, чыннан да, әдипнең кайбер авангард-модернистик, аерым алганда импрессионистик агымнарга бигүк битараф булмавын искәртә. Әмма боларны таныган хәлдә дә, унга-сулга каерылып селтәнеп, бөек реалистны аның төп үз җирлегеннән, ягъни реализмнан читләштереп карау зур хата булыр иде.

Инкыйлабтан соң илдә булган үзгәрешләр күренекле әдип иҗатына да эз салып үттеләр. "Акчарлаклар" исемле гүзәл повесть язганнан соң (аның гүзәллеген заманында Галимҗан Нигъмәти, Мөхәммәт Гайнуллин, Хәй Хисмәтуллин, Хәсән Хәйри, Гази Кашшаф, Ибраһим Нуруллин, Абдулла Сайганов, Гали Халит, Әхәт Нигъмәтуллин, Азат Әхмәдуллин, Резеда Ганиева кебек олы галимнәр бик дәлилле исбат иттеләр), әдип иҗатында беркадәр туктап тын алу, алдагы иҗат юлларын сайлау алдыннан уйлану, хәтта беркадәр иҗат пассивлыгы да сизелә. Ә бәлки узган

гасырның егерменче елларында яңа җәмгыятькә мөнәсәбәттә әле әдипнең иҗат кыйбласы, юнәлешләре ачыкланып ук җитмәгән дә булгандыр. Бу хәл аның шул чорда язган әсәрләреннән сыйфатында да сизелә. Шәриф Камалның совет чорында иҗат ителгән хикәяләре әдәби эшләнешләре ягыннан элеккеләреннән беркадәр кайтыш, хәтта зәгыйфьрәк яки публицистик язмаларга тартымраклар. "Таң атканда" /1925/ исемле инкыйлаби романы да, гәрчә "Акчарлаклар" повестеның дәвамы рәвешендә тәкъдим ителсә дә, андагыча яңа ачышларга да, авторның үзенең иҗади канәгатьләнүенә дә дәгъва итә алмый. Беренче өлештәге /"Акчарлаклар"/ инде укучы яратып өлгергән геройлар /Газизә, Гариф/ танымаслык булып үзгәргәннәр—аларның характер һәм кешелек сыйфатлары да хәзер башкачарак. Гомумән, әсәрнең социаль вазифаларга буйсындырылып эшләнгәнлеге нык сизелеп тора һәм, ахыргы җөмләләре шактый пафослы булса да, "моның инде ачык кына дәвамы булмаячак" дигәндәй, кинәт өзелгән сыман тәмамланып та куя.

Аның каравы, егерменче еллар барышында яңа дәвергә күчкәндә, автор күңелендә һәм иҗатында яңа бер перспективалы омтылыш пәйда була. Әдәбият-сәнгатьнең матурлык чыганагы икәнлеген бик яхшы сиземмләүче әдип гүзәллекне тормышның үзеннән табарга тырыша. Мондый омтылышны хәтта яңа әсәрләрнең исемнәреннән үк белеп була: "Таң атканда", "Авыл матур уйлый" /1926/, "Матур туганда" /1937/, "Ныклы адымнар" /1942/... Бу исемнәр авторның чын гүзәллеккә никадәр сусаганлыгы һәм яңа җәмгыять, яңа тормыш белән бәйле өметләрнең тормышка ашачагына ышанычы һәм теләктәшлеге зур икәнлеге хакында сөйлиләр.

Утызынчы елларның үзенчәлекле һәм хәтәр шартларында Шәриф Камалның камил һәм гүзәл әсәрләренең берсе иҗат ителә. Ул—"Матур туганда" романы. Әсәр 1937 елда туа. Бу дата советлар илендә гаделсезлек күренешләре һәм сәяси репрессияләрнең аеруча көчәйгән чагын да искә төшерә. Шушы уңайдан инде бүген—шул мәхшәрле кырыс еллардан соң күп вакытлар узгач, күңелдә кайбер сораулар да кузгала: мәсәлән: әдипләр һәм җәмгыятьнең башка намуслы кешеләре репрессия шартларында җаннары һәм киләчәкләре өчен борчылып һәм кан калтырап торган чакта шундый гүзәл һәм озын гомерле әсәр ничек иҗат ителә алган? Бу һич тә конъюнктур әсәр түгел—аңа караган "гүзәл" дигән эпитет, һич искәрмичә, дистәләгән еллар дәвамында сакланып килә—бу феноменаль күренешне ничек аңлатырга?

Чыннан да, Шәриф Камал шул көнгесен дә уйлагандыр диярге нигез бар, әмма бер үк вакытта ул киләчәк турында да кайгырткан, һәм, иң әһәмиятлесе: үз йөзен югалтмыйча, төп художниклык сыйфатын—илһамланып, ләззәтләнеп иҗат итү сәләтен саклап кала алган. Моңа ирешү өчен ул менә нинди юлны саклаган: романның структур схемасы берничә катламнан тора: берсе—сәяси-публицистик катлам—ул шулай ук беркадәр дәрәҗәдә конъюнктур вазифаларны да башкара—ул шул чорның сәяси-идеологик таләпләренә туры килә; әмма монысы—шактый өстәгесе—су асты тавының өстә күренеп торучы кечкенә өлеше генә. Сүз авылның күмәк тормышка күчү хәлләре, шушы күчеш җирлегендә барлыкка килгән сыйнфый бәрелешләр, яңа хәрәкәтнең искелекне җимерүе турында бара. Бу—романның дөньяга чыгуын тәэмин иткән фактор. Бәлки әле ул репрессияләрдән котылып калырга тырышуның иң гади бер чарасы да булгандыр. Әсәрнең башында, "Бөек Октябрь революциясенең 20 еллыгына багышлана" дип куелган сүзләрне дә игътибарсыз калдырмыйк.

Һәм тагын менә нәрсә кызыклы: роман крестьян хуҗалыкларын көчләп күмәкләштерү хәрәкәте тәмамланып, берничә ел узганнан соң иҗат ителсә дә, автор укучыларны байтак элеккерәк заманга алып китә—әсәрдәге вакыйгаларның кайчан барачагын һич тә ике төрле фикер калмаслык итеп башта ук әйтеп куя:

"1920 елның декабрь ахыры иде".

Боларны икенче бер әйбер белән дә тыгыз бәйләнештә карау мөһим: әдәбият белгечләре Шәриф Камалны мәшһүр Михаил Шолохов реалистик мәктәбенең татар җирлегендәге бер дәвамчысы дип кенә билгеләп калмыйлар—"Матур туганда" романын мәгълүм "Күтәрелгән чирәм" әсәренең татар җирлегендә кабатланышы дип тә саныйлар. Моның алай түгел икәнлеген, татар классигының кемгә дә булса

ияреп язуга мохтаҗ түгеллеген һәм романының мөстәкыйльлеген исбат итү артык кыен булмас иде.

Шәриф Камалның бу әсәрендә реализм һәм романтизм төсмерләре күптөрле чаралар, мәсәлән, юмор, сатира, лирик буяулар, бизәкләр ярдәмендә дә гәүдәләнә. Әдәбият белгечләре бу иҗаттан авангардизм элементларын, аерым алганда, импрессион дип аталучы сәнгать агымыннан килеп кергән күренешләрне дә табарга телиләр.

Әлбәттә, Шәриф Камал үзе мондый шаукымнарның берсенә дә иярәм дип язмаган. Мөгаен монда төп хикмәт татар әдәбиятының үзендәдер, бәлки әлегә без исемнәрен, атамаларын, терминнарын табып житкермәгән милли әдәбият күренешләре белән эш итә торганбыздыр?!

Мәсьәләнең болай куелышы элегрәк әдәбиятта гел саф реализмның чагылышы дип саналып килгән романның әдип иҗаты буенча дәвам итеп килгән яңачыл романтизм яисә модернизм күренешләре белән ниндидер бәйләнеше һәм уртаклыгы бар, дигән яңа кыю карашларны да бөтенләй үк инкарь итми. Романның үзәгенә куелган төп эчтәлек, идея һәм фикер бүген тагын да ачыклана төште һәм, ул бу язмабызда күренүенчә, әдәбият фәнендә күптән урнашкан традицион бәяләмә, фикер-карашлардан нык аерыла. Әйе, әдип үз алдына зур глобаль идеологик максатлар, бурычлар куймаган, ә фәкать яңача, матуррак яшәргә өметләнгән һәм шул юнәлешкә табынып алданган буын кешеләренең психологиясен күрсәтергә теләгән икән. Ул моны бик яхшы башкарып чыга алган. Әмма гаделлек, хакыйкать тантанасына бик ерак әле. Аның кайчан да бер киләчәген художник-реалист интуитив рәвештә сиземли, тоя. Аның яраткан геройлары да "туачак Бәхет һәм Матурлык тантанасына кагылышыбыз бар" дигән инанулары белән инде бүген үк сабыйларча бәхетлеләр—фәкать шуның өчен генә алар зур кыенлыкларга түзеп, Бөек Киләчәк өчен армый-талмый тырышалар, көрәшәләр... Һәм чынбарлыкта андыйлар тиз арада сыйнфый дошманнар кулыннан түгел, ә үзләре аллалаштырган, аларны көрәш өермәсенә ташлаган хакимиятләре тарафыннан үз каннарына батырылачакларын әлегә башларына да китермиләр.

Ә бөек реалист Шәриф Камал 1937 елда ук вакыйгаларның гаять тә житдиләнә баруын, канлы вәхшәтнең, репрессияләрнең кай тарафтан килгәнлеген инде чамалый. Шулай да ул әлегә әсәренең геройларын һәм әсәрне укучыларны Киләчәк Бәхет тантанасы хыялларыннан мәхрүм итми, шуларның исерткеч романтикасы рухында аларны иркәләргә кирәк дип таба, "коммунар" дигән ясалма исемне йөртүчеләрнең дә гади кешеләргә хас сөйкемле гадәт-кимчелекләре, беркатлырак, балаларча ышанулары, көндәлек тормышларының хәлләре-мажаралары хакында ярып, иркенләп, ләззәтләнеп сөйли һәм алардан әсәрнең икенче кисәге дип уйланылган "Ныклы адымнар" /1942/ исемле тәмамланып житмәгән романында да аерылмаска тырыша.

Һәм тагын бер кызыклы әйбер яисә парадокслы күренеш: гаять тә житди, сәяси дип йөртелгән бу әсәр /ә бездә сәясәтне гел житди генә була ала дип санау гадәткә кергән/ тоташтан диярлек юмор һәм сатира нурларында коендырылган.

Кыскасы, Шәриф Камалдай олы әдипләребезнең иҗатлары һәрьяклап яңадан барлап, тикшереп чыгуны сорый. Бәя-анализда элеккеге катып калган карашлардан арыну да, аз тикшерелгән өлкәләрне (мәсәлән, аның иҗатында юмор-сатираның урыны һәм әһәмияте, драматургиясе, "Ныклы адымнар" кебек бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән әсәрләре) искә алу да—бердәй әһәмияткә һәм игътибарга лаек икәнлеге аңлашыла.

♣

# "КҮҢЕЛЛӘРНЕ УЯТЫР"

Татар драматургиясенең халкыбыз рухи тормышындагы урыны һәркемгә билгеле. XIX гасыр ахырында мәйданга килгәннән соң үткән вакыт эчендә ул милли яшәешебезнең көзгесенә әверелде. Ә инде хәзерге урбанизация һәм глобализация чорында драматургия, театр сәнгате белән берлектә, милли менталитетның асылын билгеләүче традицияләр аша, яшәешнең матур үрнәкләре өчен сөенеп, ямьсез яклары өчен көенеп, милләтнең бүгенгесе һәм киләчәге сагында тора. Шуңа да сәхнә әдәбияты өлкәсендә эшләүчеләргә гаять җитди таләпләр куелу яхшы аңлашыла. Драматургиянең хәзерге торышын, үткәндәге традицияләргә таянуын, янага омтылуын ачыклау, әлеге әдәби төрнең үсеш-үзгәреш тенденцияләрен, табыш-югалтуларын билгеләргә һәм төп юнәлешләрне барларга мөмкинлек бирә. Әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Азат Әхмәдуллинның «Күңелләрне уятыр» ("Мәгариф" нәшрияты, 2007.) монографиясе хәзерге татар драматургиясенә багышлануы белән кызыксыну уята. Авторның исеме әдәбият сөючеләргә яхшы таныш. Ул—гомеренең күп өлешен драматургия төрен өйрәнүгә багышлаган фидакарь шәхесләрнең берсе. Аның әлеге хезмәте дә озак еллар дәвамында алып барылган тикшеренүләрнең җитди нәтиҗәсе булып тора.




Белгәнебезчә, бүгенге күренешләр буш урында барлыкка килми. «Яналык еш кына күнегелгән, ягъни иске эчендә туа, шунда үсә һәм формалаша,—дип яза автор.—Милли драматургиянең дә бүгенге, ягъни җәмгыятебездә бара торган үзгәреш һәм янарыш елларында яулаган унышлары да берьюлы гына, әзерлексез генә була алмас иде. Совет җәмгыятендә хөкем сөргән хәлләрнең асылын ачкан сәнгать дөреслегенә ирешү юлы аерым язучылар өчен узган гасырның 60-70 нче елларында ук башланды». Хезмәтнең нигезенә салынган әлеге концепция аның төзелеш-структурасын да билгели һәм төп мәсьәләгә бару юлын ачыклау рәвешендә аерым бүлекләрдә урын ала.

Билгеле булганча, сүз сәнгате үзенең үсеш тарихында төрле дәверләр, чорлар аша үтә һәм аның мондый бүленеше күптөрле сәбәпләргә бәйле булса да, нигез шарт буларак икесе аерылып тора. Болар—җәмгыять, халык тормышындагы тарихи вакыйгалар һәм әдәбиятның сыйфат үзгәрешләре. Шуларга нисбәтле рәвештә галим 1917 елдан соңгы татар әдәбиятының, аерым алганда драматургиянең, үсеш-үзгәрешенә бәя бирә. Дөрес, автор совет чоры сәхнә әдәбияты тарихын тулы, эзлекле тикшерүне максат итми, аның игътибар үзәгендә әлеге чор драматургиясенең асылын, үзенчәлекләрен билгеләүче мәсьәлә-күренешләр тора. Икенче төрле әйтсәк: әдәбияттагы табышлар белән бергә, яуланган позицияләрдән чигенү сәбәпләрен ачыклау аша үзгәрешләрнең котылгысызлыгын билгеләү. А. Әхмәдуллинның бу мәсьәләләргә бәйле тикшеренүләре драматургия тарихын өйрәнүнең дә нигезен тәшкил итә, чөнки аеруча күп бәхәсләр уяткан проблемалар булып нәкъ менә методологик һәм теоретик принциплар тора. 1917 елдан соң урнашкан хакимият, яна иҗтимагый-тарихи

*Күңелләрне уятыр: Хәзерге татар драматургиясе: Монография / Азат Әхмәдуллин.— Казан: Мәгариф, 2007.—223.*

шартлар сүз сәнгатенең һәм эчтәлегендә, һәм формасында яналыкларга китерә. Алар гаять төрле булып, кызганыч ки, арада иҗтимагый яшәеш мәсьәләләрен берьяклы гына аңлатканнары да байтак. Җәмгыятьтә эшче сыйныфының ролен аңлау—әнә шундыйларның берсе. Хезмәт авторы билгеләп үткәнчә, пролетариат вәкилен һәрвакыт акыллы, өйрәтүче, житәкче итеп сурәтләү, үз чиратында, интеллигенциягә, крестьянга, авыл кешесенә түбәнсетеп карауга китерде. Нәтиҗә буларак «үтә кызыллык», үтә оптимизм бөтен яшәешне дә, шуны чагылдырган әдәбият-сәнгатьне дә басып китте». Узган гасырның 20-30 нчы елларында әдәбиятта вату-җимерү, үткәннән баш тарту күренеше киң урын алу да яхшы билгеле. А. Әхмәдуллин эзлекле рәвештә әлеге мәсьәләнең фәлсәфи җирлеген ачу, аңлау омтылышы ясый. Аерым алганда, сыйнфый-социаль тигезсезлек һәм милли изелү күренешенең яңа шартларда тискәре сәясәткә юл ачуын дәлилли. Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр» драмасында Батырхан яклаган «Канлы юл—изге юл!» принцибы драматургиядә пролетариат сыйныфының канлы җинүләрен канәгатьләнеп сурәтләүгә китерә.

Хезмәт авторының игътибар үзәгендә булган һәм еш кына бәхәсләр уяткан мәсьәләләрнең берсе—халык һәм шәхес, аларның үзара мөнәсәбәте. Совет чорында, бер яктан, халык массасы җәмгыятьне үзгәртүче хәлиткеч көч итеп бирелде һәм ул шәхесне каплап китте. Икенче яктан, житди яңалык буларак, көрәшче кеше образы алга куелды. Болар исә, үз чиратында, түбәндәге берьяклы күренешләргә китерде: кешеләр яратуны аңлаткан гуманизм идеясенең мәгънәсе үзгәрде һәм изелгән, түбән катлау кешесен ярату белән бергә югары катлау вәкилен күралмау туды; кешенең шәхси тормышы тулысынча коллектив, җәмгыять мәнфәгатьләренә буйсындырылды; аерым сыйныф мәнфәгате гомумкешелек кыйммәтләреннән алга чыгарылды; «революцион аскетизм» ны төрлечә яклау булды һ. б.

А. Әхмәдуллин совет чоры драматургиясендә милли мәсьәләләрнең галәттә читләтеп үтелүенә, яисә берьяклы чишелү сәбәпләренә дә туктала. Аларның берсе—интернационализм—халыклар дуслыгы төшенчәсенә нигезләнеп, аерым милләтләрнең тарихтагы урыны түбәнәйтү, аларны руслаштыру сәясәте; икенчесе—пьесаларда рус милләте вәкилләренең мәҗбүри диярлек урын алуы һәм бары тик яхшы яктан гына сурәтләнүе; өченчесе—шәхси һәм милли мәнфәгатьләрнең революцион максатларга һәм дәүләти бурычларга буйсындырылуы. Әлеге хезмәттә ясалган тагын бер нәтиҗәне билгеләп үтик: югарыда күрсәтелгән мәсьәләләр, сүз сәнгатендәге тайпылышлар драматурглар иҗатында аеруча кискен чагылыш тапты. Бу сәхнә әдәбиятының чорга аеруча аваздаш булу үзенчәлеге белән дә аклана. Укучы дөрес аңласын, автор һич тә совет чоры драматургиясен каралту юлыннан бармый. Ул андагы табыш-яңалыкларны да җентекләп барлый, киләчәктә туачак традицияләргә нигез булачак үзенчәлекләргә кат-кат туктала. Аерым алганда, бу чорда чынбарлык белән тыгыз бәйле конфликтлар алга чыга, музыкаль драма житди үсеш кичерә, яңа жанр формалары пәйда була, фольклор белән бәйләнеш көчәя һ. б. Әмма, унай күренешләр күбәеп, матур традицияләргә нигез салынса да, әлеге чор драматургиясе, аеруча 50 нче еллар уртасына кадәргесе, бер яклы гына үсә. Әсәрләрнең еш кына иҗтимагый конфликтка нигезләнүе, төп идеянең аерым сыйныф һәм партия идеологиясенә буйсындырылуы драматургияне торгынлыкка, бер урында таптануга китерә.

А. Әхмәдуллин билгеләп үткәнчә, совет чорында әдәбият, шул исәптән драма үсеше һич тә бертөрле генә булмый. Аерым позицияләрне югалту чорлары яңа күтәрелеш һәм эзләнүләр белән алышына. Әдәбият тарихын өйрәнүчеләрнең игътибарын XX гасырның 60-80 нче еллары аеруча җәлеп итә. Галим дә бу чорны татар драматургиясе үсешенең гаять әһәмиятле дәвере дип саный, ягъни чынбарлыкны сәнгать чаралары белән чагылдыруда әлеге елларда житди сыйфат үзгәрешләре ясала, талантлы драматурглар тарафыннан классик үрнәкләр буларак танылу алачак пьесалар языла. Ә иң мөһиме—яшәп килгән системаның асылын фаш иткән, кешенең дөньяга карашын үзгәртүгә китергән, үзгәртеп корuларга әзерлекне башлаган әсәрләр 60-80 нче елларда дөнья күрә. Монографиядә ассызыклап үтелгәнчә, үткән гасырның 80-90 нчы еллары чигендә социалистик система шактый тиз җимерелеп, коммунистик идеология үзенең позицияләрен югалткан икән, монда драматургларның да роле шактый зур. «Үзгәртеп корулар

чорына керү алдыннан» дип аталган бүлектә әлеге мәсьәләләр белән бергә сәхнә әдәбиятының төп көчләре дә барлана. Аларның иң уңышлы әсәрләре мисалында һәрберсенә хас стиль үзенчәлекләре, сәнгатьчә сурәтләүдәге табышлары күрсәтелә һәм шулар аша җитди гомумиләштерүләргә килеп, төп сыйфат үзгәрешләре ачыклана. Автор Х. Вахит, Ю. Әминов, Ш. Хөсәенов кебек драматурглар иҗатына, Н. Фәттах, Т. Миңнуллин, М. Әмир, А. Гыйләҗев. Ф. Хөсни, Ә. Баян, Н. Исәнбәт, Р. Батулланың һ. б. пьесаларына белеп, яратып анализ ясый, аларга бүгенге көн биеклегеннән торып бәя бирә, әдәбият тарихындагы урынын билгели.

Әдәби процесстан читтәрәк калып килгән аерым әсәрләрнең бирелә калкытып куелуы, аларда чагылыш тапкан яңалыклар билгеләнү дә игътибарга лаек. Бу уңайдан тагын бер мәсьәләгә ачыклык кертеп үтик. Галим-тәнкыйтьче үзенең тикшеренүләрендә драматурглар иҗатына иң башта заман героен тасвирлау үзенчәлегеннән чыгып бәя бирә. Аның фикеренчә, «кайсы гына чорда булса да замандашның типик образын тудыру өчен тормыш кыенлыкларын җинеп баручы, тормышчан һәм мөһим конфликтлар уртасында кайнаучы, һәртөрле сынаулардан уңышлы чыгу нәтиҗәсендә рухи ныгучы геройларны тасвирлау беренче урында торырга тиеш». Аңлашылганча, автор типик геройны һәрвакыт уңай итеп, каршылыкларны җинеп чыгучы, зур ихтыяр көченә ия итеп күзаллый, дөресрәге, аның шундый геройларны күрәсе килә. Алгарак китеп шуны да әйтергә кирәк, А. Әхмәдуллин әлеге концепциягә җәмгыятьтә үзгәртеп корулар башлангач та тугры кала. 2004-2005 елларда «Казан утлары» журналы үткәргән «Безнең заман герое» дискуссиясендә дә ул үз карашларын яклап чыгыш ясый. Ә безнеңчә, әлбәттә, каршылыкларны җиңә алучы геройлар укучы-тамашачыга да уңай тәэсир итә. Әмма заманның типик героен шундый итеп кенә күзаллау—бәхәсле. Тормышта яхшылык янында начарлык та йөргән кебек, уңай герой янәшәсендә тискәре герой да бар. Шуңа күрә беренчесен типик дип, икенчесен андый түгел дип атау тормыш дөреслегенә каршы килү була түгелме соң?

Хезмәтнең «Яңарыш чорында татар драматургиясе» дип аталган бүлегендә XX гасыр ахыры—XXI гасыр башы сәхнә әдәбияты тикшерелә. Әйе, күпгасырлык татар әдәбияты үз тарихында ике Яңарыш дәверен үтә. Аның берсе—XII- XVI гасырга карый һәм бу чорда Кол Гали, С. Сараи, Котб, Хәразми, Х. Кятиб, Мөхәммәдъяр кебек әдипләр иҗат итә. Татар әдәбияты Шәрык Ренессансының шифалы тәэсирендә җитди сыйфат үзгәрешләре кичерә. Коръәни карашларга нигезләнгән хәлдә тормышны сәнгатьчә чагылдыруның яңа якларын ача, кеше шәхесен яшәешнең үзәгенә куеп, гуманизм традицияләрен тагы да үстерә. XX йөз башы икенче Яңарыш чоры буларак билгеле. Г. Тукай, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, С. Рәмиев, Дәрдеменд, М. Гафури һ. б. әдипләр, тормыш кануннарын тирәнтен үзләштерә барып, тасвирлауда реализм юлына чыгалар, яшәешкә, заман рухына туры килә торган романтизмны үзләштерәләр, кешенең серле, еш кына аңлап-аңлатып бетерү мөмкин булмаган якларын ачу максатында дөнья әдәбиятында модернизм дип аталган юнәлеш агымнарына йөз тотып иҗат итәләр. Әдәбият тематика һәм төр-жанрлар ягыннан да җитди үсеш кичерә, яңа әдәби көчләр белән байый, Шәрык һәм Гареб әдәбиятлары казанышларын үзләштерә барып, халык язмышын, аның рухи тормышын чагылдыруда яңарыш кичерә.

XX гасыр ахырында җәмгыятьнең бөтен өлкәләрендә барган үзгәрешләр әдәбиятка да көчле тәэсир ясый һәм аның үсешендә күзәтелгән табышлар өченче Яңарыш чоры башлану турында сүз алып барырга мөмкинлек бирә. Мондый фикер белән Й. Нигъмәтуллина, Р. Ганиева, Д. Заһидуллина һ. б. галимнәр дә чыгыш ясады. Сәхнә әдәбиятындагы яңалыклар төрле яссылыкта һәм юнәлештә чагылыш таба дип саный А. Әхмәдуллин. Аларның берсе—тормышны объектив һәм дөрес чагылдыру. Совет чорында моңа ирешүдә җитди уңышлар булса да, соцреализм иҗат методы таләпләре һәм цензура драматургларны кысада тотты. «Татар драматургиясе тормышны һәм яшәешне чын мәгънәсендә тулы һәм дөрес итеп чагылдыру юнәлешенә 1985 елдан башланган үзгәртеп корулар чорында гына аяк басты»,—дип яза автор. Моның белән бәйле икенче җитди мәсьәлә калкып чыга, ул—шәхес концепциясе. Бу чор татар драматургиясе, аерым каршылыклардан арына барып, кеше шәхесен иң зур кыйммәт буларак күтәрүгә, аның мәнфәгатьләрен

яклауга кила. Яңалыкларның тагын берсе—тематик киңлек, төрлелек һәм яңа тип геройларның сәхнәгә чыгуы. Бу очракта, гомумән, форма һәм эчтәлектәге эзләнүләр турында сүз алып бару дөрес булыр. Югарыда билгеләп үтелгәнчә, А. Әхмәдуллин татар драматургиясенең төп үсеш юлы реализм белән бәйле дип саный. Шулай да ул аерым авторларның романтик сурәтлелеккә йөз тотуын яисә модернизм элементларын файдалануын һич тә инкарь итми. Киресенчә, реалистик иҗат методы кысаларына сыймаган форма-алымнарны кулланып, «икенчел художество моделе» тудыру омтылышларын яңалык буларак тәкъдим итә. Шуны да билгеләп үтик, авторның «мондый әсәрләрдә барысы да бер хис яки фикергә хезмәт итә, ә эчке кичерешләр, психологик халәтләр юк дәрәҗәсендә» дигән бик тә бәхәсле тоела.

Хәзерге драматургияне әдәби процессның төрле чорлары, аерым алганда XX йөз башы сәхнә әдәбияты белән чагыштыру, бер яктан, аерым традицияләр дәвамчанлыгын билгеләргә, яңалыкларны ачыграк күзалларга ярдәм итсә, икенче яктан, сәхнә әдәбиятының үсеш-үзгәреш тарихын тулырак һәм билгеле бер системада күзаллау мөмкинлеге бирә. Монографиядәге яңалыкларның аеруча мөһиме аерым драматурглар иҗаты белән бәйле Т. Миңнуллин, А. Гыйләҗев, И. Юзеев, Р. Хәмид, Р. Мингалим, Ю. Сафиуллин турындагы язмалар тулы бер циклны тәшкил итә. Шулай ук З. Хәким, Аманулла, М. Гыйләҗев, Д. Салихов, Г. Каюмов кебек урта буын авторларның иҗади эзләнүләрен билгеләү дә яңа сүз буларак кабул ителә. Гомумән, биредә байтак драматургның тулы иҗат портреты тудырыла, аларның сәхнә әдәбияты тарихындагы урыны билгеләнә.

Фәнни хезмәтләрдә каршылыклы яисә бәхәсләргә этәргән урыннар булу—табигый күренеш. Биредә автор төрле еллардагы мәкаләләрне, фәнни бәяләмәләрне, күзәтүләрне файдалануын искәртеп үтә. Әлеге язмалар заман биеклегеннән торып тулыландырылсалар да, соңгы еллардагы фикерүйланулар белән аралашып, шактый төрлелеккә китерә.

Хезмәтнең икенче бүлегендә XX гасырның 60-80 нче еллар әдәби процессына әйбәт күзәтү ясала. Ләкин Янарыш чорындагы сәхнә әдәбияты торышына бәя биргәндә автор янадан бу чорның күпсанлы әсәрләренә әйләнеп кайта. Кабатлау килеп чыга. Икенче яктан, аерым әсәрләргә анализ-бәяләмәләрне тулыландыру сорала. Мисал өчен, И. Юзеевның «Кыр казлары артыннан» драмасындагы төп геройларның берсе булган Малик турында мондый нәтиҗә ясала: эшчән, булдыклы, әмма үзе өчен генә яшәүче кеше, шуна күрә киләчәге юк. Бүген—шәхси эшмәкәрлек, капитал мөнәсәбәтләр алга чыккан вакытта—әлеге караш белән килешү кыен. Аерым бер теоретик сорауларга бәйле фикер каршылыклары да очрый. Алдарак «уңай герой» проблемасына мөнәсәбәтемне белдергән идем. Авторның Ю. Әминов иҗатына бәйле рәвештә, кешеләрне һәм тормышның үсеш тенденцияләрен матур итеп сурәтләүне реализм чагылышы һәм мондый сурәтлелектә «сәнгатьчә дөреслек тулырак чагыла», диюен дә кабул итүе кыен. Аерым авторлар иҗаты тематика һәм жанр хасиятләреннән чыгып карала. Шуңа бәйле рәвештә анализ-бәяләмәләрдә чынбарлыкның дөрес чагылышы, проблемалар яңалыгы, пьесаларның жанр таләпләренә туры килүе, геройга мөнәсәбәт һ. б. мәсьәләләр өстенлек итә, ә инде эстетик як читтәрәк кала.

Профессор А. Әхмәдуллинның бу монографиясе хәзерге татар драматургиясен тикшергән хезмәтләрнең берсе буларак, үзенең фәнни нигезе, логик эзлеклелеге, фактик материалга байлыгы белән әһәмиятле. Биредә XX гасырның икенче яртысы сәхнә әдәбияты турында тулы күзаллау бар, аерым драматургларның иҗат портретлары тудырылган, традицияләр дәвамчанлыгы һәм житди яңалыклар ачыкланган. Галимнең бу хезмәте татар әдәбият белемен үстерүгә хезмәт итә. Шуңа да драматургларыбызның да, әдәбият тарихын өйрәнүчеләрнең дә әлеге хезмәткә мөрәҗәгать итәчәкләренә шикләнмәскә мөмкин.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ**

# З

**ЗӘНКИЕВ** Якуб Камали улы (6.4.1917, Иркутск шәһ. – 7.3.2003, Тобольск шәһ.), язучы, педагог, РСФСРның атказ. укытучысы (1957). Төмән укытучылар ин-тының физика-математика бүлеген тәмамлый (1940). 1934 елдан Төмән шәһәренең урта мәктәпләрендә укытучы булып эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша. Армиядән демобилизацияләнгәннән соң (1946) укытучылык эшен дәвам итә. 1952-55 елларда Тобол район халык мәгарифе бүлеге мөдире. 1955-75 тә Тобол р-ны Епанчи 8-еллык мәктәбе директоры. Себер татарлары тормышы турында "Иртеш таңнары" (1-2 кит. 1994; русчага тәрҗ. "Зори Иртыша", Төмән, 1996-98; Г.Тукай исем. ТР Дәүләт премиясе, 2002), "Ялкында өтелгән мәхәббәт" (Төмән, 1999) романнары, балалар өчен «Кайчыколак» (Төмән, 1994) исемле хикәяләр җыентыгы авторы. 1нче, 2 нче дәрәҗәдәге Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр белән бүләкләнгән.

Әд.: Луновикая красавица Сузге. Тюмень, 1997; Алишина Х. Себер татарлары елъязмачысы // Мәдәни җомга. 1997. 11 апр.; Хәмитов Г. Яшисең икән, димәк, юкка түгел...// Татар иле. 2001. 18 май.

*Г.М.Габделхакова.*

**ЗЕРНИТ** Бруно Иванович (9.8.1914, Лифляндия губернасы Скриверово а. — 6.12.1960, Казан), шагыйрь. 1920 еллар ахырыннан Казанда яши. Казан җитен комбинатында эшли, 1939 елдан «Советская Татария» г–тасы редакциясендә (әдәбият бүлеге мөдире, җаваплы сәркәтип). СССР язучыларының 1 нче съезды эшендә катнаша (1934). «Каршы килүче 140 нчы» («140–встречный») исемле беренче шигъри җыентыгы 1931 елда дөнья күрә. Бөек Ватан сугышы елларында «Гаделлек өчен сугышка» («В бой за дело правое», 1941), «Үлемнән көчлерәк» («Сильнее смерти», 1944) исемле шигъри җыентыклары чыга. Сугыштан соңгы иҗаты эпик жанрга тартым. «Иделдә кыяташ бар...» («Есть на Волге утёс...», 1949) һәм М.Җәлилгә багышланган «Плахада яңгыраган җыр» («Песня на плахе», 1957) поэмалары, Бөек Ватан сугышы геройлары турында очерклар авторы.

Әсәр.: Избранное. К., 1955.

Әд.: Гиниятуллина А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970; Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**ЗИННУР** (19 йөзнең 2 нче яртысы), шагыйрь. Аның исеме «Моны язган, Зиннурдыр — минем атым» исемле китап авторы буларак «Кыйсса–и Хуҗа Гаффан» (2нче басма, 1880) дастан–поэма ахырында телгә алына. Поэмада бөлгенлеккә төшеп, хатыны б-н улын хәерчелектә калдырып, шәһәреннән чыгып качкан сәүдәгәр Гаффан турында сүз бара. Поэмасын язганда З. шәрекъ дастаннарының әкияти сюжет элементларын файдалана. Шуның б–н беррәттән автор халык көнкүрешен, түбән катлам кешеләренең реаль тормышын, җәмгыятьтә хөкем сөргән социаль гадельсезлекне тасвирлауга күп игътибар бирә. Бу хәлдән чыгу юлларын мәгърифәтче язучы төрле һөнәрләрне үстерүдә, җәмгыятькә файда китергән хезмәт б–н шөгыльләнүдә күрә. Поэманың теле гади, халык сөйләм теленә якын, казакъ теле элементларына бай. Поэма берничә мәртәбә басыла.

*М.В.Гайнетдинов.*

**ЗӨБӘЕРОВА** Диләрә Гази кызы (9.1.1930, Сарман р-ны Күтәмәле ав.— 15.12.2000, Казан), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1980). Казан педагогия ин-тын тәмамлагач (1952), Татарстан кит. нәшриятында балалар һәм яшүсмерләр әдәбияты бүлегендә мөхәррир булып эшли. 1955-59 елларда авыл мәктәбендә укытучы, район газеталарында әдәби хезмәткәр һәм тәрҗемәче вазифаларын башкара. 1960-62 дә «Социалистик Татарстан», 1962-85 тә «Азат хатын» ж-лында бүлек мөдире. 1950 елларда «Яшь сталинчы» газетасында беренче язмалары басыла. Күмәк җыентыкларда публицистик мәкаләре дөнья күрә. Яшьләр тормышы белән кызыксыну аның «Кичер, сөеклем!» (1971), «Кызлар, кызлар» (1977), «Яшьләр күңеле» (1980) исемле җыентыкларына кергән хикәя һәм повестьларының төп темасын билгели. Публицистик мәкаләләре «Халкым хаклы» (1990) исеме белән аерым китап булып басылып чыкты.

*Г.М.Габделхакова.*

**ЗӨЛКАРНӘЙ** (Зөлкарнәев) Габдулла Галим улы (3.10.1905, Петропавловск ш. (хәзерге Казакъстан)— 6.9.1935,

*Дәвамы. 2005 елның 4нче саныннан басылып килә.*

Казан), драматург. 1925 елдан Казанда яши. Татар театр техникумын тәмамлый (1930). 1930–34 елларда Сәнгать хезмәткәрләренен республика профсоюзы ҮК (ТАТРАБИС) рәисе булып тора. 1934 елда Татар укчылар полкы взводы командиры итеп куела һәм берүк вакытта часть клуб мөдире булып тора. «Партизаннар», «Кан тамчылары», «Серләр чишелде», «Пчакка каршы пчак», «Өермә» (1932 елда Татар академия т-рында куела), «Ил чигендә» (1932), «Повар» (1933), «Ана» (1934) һ.б. пьесалар авторы.

Әдәб.: Өермә // Кызыл Татарстан. 1932. 2 ноябрь.

**ЗӨЛКАРНӘЙ** Ләис Мәүлит улы (псевд., чын фам. Харрасов) (2.4.1962, БАССРның Бакалы р-ны Саскүл (Бишкаен) ав.), шагыйрь. Казан ун-тын тәмамлаган (1984). 1983-93 елларда «Ялкын», 1993 тән «Идел» ж-лларында мөхәррир. «Балачак күге» (1984), «Кар өстендә алмалар» (1988) исемле шигырь җыентыклары, ш.у. хикәяләр авторы. З.нен иҗатына нечкә лиризм хас, эмоцияләргә бай.

Әд.: Вәлиев М. Егермедәгеләр // Учагын сүнмәсен. К., 1988.

**ЗӨЛФӘТ** (псевд., чын исем фамилиясе Маликов Дөлфәт Госман улы) (3.1.1947, ТАССРның Мөслим р-ны Яңа Сәет ав. — 15.5.2007, Казан), шагыйрь, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1992). Казан ун-тында укый. А.М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршында Югары әдәби курслар (Мәскәү, 1979) тәмамлый. «Чаян» ж-лында (1969-74), «Яшь ленинчы» газетасында (1979-83) әдәби хезмәткәр булып эшли. «Беренче карлыгачлар» җыентыгында (1968) тәүге шигырьләре басылып чыга. «Язмышлар ярында» (1971), «Утлы бозлар» (1978), рус теленә тәрҗемәдә «Осенние костры» (1985), «Адашкан болыт» (1990), «Ике урман арасы» (1995) исемле шигырь җыентыклары авторы. З. нең поэзиясендә чагылган темалар күптөрле. Шагыйрьне бигрәк тә татар халкының тарихи үткәне ("Сөембикәнең хушлашу догасы", 1978; "Нәсел тамгасы", 1999), аның мәдәнияте һәм теле язмышы ("Татар теленең каргышы", 1978) борчый. Кешеләрнең тормышларын бозган чорның фаҗигале вакыйгалары турында шагыйрь борчылып уйлана ("Марш", 1986; "Халык дошманы турында бер истәлек", 1986; "1937", 1999), замандашларының эш-гамәлләрен бәяләргә омтыла, мәхәббәт турында күп яза. Аның әсәрләрендә тыелгысыз хисләр агымы, экспрессив тәэсирлелек өстенлек итә. Ул чынбарлыктагы, табигатьтәге кечкенә генә деталь, факт, күренеш аша поэтик фикерне калку, масштаблы итеп җанландыру осталыгына ия; язу манерасына публицистик кайнарлык, ихласлык, халык иҗатына — әкият, бәет, дастан, җырларга нигезләнгән романтик образлылык, җыйнак композиция, төзек ритмика хас; теле символ-метафораларга бай. З. — Һ.Такташ традицияләрен дәвам итүче романтик шагыйрь; "традицион" шигырь формаларына өстенлек бирсә дә, анда субъектив һәм кискен каршылыкларга корылган, үзенә генә хас үзенчәлек бар. Боз һәм Ялкын, Мәхәббәт һәм Нәфрәт, Яшәү һәм Үлем, Мизгел һәм Мәңгелек кебек төшенчәләр аша З. образлы фикерләү тудыра. Аның шигъриятында һәрвакыт фәлсәфи төсмер өстенлек итә. З. шулай ук композитор Л.Хәйретдинова музыкасына «Мәкерле песи» (1974; ТАССРның М.Җәлил исем. комсомол премиясе, 1978) исемле беренче татар балалар операсы либреттосы, «Әкият» Казан курчак театрында куелган «Җен кызы» (1992), «Таңга —Чулпан, Айга— Зөһрә» (1999) пьесалары авторы да. Аның шигырьләренә композиторлар Ф.Хатыйпов, З.Гыйбадуллин һ.б. тарафыннан язылган җырлар халык арасында популярлык казанды. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт премиясе лауреаты (2000).

Әсәр.: Йөрәгемне былбыл чакты. К., 1999.

Әд.: Шабаев М. Сандугач язмышлы шагыйрь // Казан утлары. 1996. №5; Зәйдулла Р. Без гөл өзгән кырларда // Идел. 2000. №2; Юсупова Н. Тылсымлы сүз остасы // Казан утлары. 2007. №1.

*Т.Н.Галиуллин, Р.Ә.Мостафин.*

**ЗАКИРОВ** Марат Хәлил улы (27.4.1969, Мамадыш р-ны Дусай ав. туа), язучы. Казан педагогия ин-тын тәмамлый (1993). «Шәһри Казан» газетасында әдәби хезмәткәр (1990-92), Татар дәүләт яшьләр т-рында әдәби бүлек мөдире (1992-93), «Идел» ж-лында мөхәррир (1993-2001), 2001 дән «Казан утлары» ж-лында проза бүлеге мөхәррире булып эшли. «Төшкә керүче елан» (1996), «Гаптери мажаралары» (1997) повестьлары, «Кояшлы төн» (2003) шигырь җыентыгы авторы.

Әд.: Хужин М. Үзенчә // Казан утлары. 2001. №11.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

## Флүн Мусинга 70 яшь



Флүн Мусин—татар әдәбияты фәне һәм тәнкыйте өлкәсендә зур хезмәт куйган галимнәрнең берсе. 1939 елның 23 февралендә Мөслим районы Иске Карамалы авылында туып, башлангыч һәм урта белемне авыл мәктәбендә алган егет, югары белемне 1957—1962 елларда М. В. Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетының филология факультетында ала. Аны уңышлы тәмамлаганнан соң Казанга кайта, теоритик белемне практик нигездә кулланып, "Социалистик Татарстан" (хәзерге "Ватаным Татарстан") газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр вазифасын башкара. 1963 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына фәнни хезмәткәр булып эшкә күчә, кандидатлык диссертациясе яклый, филология фәннәре докторы (1983), профессор (1993) дәрәҗәләренә ирешә.

Галим-тәнкыйтьченең әдәбият тарихын һәм әдәби процессы ныклап өйрәнеп "Тормыш сынавы аша", "Тарих һәм заман", "Чорлар бәйләнешы" исемле китаплары дөнья күрә. Бер үк вакытта татар һәм рус телләрендә чыккан әлеге китаплар алтмышынчы-җитмешенче еллардагы татар совет прозасының хәлен, үсеш үзенчәлекләрен, анда күтәрелгән проблемаларны яктыртып язылган җитди хезмәтләре булып санала.

Флүн Мусин шулай ук татар әдәбияты казанышларын башка милләт халыкларына да җиткереп, "Правда", "Литературная газета" битләрендә, "Огонек", "Дружба народов" кебек танылган журналларда мәкалә-рецензияләре белән еш катнаша.

Соңгы елларда республикабызда уза торган Акмулла, Исхакый, Тукай кебек күренекле шәхесләребезгә багышланган гыйльми һәм әдәби конференцияләрдә ул даими рәвештә чыгышлар ясый, аларны матбугатта яктырта, "Гаяз Исхакый тормышы һәм иҗат юлы" (1989) исемле китабын бастырып чыгарды.

Урта мәктәпләр өчен татар әдәбияты дәреслекләре әзерләп бастыру да галим һәм тәнкыйтьче Флүн Мусин эшчәнлегенең җитди өлеше булып тора. 2008 елда басылган "Татар әдәбияты" дәреслеге (рус мәктәпләре өчен) шуның ачык мисалы.

Ул—1970 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

Аны олуг бәйрәме белән ихлас котлыйбыз, исәнлек-саулык, яңа иҗат уңышлары телибез.

# ТАТАР ЭЗЛӘҮЧЕ ДУСТЫБЫЗ

## Рәфыйк Шәрәфиевкә 70 яшь

Туксанынчы еллар башында "Азатлык мәйданы"на чыккан язучыларыбыз бүген татар әдәбияты мәйданын тота. Юкка гынамы каләмне штыкка, ә шагыйрь сүзен утлы ядрәгә тиңләгәннәр, ижат итү ул—күпчелек халыкны яклап аваз салу, тиранлыкка каршы күтәрү, көрәшкә өндәү. Бер сүз белән әйткәндә, чын язучы көрәшче генә була ала.

Рәфыйк Шәрәфиев гомер буе үзенең чын көрәшче икәнлеген белмичә яшәгән. Төгәл утыз биш ел буе Балтач районының "Хезмәт" газетасында эшләгән дә эшләгән, өлкә газета-журналларына язган да язган...

Татарстанда Балтач дигән бер төбәк бар. "Кара күл"е, Шушма елгасы, тал плантацияләре һәм этник чуарлыгы белән (анда ике төрле татар, татарлашкан мари, рус гаиләләре) тыйнак кына яшәп ята. Балтач үзе ерактан ук күренеп-мактанып тормый, чоңгылда, елга үзәнендә. Үр төшә башлагач кына кояшлы буяуга манылган койма-капкалары, өй кыеклары пәйда була. Болытлы көннәрдә дә урамнары гел аяз аның. Шул кояшлы урамнарда безнең илһамияткә исемнәре бик таныш Кариевләр, Г. Мөхәммәтшин, Ә. Фазылжанов, А. Гайфуллина, Ф. Шакирова, Н. Әминовлар капкасы да бар.

Рәфыйк Шәрәфиев Балтачның үзеннән җиде чакрым читтәрәк яши булыр. Ул Карадуганда туган, шунда үскән, район газетасы редакциясенә велосипед белән утыз биш ел буе көн саен килеп-китеп эшләп йөргән.

Чын журналист, фикерле аналитик, туры сүзле тәнкыйтьче буларак аның исеме Казанга узган гасыр азагында уянып алган сүз иреге белән килеп керде.

Мин аның 40 яшьлек чагын хәтерлим. Ул елларда Рәфыйк Шәрәфиев район газетасының редактор урынбасары иде. Ә мин—практика үтәргә дип Мәдәният сараена дүрт айга җибәрелгән шәкерт. Кичләрен районның әдәбият-сәнгать осталары белән диплом өчен зур юмор кичәсе әзерлим, көндезге вакытны әрәм итмәс өчен "Хезмәт"тә штаттагы хәбәрче.

И бу дөньяның тыгызлыгы...

1980 елда минем беренче язмаларымны укып, типографиягә кул куеп җибәргән урынбасар Рәфыйк Шәрәфиев белән шушы чаклы иҗади дуслыгыбыз дәвам итәр дип кем уйлаган?!

Мин, Казан каласында яшәп караган утыз яшьлек егет, ул чагында Балтач дигән, моңарчы һич күрмәгән зур авылга килеп төшкәч, "мөгез чыгарырга" тырышканмындыр инде, очерклар гына түгел, фельетоннар да язып, кайбер колхоз җитәкчеләре белән "Хезмәт"не дә чәкәләштергәли идем. Рәфыйк Шәрәфиев минем язмаларны астыртын киная белән, ничектер кырын карабрак укый сыман иде. Ләкин, кире бормый, кыскартмый, үзгәрттерми, мактамый, тик кул гына куя. Ә бит матбугатның кагыйдәсе бик гади—кем кул куйса, шул җавап бирә.

Рәфыйк Шәрәфиевнең ул карашын мин бүген дә тоям. "Казан утлары"на килеп кергән саен: тагын нәрсәне укыды икән инде, бик кинаяле бит моның исәнләшүе дип каушап калам. Җитмеш яшьлек дустыбыз укыганын сөйләп тормый, тиз арада язып китерә. Рәфыйк Шәрәфиев укымаган әсәрләргә шикләнеп карыйм мин хәзер. Әгәр "мин кем?!" дип масаеп йөргән кайсыдыр ки язучыларыбыз турында ул язып чыкмаган, фикерен җиткермәгән, ягъни игътибар итмәгән икән—моны иң кырыс бәя дип аңларга кирәк.

Рәфыйк Каләметдин улы (әтисенең исеме чынлап та шулай) Шәрәфиевнең "Утлы күнел" (ТКН—2001), "Татар эзләү" (ТКН—2006) һәм тапшырырга әзерләнгән "Ник

сызланасың, йөрәк" дигән китапларына житмештән артык мәкалә сыйган. Димәк, яшибез әле, татар бетә дип, үкереп елап ятасы юк, язасы да язасы! Яза бит Рәфыйк дустыбыз—жанр төрлелегеннән дә курыкмый! Кирәксә, Илдар Юзеев кебек поэзия атлантларының иҗатына анализ ясый; Мирхәйдәр Фәйзи драматургиясен сүтеп җыя; Айдар Хәлим, Марат Әмирхан, Флүс Латыйфи, Факил Әмәк кебек бүгенге прозаикларның иҗатына соклана. Шуңа күрә дә язучыларның "Җамал Вәлиди" исемендәге премиясен беренчеләрдән булып алды ул.

Иң мөһиме—бүгенге көн һәм бүгенге иҗат турында яза ул. Борынгы тарихыбызны бизәкләргә күмеп бүгенге укучыны сокландырып була; киләчәкне ашыктырып фантастика, йә мажаралы әсәрләр иҗат итсән дә ярый... Ә менә бүгенге чынбарлык турында матур әдәбият үрнәкләре тудыруы җиңел түгел. Язылган кадәресенә позитив бәя бирүе исә тагын да кыенрак. Рәфыйк Шәрәфиев исә андый әсәрләрне таба белә, тиешенчә анализлый ала.

Кичә мәдхия укыган әсәрләрнең кайсысы исән калыр? Бүген язылганнары арасында киләчәккә барып җитәрлекләре табылырмы? Иртәгесе көнебез кайсы әдипләр кулында? Тәнкыйтьчебез әнә шул юнәлештә эзләнә. Алай гына да түгел, язучыларыбыз яшәп һәм иҗат итеп яткан вәзгыятьнең сәяси каршылыкларын актив бәяли, күренекле шәхесләрне барлый, илдәге һәр кискен үзгәрешкә үзенең мөнәсәбәтен белдерә.

Балтач Татарстанның төньяк өлешендә. "Бездә кар яуды инде",—дип килеп керә ул кайбер көннәрдә. Без аны яңгырлы Казанга чакырабыз. Ул көлә генә: "Үзегез яшәгез Казаныгызда! Миңа Балтачтан бөтен дөнья күренә..."—ди.

Тукайның әнисе күмелгән Балтач якларында яшәүче язучыларыбызда сәерлек бар шул бераз...

**Камил КӘРИМОВ**

## *Алхәбәр. "Казан утлары" — 2009*

«Шул вакыйгадан соң Сәрвине Салих янәшәсеннән алдылар, бу чибәр кыз Сабит белән парлашты. Ә Салих янына Улина килеп басты. Оттымы, оттырдымы Салих—монысын үзе дә аңламый. Тик таза, нык һәм эш рәтен белгән Улина белән вагончык төртә башлагач, йөк күпкә җиңеләеп китте. Элек җанга тигән рельс киртекләре дә каршы тормыйлар, тәгәрмәчләр чыжлап кына үтә. Аның каравы карусель өстендә лом тоткан Сабит, вагончык сыртын йолыккалаган Сәрви ешрак күзгә чалындылар. Биленә кул тисә, Улина һич тә каравыл кычкырмый, тайчынмый, киресенчә шаркылдап көлә, серле елмая... Кеше белән кеше аерылган кебек, кызлар да төрледән-төрле икән...»

Әлеге юллар Сәгыйдулла Хафизовның "Сәрви-Сәрвиназ" повестыннан. Автор Татарстан Язучылар берлегенең Җамал Вәлиди премиясе лауреаты, журнал укучыларыбызга "Гомер фасыллары" дигән әсәре белән таныш.

"Сәрви-Сәрвиназ" повестында, комсомол путевкасы белән эшкә килгән ике яшь йөрәкнең язмышы җырга күчә...

♣

## Роза Хафизованың тууына 80 ел

Балалар язучысы Роза Сәет кызы Хафизова 1929 елнын 6 февралендә Бөгелмә шәһәрендә хезмәткәр гаиләсендә туган. Татарстанның хәзерге Лениногорск районы Сарабиккол авылы мәктәбендә жиде сыйныф һәм Иске Шөгер урта мәктәбендә унны тәмамлаганнан соң, 1947-51 елларда Казан дәүләт университетынын татар филологиясе бүлегендә югары белем ала. 1951-52 елларда Төмән өлкәсенең Тобол шәһәрендәге татар урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты фәннәрен укыта.

Р. Хафизованың шуннан соңгы хезмәт юлы журналистика белән бәйле: 1952-1960 елларда ул «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре»), «Сталин байрагы» (Чистай өлкә газетасы), аннары Казандагы күп тиражлы завод газетасы редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, КПССның Татарстан өлкә комитеты каршындагы Партия тарихы институтында тәржемәче һәм Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшли. 1960-62 елларда исә Мәскәүдә Югары партия мәктәбенең журналистика бүлегендә укый, шунда аспирантура курсын тәмамлый. 1962 елдан 1986 елга кадәр Р. Хафизова—«Ялкын» журналының баш редакторы.

Роза Хафизова—үзенең әдәби ижатын тулысынча балаларга багышлаган язучыларның берсе. Аның нәниләр өчен әкиятләре һәм тәрбияви эчтәлектәге хикәяләре тупланган «Кыңгыраулар жыры» исемле беренче китабы 1967 елда басылып чыга. Соңрак ул ике дистәдән артык китап авторы. Аның «Курай-малай мажаралары» (1969), «Кирлемән» (1970), «Кашкарыйлар озын гомерле» (1975), «Әкиятләр» (1976), «Без әле кайтырбыз» (1977), «Сак-Сок тавышы» (1987), «Киек каз юлы» (1988), «Актәпи ник моная?» (1991), «Карурманда ниләр булмас» (1999) кебек китаплары яшь укучылар арасында популярлык казандылар. Әсәрләрендә язучы, яшь буынга тәрбия бирү мәсьәләләрен үзәккә алып, балаларга дуслык, гаделлек, намуслылык, тыйнаклык кебек гомумкешелеккә хас сыйфатларны сендерергә, әкияти вакыйгалар, мажаралар аша сабыйлар күңелен кузгатырлык югары әхлаклы, хезмәт сөючән, ата-анага, өлкәннәргә ихтирамлы балалар образларын тудырырга омтыла. Р. Хафизованың әсәрләре бүген дә популяр.

Аның төрле елларда язган публицистик мәкаләләре, эсселары һәм юмор-сатирага караган язмалары тупланган «Дөрес юл кая илтә» (2001) жыентыгы, «Ачылмаган серләр» (2004) һ.б. китаплары да дөнья күрде. Р. Хафизованың аерым әсәрләре рус, үзбәк, казакъ, украин һ. б. телләргә тәржемә ителгән.

Матбугат һәм татар балалары әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен Р. Хафизова 1974 елда—Татарстанның, ә 1983 елда РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исемгә лаек булды. Ул—1984 елдан Язучылар берлеге әгъзасы иде. Роза Хафизова 2005 елның 20 августында Казанда вафат булды.

## Без нинди кавем?

Шигъри аргамагын әле йөгәнләргә өлгермәгән Нури Арслан заманында «Кызыл Татарстан» гәзитендә рәссам булып эшләде. Иҗат туктаган, сәмән ягы чамалы. Әмма күңеле көр, үзе горур. Пәһлеван гәүдәле дала егете, чын арслан инде, валлаһи! Тубалдай ак чәчләрен җилфердәтеп, коридорда җырлап кына йөри. Ана шигъри илһам шул чакларда килгәндер дип беләм.

—Гел казакъ даласы, дисез, ул якларга ничек барып чыктыгыз?—дип кызыксынам.

—Беркая да барып чыкмаган, шунда туып-үскән,—ди рәссамыбыз.—Белмәсәң, белеп кал, агайне: син үзең дә безнең яклардан.

—Ничек?

—Барыбыз да бер тамырдан, Алтай төркиләре без. Ашина нәселеннән, шул кавем кешеләре.

Менә сиңа мә! Мин үземне Казан татары дип йөри идем. Белмәссең тагын?!. Кеше үзгәрә бит ул. Әнә, Нури Арслан да татарның олуг шагыйре булып китте бу дөньядан. Бүген инде галимнәребез дә Алтай тамырлы төркиләр икәнлегебезне расларга омтыла. Укып белүемчә, кешелекнең генофонды нәкъ менә Алтай, Тибет тау куышларында саклана, ди.

## Соңгы сурәт, соңгы сүз

«Татарстан» журналының 80 еллык юбилее тантанасына мәшһүр җырчыларыбыз Зөһрә Сәхабиева белән Хәйдәр Бигичевне дә чакырдык. Зөһрә ханым тәкъдиме белән фойеда өчәүләп фотога төштек. Бераз читкәрәк китеп торгач, Зөһрәсен калдырып, Хәйдәр кабат минем янга килеп басты.

—Бүтән әллә төшеп була, әллә юк, тагын бер кадр алсын әле,—дип, фотографны дәштерде.

Йа, Хода! Бер айдан Хәйдәребез китеп тә барды. Аның бу фотосы соңгысы булгандыр, ахрысы.

Шулай да Хәйдәр минем күз алдымда Кремль эченнән барган азатлык демонстрациясенең уң ягыннан, яхшы айгырдай башын һавага чөеп, буй җиткән улы белән бергә атлап барадыр сыман...

## Күңел күзе күрә ул

Гадәттә, атаклы кешеләр "ат"тан сикереп төшәргә теләмиләр, ияргә ябышып яталар. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры баш режиссеры Марсель Сәлимҗанов андый затлардан түгел иде бугай. Бәлки, фани дөньядан иртәрәк китәсен сизенгәндер. Бәлки...

1984 елның июнендә аның белән әңгәмә корырга баргач, «уф» итеп бер көрсенеп алды да, кистереп әйтте:

—Минем хакта житеп торыр, дускай. Яз әле Фәрит дигән егетебез турында. Без аны Мәскәүгә, режиссерлыкка укырга җибәрергә җыенабыз, бәлки, язманың файдасы тияр.

—Алмаш әзерлисезме?

—Ә нигә?! Ифрат талантлы егет. Яңа әсәр куя, иртәгә премьерасы, кил, кара, бәя бир, язарсың.

Ике спектакль карадым. Берсе—Илдар Юзиңең «Улыбыз өйләнә, без аерылышабыз» комедиясе, Фәрит Бикчәнтәев анда үз яшендәге яшь егет Глүс ролен, ә Глүснең әнисе Зөлфияне—Фәритнең әнисен Наилә ханым Гәрәева башкарды. Искиткеч тәңгәллек! Тормышчанлык. Бәя биреп бетергесез талантлы табыш!..

Икенче тамаша—Лопе де Веганың «Мәхәббәт мажаралары». Әсәрне тиз арада һәм зур шигъри осталык белән Илдус Әхмәтҗан тәрҗемә кылган. Сәхнәгә куючы режиссер—Фәрит Бикчәнтәев. Беренче спектакльдәге шикелле үк, төп рольләрдә алар әнисе белән бергәләп уйнадылар. Тамашаны караган театр артистларының

рәхәтләнеп көлеп утырулары, «Афәрин!» кычкырып, шаулатып кул чабулары спектакльгә бирелгән олы бәя иде. Яшь талант Фәрит Бикчәнтәев уңышлары турында «Татарстан яшьләре» газетенең бер битен тутырып яздым. Мәкалә Мәскәүгә китте. Институтка керү кәгазьләренә теркәлгәндерме-юктырмы—белмим.

Бүген инде Фәрит Бикчәнтәев—данлыклы театрыбызның баш режиссеры. Күнел күзе белән күргән икән Марсель Сәлимҗанов талантны.

## Безнеке—кемнеке?

Гаҗәп инде шулай да! Ул чакта үзең эзләп тапкан, сине дулкынландырган, язарга теләгән тема яки берәр күренекле шәхес торып кала, редакция җитәкчелеге кушкан буенча алдынгы тукучы яисә чучка караучы апай янына чыгып йөгерәсең. Шуны күккә чөеп мактыйсың.

—Курманаев турында яз,—диделәр, кулыма адрес тоттырып.

—Кем соң ул Курманаев?

—Наданлыгыңны күрсәтмә, бар, архивка кер, өйрән,—ди бүлек мөдире.

Тиешле белешмәләрне туплап, шактый гына коралландым, мәгәр. Курманаев дигәннәре (исеме хәтердән чыкты менә) ул чактагы үлчәү белән легендар шәхес иде. Октябрь инкыйлабыннан соң, Татбригада командиры сыйфатында бөтен Урта Азияне, Төркестанны айкаган зат.

Адреста күрсәтелгән Татарстан урамындагы мәгълүм йортның фатирына чылтыраттым. Ишекне... Будённый ачты. Тач үзе! Буе 2 метр чамасы, имәндәй базык гәүдәле. Ә мыегы—Будённыйның борын астыннан кубарып ябыштырылган диярсең. Куе, озын, очлары исә кәкрәеп өскә таба үрләгән. Аягында, җәй уртасы булуга карамастан, озын кунычлы, тез башларын томалаган кызгылт күнитек. Югалдым да калдым ишек төбендә.

—Кер,—ди хуҗа, алдан телефон аша сөйләшүебезне искәреп. Кердем. Инде кызыл күнитек түгел, стенага эленгән олы Бохара келәме, аңа беркетелгән әкәмәт озын кылычлар, хәнҗәр, алтатар һәм жиз быргы гаҗәпләндерде. Менә нинди полководец икән ул Курманаев! М. Фрунзе, Я. Чанышев, Ш. Усмановлар белән бергә, Урта Азиядә басмачларга каршы погром ясап, Совет хөкүмәтен урнаштырып йөргән кеше шундый булырга тиештер дә инде!..

60нчы елларда ук сигез дистәне тутырган хәрби ветеран әле һаман да гайрәтлелеген югалтмаган. Келәмдәге экспонатларына ишарәләп, кайсының кайчан, кем тарафыннан, нинди уңышлары өчен бүләк ителүен, давыллы яшьлек еллары турында бәян кылды. Болар хакында тәфсилләп язып та чыктым.

—Урта Азия безнеке!—диде, әңгәмәбез ахырында карт большевик.

Үзбәк, таҗик, төрекмән, кыргыз башкачарак уйлый бүген ул хакта.

Чөнки берчак мина да элэкте үзбәкләрдән! Өлкәннәребез әнә шул чакта кылыч уйнаткан өчен...

## Әдәбият алашасы

Мин аны яклап язам. Журналист, тәнкыйтьче Фатыйх Мөсәгыйтьне...

Нәшриятта яңа китап басылса, Ф.Мөсәгыйть аны шул кичтә үк укып чыга. Театрда премьера——яңа әсәр сәхнәләштерелә. Ф.Мөсәгыйть шунда. Ике-өч көн дигәндә матбугатта йә унай, йә үтергеч тәнкыйть мәкаләсе басыла. Бетте бит безнең заманда тәнкыйть дигән татлы җимеш яки әче торма.

Инде үтергеч тәнкыйтькә кайтыйк. «Әче торма» дигәннәре заманында шагыйрь Һади Такташның да бәгърен әчеттергән. Тикмәгә генә шагыйрь Фатыйх Мөсәгыйтьне «әдәбият алашасы» дип атамаган да инде!

Пенсиягә чыккач, Фатыйх ага Мөсәгыйтьне бүләкләре белән өенә озатып куюны миңа йөкләделәр. Сак кына Такташ сүзләренә ишарә ясадым. Ямьсез янгыраган «алаша» сүзен кулланмаска тырыштым. Үзе искәртте.

—Әдәбият-сәнгать йөген минем ишеләр дә тартып барды,—диде тәнкыйтьче.— Такташка үпкәләмим, ачуым басылды, ул юк бит инде.

Бүген Фатыйх Мөсәгыйть үзе дә юк инде.

**Госман ГОМӘР**

## Рифкать Имаев



Имаев Рифкать Гаян улы 1948 елның февраль аенда, Балык Бистәсе районы, Татар Казаклары авылында туа.

1966 елда Котлы Бөкәш авылындагы урта мәктәпне тәмамлагач, Түбән Кама шәһәренең 44 нче һөнәр училищесына укырга керә, аны тәмамлаганнан соң, ягъни 1969 елда "Нефтехим" производство берләшмәсенең (хәзер "Нефтехим" ачык акционерлык җәмгыяте) синтетик каучук заводына аппаратчы булып урнаша һәм шунда 40 елга якын хезмәт куеп, 2008 елда лаеклы ялга чыга.

Шигырьләрне мәктәптә укыганда яза башлый. Алар башта балалар матбугатында, "Идел", "Мәйдан", "Казан утлары" журналларында басыла. Түбән Камада чыгучы "Туган як" һәм "Хезмәттәш авазы" газеталары да укучыларын аның иҗаты белән даими рәвештә таныштырып бара.

Рифкать Имаевның әлегәчә ике китабы дөнья күрде. Беренчесе—"Гомер агышлары", ул 2004 елда нәшер ителде. 2007 елдагысы "Алма балланган вакыт" дип атала. Тиздән "Күңелем бизәкләре" исемле яңа китабы чыгачак.

Аның шигырьләренә, чын мәгънәсендәге хезмәт кешеләрендәгечә, сабырлык, эшкә бирелгәнлек, хис-тойгылар чынлыгы, самимилек хас. Р. Имаевның гражданлык шигырьләре белән рәттән лирик характердагы шигырьләре дә байтак. Кырык еллап иҗат итү дәверендә ул профессиональ дәрәҗәгә ирешкән шагыйрь.

2008 елның 13 ноябрендә, Кабул итү коллегиясе карары нигезендә, Татарстан Язучыларының идарә утырышында Имаев Рифкать Гаян улы Татарстан Язучылар берлегенә (тәкъдимнамә бирүчеләр—Факил Сафин, Фәтхулла Абдуллин, Рәшит Бәшәр) кабул ителде.

## Әлфия Ситдыйкова



Ситдыйкова Әлфия Мирзанур кызы 1957 елда Актаныш районы Күҗәкә авылында колхозчы гаиләсендә туа. 1972 елда Күҗәкә сигезьеллык, 1974 елда Пучы урта мәктәбен тәмамлый. 1975тә Чаллыга килеп, КамАЗ заводына эшкә урнаша, йөк төягеч машинада егерме ел эшли. 2001 елдан «Чаллы-ТВ» телерадиокомпаниясендә музыкаль редактор, 2006 елдан «Күнел» радиосында өлкән корреспондент булып хезмәт юлын дәвам итә. Әдәбият-сәнгать әһелләренен тормышы һәм иҗат юлын яктыртучы «Әдәби учак», «Илһам нуры» тапшыруларын әзерләп алып бара. Шул елларда Чаллы дәүләт педагогия институтынын филология факультетын тәмамлый.

Чаллы Язучылар оешмасы каршында эшләп килүче «Ләйсән» әдәби берләшмәсенә 1976 елдан бирле йөри. Беренче шигырьләре 1977 елда «Кама таннары» газетасында дөнья күрә, 1979да «Яшьлегем Чаллы» күмәк җыентыгында басыла.

2003 елда Әлфия Ситдыйкованың Чаллы газета-китап нәшриятында «Йөрәгемә яфрак сыена» дигән шигырьләр китабы чыга. 2004 елда «Җанда кабынган учак», 2006 елда «Хисләрем канаты—Күҗәкә», «Назга сусау» дип исемләнгән шигырь китаплары дөнья күрә. Ул китапларга кереш сүз язып фатиха бирүчеләр—күренекле язучыларыбыз: Рәдиф Гаташ, Факил Сафин, Рәшит Бәшәр... 2007 елны Татарстан китап нәшриятында «Два родника родной земли. Туган якның ике чишмәсе» дип исемләнгән тәрҗемәләр китабы (тәрҗемәчесе Вера Хәмидуллина) басылып чыга.

2008 елның декабрь аенда, Кабул итү коллегиясенен карары нигезендә, Татарстан Язучыларынын идарә утырышында Ситдыйкова Әлфия Мирзанур кызы Татарстан Язучылар берлегенә (тәкъдимнамә бирүчеләр—Рәшит Бәшәр, Рәдиф Гаташ, Мансур Сафин) кабул ителде.



*Шагыйрь Мәхмүт Хөсәен, журналист Зәрия Хәсәнова, шагыйрь Фәрит Габдрәхим, "Кызыл таң" газетасы редакциясендә. 1988 ел. Уфа.*



*Шагыйрь Рәшит Гәрәй. (1931—1999).*



*Казахстанда яшәүче татар язучысы Ибраһим Салахов Казандагы яшь журналистлар арасында. 1994.*



*Татарстан Язучылар берлегенең Кабул иту коллегиясе әгъзалары. Сулдан уңга: Мөсәгыйт Хәбибуллин, Рөстәм Кутуй, Шаһинур Мостафин, Зиннур Мансуров, Равил Фәйзуллин (рәис), Гөлшат Зәйнашева, Газинур Морат, Марсель Галиев. 2000 ел. Казан.*



*Җырчы Флёра Сөләйманова.*



*Казаннан килгән яшь язучылар Уфадагы каләмдәшләре янында. 2005 ел.*

2008 елгы 5-9 саннарда чыккан "Хунвейбин" романының беренче китабында авторның гомере буе гаделсезлеккә каршы, тәү карашка уңышсыз кебек күренгән көрәше гомумиләштерелгән шикелле.

Татар милләтен, аның мөстәкыйль дәүләтчелеген Явыз Иван таркатканнан соңгы фаҗигаи дәверне һәм аның нәтиҗәләрен Айдар Хәлим мосафир Иркен Сәлахи кичерешләре, аның үтә дә авыр тормыш юлы аша бирә. Дөнья буйлап сибелгән күптән дә күп татарлар кебек, Иркен дә башка ватаннар табарга мәҗбүр була. Туган ватаны Уйгырстанда хунвейбиннар Сәлахиләрне түзеп тора алмаслык хәлгә житкереп, туган җирләрен калдырып китәргә мәҗбүр итәләр. Икенче ватаны АКШ югары мәдәниятле ил булса да, Иркен Сәлахи тарихи ватанын сагынудан туктый алмый. Гомере буе аны идеаллаштырып, илаһи газизлек дәрәҗәсенә күтәреп яши. Тик, анда кайткач, татарның тарихи инсаный сыйфатларын таба алмый иза чигә. Исемнәрнең "кәкрәйтеп" тәрҗемә ителүен (5 сан, 13 бит), татар баласына ят исемнәр кушылуны (41 бит), кешенең бер-берсен, бигрәк тә өлкән яшьтәгеләрне ихтирам итмәвен (23 бит), ярым-йорты урысча сөйләшергә тырышып йөрүне (40 бит) һәм башка бик күп тискәре сыйфатларны күреп, Иркен Сәлахи заман татарының бар нәрсәгә дә битараф булуына хәйран кала. Барыннан да бигрәк диннәр "...ярым-йорты мәҗүси хәләттә" булган кебек, илаһи моң таратып чылтырап аккан татар теле чишмәсенең тирес суына әверелә баруын авыр кичерә ул. Чөнки, тел бозылды исә, югалды исә (Алла сакласын!) татар да бозылды, югалды дигән сүз. Шулай итеп, Иркен ага ватанына ярсулы күңел белән, милләтенең беренчел сафлыгын күрергә өметләнеп килә. Әлеге изге өметләрне ул татар нәселен дәвам итүче хатын-кыздан эзли, гади халык арасыннан һәм хуҗа кешеләрдән эзли. Кабер ташларыннан, табигать һәм төзелеш күренешләреннән эзли. Әмма таба алмый. Татар хәлен Иркен ага бүгенге экология хәле белән тиңли. Шул экология хәлендәге "кәҗә" Зөфәр образын автор ярым шаяру аша бирсә дә, аның язмышында тирән трагизм галәмәтләре ята. Кәҗә хөкемендә калган Зөфәретдин образында без, шул дәвер кешеләре буларак, үзебезне дә күрәбез. Зөфәретдин яшьлегендә формалашкан идеология корбаны дәверен сукыр рәвештә кичерүебез күз алдыннан үтә. Ләкин Зөфәретдин, гаделсезлек артыннан яңа гаделсезлекләр кичереп яшәүгә дә карамастан, кемнәрдер кебек өметсезлеккә бирелеп дөньядан китәргә җыенмый, Иркеннең кинәшче артыш таягы кебек сердәше һәм юанычы булган тальянын ташламый, үзенчә көрәш юллары табарга тырыша.

Айдар Хәлимнең теле ифрат бай, укырга җиңел. "Әсәрнең сюжеты, яратылыш, төенләнеш, үсеш юллары гаять катлаулы",—ди автор роман алдыннан биргән кереш-аңлатмасында. Әмма, бу катлаулылыклар укучыга төп һәм иярчен геройлар янында үзенне тоярга, алар тарафыннан әйтелеп бетмәгән фикерләрне күңелеңдә дәвам итәргә комачауламый. Авторның элекке әсәрләрен дикъкать белән укып барган кеше өчен биредә катлаулылык шактый кими. Әсәрнең тел байлыгы һәм үзләштерүгә җиңеллеге көчле чагыштырулардан тыш авторның рус сүзләрен файдаланмавындадыр һәм, киресенчә, инде күптән көндәлек сөйләмнән генә түгел, әдәбияттан төшеп калып барган, әмма йөрәккә якын гарәп сүзләрен, әйтемнәрен уңышлы кулланудадыр дип уйлыйм. Гомумән, романны укыганда аның мөселман рухында язылуыннан күңелгә якынлык һәм җан сихәтлеге тоясың.

Журналның "Хунвейбин" басылган саннары кулдан-кулга китте. Халык укый!

**Флүр СОЛТАНОВ.**
**Әлшәй районы,**
**Ким авылы.**
**Башкортстан.**

## УКАЗ БУЛДЫ. АЛДА ЗУР ЭШЛӘР

РФ Президенты Д. Медведев "2013 елда Казан шәһәрендә XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасын үткәрүгә әзерлек турында" Указга кул куйды.

Анда болай диелә:

"2013 елда Казан шәһәрендә XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасын үткәрүгә әзерләнү максатыннан чыгып:

1. Россия Федерациясе Хөкүмәтенә:

а) Россия студентлар спорт берлеге катнашында 2013 елда Казан шәһәрендә XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасына әзерләнү һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты берлеген төзергә;

б) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, шулай ук Россия студентлар спорт берлеге катнашында 2013 елда Казан шәһәрендә XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасына әзерләнү һәм аны үткәрүгә юнәлдерелгән чаралар эшләргә һәм гамәлгә ашырырга;

в) 2013 елда Казан шәһәрендә XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасына әзерләнү һәм аны үткәрү өчен Россия Федерациясе дәүләт милкендәге кирәкле капиталь төзелеш объектлары исемлеген билгеләргә (федераль бюджет ассигнованиеләре хисабына финанслау нигезендә);

г) гаммәви мәгълүмат чараларында 2013 елда Казан шәһәрендә XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасына әзерләнүне, шул исәптән студентлар спортын үстерүнең актуаль проблемаларын яктыртуда ярдәм итәргә.

2. Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнарына 2013 елда Казан шәһәрендә XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасына әзерләнү һәм аны үткәрү чараларында катнашырга тәкъдим итәргә".

## БӨЕК ӘДИПНЕҢ ЮБИЛЕЕ УҢАЕННАН

**Казанда татар әдәбияте классигы, күренекле сәясәтче һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның тууына 130 ел тулуга багышланган чаралар булып узды.**

***

М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасында Гаяз Исхакыйның тууына 130 ел тулуга багышланган тантана булды.

Тамашачыларны Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева сәламләде.

—Татар әдәбияте классигы, гуманист язучы, күренекле сәясәтче һәм җәмәгать эшлеклесе, милли героебыз Гаяз Исхакый татар халкы тормышында зур урын били,—диде ул.—Үзгәртеп кору чорында әдипнең мирасы туган иленә кайта башлаган иде. Бу эшне ахырына җиткерү безнең изге бурычыбыз.

Аннары З. Вәлиева тамашачыларга Президент М. Шәймиевнең котлау хатын укып ирештерде. "...Быел татарның әдәбияты һәм иҗтимагый фикере үсеше өчен күп эшләр эшләгән мәшһүр язучы, драматург, журналист Гаяз Исхакыйның тормышын, иҗатын популярлаштыру җәһәтеннән чаралар оештырылды. Татарстанда һәм чит төбәкләрдә гомер кичерүче татарлар һәм бүтән милләт вәкилләре "Бичара кыз", "Зиндан", "Зөләйха", "Жан Баевич", "Олуг Мөхәммәд" һ. б. әсәрләр иҗат иткән авторны зур хөрмәт белән искә ала. Башкалабыз Казанда һәм республикабызның бүтән шәһәрләрендә Гаяз Исхакый исемен йөрткән урамнар бар. Туган авылы Яуширмәдә тарихи-мемориаль һәм этнографик комплекс эшләп килә. Шуңа өстәп, Гаяз Исхакый исемендәге еллык әдәби премия гамәлгә куелды. Быелдан башлап ул Мәдәният министрлыгы белән Язучылар берлегенең уртак премиясенә әйләнде. Гаяз Исхакыйның тормышы һәм иҗаты күп монографияләрдә, тематик җыентыкларда, диссертация һәм мәкаләләрдә яктыртылды. Озак вакыт узуга һәм ара ераклыгына карамастан, Гаяз Исхакый туган ягына якташларының күңелендә мәңгегә калыр өчен әйләнеп кайтты. Гаяз Исхакый—татар халкының горурлыгы. Ул—милли үзаныбызны үстергән шәхес",—дигән сүзләр бар Президент котлавында.

З. Вәлиева шулай ук Гаяз Исхакый премиясенең быелгы лауреатларын игълан итте һәм аларга дипломнар тапшырды.

Кичәдә тамашачыларны Татарстан Язучылар берлеге рәисе И. Ибраһимов та сәламләде.

—Гаяз Исхакый иҗатка, Тукаебыз кебек үк, иртә килә һәм үзен талантлы язучы, үз кыйбласын тапкан көрәшче итеп таныта,—диде ул.—24 яшендә, ягъни 1902 елда ул бөтен татар җәмәгатьчелегендә шартлау булып кабул ителгән "Ике йөз

елдан соң инкыйраз" әсәрен яза. Әдип инкыйразның сәбәпләрен чит-ятлардан эзләми. Иң әүвәл әхлак бетә, аннан дин бетә, аннан халык үзе бетәчәк... Әдип халыкны кисәтә, инкыйразны булдырмас өчен көрәшергә өнди.

Истанбулда Гаяз Исхакый фонды рәисе Түләй ханым Дуләм Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Миңнуллинга Гаяз Исхакыйга кагылышлы һәм әлегә кадәр Истанбулда сакланган кайбер документларны тапшырды.

Кичәдә Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле, М. Таминдарова җитәкчелегендәге Татарстан дәүләт камера хоры, А. Фәйзрахманов җитәкчелегендәге Татар дәүләт фольклор ансамбле, Ә. Җаббарова җитәкчелегендәге "Хыял" камера хоры, шагыйрьләр Р. Вәлиев, Р. Миңнуллин, Р. Зәйдулла, Ф. Тарханова, Л. Шәех, Л. Гыйбадулина, Р. Сәлахов, җырчылар В. Ганиева, И. Вәлиев, Р. Асаев, актерлар Р. Таҗетдин, И. Габдрахман, Ә. Хисмәт чыгыш ясады. Кичәдә танылган актер Р. Төхфәтуллин төшергән "Зөләйха" фильмыннан кадрлар, Г. Камал исемендәге театрда куелган шул исемдәге спектакльдән күренеш, С. Өметбаев исемендәге Минзәлә Татар дәүләт драма театры коллективы куйган "Сөннәтче бабай" спектакленнән күренеш күрсәтелде.

Кичәне Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Л. Шакирҗан һәм Татарстанның атказанган артисты Ф. Җиһанша алып барды.

***

ТР Мәдәният министрлыгының конференц-залында "Гаяз Исхакый иҗаты: хәзерге караш" дигән темага халыкара фәнни-гамәли конференция дә мәшһүр язучының олуг юбилее уңаеннан үткәрелде. Мәдәният Министрлыгы, Фәннәр академиясе, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Язучылар берлеге бергәләп уздырган бу чарада Төркия, Башкортстан, Чуашстан, Казакъстан, Удмуртия, Татарстан галимнәре, язучылар, җәмәгать эшлеклеләре катнашты. Гыйльми җыенда "Гаяз Исхакый һәм татар әдәбияте", "Гаяз Исхакый һәм татар теле, мәгарифе, тарихы" дигән темаларга 60тан артык чыгыш һәм доклад тыңланды.

Конференцияне Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Миңнуллин ачып җибәрде һәм алып барды. Ул Гаяз Исхакыйны "татар халкының зирәк идеологы һәм сәяси әйдәп баручысы" дип атады һәм бу феноменаль шәхеснең милләтебезнең якты киләчәге, азатлыгы, мәгърифәтле, динле, иманлы булуы өчен бөтен гомерен багышлавын әйтте.

ТР Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева үзенең тәбрикләү чыгышында иң әүвәл Г. Исхакыйга багышланган конференциянең ТР Хөкүмәтенең элекке бинасында—мөһим карарлар кабул ителгән йортта үткәрелүен искәртте, моны яна мөмкинлекләр тудырылуның үзенчәлекле күрсәткече, дип атады. З. Вәлиева, шулай ук, сәяси инанулары һәм әсәрләре өчен эзәрлекләнгән бу шәхес турында яшь буынга белгертеп калдырырга тиешлегебезне әйтте. Бу унайдан галимә Лена Гайнанованың, Гаяз Исхакыйга багышланган конкурс үткәреп, укучыларны, балаларны, яшьләрне һәм өлкәннәрне әдипнең тормышы һәм иҗаты белән кызыксындыру буенча зур эш башкаруы да искә алынды. "Бәйгедә төрле яшьтәге кешеләр, төрле һөнәр ияләре катнашты, ә сораулар шундый итеп куелган иде, ана җавап бирер өчен әсәрләрне укырга кирәк булды",—диде З. Вәлиева. Ул шулай ук көндәлек матбугатта басылган материалларда әйтелгән фикерләрнең тормышка ашарга тиешлеген дә искәртте. Әдипнең чит илләрдә дә басылган әсәрләрен кертеп, 40 томлыгын чыгару, Казанда Г. Исхакыйның музеен булдыру турындагы тәкъдимнәр—шундыйлардан.

ТР Фәннәр академиясе президенты киңәшчесе, академик Миркасыйм Госманов: "Гаяз Исхакыйның иҗаты, тормыш юлы шактый өйрәнелде. Әмма без аны кеше буларак әлегә аз беләбез",—диде. ТР Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов Гаяз Исхакыйның гомерен көрәштә үткәрүе, аның шул юлны аңлы рәвештә сайлавы хакында сөйләде. Шулай ук, башка ораторлар да әдәбиятның киләчәктәге үсеш тенденцияләре хакында кирәкле һәм җитди фикерләр әйттеләр.

***

Татарстан китап нәшриятында татар әдәбияты классигы Гаяз Исхакый әсәрләренең 7 нче томы дөнья күрде. Хәзерге вакытта Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре тагын 8 томны басмага әзерли. Бу хактагы карарны ТР Министрлар Кабинеты Гаяз Исхакыйның тууына 130 ел тулу уңаеннан кабул итте.

Күптән түгел редакция коллегиясенең татар әдәбияты классигының алда торган юбилеена багышланган утырышы булды. Анда сүз томлыкларны текстология ягыннан әзерләүгә кагылышлы катлаулы мәсьәләләр хакында барды. Аларның кайберләренең структурасына төзәтмәләр кертелде. Утырышта катнашучылар шулай ук 2010 елга Гаяз Исхакый әсәрләренең тулы җыелмасы укучы кулына ирешер дигән ышаныч белдерде.

***

Татарстанда 2008 елдан башлап классик язучы, җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакый исемендәге премия белән язучылар гына түгел, әдипнең иҗади мирасын таныту

көч куйган галимнәр һәм җәмәгать эшлеклеләре дә бүләкләнә башлады. Әлеге премия Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлеге белән берлектә гамәлгә куела. 2008 ел өчен Г. Исхакый исемендәге премиягә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры директоры Шамил Закиров, язучы иҗатын өйрәнүче галимә Лена Гайнанова һәм вафатыннан соң шагыйрь Харрас Әюпов лаек булды.

Премияләрне 11 декабрьдә М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында тантаналы кичәдә Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева тапшырды. Күптән түгел арабыздан киткән Харрас Әюповка тиешле бүләге аның хатыны Люзия ханымга бирелде. «Гаяз Исхакый мирасын мәңгеләштерү эшен кайнар йөрәкле милләтпәрвәрләребез дәвам итсеннәр иде. Бүген аның иҗатын өйрәнү, аны таныту—безнең барыбыз алдында да торган бурыч»,—диде Зилә Вәлиева.

### МИЛЛӘТНЕ БЕРЛӘШТЕРҮ ЮЛЫНДА

11-13 декабрь көннәрендә Казанда Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының 2008 елгы эш нәтиҗәләре буенча киңәйтелгән утырышы булды. Беренче көнне төрле төбәкләрдән килгән Конгресс вәкилләре комиссияләргә бүленеп эшләде. Икенче көнне утырышның эше "Казан" милли мәдәният үзәгендә дәвам итте. Башта Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закировның хисап нотыгы тыңланды. Аннары татар иҗтимагый оешмаларының 2008 елдагы эш нәтиҗәләре һәм 2009 елга яңа эш планы тикшерелде. Милләттәшләребез өчен түгәрәк өстәлләр дә үткәрелде. 13 декабрь көнне исә "Казан" милли мәдәният үзәгендә Конгресс тарафыннан оештырылган "Татарстанның эшлекле партнерлары" форумы узды. (Әлеге утырыш турында тулырак язманы журналыбызның киләсе санында тәкъдим итәрбез.)

### УНИКАЛЬ ТОМЛЫКЛАРНЫҢ БЕРСЕ

Татарстан Фәннәр академиясендә "Татарика" атласлары сериясеннән "Этнография" томын тәкъдим итү тантанасы булды. Җиде томлык татар тарихы кебек киң колачлы саллы хезмәтләр Рафаил Хәкимов җитәкчелегендәге Тарих институтының чираттагы зур уңышы.

Әүвәл чыккан икесе татар халкы тарихын Евразия халыклары белән бәйләнешләрдә чагылдыра, Евразиянең борынгы карталарында күз алдында китереп бастыра. Өченче том милләтебезнең мәдәни, рухи һәм көндәлек-көнкүреш тормышын, табигый мохитен, төпләнеп яшәү төбәкләрен сурәтли. Бу хезмәт бизәлеше, бик бай мәгълүмат туплануы белән милләтебезне дөнья халыклары тарихында тагын да киң кырлырак, тәфсилләбрәк шәрехләргә мөмкинлек биргән. Китап сувенир-бүләк итеп эшләнгән. Ана Казан ханлыгы чорындагы татарлар тормышы турында диск та кушылган. Китапның 6 килограмм авырлыкта булуы үзе генә дә анда никадәр зур материал туплануы турында сөйли. Хезмәтнең бәясе—6 мең сум. Шуңа карамастан, тиражы аз булу сәбәпле ул ирекле сатуга чыкмаячак.

### ЯШЬЛӘР ФОРУМЫ

Казан Ратуша бинасында «Мәдәниятара диалог һәм аның диннәрара диалогта чагылышы» дигән Халыкара яшьләр форумы ачылды. Анда 30 яшькә кадәрге мөселман, христиан һәм яһүд диннәрен тотучы 100дән артык вәкил җыелды.

Форумда дини билгеләр буенча дискриминация белән бәйле проблемалар каралды. Алар хакында җентекләп фикер алышу «Мәдәниятара диалог һәм мәгариф», «Сүз иреге һәм дини этика», «Мәдәниятләр һәм цивилизацияләр бәйләнешендә яшьләрнең роле», «Яшьләр һәм миграция» кебек тематик төркемнәрдә узды.

Әлеге халыкара форум «Барыбыз да төрле—һәммәбез дә тигез» Европа кампаниясенең дәвамы рәвешендә үткәрелде. Мәгълүм булганча, аның кысаларында узган елның сентябрендә Казанда җәмгыять үсеше файдасына күптөрле дини, этник, социаль һәм мәдәни берләшмәләрнең потенциалын куллану мөмкинлекләре турында фикер алышынган иде. Форумның төп максаты—төрле дин вәкилләренең дустанә мөнәсәбәтен, дәүләт структуралары һәм дини оешмалар арасындагы диалогны һәм дини берләшмәләрнең үзара элемтәләрен күрсәтү.

### ТАТАР ШАГЫЙРЕНӘ ШӘРӘФЛЕ БҮЛӘК

2008 ел ЮНЕСКО тарафыннан Мәхмүд Кашгарый елы дип игълан ителгән иде. Шушы көннәрдә Истанбул каласында шул уңайдан йомгаклау кичәсе уздырылды.

Төрек мәдәниятенә хезмәт итү фондының тырышлыгы нәтиҗәсендә төрки халыкларның телләрен, әдәбиятләрен, мәдәниятләрен саклау һәм үстерү, тарихларын өйрәнү һәм башка милләтләргә дә таныту буенча хезмәт куючыларга 1999 елдан бирле Төрек теле шәрәфле премиясе бирелеп килә. Быел әлеге мәртәбәле бүләккә дөньяның төрле илләреннән биш кеше—Токио университеты галиме Тадаши Сузуки, Бухарест университеты тюркологы, профессор Аги-амин Баубек, Төркмәнстанның танылган язучысы һәм шагыйре Ораз Ягмур, Үзбәкстан журналисты, язучы һәм шагыйрь Әшкабил Шүкүр һәм Татарстан Язучылар берлеге рәисе, шагыйрь Илфак Ибраһимов лаек булды.

Бүләк ияләрен олылау кичәсен Төрек мәдәниятенә хезмәт итү фонды рәисе Метин Әриш ачып җибәрде. Ул 2008 елның ЮНЕСКО тарафыннан Мәхмүд Кашгарый

елы дип игълан ителүнең тарихи әһәмиятенә тукталып, аның "Диване лөгатет төрек" әсәренең эчтәлеге турында фикерләрен бәян итте. Сүзен татар шагыйре Габдулла Тукайның төрекчәгә тәрҗемә ителгән "Туган тел" шигыре белән тәгәлләде.

Тантанада Төркия Президенты аппараты генераль сәркәтибе, профессор Мостафа Әсән, Истанбул губернаторы урынбасары Фәйзуллаһ Өзҗан, Төрек теле институты житәкчесе, Шүкрү Һалюк Акалын һәм башка галимнәр чыгыш ясады.

Төрек теле шәрәфле премияләрен иялөренә Төркия мәдәният һәм туристлык министры Эртугрул Гюнай тапшырды.

## ШИГЪРИ САБАН ТУЕ

Казанның УНИКС концерт залында чираттагы шигъри Сабан туе үткәрелде. Казан дәүләт университеты, КДУның татар филологиясе һәм тарихы, журналистика һәм социология факультетлары, "Әллүки" әдәби-ижат берләшмәсе тарафыннан оештырылган әлеге конкурста Казан, Чаллы, Алабуга, Минзәлә шәһәрләрендәге, шулай ук Башкортстанның Стәрлетамак каласындагы югары уку йортларында белем алучы, ижат белән шөгыльләнүче студентлар катнашты.

Бәйгедә каләм тибрәтүче 25 кыз һәм егет әдәбият сөючеләр һәм дәрәжәле жюри хозурында үзләренең иң яхшы дип саналган бер шигырен укып күрсәтте. Аннары Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис житәкчелегендәге жюри әгъзалары—галим һәм язучы Тәлгат Галиуллин, шагыйрьләр Зиннур Мансуров, Госман Садә, Жәүдәт Сөләйман, Фәйрүзә Мөслимова, Ленар Шәех сәхнәдән яңгыраган һәр әсәргә этрафлы рәвештә бәя бирде. "Шигъри Сабан туе-2008" конкурсы йомгаклары буенча КДУның юридик факультеты студенты Рифат Сәлах беренче урынга лаек булды. Ә Булат Ибраһимов (КДУ)—икенче, Резеда Гобәева (КДУ) өченче урынны алды. Кызыксындыру бүләкләре яшь каләм ияләре Рүзәл Мөхәмматшинга (ТДГПУ), Ләйсән Фәтхетдиновага (КДУ) һәм Стәрлетамак дәүләт педагогика академиясеннән Алинә Хөсәеновага тапшырылды. Ә "Тамашачы мәхәббәте"н Гөлфия Гарипова казанды.

## ТАРИХКА КАРАП, КИЛӘЧӘКНЕ УЙЛАП

Моннан 103 ел элек, 1906 елның 22 декабрендә Казанда беренче тапкыр татарча спектакль уйнала. Ул көн татар театрының туган көне булып исәпләнә. Ел ахырында Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында бу җәһәттән тантаналы кичә оештырылды. Аның беренче булегендә татар театрының нигез ташларын салган актер, режиссерларны—120 еллыгы уңаеннан Нәгыймә Таҗдарованы, тууларына 110 ел тулу уңае белән Илдар Мәҗитов, Сәет Булатов, Сөләйман Вәлиев-Сульва, Каюм Бариевны, 100 еллыгын билгеләп үтү җәһәтеннән Асия Масаутованы, 90 еллыгы уңаеннан Шакирҗан Харисов, Барый Әшрәпов һәм башкаларны искә алдылар һәм шушы көннәрдә гомер бәйрәмен билгеләп үтүче актриса Асия Харисованы тәбрикләделәр.

Аннан соң бертөркем сәнгатькярләргә Д. Сиражиев исемендәге премияләр тапшырылды. Мәгълүм булганча, әлеге премия 1999 елда Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм әдәбият, сәнгатькә ярдәм итүче "Жыен" фонды тарафыннан гамәлгә куелган иде. Ул театр үсешенә өлеш керткән ижатчыларга тәгаенләнгән. Быелгы лауреатларны да кертеп исәпләгәндә, Д. Сиражиев исемендәге бүләккә 51 театр әһеле лаек булды. Ә быел ул театрда купьеллык нәтиҗәле эшчәнлеге өчен Түбән Кама Татар дәүләт драма театры директоры Фәнис Чабатовка, Г. Камал исемендәге театрда "Кара чикмән", "Эзләдем, бәгърем, сине", "Казан сөлгесе", "Бәби" спектакльләрендә биюләрне куйган өчен Украинаның атказанган сәнгать эшлеклесе Олег Николаевка, Г. Камал исемендәге театрның кече залында Т. Миңнуллинның "Дуслар жыелган жирдә" әсәрен сәхнәләштергәне өчен яшь режиссер, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетының чыгарылыш курс студенты Лилия Әхмәтова-Шәйдуллинага, театрдагы купьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Әлмәт Татар дәүләт драма театры актеры Рамил Минхановка, татар театры сценографиясен өйрәнүдәге зур хезмәте өчен Рауза Солтановага, Г. Камал исемендәге театрның музыка бүлеге мөдире Фоат Әбүбәкеровка, П. Кальдеронның "Жизнь есть сон" әсәрен тәрҗемә иткән өчен шагыйрь Ркаил Зәйдуллага бирелде.

## "ТАТНЕФТЬ"НЕҢ ИГЕЛЕКЛЕ ГАМӘЛЛӘРЕ

Әлмәт каласында "Татнефть" ачык акционерлар җәмгыяте оештырып җибәргән "Рухият" рухи яңарыш фонды тарафыннан нәшер ителгән китапларны җәмәгатькә тәкъдим итү кичәсе булды. Бу юлы 9 китап тәкъдим ителде. Алар арасында татар укучысына аз билгеле булган, Әлмәт районының Габдрахман авылында туып үскән, ләкин хезмәт юлы Башкортстанда, республиканың житәкчесе постында үткән Афзал Таһиров, язучы Жәмит Рәхимов томлыклары, "Шәхесләребез" сериясеннән "Бертуган Туйкиннар" дигән һ. б. китаплар бар иде.

"Татнефть" бик җаваплы төстә социаль сәясәт алып бара. Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның бай милли гореф-гадәтләрен саклауга һәм тормыштагы урыннарын ныгытуга, мәдәниятне һәм сәнгатьне үстерүгә һәм куәтләүгә зур игътибар бирә. 1997 елда оештырылган "Рухият" фонды нәкъ шул максатларга хезмәт итә дә инде. Шул вакыттан бирле фонд тарафыннан 130 исемдә китап дөнья күрде. Аларның гомуми тиражы

250 меннән артып китә. Басылып чыккан китапларның шактый өлеше район һәм шәһәр китапханәләренә, Бөтендөнья татар конгрессына, Казан дәүләт университетына һәм башка югары уку йортларына, шулай ук театрларга, бүтән мәдәният учакларына, Россия төбәкләрендә яшәүче татарларга бүләк ителә.

### "НАРСПИ"ГА 100 ЕЛ

Чуаш әдәбияте классигы Константин Ивановның атаклы "Нарспи" поэмасы язылуга 100 ел тулды. Шушы унайдан Татарстан Халыклар дуслыгы йортында махсус конференция үткәрелде.

Юбилей конференциясен Татарстан Фәннәр академиясенең баш гыйльми сәркатибе Дания Заһидуллина алып барды. Ике халыкның әдәби казанышлары һәм мәдәни бағланышлар турында ихлас сөйләшүдә күренекле галимнәр Фоат Галимуллин, Тәлгат Галиуллин, Җәүдәт Сөләйманов, Чуашстанның халык шагыйрьләре Порфирий Афанасьев, Валерий Тургай, Татарстанның халык шагыйрьләре Ренат Харис, Роберт Миннуллин, Чуашстан мәдәният министры урынбасары Михаил Краснов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев, Чуашстан радиосының баш мөхәррире Ольга Тургай һ. б.лар катнашты.

Шунысы да игътибарга лаек: шагыйрь Ренат Харис К. Ивановның "Нарспи"е тәэсирендә "Нарспи эзе" дигән яңа поэма иҗат иткән. Җыенда ул поэмадан да өзекләр яңгырады.

Конференция үткәрелгән залда Константин Иванов китапларыннан күргәзмә дә оештырылган иде.

### ДРАМАТУРГ ИСЕМЕНДӘГЕ

Узган ел ахырында Арча районы Сикертән авылы мәктәбенә классик драматург, татар театрына нигез салучыларның берсе Галиәсгар Камал исеме бирелү уңаеннан зур тантана булып узды.

Тантанада Галиәсгар Камалның Диләрә Даутова һәм Фидакарь Камалетдинов, Габдрахман Камал (Галиәсгар Камалның бертуганы) улы Искәндәр Камаловның катнашып, чыгыш ясавы, истәлекләр белән уртаклашуы үткән тарихны якынайтып, җанландырып җибәрде.

Тантананың әдәби-музыкаль өлешендә Г. Камал театры артистлары Равил Шәрәфи, Зөлфирә Зарипова, Фирая Әкбәрова, Луара Шакирҗанова, Илдус Габдрахманов, музыкант Фоат Әбүбәкеров, театр директоры Шамил Закиров катнашты. Артистлар Г. Камал пьесасы буенча куелган "Бүләк өчен" спектаклен тәкъдим иттеләр. Мәктәп коллективы исә "Беренче театр" спектаклен сәхнәләштергән иде.

Әлеге чарада Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев, шагыйрьләр Хәнәфи Бәдигый, Илсөяр Иксанова, "Ватаным Татарстан" гәзитенең баш мөхәррир урынбасары Фәния Әхмәтҗанова, КДУ доценты Илһам Фәттахов, Арча Педколлиятенең элеккеге директоры Илдус Сәгъдиев һ. б. катнашты, чыгыш ясады.

Анда муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Надия Мифтахетдинова, укучылар, укытучылар, ата-аналар, җирле үзидарә җитәкчеләре, матбугат, телевидение вәкилләре, язучылар, галимнәр, артистлар катнашты.

### ОНЫТЫЛМАС ШАГЫЙРЬ

Узган ел вафат булган күренекле шагыйрь, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Роберт Әхмәтҗановның исемен мәңгеләштерү юнәлешендә якташлары инде кайбер чаралар күрә дә башлады. Шагыйрьнең туган авылы Иске Арышта (Балык Бистәсе районы) янартылган мәдәният йортына аның исеме бирелде. Йортның бер бүлмәсе музей итеп оештырылган; анда шагыйрьнең шәхси әйберләре, китаплары, кульязмалары, хөкүмәт бүләкләре экспонат итеп урнаштырылган.

Бәйрәм тантанасы югары дәрәҗәдә зур оешканлык белән үтте. Казаннан һәм күрше-тирә авыллардан күп халык җыелган иде. Тантанада катнашкан якташлар һәм кунаклар—Татарстан Дәүләт Советы депутаты, шушы авылда туган Илсур Сафиуллин, Татарстанның халык шагыйре Роберт Миннуллин, Балык Бистәсе районыннан чыккан шагыйрьләр Равил Фәйзуллин, Мансур Шиһапов, Мидхәт Миншин, язучылар Вакыйф Нуруллин, Әхәт Гаффар, Госман Гомәр, Әхәт Сафиуллин, Хәлим Җәләл һ. б. Роберт Әхмәтҗанов турындагы истәлекләре белән уртаклашты, шагыйрьнең исемен мәңгеләштерү буенча башкарган эше өчен Балык Бистәсе муниципаль районы башлыгы Илһам Госман улына, Татарстан Мәдәният министрлыгына рәхмәтләрен җиткерде.

Кунаклар Иске Арыш мәктәбе белән дә танышты, аннары Балыклы Чүкәй авылы урта мәктәбендә булды.

Язучылар мәдәният йортына һәм мәктәпкә үз китапларын бүләк иттеләр.

### ФӘНИС ЯРУЛЛИН МУЗЕЕ

Яңа Савин районының 103 нче мәктәбендә шагыйрь, прозаик, драматург, Муса Җәлил һәм Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Фәнис Яруллинның музее ачылды. Биредә әдипнең шәхси әйберләре, китаплар, грамоталар, фотосурәтләр, язу машинкасы һ. б. предметлар тупланган.

Музейны ачу тантанасында әдип үзе, хатыны, дуслары, туганнары катнашты. Мәртәбәле кунаклардан ТР мәдәният министрының беренче урынбасары Айдар Гайнетдинов, Мәгариф һәм фән министры урынбасары Данил Мостафин, Казан

шәһәре башкарма комитетының мәгариф идарәсе башлыгы Илсур Һадиуллин, җырчы Гөлнара Тимерҗанова бар иде.

Музейны ачучылар шагыйрьгә багышланган "Фәнис Яруллин очышлары" дигән документаль фильмның (авторы—Әнвәр Габдрахманов) премьерасын да карадылар.

### ТАТАРЛАРНЫҢ ГАМӘЛИ СӘНГАТЕ

ТР Милли музеенда «Казан татарларының гамәли сәнгате: тарих һәм бүгенге көн» күргәзмәсе ачылды. Биредә XIX гасыр үрнәкләре белән берләттән бүгенге көн осталары эшләнмәләрен дә күрергә мөмкин. Экспонатлар арасында милли киемнәр, зәркән һәм керамика әйберләре бар. Оештыручылар нияте буенча, экспозиция Казан татарлары һөнәрчеләре һәм осталары тормышын һәм эшчәнлеген чагылдырырга тиеш.

### АЛСУНЫҢ ЯҢА АЛЬБОМЫ

10 декабрьдә "Пирамида" мәдәни-күңел ачу комплексында җырчы Алсуның "Туган тел" дип исемләнгән яңа альбомын тәкъдир итү кичәсе булды.

Алсу, күпләргә мәгълүм булганча, моннан берничә ел элек "Евровидение" конкурсында җиңү яулаган татар кызы. Монарчы аның үз телебездә башкарган җырлары юк дәрәҗәсендә иде. Бу юлы ул милләттәшләребезне куандырды дип әйтеп була.

Әлеге музыкаль җыентыкта татар халык җырлары, шулай ук бүгенге көн авторлары тарафыннан Алсу өчен махсус язылган әсәрләр урын алган. «Туган тел» җырын исә Алсу җырчы Ренат Ибраһимов белән берлектә яздырган.

### ХАЛЫКЧАН ОРКЕСТР КОРЕЯДА

Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Анатолий Шутиков җитәкчелегендәге халык уен кораллары дәүләт оркестры Көньяк Кореядә гастрольләрдә булып кайтты. Оркестрның 15 еллыгы уңаеннан оештырылган бу иҗади хисап уңышлы үткән. Сеул шәһәрендә булып узган Россия сәнгате фестивалендә оркестр Гран-при белән бүләкләнгән. Кореягә оркестр белән Г. Тукай исемендәге филармониянең җырчылары Георгий Ибушев, Рөстәм Маликов, Резидә Галимова да барган. Алар башкаруында татар халык җырлары, композиторларыбыз әсәрләре яңгыраган.

### МИНЕ ЙОЛДЫЗЛАРДАН ЭЗЛӘГЕЗ

Татарстанның халык артисты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Дамирә Кузаеваның тууына 60 ел тулды Ул тумышы белән татар әдәбиятенә һәм сәнгатенә талантлы ул-кызлар биргән Пермь краеның Барда районыннан. Декабрь аенда туган авылы Төнгүктә актрисаның юбилеена багышланган чаралар булып узды. Шуларның берсендә—"Мине йолдызлардан эзләгез" дигән гаилә театрлары фестиваленең йомгаклау кичәсендә Әлмәт Татар дәүләт драма театры артистлары да катнашты. Алар спектакльдән өзек башкарды, актриса хакындагы истәлекләре белән уртаклашты. Шулай ук Дамирә Кузаеваның каберенә таш та куелды. Татар театры сәнгатендә якты эз калдырган мәшһүр актрисаның истәлеген якташлары кадерләп саклый.

### ЮБИЛЕЙ КИЧӘЛӘРЕ

***

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Алиш исемендәге премия лауреаты Вакыйф Нуриевка 50 яшь тулды. Шул уңай белән Актерлар йортында язучыга багышланган әдәби-музыкаль кичә узды. Юбилярны мәдәният министры урынбасары Г. Нигъмәтуллина, Язучылар берлеге рәисе И. Ибраһимов, каләмдәшләре З. Хөснияр, Г. Морат, Л. Лерон, Г. Садә, Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Н. Мифтахетдинова, галим Ә. Хуҗиәхмәтов, якташлары Галиевләр гаиләсе тәбрикләде. Театр училищесы укучылары бәйрәмдарның хикәяләрен укыды.

Кичәне язучы Камил Кәримов алып барды.

***

Актерлар йортында драматург һәм шагыйрь Хәбир Ибраһимның 50 яшьлек юбилее үтте. Мәдәният министры урынбасары Гөлшат Нигъмәтуллина аңа «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медален тапшырды. Юбилярны Апастан килгән якташлары, Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, республика театрлары җитәкчеләре һәм артистлар тәбрикләде. Танылган җырчылар Асаф Вәлиев, Рафаэль Сәхабиев, Илсур Сафин, Нурзадә үзләренең котлауларын җыр аша җиткерделәр. Кичәдә шулай ук юбиляр әсәрләре буенча куелган спектакльләрдән өзекләр дә күрсәтелде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә:* *«Төлке»*—Б. Гыйльванов эше.

*Дүртенче биттә:* шагыйрь һәм рәссам **Хәмит Латыйпов**.

# Яңа китаплар




**Абзалова-Сәлманова Роза.** Иманлы төбәк жәүһәрләре. —Казан: "Сүз" нәшр., 2008. —272 бит. Тиражы—2500 данә.

Соңгы елларда төбәк, шәһәр, район, аерым авыллар тарихына багышланган хезмәтләр шактый еш дөнья күрә. Аларның, табигый, һәрберсе үзгә: эчтәлек-колачы ягыннан да, фәнни-тарихи тирәнлеге белән дә. Автор үзенең бу документаль китабында Түбән Чыршылы (борынгы исеме—Чәшеле) авылы тарихы аша Әлмәт-Шөгер якларында туып-үскән күренекле шәхесләрнең катлаулы тормыш юллары турында бәян итә, атаклы мәчет-мәдрәсәләрнең эшчәнлеген яктырта, Бикчура хан, Ризаэддин Фәхреддин һәм башка мәшһүр затларның нәсел шәҗәрәләре, кылган гамәлләре турында тәфсилләп сөйли. Китап бай иллюстратив материалларга, уникаль документларга, ышанычлы истәлекләргә таянып язылган.




**Ленар Шәех.** Дүртенче кат... Бишенче кат...: Шигырьләр, поэма. —Казан: Татар. Кит. Нәшр., 2008.—176 б. Тиражы—2000 данә.

Бу җыентык—Ленар Шәехнең чираттагы китабы. Ул моңа кадәр дә олылар һәм балалар өчен берничә китап чыгарган иде инде. Аның бу җыентыгы алар арасында иң күләмлесе. Китап аннотациясендә мондый сүзләр бар: "Яшь шагыйрьнең лирикасы кайчак сагышлы, гамьле, берара шаян, якты. Ә юморы, сатирасы үткен, төрттерүле... Шагыйрь укучыларны үз дөньясына чакыра". Китапка кереш сүзне Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин язган.



Хәмит Латыйпов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)